ӘМИР ФАТЫЙХОВ

# ТАЙНА ИЛЕ

**Әмир Фатыйхов**

# ГӘЙНӘ ИЛЕ

**(Гәйнә олысы, Барда районы тарихы)**

**Беренче китап**

Рецензентлары: Татарстан фәннәр Академиясе академигы И.Р.Таһиров; ТФАның Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре Д.М.Исхаков.

Редакторы: филология фәннәре кандидаты Р.Ф.Ягъфәров.

Тышлыкның художнигы: рәссам Э.Я.Зарипов.

Барда, 1995 ел.



# Фидакарь зат

Дөньяда үз мәнфәгатьләрен дә онытып, гомерләрен изге эшкә - үзеннән элек яшәгәннәрнең тормышларын өйрәнүгә багышлаган кешеләрне, олы галимнәрне күп беләм, күп аралашырга туры килә. Әмма алар арасында фәнни дәрәҗәләр артыннан йөрүне кирәк тапмаган күркәм бер тарихчы кешегә олы ихтирам хисләре саклап йөрим. Ул - Әмир ага Фатыйхов.

Шушы тыйнак һәм фидакарь зат менә утыз елдан артык инде Тол буенда яшәүче татарларның тарихын язу белән мәшгуль. Аның өчен материал җыю максатларыннан кайда гына булмады ул: Мәскәүнең үзәк,Урал өлкәләренең, Башкортстан, Татарстан, Удмуртия архивларында эшләде, тарихчы- галимнәр белән аралашты. Истәлекләр язып алу өчен Барда һәм башка төбәкләрне йөреп чыкты. Нәтиҗәдә Гәйнә олысы, Барда районы тарихы буенча олы тарихи мирас туплады.

Әмир ага тумышы белән Пермь өлкәсенең хәзерге Орда районы Кече Башап авылыннан. Ул үзенең хезмәт юлын туган авылында электромонтер булудан башлаган. Техникум, Югары партия мәктәбен бетереп, культура-агарту эшләрендә эшләгән. Мин белгәндә инде ул Барда район гәзите «Таң»ны җитәкли - аның редакторы иде. Читтән торып Казан университетының журналистика факультетын тәмамлады. Мин дә, 1960 елларда каләм тибрәтә башлаган яшь кеше, аның мәрхәмәтле кулы астында хезмәт юлымны башлап җибәрдем һәм аны остазым саныйм.

Әмир ага Барда район гәзите редакциясендә һәм 1970 еллардан башлап Башкортстанның Яңавыл гәзитендә эшләгән чорларда бик күп туган як тарихына багышланган мәкаләләр, очерклар язды. Аның байтак кына әдәби әсәрләре дә бар.

Әмир аганың «Гәйнә иле» дип исемләнгән хезмәте күпьеллык эзләнүләре, тынгысыз иҗат җимеше. «Гәйнә иле»н укучылар бу фидакарь кешегә бик рәхмәтле булырлар. Әлеге хезмәт өлкәнең тарих укытучылары өчен бигрәк тә көтеп алган кыйммәтле бүләк.

Бу китапта Гәйнә иле тарихы 1941-1945 еллардагы сугышка кадәрге чорны үз эченә ала. Хәзер ул аннан соңгы чор тарихын язу белән мәшгуль. Иҗат уңышлары телик бу изге җанлы кешегә. Алдагы көндә аның Барда төбәге турындагы тулы тарихын кулыбызга алырга насыйп булсын.

**Рәшит ЯГЪФӘРОВ.**

# I. Гәйнә иле борынгы чорда

Урта Уралда үзенчәлекле этник утрауны хәтерләткән безнең Гәйнә иле күпләрне кызыксындырган. Төбәктә урнашып калган исем - атамалар, топ халкының тел үзенчәлекләре кемне кайларга гына алып китми дә, кай яклардан телче-галимнәрне үзенә җәлеп итми.

Моның сәбәпләрен аңлау өчен безгә кешелек дөньясы үткән миллион еллар төпкеленә, «тарих аталары» Геродот, Страбоннар кеше яшәмәслек кыргый төбәк дип санаган бу җирләргә беренче кешеләр аяк эзе калдырган чорларга ук төшеп әйләнергә кирәктер.

Җир шарында кешеләр барлыкка килгәннән соң өч-өч ярым миллион еллар үткән. Моннан 800 мең еллар элек Боек бозлык чоры башланган, аның көньяк чите Саратов, Днепрның түбәнге агымына кадәр җиткән, тик калку Уралда ул бүгенге Пермь шәһәре урнашкан җирләрдән көньяккарак үтә алмаган.

Бозлавык чорына кадәр безнең якларда климат бик йомшак булган. Кама буйларында филләр, мөгезборыннар яшәгән. Калынлыгы икешәр чакрымга җитешле бозлар төньяктан көньякка таба хәрәкәт итеп, үзләре белән кырыс климат алып килгән, элекке җылы яратучы хайваннар үлеп беткән. Алар урынына салкынга чыдам мамонтлар, йонлы мөгезборыннар, боланнар барлыкка килгән. Йөз меңнәрчә елларга сузылган бу чорда бозлык берничә тапкыр чигенеп, берничә тапкыр янә көньякка шуышкан. Әнә шушы бозлык чорында, моннан йөз мең чамасы еллар элек безнең якларга беренче кешеләр килеп чыкканнар. Неандерталец дип аталган бу беренчеләр, тупас таш кораллар белән коралланып (шуның өчен бу чорны борынгы таш - грекча палайес литос - гасыр дип атыйлар), су буйларында яшәренеп, су эчәргә төшкән хайваннарга сунарчылык иткәннәр. Әлеге шул таш кораллары белән бәреп үтереп, шул ук таштан эшләнгән пычаклары белән тиресен тунап, итен ашамлык итеп кулланганнар, ә тиресен шунда ук эшкәртеп, кием-салым, торак-урын ясау өчен үзләре белән алып китә торган булганнар.

Археологлар бу сунарчы неандерталецларның эзләрен (вакытлы тукталу урыннарын, эш коралларын, сөякләрен) Чусовой елгасының иң түбәнге агымнарында, Вычегда, Печора буйларында табалар. Алар бирегә Себер ягыннан да, Идел буйлап Кавказ, Урта Азиядән дә килгәннәр.

Бозлык чорының ахырында бозлар эреп, эре- эре елгалар хасыйл булган. Арал һәм Каспи диңгезләре тоташ зур диңгез булып җәйрәп яткан. Моңарчы Каманың кечкенә кушылдыгы булган Идел шушы чорда зур елгага әверелгән һәм Кама аның кушылдыгы булып калган.

Бозлык эреп, чигенеп, җир-кырлар яңадан яшеллеккә күмелгәч, Урал итәгенә кешеләр ешрак килеп йөри башлаганнар. Моннан 25 мең еллар элек әзер тау куышлары белән генә чикләнмичә, алар үзләренә уңайлы урыннарда шалаш, землянкалар корып тора башлаганнар. Яңа таш гасырда (неолит чорында) алар балчык изеп савыт-саба ясарга өйрәнгәннәр (1.10-35 бб.).

Утрак тормышта ыруглар кабиләләргә оеша башлаганнар. Мезолит (бронза) чорында Идел-Кама буенда бура кабиләләре, иран телле кабиләләр, алардан төньяктарак угро-фин халыкларының иң ераккы кабиләләре булуы билгеле. Урта мәктәп, югары уку йортларында өйрәнгән «Тарих» буенча Көньяк Уралда, Иделнең түбән өлешендә скифлар, савромат, сармат, аланнар яшәгәнлеген беләбез.

Кешелек тарихыннан күп нәрсәне без күп мең еллар язулы гарәп, фарсы, грек, кытай тарихчыларының әсәрләрендә табабыз. Алар исә Каспидан төньяктагы җирләр турында ишетеп кенә белгәннәр. Борынгы тарихчылар Геродот, Страбон, мәсәлән, скифлардан ары гомумән кеше яшәми, дип уйлаганнар. Страбон хәтта Ирландияне яшәү өчен яраксыз, анда тик кыргый халыклар гына яши дип санаган. Геродот, без яшәгән Уралны күз алдында тотып, болай дип язып калдырган: «Дон артында савроматлар, «егра»лар (кыргый кешеләр) яши, анда сигез ай чыдап булмаслык салкын, туктаусыз кауры́й (кар дигән сүзне белми) өча» (3.30-32 бб.).

Безнең эраның 79 нчы елында үлгән Өлкән Плиний аларны да уздыра: «Балтик диңгезендәге утрауларда коточкыч гыйфритләр (получудовища) яши, берәүләре ат аяклылар, икенчеләренең колаклары бөтен тәннәрен капларлык зурлар», дип яза (3. 36 б.).

Көньяк океаннар аша бөтен Азияне әйләнеп чыккан Венеция сәүдәгәр-сәяхәтчесе Марко Поло (XIII гасыр), әлеге Плиний һ.б., гарәп язучыларына таянып, Азия һәм Европаның төньягын «Караңгылык иле» (русчага «Страна Тьмы» дип тәрҗемә ителгән) дип атый, «анда һәрвакыт караңгы, кояш та, ай да, йолдызлар да юк, бездәге эңгер-меңгер кебек һәрчак караңгы. Анда яшәүчеләрнең патшалары да юк, алар ерткычлар кебек яшиләр, беркемгә дә буйсынмыйлар...» (3. 81 б.).

Болары безнең якларны ишетеп кенә белгән борынгы тарихчыларның язганнарыннан. Алардан Гәйнә иле кебек конкрет төбәкләр турында мәгълүматлар өмет итеп булмый. Шуңар без үз галимнәребезгә мөрәҗәгать итеп карыйк, алар ни әйтер.

Беренче сүзебез - археологларга. Җир йөзендә моннан меңнәрчә еллар элек ни булганын җирнең үзеннән дә әйбәт белүче юк. Археологлар әнә шул җир үзе саклаган бөек тарих архивын ачып, үткәннәрнең гади кешеләре тормышының елъязмасын табалар. Җир куеныннан алар тутыгып беткән тимер- томыр әйберләр - музейлар өчен экспонатлар гына казып чыгармый, ә алар ярдәмендә конкрет төбәктә кайчан ниләр булганлыгын, анда нинди халыклар яшәп, аларның ни белән шөгыльләнгәнлекләре турында җирнең үзеннән сөйләтәләр. Алар казып

чыгарган җансыз шаһитларның, кем әйтмешли, теле генә юк. Кем өчендер телсез алар, археологлар исә аларның һәр бортегендә калын китапларга җитәрлек мәгълүматлар алалар.




1992 елда Кодаш авылы янында курган-кабердән казып алынган әйберләр: 1. Бронза бөти-, 2. Җиздән коелган каеш башы. 3. Түшкә тагыла торган кыңгыраучык.

Югарыда сез Каманың сул кушылдыгы Чу суы (Чусовой елгасы) буенда булган беренче кешеләр турында укыдыгыз. Чу суына Сөлил, Сөлилгә Ирән елгасы кушыла. Ирәнгә сул ягыннан эссе җәй көннәрендә дә тешләреңне камаштырырлык салкын сулы Башап елгасы килеп кушыла. Элегрәк ул бүгенгесе кебек Кыек чук буйлап түгел, ә Эчкәре чук аша аккан һәм Ирәнгә Кече әрәмәлекнең көньягыннан килеп кушылган. 1988 елда Кама-Вятка археологик экспедициясе Удмурт дәүләт университеты профессоры, кафедра мөдире Римма Дмитриевна Голдина җитәкчелегендә шушы урында казу эшләре алып барды һәм... безнең эрага кадәр өч меңенче елларда (5 мең еллар элек!) яшәгән авыл урынына тап булды. Сылва культурасына караган бу авыл урынында казу эшләре элегрәк тә үткәрелгән һәм анда кремний кыргычлар, нуклеуслар, пычаксыман пластинкалар табылган иде (5).

Бусы минем туган авылымда, Кече Башапта (ул Пермь өлкәсенең Орда районына керә), Гәйнә иленең төньяк-көнчыгыш чигендә ачыкланган борынгы авыл урыны. Ирән буенда моннан тыш та байтак истәлекле урыннар - иллеләп шәһәрлек һәм авыл урыннары теркәлгән.

Археологлар Тол буенда да күп истәлекле урыннар ачтылар һәм ача киләләр. Без хәзер шушы археологик һәйкәлләрне карап үтик.

1986 елда Бардадан 25 чакрым ераклыкта Барда шәһәрлеге (городище) ачылды. Археологлар аны бронза чорына, безнең эрага кадәр X-IX гасыр-

ларга карый, дип исәплиләр. Анда табылган әйберләр арасында савыт-саба да булып, алар безнең эрага кадәр II - безнең эраның IY гасырларына карый дип исбатлана. Димәк, шәһәрлек ким дигәндә моннан оч мең ел элек барлыкка килгән һәм мең ярым ел яшәгән.

1988 елда Кама-Вятка археологик экспедициясе Бардадан 2,5 километр тоньяктарак I шәһәрлек ачты. Бусы безнең эрага кадәр III - безнең эраның III-Y гасырларына карый.

Бүгенге көнгә Барда исеме белән аталган барлыгы дүрт шәһәрлек билгеле. Дүртенчесе Бардадан 4,5 километр тоньяктарак 26 метр биеклектә урнашкан һәм ул ике туфрак өеме (вал) белән уратып алынган. Бусын археологлар урта гасыр башына караган авыл дип исәплиләр.

Әмҗе елгасының уңъяк ярында берсе Байавылдан 300 метр, икенчесе 700 метр көнчыгышта ике авыл урыны табылды. Археологлар аларны Куземьяр I һәм Куземьяр II исеме белән теркәделәр. Беренчесе тимер гасырга (безнең эраның I меңъеллыгы башы), икенчесе шушы ук тимер гасырның башлангыч чорына карый.

Пермь дәүләт университетының Археология бүлегендә «Пермь өлкәсенең археологик истәлекләр исемлеге» дигән документ саклана. Аның «Барда районы» дигән бүлеген ачабыз һәм укыйбыз:

I. Аклыш шәһәрлеге. Безнең эраның I меңъеллыгының беренче яртысына карый. Тол елгасының уңъяк ярында, авылдан 1 километр тоньяк-көнчыгышта.

2. Аклыш I авыл урыны (селище). Бүгенге авыл эчендә.

3. Аклыш II авыл урыны. Тол елгасының уңъяк ярында, авылдан 1,5 километр тоньяк-көнчыгышта.

4, 5, 6, 7. Ике Барда шәһәрлеге һәм шул исемдәге ике авыл. Беренче шәһәрлек безнең эрага кадәр YI - безнең эраның III гасырлары белән билгеләнә, калган өчесе I-III гасырларга карый дип санала.

8. Елпачиха (Үдик) I авыл урыны. Беренче меңъеллык. Кече Әмҗенең сулъяк ярында, авылдан 0,2 километр көнчыгышта.

9. Елпачиха II авыл урыны. Ананьин чорына, ягъни безнең эрага кадәр Y-III гасырларга карый. Кече Әмҗенең сулъяк ярында, 0,5 километр көнчыгышта.

10. Елпачиха III авыл урыны. Тимер гасыр (безнең эраның I нче меңъеллыгы башы). Авылдан 3,5 километр көнбатышта.

11. Искир. Авыл урыны. Тимер гасыр (I меңъеллык башы), авыл эчендә. Пиктер отчетта бу борынгы авыл урыны Толның сулъяк ярында итеп күрсәтелә, ә үзе - «авыл эчендә».

12. Елпачиха шәһәрлеге. Безнең эрага кадәр IY-II гасырлар. Кече Әмҗенең сулъяк ярында, авыл эчендә.

13. Красноярр I авыл урыны. Безнең эрага кадәр Y-III гасырлар. Толның уңъяк ярында, II Әрҗәннән 1,5 километр тоньяк- көнбатышта.

14. Красноярр II авыл урыны. Безнең эрага кадәр Y-I гасырлар. II Әрҗәннән I километр тоньяк-көнбатышта.

15. Краснояр III авыл урыны. Шул ук безнең эрага кадәр Y-III гасырлар. Толның уңъяк ярында, I Әрҗәннән 7 километр көнбатышта.

16. Краснояр I шәһәрлеге. Безнең эрага кадәр II - безнең эраның III гасырлары. Авыл эчендә.

17. Краснояр II шәһәрлеге. Шул ук чорларга карый.

18. Куземьяр авыл урыны. Беренче меңъеллык. Кече Әмҗенең сул ярында, авылдан 0,3 километр көнчыгышта.

19. Талая речка, авыл урыны. Тимер гасыр.

20. Чувашаево. Авыл урыны. Безнең эрага кадәр Y-III гасырлар. Олы Әмҗенең сул ярында, авылның коньяк чигендә.

21. Шермейка шәһәрлеге. Алтынай елгасының сулъяк ярында, авыл территориясендә.

22, 23, 24. Шермейка I, II, III авыл урыннары. Өчесе дә Алтынай елгасы буенда, Шермейка авылы территориясендә (6).

«Пермь өлкәсенең тарих һәм мәдәни истәлекләре» дигән китапта Борынгы Гәйнә олысына караган территориядә Сидяха елгасында биш шәһәрлек (безнең эрага кадәр Y гасырдан башлап), Краснояр шәһәрлеге, Оса шәһәрлеге (Оса авыл хуҗалыгы техникумы территориясе), Пещерское шәһәрлеге (ике метр биеклегендә туфрак өеме һәм чокыр сакланган). Бу шәһәрлекләрнең барысы да Тол елгасы буенда урнашкан һәм безнең эрага кадәр үк булганнар.

Оса шәһәреннән ерак түгел табылган Кама- Жулановская исеме белән аталган мезолит чоры тукталышы (вакытлы тору урыны) да, неолит чоры тукталышы Кряж да шундыйлардан. Тора-бара бу «вакытлы»лар арасында шактый эре даими торак урыннар да барлыкка килгән (7).



Урман кабиләләре кулланган ут алу җайланмасы, кыска чалгы, аюга тозак.

Галимнәр балык аулап, сунарчылык белән көн күргән бу тәүге кешеләрнең үзара нинди телдә аңлашканлыкларын да ачыклаганнар. Көнчыгыш Европа һәм Урал артында барлыкка килгән урман кабиләләре арасында, дип яза лингвистлар, фин-угор тел бердәмлегенең (финно-угорская языковская общность) нигезе барлыкка килгән. Һәм анда яшәүчеләр үзләреннән көньяктарак (хәзерге Башкортстан, Чиләбе өлкәсе җирләрендә) яшәгән кабиләләрнең «горновойлары»нда коелган бакыр һәм җиз әйберләрне үз әйберләренә алмаштырып алып кайткалаганнар, аларны тирегә алмашу өчен көньяк кешеләре үзләре дә алып килгән (8. 164-188 бб.).

Безнең эрага кадәр ике меңенче елларда металл әйберләр ясау өчен чимал Уралга Идел буйлап Төньяк Кавказдан китерелгән, соңрак Уралның үзендә дә (Урал артында) тимер рудасы табылган. Безнең эрага кадәр ике меңенче елның урталарында Түбән һәм Урта Чулман-Кама буе кабиләләре металлны урында үзләре чыгарган бакыр комыннан койганнар һәм аннан үзләре үк металл әйберләр эшли башлаганнар. Бер үк вакытта терлекчелек, җир эшкәртеп иген игүләр үскәннән-үсә барган. Төньяк Кавказ, Кара диңгез буендагы грек колонияләреннән, Урта Азия һәм Иран илләреннән кыйммәтле тирегә алмашу өчен төрле әйберләр китерелгән.

Кама буенда безнең эрага кадәр YII-III гасырларда төрле кабиләләр берлекләре (союзы) барлыкка килгән. Безнең булачак Гәйнә иленең үзәгендә, Тол елгасы бассейнында (Барда, Үдик, Әрҗән шәһәрлекләрендә, Чувашай һ.б. авыллар урыннарында) яшәгән берлек иң зурлардан саналган. Аның үзәге булган Оса шәһәрлегендә бик күп янган бодай калдыклары табылган. Аның 72,5 проценты борай, 27,5 проценты арпа. Иген чәчү өчен җир китмән белән эшкәртелгән, уру өчен урак кулланылган. Болар — Уралда игенчелек турында иң борынгы мәгълүматлар (9. 213 б.).



Китмән



Шәп-чабагач

XYIII-XIX гасырларда Гәйнә иленең бөтен Уралда иң күп иген чәчүе, башка урыннарда күчмә терлекчелек белән шөгыльләнгәндә аның нигездә игенчелек белән шөгыльләнүе, Соликамск, Ирбит кебек эре ярминкә-базарларда ашлык белән сәүдә итү дәрәҗәсенә күтәрелүе менә кайлардан килә!

Бездән төньяктарак коми, ханты-манси халыкларының борынгы бабалары яшәгән. Оса кабиләләр берлеге удмуртларның борынгы бабаларын берләштергән. Ә коньяк урман- дала районнарында күптәннән яшәп килгән җирле кабиләләрне (угорларны) төньякка кысрыклап яисә үзләренә йотып, төрки кабиләләр килеп урнашкан.

Билгеле археолог А.Х.Халиков бу үзгәреш I-IY гасырларда (ягъни «бөек күченеш» чорында) булган ди (10. 21 б.). Бу фикерен ул «Татарика» дигән җыентыктагы мәкаләсендә янә кабатлый: «Кама һәм Идел буеның төркиләшә башлавын, ягъни биредә төрки телле кабиләләр күренә башлауны һуннар заманыннан (безнең эраның III-IY гасырларыннан) алырга кирәк» (11. 336 б.).

Һуннар үзләрен һунну дип йөрткәннәр, ә Ауропада аларны гун дип атаганнар. Этнос буларак һуннар үзәк Азиядә формалашканнар. II гасырда алар Җидесуны яулап көчле держава төзегәннәр. Ләкин аларга сяньбиләр (монголларның борынгы бабалары) тынгылык бирмәгән. Бу вакытта һуннар 300 мең чамасы булган дип исәпләнелә. Шулардан 20-30 меңе сяньбиләр эзәрлекләвеннән качып, 158 елда Идел-Урал ягына килеп чыгалар, Донга барып җитәләр. Ике елдан артык вакыт эчендә турыдан исәпләгәндә 2600 км. юл үтәләр. Билгеле, бу кадәр юлны иярне үз иткәннәр, шуннан торып сугышкан, шунда ял итә алганнар гына үтә ала. Хатын-кызлар, картлар һәм бала-чага ияртеп, гадәти күченү рәвешендә моны эшләп булмый. Сяньбиләр эзәрлекләве бер сәбәп. Шуның өстенә II-III гасырларда коньяк далаларда көчле корылык чоры булуы билгеле. Эзәрлекләүләрдән дә, корылыктан да берьюлы бер генә юл белән - урманлы далаларга качып кына котылып була. «Ярсулы һуннар» шулай итәләр дә. Монголиягә кире кайтмыйлар. Ә IY гасырда һуннарның гомум күченеше башлана.

Европада һуннарны әле бүгенгә кадәр мәдәниятсез кыргый халык итеп тасвирлау өстенлек итә. Һуннар турында күп хезмәтләр язган Лев Гумилев «Күчмәннәр культураны кабул итәргә, иҗат итәргә сәләтсез дигән легенда - ул «кара легенда» ди. Бөек дала күчмәннәре кешелек һәм культура тарихында европалылар һәм кытайлардан, мисыр һәм фарсылардан... ким роль уйнамаганнар. Ләкин аларның роле үзгә, оригиналь, байтак вакытлар һәм әлегә кадәр күпләр моны аңлый алмый яисә аңларга теләми» (12.70-82 бб.).

Һуннар Европага биредәге халыклар белмәгән күп яңа нәрсәләр: озәңге, өсте ябулы арба (кибитка), кәкре кылыч, укны 700 метрга кадәр очыра торган «М» хәрефе формасындагы озын җәя, киездән корыла торган түгәрәк юрта, кытай тукымалары алып киләләр. Иң мөһиме, биредә алар иҗтимагый стройның үзгәрүенә, яңа система туугa сәбәпче булалар.

Культурасыз кыргыйлар (варварлар) дип исәпләнгән һуннарның язуы да булган. Пермь губернасы Чардын өязе Керче авылы янында узган гасырда, башка күп әйберләр белән бергә, язулы алтын-көмеш савытлар табыла. Казан археологы Әзһәр Мөхәммәдиев күптән түгел әлегә кадәр беркем тарафыннан укылмаган шушы язуны укып, А.Македонский, Юлий Цезар кебек үк халыклар гение буларак мәгълүм һуннар каганы Атилланың уртанчы улы Денгиззихның безнең якларда патшалык итүе, Идел-Йорт падишаһы булганлыгы турында язып чыкты. Аның әйтүенчә: «Язу һун телендә, ә һун язуы безнең эрага кадәр 174 еллар тирәсендә Туран дәүләтендә сугылган акчалардан мәгълүм» (13).

Шушы ачыштан соң, 1993 елның 25-26 февралендә Бардада фәнни-гамәли конференция үтте. Анда Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе, ТФА академигы И.Р.Таһиров: «Сезнең якта атаклы Атилланың улы яшәгән һәм шушында җирләнгән», - дип белдерде.

453 елда әтисе үлгәннән соң аның улы Денгиззих 90 ел буена Рим империясен талау белән шөгыльләнгән готларга каршы сугышлар алып барган, Константинополь сарае (Византия) белән союз һәм сәүдә оештырырга омтылыш ясаган. Бу эше барып чыкмагач, Днепр буена кайткан, ләкин анда да тынычлап яшәргә мөмкинлек булмаган: көнбатыштан шул ук готлар тынгылык бирмәгән, көнчыгыштан - болгарлар, төньяктан савирлар һөҗүм итеп торган (12.135-139 бб.).

Әнә шундый шартларда яшәүдән туеп, Денгиззих гаскәре белән Идел-Кама буена күченгән, гомеренең соңгы елларын шушында үткәргән булып чыга.

Борынгы Рим империясендә колбиләүчелек җәмгыятенең феодализм белән алмаштырылуына китергән һуннар безнең Урта Урал-Кама регионында да яңа система - гомум милекчелеккә нигезләнгән җәмгыять урынына хосусый милеккә нигезләнгән җәмгыять барлыкка китергәннәр. Моңарчы кешеләр туганлык буенча ыругларга, кабиләләргә берләшсәләр, моннан соң алар күршелек общинасында, ягъни хәрби демократия тибындагы стройда яши башлаганнар.

Урал буенда яшәгән угро-фин, фин-пермь кабиләләре тормышында, аларның төркиләшүенә һуннардан тыш бүтән төркиләр, аерым алганда Кара һәм Каспий диңгезләре тирәсен, Кавказ, Урта Азия җирләрен, ягъни шул ук хун-гуннар державасы территориясен берләштергән Төрки каганат, бу каганат таркалгач,Түбән Иделдә барлыкка килгән Хәзәр, башта Кара

һәм Азак диңгезләре ярында, аннары Идел- Кама буенда барлыкка килгән Болгар дәүләтләре байтак тәэсир иткән. Әйтик, академик М.Зәкиев Идел-Урал буеның төркиләшүен безнең эрага кадәр үк башланган процесс дип саный. Ул «Урал- Идел регионында башка кабиләләр белән бергә төрки телле кабиләләрнең дә скифлар чорыннан ук (безнең эрага кадәр YII-IY йөзләрдә үк) яшәгән булуларын танып эш итү кирәклеген» күрсәтә (14).

Идел-Урал арасында төрки телле кабиләләрнең безнең эрага кадәр үк яшәүләре, җирле халыкларны ассимиляцияләве турындагы фикер бүген генә туган нәрсә түгел. Бу бәхәсле мәсьәләгә башкортларның этногенезын тикшерүгә багышланган 1969 елгы Уфада уздырылган фәнни-конференция берникадәр ачыклык кертте. Анда чыгыш ясаган галимнәрнең кайберләренә тукталып үтик.

**В.Ф.Генинг:**

- Безнең эрага кадәрге соңгы гасырларда Агыйделнең урта агымында «прохор культурасы кешеләренә охшаш пиндидер яңа төркемнәр барлыкка килә. Алар күчмәннәр түгел, ә утрак тормышлы игенчеләр, көтүчеләр» (15. 111-129 бб).

**В.А.Оборин:**

- Генинг сөйләгән культурага охшашлыклар Пермь өлкәсенең Елово районында табылган керамикада нык сизелә. Алар безнең эрага кадәр Y-II гасырларга карый һәм Башкортстан территориясендә табылганнар белән бер.

Фоки районындагы Сайгатка каберлеге, Күңгер районындагы Клепово каберлеге, Тол буе бассейнындагы Б.-Никольск II шәһәрлеге дә шундыйлардан.

Пермь археологы В.А.Оборин бу культурага караган һәм III-IX гасырларда яшәгән кабиләләрне Мазунин кабиләләре дип атый, аларның Оса урман-даласына үткән булуларын фараз итә һәм шушы чордан урта Кама буенда, аеруча Сылва бассейнында топонимика да үзгәрә, ди (16. 130-135 бб.).

**А.Х.Халиков:**

- ... бу кабиләләр «Агыйдел тамагына кадәр үтеп кергәннәр һәм аннан Сылва бассейнына һәм Камага күчкәннәр, күрәсең» (17. 30-37 бб.).

**Р.Г.Кузеев:**

— Б.Н.Заходер «Каспийский свод сведений о Восточной Европе» дигән китапта (М., 1962) мадьярларның ике катламы турында хәбәр итә: аларның берсе бәҗәнәкләр иле белән болгар эсегельләре иле арасында яшәгән, ди. Болгарлар килгәч, яңа төр болгар-мадьяр этник процессы һәм угор-мадьярларны төркиләштерү башлана. Шушы этник средада YIII-IX йөзләрдә башкорт халкының элгәрге этник катламы формалаша (18).

«Башкорт халкының этник тарихына кыскача очерк»ында Р.Г.Кузеев төньяк-көнбатыш башкортларының формалашуында җирле халыклар зур роль уйнады, ди. Болгар- угорлар (бусын без болгар-мишәрлар дип төзәтәбез) компонентында юрматы, юрми, гәйнә-тархан, булгр, танып, мишәр- юрматыларны санап китә һәм бишесенең болгар үзенчәлекләре барлыгын билгели (кара: АЭБ. Том Y, 32-60 бб).

**П.Д.Степанов:**

- Язма чыганакларда (Балхи, Ибн-Даста, Гардизи, Константин Багрянородный, «Повести временных лет») «мадьярлар Болгарга якын яшәгәннәр, ике мең кешедән торганнар, болгарларга буйсынганнар, урманнар артында яшәгәнлектән, аларга беркем дә һөҗүм итә алмаган... Бәҗәнәкләр белән чиктәш яшәгәннәре башджарт дип аталган, алар һәм бәҗәнәкләр төркиләр, аларның иген басулары күп» (19. 136-147 бб.).

Рубрукның «Көнчыгыш илләргә сәяхәт» (М. 1957. 122, 211 бб.) дигән китабыннан «огор-угырлар - алар венгрларның бабалары, YI гасырда Идел белән Урал арасында яшәгәннәр, XIII гасырда да әле бу территория кешеләренең телләре венгрларга аңлаешлы булган» дигән сүзләрен өстәсәк, бу мадьярларның нинди кавемнән булганлыклары аңлашылып тора.

Туган ягы турында әз генә булса да мәгълүматы булган кеше гаҗәпләнергә мөмкин: шушы кадәр билгеле мадьяр- бажкарларны ник соң әле безгә гел генә венгрлар дип тукып килделәр, антик тарихчылар язганга ышанмаска нәрсә комачаулаган?

Ә.Г.Мөхәммәдиевның югарыда күрсәтелгән хезмәтендә Кама буенда табылган көмеш тәңкәләрдәге язуларны укый алучы булмый, чөнки «Туран сүзе үзе үк куркыта» дигән сүзләре бар. Уралда яшәгән мадьярларның төрки булуын тану да кемнедер куркыткан, кемгәдер цивилизацияле Европаны санга сукмау, Көнчыгыш халыкларын алардан өстен куюбулып тоелган, күрәсең.

М.З.Зәкиевның «Мишәрләр һәм мадьярлар турында» дигән хезмәтен укыгач, бу фикер тагын да ныгый төшә. «Мажарлар - алар мишәрләр, төрки телле куман-кыпчаклар», - дип яза галим әлеге хезмәтендә (20, 280б.). Күп еллар шушы атаманың килеп чыгышы белән шөгыльләнгән венгр галиме Ю.Немет мишәр һәм мадьяр этнонимнарын бер үк сүзнең ике варианты дип саный, ләкин ул мадьяр вариантын беренчел дип раславы белән ялгыша, ди М.З.Зәкиев. Башта бу атама билгеле бер этник төркемгә карата кулланылган, соңыннан, этнос икегә аерылгач, вариантларның

берсе (мишәр) төрки телле булуын дәвам иткән этносның, икенчесе - мадьярларның, венгрларның үзатамалары булып киткән (20. 280-281 бб.).

Маджар-мишәрләр төрле чорда төрлечә аталып йөртелгәннәр; куман (половецлар) хакимлек иткән вакытларда алар арасында кубан яисә губин дип атап йөртелгән төркем дә булган. Бусы безнең өлкәдә еш очрый торган Губан атамасын хәтерләтеп тора (Орда районында Губан авылы бар). Алтын Урда чорында коньяк татарларны пугай дип йөрткәннәр. Шул ук вакытта мишәр (мишә - урман, әр - кеше) атамасы да сакланган.

Шулай итеп, мадьяр-мажар-мишәрләр Урал башкортларын, идел болгарларын һәм Венгрия халыкларын формалаштыруда катнашкан уртак этник компонент булып чыга.

«Татар-мишәр һәм Казан татарлары уртаклыгының тарихи нигезләре» дип аталган хезмәтендә А.Х.Халиков безнең өчен бик тә кызыклы күзәтү-чагыштырулар үткәрә: «Интересные параллели в языке и некоторых этнографических деталях наблюдаются между татарами-мишарями и почти никогда не контактировавшими с ними нохратскими (чепецкими) и пермскими (бартымскими) татарами. Не исключено, что они являются отголоском той древнейшей тюркской общности, которую в YI-YII веках еще сохранили племена, входившие в состав Тюркского каганата и в это же время появившиеся на берегах Камы и Суры (21.340 б.)... племена, близкие к этнониму буртас, входили и в состав более восточного болгарского населения IX-X вв. Как известно, в составе этого населения значительное участие принимали племена, связанные с культурами ломоватовско- поломского типа. Некоторые из них, вероятно, носили имя Буртаспертас. Последние упоминаются пермским летописцем среди пермских племен, локализованных где-то в районе среднего течения Камы рядом с устьем р.Чусовой. Между прочим, живущее здесь татарское население носит имя «бартымских татар». Авторы IX-X вв. сообщают, что где-то в районе локализации буртас «между землею печенегов и землею булгарских эсегель лежит первый из краев мадьярских» (21, 342, 345 бб.).«Бөек күченеш» чорында төрки кабиләләр (һуннар, бәҗәнәкләр һ.б.) кысрыклавы аркасында көнбатышка күченгән кабиләләр составында мишәрләрнең бер өлеше Дунай буена, Паннониягә барып җитәләр, фин-угор кабиләләре арасына эләгеп, ассимиляцияләнәләр. Кара диңгез буеннан күченеп киткән болгарлар кебек, телләрен үзгәртәләр, мадьяр исеме белән үз атамаларын саклыйлар. Мишәрләрнең зур территорияне алып торган икенче өлеше «Идел болгарлары, башкортлар, руслар, мордвалар, чуашлар составына кереп киткән» (20. 285 б.).

Урта Уралда яшәгән утрак тормышлы мишәрләр турында моннан тыш та байтак материал китерергә булыр иде. Пермь галиме В.А.Оборин Каманың сул ярында, Сылва, Бабка, Мулянка, Тол, Сарс, Танып буенда яшәгән остякларны мадьярларның еракы бабалары дип атый. Шуннан остяк- иштәкләр дә мажар-мишәр этносыннан булган дип аңлашыла.

1912 елда басылган «Башкорт тарихы»нда (авторы Мөнир Һадыев) бәҗәнәкләр кысрыклавы нәтиҗәсендә алар (мажар- мишәрләр) 884 елда Алмус җитәкчелегендә Уралдан киттеләр, диелә.

В.Ф.Генинг Иделне кичеп көнбатышка юнәлеш алган мадьярлар берлегендә 2 угор, 5 төрки кабилә булганлыгын искәртә. Димәк, бүгенге тарихчыларга мадьяр-мишәрләр угорлардан чыккан дип ялгышу өчен дә нигез юк түгел икән (җидедән икесе угор бит).

Безнең якларда мишәрләр яшәве хакимият органнарының рәсми кәгазьләрендә дә теркәлеп калган. 1742 елда Уфа воеводасы Н.Д.Мерзлякин сенатка шуны хәбәр иткән: «Мишәрләр, чирмешләр һәм вотяклар, шул исәптән аз санда башкортлар да яшәгән Оса юлы олысларында һәм Күңгер өязендә игенне күп чәчәләр һәм ул җитәрлек уңа да. Бу яклардан икмәкне Уфага су юлы белән түбәнгә агызу җиңел» (23. 487-509 бб.).

Мадьяр-мишәр атамасы риваятьләрдә, шәҗәрәләрдә дә очрый, алар турында Оса краеведлары күп язды. «Барда авылы тарихыннан» дигән мәкаләсендә А.Шестаков, мәсәлән, «Рус колонизациясенә кадәр Тол буе бассейнында угор кабиләләре: хантлар, манси һәм мадьярлар яшәгән, IX гасырда мадьярлар көнбатышка күчеп киткәннәр», дип яза (24). Угорлар дип ялгышсалар да краеведлар да, нәсел агачы төзүчеләр дә Гәйнә илендә мадьяр-мишәрләр яшәгәнлеген белгәннәр.

Эсегельләрне мадьярлар диючеләр бар. 1991 елның 26-28 февралендә Казанда «Болгар- Киев сәүдә юлы» дигән темага багышланган фәнни конференция узды. Анда шушы сәүдә юлында 1984 елдан бирле казыну эшләре алып барган ике Академия археологлары чыгыш ясады. Болгар-Киев сәүдә юлы - атаклы «Ефәк юлы»ның бер тармагы. Болгар сәүдәгәрләре аны Кама буйлап үзләреннән арырак яшәгән халыклар (вису, югра) ягына сузганнар. Бу яклар белән сәүдә итү элемтәсе Пермь тирәләре Рус дәүләтенә кушылгач та өзелмәгән.

Кай тарафтан үткән соң бу юл?

«Кайбер урыннарда Кама буйлап үтсә дә, гел яр буйлап үтмәгән ул. Гадәттә борынгы кешеләр еракка юлны субүләр калкулыклар аша, елганың үзеннән читтәрәк сала торган булганнар». Конференциянең төп оештыручысы А.Халиков шундый аңлатма биргән иде. Шәҗәрәләр белгече Марсель Әхмәтҗанов та: «Каманың бу ягында, Удмуртиядә Тат. Парзи дигән авыл бар. Бу сүз парча (ефәк) дигән сүздән. Сезнең Барда атамасы да шул сүздән түгел микән?» - дип өстәгән иде.

Икс җавапны да күңелемә салып, шәһри Болгардан үзебезгә таба сызык сызам: Агыйдел-Танып буйлап ул Толның уң ягына, археологлар Барда шәһәрлеге дип атаган җирләргә килеп чыга. Аннан инде Тол-Тор, Күңгер, борынгы Усолье, Чардын крае, гарәп илчесе Ибн-Фадлан вису дип атаган халыклар яшәгән җирләр...

А.Х.Халиковның тагын бер фикере истә калган: «Сезнең як халыклары төп эсегельләр, Ломоватй культурасына караган төрки телле Иске Ил кабиләсеннән. Шуннан инде үзегез әйткән Искилде авыллары». Икенче галимнәр исә: « - Юк, эсегельләр алар мадьярлар. Сез, нигездә, нугай татарлары», - дип аңлаталар.

Безгә Ломоватй культурасы белән Ижевск галимнәре шөгыльләнүе мәгълүм. Һәм без Барда районында ачылган археологик истәлекләр исемлеген тотып шунда юл тотабыз. Удмуртия дәүләт университеты

профессоры Римма Голдина безне күптәнге танышыдай каршы ала, бик теләп Вятка-Кама экспедициясе башкарган эшләр турында сойли һәм үзенең 1985 елда басылып чыккан «Ломоватская культура в Верхнем Прикамье» дигән китабын бүләк итә. Әйтә:

- Ломоваты культурасы фәкать пермь халыкларына нисбәтле. Эсегельләргә килгәндә, бик аз санлы бер кабилә ул, әз генә вакыт Каманың түбәнге агымында булган. Кем дә булса бу кечкенә торкемне кайсыдыр халыкны төркиләштерүдә катнашкан дип әйтә икән, моның өчен зур фантаст булырга кирәк...

Ә бит фантазиягә бирелмичә генә уйлаганда да Искилде авыллары бар һәм бер Барда районында гына да түгел.

Эсегельләрнең ломоваты-полом культурасына караганлыгын, IX йөзнең урталарына кадәр протоболгарлар белән кардәш булганлыкларын А.Х.Халиков та инкар итми, иске ил кабиләсе чыгышы белән Кама (Чулман) һәм Урал буйларына бәйле, ди (25. 22 б.).

Эсегель-искилләрне 921-922 елларда Идел Болгарстанына сәяхәт ясаган гарәп илчесе Ибн-Фадлан да искә ала: эскелләр Болгар патшасына буйсынганнар, ди ул, Болгар иле исламны рәсми төстә кабул иткәнче үк әле аларның мәчете булган, Болгар патшасы Алмуш хан икенче кызын яһүд динендәге хәзәр каганына көчләп алып китүдән коткарып калу өчен эскәл кабиләсе кнәзенә биргән (26).

Барда районындагы Искилде авыллары чагыштырмача яшь авыллар: Түбән Искилдегә XIX гасырның беренче чирегендә, Югары Искилдегә 1842 елда нигез салынган. Алар тирәсендә дә Акбаш авылындагы кебек язулы ташлар булган, диләр. Димәк, узган гасыр башында һәм уртасында районның иң борынгы авыллары Үдик, Иске Башап, Әрҗән, Солтанайлардан күченеп киткән Сәхәветдиновлар, Хәмитов, Вәлитов, Әҗмәтов, Касимовлар мәңге буш торган җирләргә түгел, ә кайчандыр борынгы бабалары яшәгән төбәккә күченгәннәр.

Безнең алда 1993 елда чыккан «Татарстан» журналының 9 нчы саны (русчасы). Анда тарихчы-галим Евгений Казаковның «Борынгы Паскатир иле» дигән мәкаләсе урнаштырылган. Әлеге атама, дип яза автор, язма чыганакларга «баскарт яисә паскарт» булып кереп калган. Һәм бу атама белән алар территориясенә соңрак килеп чыккан соңгырак чор төрки күчмәннәрне, XY гасырда күчми калган баҗҗарларны кысрыклаган яисә ассимиляцияләгән башкортларны атый башлаганнар булса кирәк (27. 45 б.).

Тарихта моңа охшаш хәлләр еш очрый. Без татар атамасының да безгә ничек килеп «ябышканлыгын» беләбез.

Е.Казаков баскартларга нисбәтле археологик истәлекләр арасында Сөлил бассейнында ачылган Усть-Кишерть, Селянин каберлекләрен искә алып үтә, паскатир- баҗҗарлар Идел болгарлары белән тыгыз элемтәдә торганнар, алар җитештергән көмеш, җиз әйберләрне киң кулланганнар, ди. Боларын без Ижевск археологлары тарафыннан Кодаш авылындагы иске курган- каберлектән казып чыгарылган әйберләр үрнәгендә үз күзебез белән дә күрдек. Е.Казаков мәкаләсенә иллюстрация итеп би-

релгән карта-схема күп нәрсәне ачыклый. Карагыз: булачак Гәйнә иле тулысы белән Паскатирлар иленә кереп киткән. XIII-XIY гасырларда гәйнәләр шушы ил территориясенә килеп урнашканнар, өлешчә конбатышка күченеп киткән, өлешчә үз урыннарында торып калган аборигеннарның атамасын үзләренә кабул иткәннәр, ягъни бажджар-башкорт дип аталып киткәннәр.




Безнең як төркиләрнең мадьяр-болгар чыгышлы булуларын уртак атамалардан күрергә була. Венгр-мадьярларда да, башкортларда да юрми, еней кабиләләре булган. Ермия, Әрәмә атамалары әнә шул юрми сүзеннән, кабилә исеменнән.

Пермь татарларын формалаштыруда катнашкан төп компонент буларак катнашкан мишәр- мадьярларның урынын һәм ролен диалектологлар бик әйбәт ачыкладылар. Сараш авылында туып үскән якташыбыз Дания Сарманаева (1917-1974) «Урта Урал татарлары теленең диалекталь үзенчәлекләре» дип аталган кандидатлык диссертациясендә (1950) пермь татарлары сөйләшен очкә - Барда, Уинск һәм Красноуфим-Манчаж сөйләшләренә бүлеп тикшерә. Беренчесен ул татар теленең урта диалекты,

икенчесен конбатыш (мишәр) диалекты, өченчесен - барлык диалектларның да үзенчәлекләрен үз эченә алган катнаш диалект итеп карый (28).

Пермь татарлары сөйләшенең мишәр диалекты белән уртаклыгына диалектолог Д.Б.Рамазанова да күп игътибар бүлә һәм бу уртаклыкның сәбәбен XYI гасыр ахырында Оса дәругының коньяк өлешенә йомышлы мишәрләр күчерелүдә күрә (29. 141 б).

Без үз телебезнең казан татарлары теленең бер диалекты икәнен таныган хәлдә аның әдәби телдән нык аерылуын, мишәрчә сүзләрне мул куллануыбызны (бөгөн, итмәк, өй диясе урында ү, буяу урнына сырлау, сөлге урнына тастымал дип әйтү һ.б.), кайбер очракларда бөтенләй бүтәнчә (мишәрчә) «сүләшә» башлавыбызны үзебез дә абайлыйбыз. Районыбызның мәшһүр галимәсе Дания Сарманаева безнең сөйләшне очкә бүлеп дөрес эшләгән дип уйларга кирәк: безнең мишәрчә («һ» авазын кулланмыйча, «ф» урнына «п» кулланып ) каты сөйләшүебез Уинск ягында (һәм анда гына да түгел, ә бөтен Ирән буе авылларында) аеруча нык сизелә.

Телче-диалектологлар пермь татарларының теле мишәрләр һәм Себер татарлары телләренә якын тора дип язалар икән, без бу якынлыкны читтән күчләп күчерелгән йомышлы татар-мишәрләр алып килгән үзенчәлек итеп түгел, ә борын-борыннан шушында яшәгән, Идел буеннан һәм Себердән килгән кавемнәрнең күчле йогынтысына карамастан, үзләренең иске (архаик) сыйфатларын саклап киләләр, дип кабул итәргә тиешбез.

Венгр-мадьярларның мишәр-мажарлардан булуын яхшырак аңлау өчен биредә мин Суфиян Поварисовның «Энҗеләр кайда ята?» дигән кызыклы мәкаләсен («Казан утлары», 1994, N 7) укырга тәкъдим итәр идем. Телче-галим һәм язучы С.Поварисов Венгриядә күргән-ишеткәннәрне шул илдә хезмәт иткән безнең үз кешеләребез дә күреп-ишетеп кайта. Бардадан Галим ага Юсуфкулов, мәсәлән, венгрларның бастырык, алма, балта, ыбыр-чыбыр, сыра сүзләрен куллануларын ишетеп йөргән.

Пермь татарларын формалаштыруда катнашкан икенче зур компонентның - безнең якларга монгол яулары, Алтын Урда чорында килеп чыккан кыпчакларның эзләре топонимикада җиңел күзәтелә: охан (чуртан) сүзеннән ясалган Оханск, Куеда районындагы Кыпчак авылы, Төй, Карагаш, Кумыс, Ябалак, Алтын, Казаклар, Каракүл, Урак... Һәр авыл тирәсендә диярлек вак күлләрнең, чишмә, тау, үрләрнең атамалары «мин кыпчак сүзеннән ясалганмын» дип кычкырып тора, тик аларны таный белергә генә кирәк.

Кыпчак атамасы үзе үк бу этносның берничә кабилә-кавемнән торганлыгын искәртә: кыу (аксыл-сары, коба), чак (сак-борынгы скиф кабиләләренннән берсенең атамасы), шуннан аларның икенча атамасы - аксыл-сары чәчлеләр (30. 103 б).

Гәйнә сөйләшенең үзенчәлекләре турында сүз чыккан саен бер нәрсә искә төшеп тора:

«Килең, бу Йосыфка су бирең», «моны үлтермәң, монда бер козог бар, шул козогка ташлаң». Алтын Урда заманында язылган , Йосыф һәм Зөләйха мәхәббәтенә багышланган «Оҗмахка ачык юл» дигән әсәрдән өзекләр болар. Бактың исә «килең», «бирең», «үлтермәң», «әшкәрә». Дөньяда

җиде-ун миллион татар булып, тик безнең тобәктә (Гәйнә һәм Боре сөйләшләрендә) генә шушы сүзләр сакланган икән.

Татар теленең диалектологик сүзлеген кулыгызга алыгыз, «әшкәрә» сүзен карагыз: фарсыдан дип күрсәтелгән сүз тик бер гәйнә сөйләшендә генә тамырлашып калган. Нәрсә бу? Иран кадәр җирдән аны Алтын Урда башкаласы Сарайга (әсәр шунда язылган), аннан Гәйнә иленә кем алып килгән? Ай-һай бу тарих...

Хәер, тарихның Гәйнә белән «ирмәкләр» ясавы моның белән генә бетми. Телчеләр архаизм, диалектизм дип атаган сүзләр бездә санап бетергесез. Ничә тапкыр яңартылып чыгып килгән «Диалектологик сүзлек»ләр дә сыйдырып бетерә алмый аларны.

Гәйнә иленең борынгы заманнар белән бәйләнешен иске ай исемнәре (хут, хәмәл, сәүер һ.б.), көн исемнәре (туган көн, атлаган көн, кан көн һ.б.), күп төрле ырымнар, йолалар да искәртеп тора.

Пермь татарлары, аларны формалаштыруда катнашкан аерым кабилә-ырулар турында күп хезмәтләр язган этнограф Дамир Исхаков кыпчакларны нугайларның бер кабиләсе булган дип исәпли, «кый»ылдап сөйләшүче бу нугайларның Кара диңгез буеннан, Кырымнан килүләрен конкрет мисаллар белән раслый (31. 176 б).

«кый»ылдап сөйләшүдән тыш та танытыр нәрсәләре булган нугайларның. 1547 елда «нугай татарлары» Чердынь янында русларны тармар иткәннәр. 1564 елда Строгановлар «нугай кешеләреннән һәм башка урдалардан саклану өчен Орлов шәһәрен төзегәннәр. 1572 елда Строгановларга җибәрелгән бер грамотада нугайларга, чирмешләргә, удмуртларга һәм остякларга каршы көрәшү турында әйтелә (32. 52, 65 бб).

1546-47 елларда нугайлар Уралдан Төньяк Кавказ якларына күпләп күчә башлыйлар. Бу процесс Казан ханлыгы тармар ителгәч тагын да көчәя. Күчми калган Тол, Ирән, Солил буе нугайларын иштәк (остяк) дип атап йөртә башлаганнар. Бәлки бу исем (иштәк) нугайлар үзләре тараткан исемдер, дип уйларга урын бар, ди Д.Исхаков (32. 65 б). Рус чыганакларында, «Башкорт шәҗәрәләре»ндә алар башкорт дип атала, ә Ирән буе авылларында (мәсәлән, Кече Башап авылында), гәүдәгә кечерәк булганнары өчен микән, аларны «чәкүшкә» дип йөрткәннәр.

Л.Н.Гумилевның «Борынгы төркиләр» дигән китабында тугыз татар, утыз татар, тәләс, сеп кабиләләре турында сүз алып барыла. Башта алар һуннар, Төрки каганатлары составындагы далаларда күченеп йөргәннәр, соңрак кыпчаклар биләгән территориядә искә алыналар. «Безнең эрага кадәр III гасырда тәләсләр Ордостан конбатышка таба далада яшиләр... IY гасыр ахырында төньякка күченәләр», «алар кыюлар, ирекне яраталар, буйсынып яшәргә теләмиләр», дип язып калдырган тәләсләр турында XIX гасырның бөек шәрыкчысы Н.Я.Бичурин (1777-1853). (33, 141 б).

Шуннан чыгып, без әйтә алабыз: бүгенге Уинск районындагы Тәләс елгалары һәм авыллары, бу район гәзитендә язылганча, «тал асты» дигән мәгънәне түгел, ә кабилә-ыруг атамасын белдерә. Һәм без XYII-XYIII гасырлар чигендә барлыкка килгән Сеп, Тәләс авылларына еракны бабалары шушы кабиләләрдән булган кешеләр нигез салган, дип әйтә алабыз.

Болгарлар безнең өлкә территориясендә Алтын Урда чорында, аеруча Аксак Тимер яуларыннан соң күренә башлаганнар. Бу чорда алар Каманың иң югаргы агымына кадәр күтәрелгәннәр, кайбер Чудь шәһәрләренә дә хуҗа булганнар (1). Роданов тибындагы истәлекле урыннарда төрле болгар әйберләре: балчык һәм металл савыт-саба, көмеш әйберләр табылган (34). 179 урында табылган материалларга (савыт- саба, җир эшкәрту һәм сугыш коралларына) махсус тикшеру үткәреп һәм башка язма чыганакларга (фольклор һәм лингвистик материалларга) да таянып, Пермь галиме А.М.Белавин безнең өчен бик тә кызыклы хезмәт язды (35). Анюшкар шәһәрлегендә табылган археологик истәлекләрдә болгар керамикасы 5, Кудымкарда 15, Рождественскида 35, Абрамовода 50 процент тәшкил итә, дип яза автор. Соңгысында казып чыгарылган объектлар арасында ике яруслы чүлмәк яндыру мичләре, ерак түгел болгар зираты, бары тик болгар кызлары гына тага торган чулпылар, һөнәрчелек инструментлары, җир эшкәрту кораллары да булу болгарларның бирегә даими яшәүләрен күрсәтүче факт. Болгар керамикасы табылган иң ераккы нокта итеп автор Гайны авылы янындагы Гәйнә шәһәрлеген күрсәтә. Болгар әйберләре Сылва бассейнында дүрт урында, аерым алганда Бартым тирәсендә дә табылганнар.

Болгар сәүдәгәрләре төньякта яшәгән Ару, Вису, Йура, Чулман кабиләләре белән сәүдә иткәннәр һәм бу сәүдәне кулларыннан ычкындырмау, тоз, җиз, тире чыганаклары булган Вису-Чулман иленә чит ил сәүдәгәрләрен кертмәү, керә калсалар, аларны юк итү чараларын да күргәннәр. (35.3-15 бб).

Болгарларның эзен без Кама буе топонимикасында һәм этнонимында ачык күрәбез. Пермь районында Болгар авылы, Башкортстанның чиктәш районнарында берничә Болгар авылы, кайбер башка авылларның, мәсәлән, Очер районындагы Черти авылы кешеләренең әле бүген дә үзләрен «без болгарлар» дип санавы, Барда кешеләрендә «без Болгар башкортлары, Гәйнә култасыннан» кебек язулы иске китап-дәфтәрләр саклануы - болар барысы да Боек Идел Болгары чорында безнең якның шушы дәүләткә мөнәсәбәтле, аның составында булуын раслаучы фактлар.

Йәнә бер кызыклы һәм гыйбрәтле факт. Орда районы үзәгендә бик тә сыйфатлы кирпечтән салынган зур чиркәү бар. Клуб ролен үтәгән елларда берничә тапкыр аның манарасына шартлаткыч салып, җимерергә дә маташып карадылар - булдыра алмадылар. Район музеенда язылганга һәм экскурсовод сөйләве буенча, Орда чиркәве башта агачтан булган икән, 1640 елда аны Дунай буеннан килгән болгарлар салган. Игътибар итегез: 1640 елда һәм болгарлар тарафыннан! Салам-кабык түбәле, мичсез 27 йорттан торган авыл, ачтан үлмәс өчен печтекәй (наратбаш үләне) җыеп, шуны онга әверелдереп, күмәч пешереп җан асраган кешеләр шул кадәр җирдән төзүчеләр чакыртып, чиркәү салдыру турында уйлый диме? Икенчедән, Ордага руслар 1648 елда, ягъни гыйбадәт кылу бинасы төзелеп 8 ел үткәч килгәннәр. Бу беренчеләрнең каян килгәнлекләре, исем-фамилияләре дә билгеле, «алар күп еллар бу җирләрнең әүвәлге хуҗалары белән авыр сугышлар алып барганнар», «башкорт феодаллары һөҗүменнән

саклау өчен анда Чердыньнан гарнизон җибәрелгән» (36). Бу юлларның дөреслеге (алда күрербез) Кече Башан авылы турындагы риваятьләр белән дә раслана. «Бер кадак куллланмыйча болгарлар төзегән чиркәү», шулай итеп, чиркәү түгел, ә колонизаторлар басып алган авылның мәчете булып чыга.

Колонизация чорында болгар-татарны ил- йортыннан куып чыгарып, мәчетләрен чиркәү итү, әзер йортларга кереп урнашу ул чакта руслар өчен законлы чара итеп каралган. Басып алынган җирләрдә хокүмәт алардан өч ел налог та түләтмәгән.

Болгарлар төньякка бер юл белән - Кама һәм аның кушылдыклары буйлап күтәрелгәннәр. Башкортлар исә безнең якка ике юл белән килгәннәр: Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан (башкорт галиме Р.Г.Кузеев термины буенча «Борынгы Башкортстан»нан) Агыйдел-Караидел елгалары аралыгыннан Таныи, Бүә буйларына, Урта Кама һәм Тол буена һәм Урал таулары артыннан Караиделнең үрге агымы буйлап Ирән һәм Тол елгалары башына килеп чыкканнар һәм Тол, Тол-Тор елгалары буенда ике агым бергә очрашкан (37. 279 б). Р.Г.Кузеевның язуына карагапда, башкортлар төньякка вак төркемнәр булып күченгәннәр, шуңар аларны аерым авыллларда үзгә этнос буларак аерып күзәтеп тә булмый.

XYII гасыр ахырларына кадәр Гәйнә илендә башкорт дип аталган төркемнәр очрамый. Безнең як кешеләре турында беренче сүзне әйтүче рус миссионерлары монах Епифаний (1396), коми-пермякларны чукындырырга җибәрелгән Стефан Пермский, Трифон Вятскийлар аларны гәйнәлеләр. остяклар, басурманнар. агаряннар дип атыйлар.

Урта Урал, Гәйнә иле төркиләрен башкорт дип атау XYII йөз ахырында - XYIII йөз башында, ягъни рус колониаль хакимияте аякка басып, җирле халыкларны исәпкә алулар белән бергә башлана. Сәбәбе билгеле, «үз иреге белән» Русиягә кушылган башкортларга патша хокүмәте баштагы чорларда гына булса да үзләренчә яшәү мөмкинлеге бирә, Казан, Нугай ханнары биргән ярлык-грамоталарны үз кочендә калдыра, эчкё эшләренә бик кысылмый. «Урыс дәүләтенә буйсындырылган бер генә төбәктә дә мондый иркенлек юк» (38). Русиягә кушылганнан соң ике гасыр халык санын алуларның булмый торуыннан файдаланып, Идел буеннан, Казан һәм Минзәлә якларыннан куылып яисә үз иреге белән күченеп килгән бар халык башкорт булып языларга тырышкан. Моны башкорт галиме У.Х.Рахматуллин да билгеләп үтә: «Уфа өязенең көнбатыш һәм төньяк өлешләрендә яшәүче чуашлар, татарлар һәм марилар XYII гасырда башкорт дип аталып йөртелә башлыйлар. ... Билгеле бер чорда, бигрәк тә XYI гасырның икенче яртысында һәм XYII гасырда башкорт сүзе административ термин буларак һәм сословие атамасы буларак кулланылган» (39).Башкортка күчкән типтәр һәм мишәрләрне «яңа башкортлар» дип атап йөрткәннәр. Болары турында хакимият органнары төзегән, патшага рапорт итеп җибәргән язмаларда укырга мөмкин.

Минем карашымча Гәйнә илендә башкорт этносыннан булган чын башкортлар сан ягыннан бик аз булганнар, алары да безнең якларга күченеп килгәнче үк инде татарлашып беткән булганнар (Кара: Р.Г.Кузеев. «Про-

исхождение башкирского народа». М., 1974). Хәер, моны Таңыптагы башкорт зиратына җирләүләрнең безнең гасыр башында тукталып калуы, зиратның ташландыкка әверелә язуында да күрергә мөмкин.

Иң борынгы заманнардан алып рус колонизациясенә кадәрге чорларга күзәтү ясап, А.А.Берс шундый нәтиҗә ясый.

«Төрле вакытта Уралга төрле халыклар үтеп кергән. Урал Көнчыгыш һәм Көнбатыш йогынтысының үзара бәйләнешкә кергән урыны», «фин-угорлар, самоедлар, грек һәм гарәпләр, һинд һәм кытайлар, болгарлар һәм башкортлар, фарсы, гот, скиф, сармат һәм бүтән төр төркиләр очрашкан, ахырда, Болгар һәм Казан ханлыкларын тар-мар иткәннән соң, урыслар килгәннәр. Урал территориясендә бик күп борынгы культуралар бәйләнешенең тәртибен өйрәнергә мөмкин», бирелә «иске дөнья хăлыклары тарихыннан аңлаешсыз байтак мәсьәләләрне хәл итү өчен бик тә кыйммәтле материаллар табарга мөмкин... Борынгы Уралның серләрен аңлау өчен ачкычны Себер һәм Кара диңгезнең төньяк ярларыннан тыш Кытай, Персия (Иран) һәм Урта Азиядән эзләргә кирәк» (40).

Көньяк далаларыннан аермалы буларак, Урта Урал-Кама аралыгы зур юллардан читтәрәк торган, аның аша меңәрләгән башлы табыннар белән көченеп йөреп булмаган. Дулкын-дулкын булып Азиядән Европага агылган кабилә-урдалардан аерылып, аларның әле берсе, әле икенчесе Кама-Чулман буена, андагы урманлы далаларга үтеп кергән, шунда үз урдаларын булдырган.

Төркиләрнең Урта Уралны үзләштерүләре безнең эрага кадәр үк башланып, һуннар чорында нык көчәйгән. Алтын Урда чорында, Болгар һәм Казан ханлыклары тар-мар ителгәч, бу процесс массовый төс алган. Гәйнә иленең барлыкка килүе, кичәге күчмәннәрнең бергә килеп утрак тормышка күчүе, авыллар булып утыруы әнә шушы соңгы чорга туры килә. Рус миссионеры изге Стефан Пермский (XIY гасыр ахыры) аларны гайнане, остяки, басурмане, агаране дип атый. Ул заманнарда безнең як төркиләрен руслар шулай атап йөрткәннәр.Без инде Гәйнә исеме алган ил халкының элегрәк чорларда төрле исемнәр белән аталып йөртелүен, алар арасында һуннарның, алан, савир, таз, иске ил, тиссагет, мадьяр-мишәрләрнең,татар исеме йөрткән кабилә вәкилләренең дә булуын беләбез.

Алар янына урта гасырларда зур-зур төркемнәр булып болгар, кыпчак, нугайлар, вак төркемнәрдә этник башкортлар килеп урнашкан.

Гәйнә иле Русиягә кушылгач, халкының бер өлеше (аеруча Пермь, Күңгер якларындагылары) ясаклы татарлар дип, Уфа провинциясе-губернасында калган кечерәйтелгән Гәйнә олысындагылар күбесенчә башкортлар дип атала башлаганнар. Кайчандыр дистәләгән исем белән аталып йөртелгән ыруг-кабиләләр вәкилләре ике мең елдан соң, шулай итеп,·ике генә исемне саклаганнар. Перепись вакытларында берәүләр башкорт булып, икенчеләр татар булып языла. Хәтта бер үк гаиләдә ике төрле язылып йөрүчеләр бар. Ләкин кем ничек язылуга карамастан, аларның барысын да «пермь татарлары» дип йөртәләр.

## Кулланган әдәбият:


1. Бадер О.Н., Оборин В.А. На заре истории Прикамья. Пермь, 1958.

2. История Урала. Том I. Пермь, 1963.

3. И.П.Магидович. Очерки по истории географических открытий. Том I. М., 1949.

4. Л.Успенский, К.Шнейдер. За семью печатями. М., «Мол.гвардия», 1963 г.

5. В.А.Оборин. Свидетели глубокой старины. Звезда, 1976, 29 сентябрь.

6. Пермь өлкәсенең археологик исталекләр исемлеге. Пермь, 1986.

7. Пермь өлкәсенең тарих һәм мәдәни исталекләре. Пермь, 1971.

8. А.В.Збруева. История населения Прикамья в ананьинскую эпоху. («Материалы и исследования по археологии Урала и Приуралья». Том 5. М., 1952 г.)

9. В.Ф.Генин. Узловые проблемы. («Археология и этнография Башкирии». Том 5. Уфа, 1971).

10. А.Х.Халиков. Истоки формирования тюркоязычных народов Поволжья и Приуралья. («Археология и этнография Татарии». Вып. 1. Казань, 1971).

11. А.Х.Халиков. Исторические корни общности татар-мишарей и казанских татар. «Tatarika.. Хельсинки, 1987.

12. Л.Н.Гумилев. Тысячелетие вокруг Каспия. Баку, 1991.

13. Ә.Г.Мөхәммадиев. Антик чорга караган төрки алифбасына нигезләнгән язмалар. - Татарстан хәбәрләре, 1993 ел, 11 декабрь.

14. М.Закиев. Күршеләребездән гыйбрәт ал. Соц.Татарстан, 1990 ел, 30 сентябрь.

15. В.Ф.Генинг. К вопросу об этническом составе населения Башкирии в I тысячелетии. «Археология и этнография Башкирии» - АЭБ, том II. стр. 111-129; том IY. стр.332-346.

16. В.А.Оборин. О связях племен Верхнего и Среднего Прикамья с племенами Башкирии в эпоху железа. АЭБ. Том II. стр. 130- 135.

17. А.Х.Халиков. Общие процессы в этногенезе башкир и татар Поволжья И Приуралья. АЭБ, том IY.

18. Р.Г.Кузеев. Урало-Аральские этнические связи в конце I тысячелетия нашей эры и истории формирования башкирской народности. АЭБ, том IY. 1971. Краткий очерк этнической истории башкирского народа. АЭБ, том Y.

19. П.Д.Степанов. Памятники мадьярских (венгерских) племен в среднем Поволжье. АЭБ, том II.

20. М.З.Закиев. Мишәрләр һәм мадьярлар турында. «Tatarika», Хельсинки, 1987.

21. А.Х.Халиков. Татар-мишәр һәм Казан татарлары уртаклыгының тарихи нигезләре. «Tatarika», Хельсинки, 1987.

22. Материалы по истории БАССР. Том 3, М. -Л. 1949.

23. Археология и этнография Башкирии. Том III. М. -Л. 1949.

24. «Советское Прикамье», 1962, N 120.

25. А.Х.Халиков. Беренче дәүләт. Казан, 1991.

26. Ибн-Фадланның Итиль елгасына сәяхәте һәм Болгарда Исламны кабул итү. «Дастан» - «Мифи-сервис» нәшриятләре, 1992.

27. Евгений Казаков,- Паскатирлар иле. Татарстан журналы, 1993, N 9.

28. Д.М.Сарманаева. Урта Урал татарлары теленең диалекталь үзенчәлекләре. Кандидатлык диссертациясе. Казан, 1950.

29. Д.Б.Рамазанова. Пермь татарлары сөйләшенең формалашу тарихына карата. В кн.: Пермские татары. Казань, 1983.

30. М.З.Зәкиев. Болгар патшасы ни өчен Сәкалибә патшасы дип аталган? - Мирас, 1994, N 5-6.

31. Д.М.Исхаков. Пермь татарлары. - Казан утлары, 1991, N 8.

32. В.Шишонко. Пермкая летопись. 1-й период. Пермь, 1881.

33. Л.Гумилев. Древние тюрки. М. 1967, 1993.

34. А.А.Спицин. Вещественные памятники древнейших обитателей Вятского края. Вятка, 1889.

35. А.М.Белавин. Волжская Болгария и Пермское Прикамье в X-XIII веках. Автореферат канд. диссертации. Ленинград, 1991.

36. История села Орда. Дипломная работа Л.А.Друзиной. ПГУ, 1979.

37. Р.Г.Кузеев. Развитие хозяйства башкир в X-XIY вв. АЭБ, том III˄ 1968.

38. Д.Б.Рамазанова. Ык ага чик сызыгы булып. - Идел, 1993, N 9.

39. У.Х.Рахматуллин. Крестьянское заселение Башкирии в XYII в. В кн.: Крестьянство и крестьянское движение в Башкирии в XII-нач XX вв. Уфа, 1981.

40. А.А.Берс. Прошлое Урала. М., 1930.

# II. Халыкның хәтер сандыгыннан

Кадерле укучым, хәзер инде безгә аерым авыллар, төбәкләр тарихына да күчәргә ярый торгандыр.

Дөрес, борынгы авылларның төгәл кайчан барлыкка килүен ачыклау өчен бездә архив материаллары юк дәрәҗәсендә, булганнары исә соңгы дүрт йөз еллык чорны гына чагылдыра. Аннан алдарак чорларда, Болгар ханлыгы, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында язылган документлар безгә килеп җитмәгән—алар яулап алу сугышлары вакытында юкка чыкканнар. Безнең халыкка 1552 елда Явыз Иван гаскәрләре Казанны алганда аеруча зур зыян китерелгән: Казан ханлыгының бай китапханәсе һәм архивы юк ителгән. Шуңа күрә безгә күбесенчә халык хәтеренә, риваятьләргә мөрәҗәгать итәргә туры киләчәк.

1980 елда Уфада «Башкорт халык иҗаты. Риваятьләр, легендалар», 1983 елда Казанда «Пермские татары» дигән китап, 1987 елда «Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар» басылып чыкты. Аларда борынгы Гәйнә илен тәшкил иткән территориядә язып алынган байтак риваять, легенда, шәҗәрә тупланган. Алардан иң киң таралганы, бу китапларның өчесендә дә китерелгәне—«Гәйнә» риваяте. Бу риваятьнең төп эчтәлеге шуннан гыйбарәт:

Болгардан ике бертуган Ирменшаһ белән Гайнетдин Кама буйлап Тол тамагына кадәр киләләр. Ирменшаһ Толның урта агымында тукталып, «Ирем»гә—Әрәмәавылга нигез сала. Гайнетдин ары китә. Берзаман Ирменшаһ аккан суда йомычкалар күреп, үрдә дә кешеләр яши икән дип, шуларны күрергә китә. Һәм шунда энесен таный—бусы Таныл авылына ишарә. Энесендә кунак булып, Ирменшаһ үз авылына кайта. Ул балык тотып, сунарчылык итеп яши. Берзаман давыл чыгып, дулкын köймәсен каплый, Ирменшаһ батып үлә. Хатыны: «Мине ирсез иттең, тол калдырдың, инде үзеңнең дә исемең Тол булсын», дип каргана. (1. 161-162.; 2. 175). Һәм шуннан соң моңа кадәр Җеренҗе дип йөртелгән елга Тол исеме ала.

Гайнетдин берзаман, үзе аткан җәнлекләрнең тиресен җыеп, Күңгергә барып чыга. Һәм анда бу җирләрнең Чардынга буйсынуын белеп кайта. Кайта да, бүләккә бер күтәрәм чыра алып, ук белән җәяләрен тагып, шунда китә. Чардын падишаһы аның осталыгын тикшереп карарга булып, «кырык сажин җирдән балдак эченнән угыңны чыгара алсаң, үзең торган җирдәге урманнарны сиңа бушка бирәчәкмен», ди. Гайнетдин угын балдак эченнән чыгара, һәм Чардын падишаһы әйтә:

—Шушы Тол суына нинди сулар төшәләр, шул суларның башларыннан барлык урман һәм җирләр сиңа ихтыяр булыр, бүлгесез, дип, зимләмирләр җибәреп, үлчәп бирәләр. Шуны «Гайнский участок» дип, ә бу җирнең үзен Гәйнә дип атаганнар (1. 162-163).

Байавылда Аптуков Мортазадан (1894-1975) язып алынган риваять шулай сөйли (Җәя эчендә шунысын да искәртеп үтик: Мортаза бабайның әние Тукайның бабасы Зиннәтулла Әмиров белән бер нәселдән).


Пермь (с 1482 к вел. кн. Московскому)
„Вятская земля“
(с 1489 в составе в. княж. Московского)
Земля Строгановых (с 1558 г.)
Чусовские городки 1568
Оса (Новоникольская д. 1557)
Иренско-Сылвинские „остяки“ (вогуличи) и татары
Сарапул
Северо-зап. башкирские племена
Бельские племена
Восточные башкирские племена
Уфа 1574
Турагтау
Бирск
Казанское ханство
Удмурты
Сибирское ханство
Ногайская орда
„Большие ногаи“
Урал-Тау
Обозначения
Приблизительные границы Русского государства в середине XVI века
Области, находившиеся в первой половине XVI века в зависимости
от Ногайской орды
„ Сибирского ханства
„ Казанского ханства
Этапы вхождения башкирских племен в состав Русского государства:
I 1552–1553 гг.
II 1554 г.
III конец 1555 - нач. 1556 гг.
IV 1556 - начало 1557 гг.
V конец XVI - нач. XVII вв.
Примерные очертания Уфинского уезда в XVII веке

Ирменшаһ белән Гайнетдин турындагы легенданың берничә варианты бар. Бер төрләрендә ике бертуган Тол буена Болгар иленнән Чулман (Кама) буйлап киләләр, икенчеләрендә күктән төшәләр, карлы яклардан боланга атланып килеп чыгалар (Гәйнә белән Әйнә). Болан кинәт туктап кала, тоякларын кага. Шунда Гәйнә белән Әйнә усал хуҗабикә Тулава (тул—ут, ава—хуҗабикә) яшереп саклаган утны күрәләр. Утны азат итү өчен көрәш башлана. Туганнарның берсе, Әйнә, үлә, ә Гәйнә җир астында яшереп тотылган утны азат итә, болан тиресеннән тегелгән капчыкка салып, аны Толның көньяк ярына алып чыга, шунда үз җәйләвен булдыра һәм Гәйнә ыруын башлап җибәрә (3,4).

Бу риваятьнең «Татар халык иҗаты»нда басылганы «Бохарадан өч туган семьялары белән килгәннәр Казан шәһәренә. Аннан бер туганнары Казанда калган», дип башлана. Төп эчтәлеге—югарыда китерелгәнчә (2. 175-176 бб).

Куян (Коянова) һәм Култай авыллары халкы исеменнән 1794 елда язылган бер документта шундый риваять китерелә:

«XIII йөздә бабалары Азиядән килеп Идел һәм Кама янында утырганнар, аннан соң Чусовой елгасы тирәсендә яшәүчеләрне буйсындырып, үзләренең күчеп йөрү төбәген Камага коючы елгалар буена җәелдергәннәр... Алар кыпчак һәм Казан патшаларына буйсынганнар, ләкин үзләренең йортларында (аерым биләмә, төбәк мәгънәсендә; рус чыганакларында юрт дип бирелә) үз биләре булган. Иван Грозный Казанны буйсындырган вакытта Мулла елгасы тамагында яшәгән Мулла татарларының биләре Урак-би Мәмәткулов булган, ә Түбән Муллада яшәүчеләрдә би булып аның энесе Сөендек үз кешеләре белән яшәгән, аларның аталары Мәмәткол имам (яисә мулла) булып торган. Русларның көчен күреп, аларга буйсынганнар. Моның өчен алар һәр кешедән 1 сусар тиресе түләргә тиеш булганнар. Тулвалылар белән бергә соңга таба (1700 елга кадәр) 276 шар сусар тиресе бирергә тиеш булганнар, 1700 елдан акчалата түләгәннәр».

Бу риваять күп төрле чыганакларда, шул исәптән «Труды Пермской ученой архивной комиссии-ПУАК» дигән китапта (Пермь, 1893) басылган. XIX йөздә ул Риза Фәхретдин кулы белән күчерелгән. 1986 елда Уфада рус телендә чыккан «Башкортстан тарихы һәм мәдәнияте чыганаклары» дигән китапта басылган. Биредә Д.Исхаков тәрҗемәсендә «Казан утлары» журналында басылган «Пермь татарлары» дигән хезмәтеннән алып бирелә.

Шунда ук Уинск районының Иштирәк авылында табылган бер кулъязмадан күчереп алынган шәҗәрә дә китерелә:

«Җан-Егет атасы Бөйорган, Бөйорган атасы Хуҗаш, Хуҗаш атасы Хуҗа Шәех, Хуҗа Шәех атасы Нур Собу, Нур Собу атасы Дәүләт Бирде, Дәүләт Бирде атасы Сайын Хуҗа, Сайын Хуҗа атасы Буйын Хуҗа, Буйын Хуҗа атасы Байсары би, Бүрежан би, Күкбүре би—бу өч агалы-энеле Нугайдан чыкканнардыр. Әүвәл падиша хәзрәтләренә баш салган Хуҗаш бидер».

Бу шәҗәрәне Саз (Йанапай) авылында укыган бер шәкерт күчереп язган булган. Тел белгече Д.Б.Рамазанова язып алган риваятьләрдән күренгәнчә,

бу авылга Йанапай исемле кеше нигез салган. Йанапай—Ирән буена беренче булып килгән Карей Мемсяков дигән кешенең улы. Мемсяковның тагын өч улы булып, алар да үз исемнәрендә Бикбай, Иштирәк һәм Карьяу авылларына нигез салганнар (5. 172-173 бб).

Оса өязенең көньяк күршесе булган Бөре өязенең төньяк чигендә язып алынган шәҗәрәдә Кара җау исеме бар. Үзеннән-үзе сорау туа: Бу Кара җау һәм безнең Искәвылның икенче атамасы булган Карьяу бер үк кеше түгел микән? Риза Ишморатның әнисе ягыннан булган бу шәҗәрәнең башында Боркет би тора, ә Боркет би нәселе «Кара диңгез буеннан, Кырымнан», кый кушып сөйләшүче нугай-кыпчаклардан. Бөркет бинең улы Татагай би дә «Кырымнан килеп, Агыйдел буйлап күчеп килгән» (шунда ук, 175-176 бб).

Карьяу-Карҗау исеме белән аталган Карьево авылы һәм четвертендә 1623-1625 елларда Михаил Кайсаров 67 остяк һәм татар юртасын һәм аларда яшәгән 81 остяк һәм татарны, 4 чирмеш һәм мордва юртасында 4 чирмеш һәм мордваны исәпкә алган. Аларның вотчиналарын Камгур елгасының башыннан алып ике яклап Ирән елгасына кадәр ун чакрым, шушы елга тамагыннан түбәнгә таба Ирән буйлап һәм дә башыннан Ирәнгә кадәр Тол суы, ике яклап, 20 чакрымга, һәм дә башыннан Ирәнгә кадәр ике яклап Башан елгасы, 10 чакрымга җәелгән (6.127 б).

Бу елларда бу тирәдә бер рус авылы да булмаган. Соңрак ясаклы Сылва татарлары Иметбай, Канзабай (бу исемне краеведлар Кинзәбай, Кызылбай дип язалар) һәм Тимербай Левкас уллары һәм яңа чукынган татар Анашк Калмыков Кишерть авылын һәм шул тирә җирләрне Соликамск кешесе Федор Елисеевка саткач, бу яктагы байтак җирләр, шул исәптән Барда елгасы бассейнының яртысы русларга күчкән (шунда ук, 288-297 бб).

М.Кайсаров калдырган «Күңгер писцовый кенәгәләре» буенча XYII йөз башында Ирән буенда Байса Акбашев, Урмамәт һәм Батыр Тайсиннар, Байсарый Тарасов, аның уллары Акназар, Яппар, Кайназар Баюргановлар, Карьяу олысында Тойгильде, Тоголче Терегуловлар, алар белән бер йортта чирмеш Акбайтал Биктимеров, Ишдәүләт, Янбай Карьяу уллары, Тәләс елгасы буенда Акильдеев уллары, Солил елгасының үрге агымында остяклар Якшәит һәм Тогабердей Кулышевлар, Кильделей-Кулышев, Кичкенәшай Колычбаевлар яшәгәнлеге билгеле (7).

Карьяу авылына нигез салган Карьяу Мемсяков 1612 елда бик карт кеше булган, дүрт улының берсендә, Янбайда яшәгән (8).

1579 елда язмачы И.И.Яхонтов, 1623-1624 елларда Михаил Кайсаров язып калдырган Писцовый кенәгәләрдән һәм 1679 елгы салым җыю кенәгәләреннән без шулай ук Ирән, Бөрмә, Бабка, Шауба, Сөлил бассейннарында, ягъни Гәйнә иленең көнчыгыш тарафында, татар, остяк, чирмеш, чуаш кауемнәреннән булган кешеләр яшәгәнлеген һәм аларның түбәндәге авыллары булганлыгын беләбез:

Солил һәм Ирән буендагы 4 четвертьтә (олыста) М.Кайсаров тарафыннан 72 йортта 86 ир-ат, Күңгер воеводасы Семен Толстов тарафыннан 340 йортта 879 кеше, шул исәптән Карьяу четвертенең 9 авылында (Байчын, Тор, Иске (Зур) Карьяу, Яңа (Кече) Карьяу, Шалканды, Зур һәм Кече

Башап авылларында, Казай, Янечтә) 83 йортта 241 кеше, Ирәнбаш четвертендә 17 авылда (Иске һәм Яңа Тәләс, Медянка, Иске Курамыш (Кормакаш?), Үрге Сарс, Крым- Сарай, Исәнбай, Югары Төш, Корманак һ.б.)—107 йортта 296 кеше (218 татар, 65 мари, 11 чуаш), Шауба четвертендә 62 йортта 189, Үрге Сөлилдә 15 авылда 339 кеше исәпкә алынган. Писец-язмачылар захребетниклар һәм подсоседниклар дип атаган йортсызларны да кертеп, 4 четвертьтә салым түләрдәй 1133 ир-ат (785 татар, 311 мари, 15 удмурт, 20 чуаш) исәпкә алына (6,7).

Искәвыл (Карьяу) авылыннан өч кенә чакрымда шул ук Ирән буенда Тор елгасы тамагында Тор (Усть-Турка) авылы урнашкан. Аңа нигез салучылар арасында «ясаклы Сылва татарлары Иметбай, Канзибай һәм Тимербай Левкас уллары» һәм «ар Актырнак» исемнәре атала. (9).

«Ар Актырнак» дигән сүзне туган як буенча белгеч Мәгъсүм Хәбибуллин (1898-1991) «ул мадьяр-мажарлар» дип аңлата. (Мәгъсүм ага күп еллар колхоз рәисе булып эшләде, авыллар тарихы буенча байтак нәрсә белә иде).

Гомумән рус язмачылары һәм аларга таянып зур хезмәтләр язган тарихчылар, шул исәптән А.Дмитриев та, Ирән, Сөлил буенда яшәгән халыкларның нинди ыруг-кабиләдән булганлыкларын белеп бетермәгәннәр. Моны күп краеведлар да билгеләп үтәләр. Орда краеведы Ф.Пшеничников, мәсәлән, туп-туры ярып сала: «Руслар үзләре басып алган халыкларның нинди кабиләләрдән торганлыгын начар белгәннәр»,—ди Орда район гәзите «Верный путь»та басылган һәм югарыда күрсәтелгән бер мәкаләсендә.

Куылып, кыйналып йөртелү ягыннан Орда районындагы Кече Башап авылының тарихы бик гыйбрәтле. Авыл картларының сөйләве буенча бу авылга нигез салучыларның еракы бабалары Ирән буйлап көньяктан килгәннәр. Кешеләр күбәеп, күченеп йөрү өчен җирләр тарая башлагач, акрынлап алар утрак тормышка күчкәннәр. XYII йөз урталарында, ягъни безнең якларны Русиягә куша башлаганда, алар Орда тирәсендә ярымкүчмә тормыш алып барганнар.1648 елда Ирән елгасыннан ике чакрымда Камгур елгасы буенда Күңгер кәлгәсе төзелә башлагач аларны аннан куганнар. Берникадәр вакыт (1648-1660 елларда) алар Яссы тауда, бүгенге Ясыл авылы урынында торып алганнар. Бу авылның атамасы «асыл таштан», төрки исем Асылдан дип әйтүчеләр бар. 1623-1624 елларда М.Кайсаров үткәргән перепись буенча Ирән буйлары, күреп үттек, башыннан ахырына кадәр татар, остякларның биләмәләре дип рәсмиләштерелгән. Шуңа карамастан, XYII йөзнең алтмышынчы еллардагы Ясыл елгасы буе (Ирәннең уң кушылдыгы) «буш яткан» җирләр дип бәяләнә һәм Тиханов авылы крестьяннары Васька Зайков белән Дьяк Шеломовларга биләмә итеп бирелә. Биш-алты ел эчендә бирелә берничә рус авылы үсеп чыга (10). 1667 елда Ясылда агач чиркәү (!) салына һәм авыл Покрово-Ясыл исеме белән йөртелә башлый. (11).

Покрово-Ясыл авылының дистәдән артык кешеләре татар фамилияләрен йөртә. Аларны христиан динен кабул итеп, куылмыйча калганнар дип уйларга кирәк.

Шушы вакыйгалардан соң (әллә аңа кадәр үкме—бусын ачыклыйсы бар) безнең бабайлар, Ясыл елгасы тамагына күчерелгән авылларын да ташлап, Ирәнне кичәләр, Ашап елгасы ярына (бүгенге Ашап чиркәве урынына) барып утыралар.

Башап авылы турындагы риваятьнең бер вариантында Ясылдан алар Ашап елгасы тамагына якын Кулавыл дигән урынга күченәләр, дип әйтелә. Сүз Ясыл тамагына күченгәннәрдән аерылып киткәннәр турында бара булса кирәк. Һәрхәлдә Ашап елгасы бассейнында бу күченүдән соң ике Башап авылы (Зур һәм Кече Башап) барлыкка килә. Икесе дә Оса өязенең Орда станы Карьяу олысы составында йөри. Территориаль бүленеш һәм аталышы Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларындагыча калган, колонизаторлар яңасын эзләп баш ватып тормаганнар, халыктан җыясы салымны гына арттырганнар: Ирән буенда яшәүче тарханнардан җан башыннан элекке бер сусар тиресе урынына бишәрне түләттерә башлаганнар.

Орда краеведы Ф.П.Пшеничников Ашап елгасы буендагы җирләргә Ирән остяклары йөзбашы Яхшовит Кулешов хуҗа булган дип яза (12). М.Кайсаров язмалары буенча без бу кешене Якшәит дип беләбез. Аның белән бергә Тогабирде Якшәитов, Кильдели Кулышев, Кичкенаш Колычбаевлар искә алына, әмма авыллары күрсәтелми (7. 125 б).

XYII йөз ахырларында Ашап елгасы буена промышленник Демидовларның күзе төшә. 1703 елның 14 апрелендә Бөкре Никита Демидов «Күңгердә тимер заводы төзәргә яраклы урын эзләргә» рөхсәт сорап Петр I патшага хат яза. Рөхсәт озак көттерми, дүртенче көнендә үк алына. Ләкин Ирән буе татарларының гына түгел, ә рус крәстиәннәренең дә ризасызлыгына очрап, завод салу тоткарлана—ул 1745 елда гына төзелә.

Завод салу өчен Карьяу олысының байтак җирләре тартып алына. Демидовлар бу җирләр өчен нибары 121 сум акча түлиләр. Соңрак 386 сумга бөтен Ашап елгасы буен сатып алалар. Община белән төзелгән актклешү буенча Демидовлар җирле халыкны «теләсә нинди кыерсытулардан сакларга», ә җирле халыктан һәр кеше җәен 17 көн, кышын 21 көн заводка эшләргә—агач кисәргә, күмер яндырырга, бакыр рудасы чыгарырга һәм аны заводка ташырга тиеш була. Билгеләнгән норманы үтәмәүчеләргә карата завод хуҗалары үзләренчә чара күрәләр: эшләгән эшләре өчен түләмиләр, хуҗалыкларын туздыралар, үзләрен таяк белән кыйныйлар. Шундый җәбер-золымга түзә алмаган халык коралга тотынырга, Зур Башап кешеләре исә күченеп китәргә мәҗбүр булалар. Аларның бер өлеше Башап елгасы буена килеп, Кече Башап авылы булып утыра, калганнары Калдыгыс (Калдык оч, бу авыл перспективасызга саналып, алтмышынчы елларда бетерелгәнгә кадәр рәсми кәгазьләрдә Зур Башап дип йөртелде), Шалканды, Искәвыл (Карьяу) авылларына таралалар (1. 158 б).

Шулай итеп, йөз елга якын вакыт эчендә (1648 елдан 1745 елга кадәр) Башап кешеләре алты тапкыр күченергә мәҗбүр ителәләр. Буйсынмас башаплыларны аннан да кумакчы булып, завод хуҗалары отряд арты отряд җибәрәләр, ләкин авыл батырлары аларны Аткары таптаудан ары җибәрмиләр: Сырт өстән атып куалар. Соңгы килүләрендә ике карагай

арасына тартылган җәядән атып ат өстеннән атаманнарын җиргә мәтәлдерәләр. Авылга һөҗүм итүләр шунда гына туктала. Бу хәлләрне мица кырыгынчы елларда Кече Башап авылында Шайнур бабай сөйләгән иде.

Кече Башап авылы баштагы чорда бер- берсеннән чабулыклар белән аерылган ике- өч йортлы берничә чуктан торган. Һәр зат үзенә бер чук булып утырган. Аю һәм бүре җәвере Урта һәм Аткары чукта, бүтәннәре Колакбаш, Кыек, Эчкәре чукларны, карга һәм чабак затлары—Сыртас чукны нигезләгән.

1679 елда Кече Башапта 8 йорт, 24 ир-ат, йөз елдан хуҗалыклар саны 28 гә, анда яшәүче дәүләт крәстиәннәре 85 кә җиткән. Бүгенге көндә Кече Башап авылы берүзе бер колхоз, 430 хуҗалыкта 1200 ләп кеше яши.

Тарихчы-галимнәрнең язуына караганда, Ирән-Солил буе татарлары XIII гасырда формалаша башлаганнар. Урта Урал Руссиягә кушылганда алар утрак тормышка күчү процессын кичергәннәр, аучылык, кортчылык, терлек асрау һәм игеп игү белән шөгыльләнгәннәр.

Пермь губернасы администрациясе «инородецларның килеп чыгышларын, кайдан башлануларын ачыклау өчен» 1789 елда халыктан сорау алу үткәргән. Пермь һәм Оса өязе татарлары һәм башкортлары куелган сорауга «Без тархан нәселеннән, биредә бик борынгы халык, Иван Васильевич Казанны басып алганнан соң Русиягә кушылганбыз, аңарчы үзебезнең Нугай ханнары кул астында яисә подданныйлыгында булганбыз», дип җавап биргәннәр (1. 6 б).

Тол буенда Таньп авылы иң борынгы авыллардан санала. Беренче булып анда Казан ягыннан чукындырудан качкан типтәр- татарлар килеп урнашкан. Алар арасында иң өлкәне Биккул бабай Кушкилдин булган. Ул чаңгыда берничә тапкыр Чардинга барган, барган саен бүләккә кыйммәтле җәнлек тиреләре алып барган. Соңгы баруында сәхтиянга (хайван тиресенә) язылган документ алып кайткан. Таньп типтәрләренә Ермия елгасының башыннан Толга кадәр, Ермия тамагыннан Каҗмакты (Барда) елгасына кадәр җирләр беркетелгән. Барда елгасы буена да типтәрләр хуҗа булган. Алар да Казан ягыннан күченеп килгән осталар (тегүчеләр, вак сәүдәгәрләр) булганнар. Аларны Бардабаш типтәрләр дип атаганнар. Егерменче елларда Бардабашта атаклы Ярулла тегүче яшәгән.

Таньпта Чурагулов, Чуракаев, Туйгилдин, Гомәров, Якупов, Яткулов, Илмакачев, Нурмохәммәтовлар нәселләре иште булган. Бер нәсел кешеләре бер тирәдәрәк урнашканнар. Шуннан типтәр җыен, мәчет җыен, тавык җыен дигән урамнар барлыкка килгән. Соңрак күченеп килгән башкортлар «башкорт җыены», арлар «ар җыен» булып утырганнар. Ар җыенда Батыркаевлар нәселе иң зуры булган, Урастимиров, Алешкиннар мари чыгышлы иде, дип яздырган «Пермские татары» дигән китапка кертелгән мәгълуматларны биргән Гарифулла ага Нурмохәммәтов. 1974 елда ул аларны Урастимиров Хисаметдин (1895-1981) белән Хәлилов Хәтми (1910-1991) агалардан язып алган. Алтмышынчы елларда Хисаметдин ага аларны миңа да әйтеп яздырган иде. Бу картлар исән чагында Таньпның типтәр, мәчет, тавык, ар, чирмеш һәм башкорт җыеннары

турында күпләр белә иде, үзләренең нәсел агачларын (шәҗәрәләрен) белүчеләр дә бар иде.

Таныпның күпторле кабилә вәкилләре тарафыннан нигезләнүен иске зиратлар да «әйтеп тора»: авылның Күчтәнти ягында Типтәр зираты, Сараш ягында—башкорт зираты, авылдан ерак түгел арлар, яисә «озыннар» зиратлары дигән урыннар бар. Дөрес, аларны хәзер урман баскан.

Үзе утырган елга исеме буенча авыл башта Ермия дип йөртелгән, соңрак Таныл атамасын алган. Бер-берсен алыштырган бу ике атаманың нигезендә кабилә исемнәре ята.

«Пермские татары» дигән китапка кушымта итеп бирелгән мәгълуматларда Таныл якынча моннан 300 еллар элек нигезләнгән, ул Тол буенда иң карт, элекке өяз үзәге Осадан да картрак авыл дип күрсәтелә. Юрми һәм Таныл кабиләләренең безнең якларга моннан күпкә иртәрәк күчеп килүләре билгеле. Дөрес, XIII-XIY гасырларда Бөгелмә- Бәләбәй калкулыгыннан кузгалып, аларның берсе башта Таныл елгасы буенда, икенчесе Ермия елгасына җитеп тукталган, Казан ханлыгы тар-мар ителеп, көчләп чукындырулар башлангач, әчкәрәк, урманга күченгән булырга мөмкин. Һәрхәлдә Оса каләсе төзелә башлаудан элек үк Тол буенда авыллар булган, шул исәптән Таныл урынында да авыл булган.Әлеге китапта Башап елгасы буендагы Ар Башап турында да сүз бар. Оса музеенда сакланган бер язмада 1470 елда бу авылда алты йорт булуы әйтелә. Димәк, бу авыл да Үдик, Әрҗән шикелле борынгы авыл.

XIII гасырга карый дип исәпләнгән һәм Сүҗде авылында Рәфхәт Бохаров (Барда) язып алган «Җиде газиз»дә (дөресе «Җиде газый». Бардада мәрхүмә Әминә Әмирова- Акманаева, Әнисә Булатова-Әмирова апалар һәм башкалар кадерләп саклаган «Изгеләр исемлеге»ндә алар шулай аталалар) Гәйнә кешеләренең үз җирләрен саклаулары турында сөйләнә. Шушы бурычны башкару өчен алар Толның биек ярына сакчылар куя торган булганнар. Солтанай авылы турысында Толның уң як ярында, биек тауда Солтан-газиз, Кызылъяр-Әрҗән турысында Хәсән-шәех, Таныл янындагы Ыйык тауда Солтан-Әхмәт, Толбашта Сәит-Сәлим, Сүҗде турысындагы Бүзат тауда Миңлемәгасүм, ярымтыклар авылы дип йөртелгән Тауавылда (яисә Бавыр тауда) Моратхуҗа; Җермиябашта Солтангали-газиз торган. Тоннәрен алар дошман килүен ут ягып белгерткәннәр. Берсе якса, аны икенчесе, өченчесе кабатлаган һәм шул рәвешле яман хәбәр барлык газыйларга җиткерелгән һәм алар аша барлык авылларга таратылган. Тауда ут күрүгә ир-ат кулына корал алырга, ат менәргә тиеш булган. Риваятьтә газыйларның үз илләрен кемнән саклаулары әйтелми. Шулай да без беләбез: Гәйнә иле Болгар дәүләтенең төньяк-көнчыгыш чигендә урнашкан, аның чиге шушы ханлыкның чиге булган. Димәк, безнең җиде газыйларыбыз бер Гәйнә тобәген генә түгел, ә бөтен Болгар ханлыгын саклаганнар.

Түбәнавыл кешеләре җиде газыйның берсе Толның биек ярында, Тугызак тауда җирләнгән дип исәплиләр, ә Осада яшәүче татарлар газыйларның җиденчесе Оса районындагы Тишководан ерак түгел Кама борылы-

шында сакта торган, бу урын изге санала, аннан үткәндә пароходлар гудок биреп үтә, дип сөйлиләр.

Тыныч заманнарда, якын-тирәдән ул-бу ишетелмәгәндә, мәсәлән, ураза вакытында, тауда ягылган учак сәхәр ашау вакыты җитүен белдергән. Бу очракта учакны беренче булып ягу хокукы Солтанай белән Сараш турысындагы тауда торган Солтангалибкә бирелгән. Шуңар иске китап тышларында теркәлеп калган җиде газыйның анда торганы беренче итеп күрсәтелә һәм аның урыны Сараш (ягъни «сары аш»—сәхәр ашы, сәхәргә тору вакытын белдерүче урын) дип йөртелә. Борынгы болгар этносының үзатамасын да, нигез телен дә саклап килгән балкар телендә «сары аш» әле бүген дә сәхәр ашы дигәнне белдерә.

Сүҗде атамасыннан гарәп, фарсы телләрен белүчеләр «әсәһи-с-сүҗиде» яки «әсәһе-с- сүҗиди» ярдәмендә «бишенче» дигән мәгънә китереп чыгаралар. Газый-сакчыларның теркәлү тәртибе буенча да Бүзат тауда торган Миңлемәгасум бишенче урында. Бер уңайдан шуны да искәртеп үтик: Барда белән Сүҗде арасында Бүзат дип йөртелгән авыл да булган. Елгасы җир астына китеп юкка чыккач, бу авыл кешеләре, нарат урманны кисеп, Каҗмакты елгасының түбәнге агымына күчеп утырганнар. Ә «юкка чыккан» елгасы Тол ярында көчле чишмә булып әле бүген дә ургып ята.

Сараштa, ягъни сәхәргә тору вакытын белдергән урында торган Солтангәзизне тәртип буенча беренчесе дидек. Удмурт галимнәре, борынгы пермь халыклары теленә нигезләнеп, Үдик атамасын да «бер» дигәнне аңлата диләр. Бу авылның икенче атамасы Елпачиханы шул ук телче-галимнәр төркиләшкән угры исеме «Ялпач»тан дип, исемнең үзе Уралга XIII-XY гасырларда Алтын Урда тарафыннан басып алынган Идел Болгарстаныннан килгән дип аңлаталар. Без моны YII гасырдан бирле гәйнәлеләр яшәгән Ык буеннан дип аңларга тиеш булабыз. В.Ян әсәрләрен укыган кеше белә булыр: Горгәнҗәнең икешәр йөз дөяләргә төялгән затлы товарлар белән Тәбриз, Багдат, Идел Болгарына кадәр йөреп сату итүче сәүдәгәренең һәм Чыңгыз ханның Хорезмдагы илчесенең дә исеме Мәхмүд Ялвач.

Күп исем-атамалар безнең якларга Идел буе болгарлары һәм башкортлар килгәнче үк әле Төрки каганлыгыннан яки аннан да элегрәк, һуннар хәрәкәте чорында (III-IY гасырларда) Коньяк Уралдан, Көнбатыш Себердән кысрыкланып күченгән төрки телле кыпчаклар, тиссагетлар һ.б. белән килгәннәр.

Гәйнәне алыштырган Барда атамасына килсәк, аның мәгънәсен рус галиме А.Матвеев балык исеме «бәрде» белән бәйләп аңлата. Нинди җиңел! Ирән гидронимын «әйрән»нән алганы кебек, аның бу аңлатмасын да җитдигә санап булмый. Гәйнә кебек, Барданың да эзе еракларга китә. Бу исемне йөрткән авыллар да байтак: Әзербайҗанда район үзәге, Урта Азиядә, Пермь өлкәсенең Кишерть районында шундый исемле авыл һәм елга. Караидел (Уфа) елгасы буенда Барда сырты бар. Элекке Дуван олысында Югары Бартым, ясаклы чирмешләр яшәгән Яңа һәм Түбән Бартым авыллары булган (9. 283 б).

Иске төрки телдә язылган китапларда «вә- әл-әрдә», вә-әл-әрди», «фи-әл-әрди» сүзләре очрый. Соңгысындагы «фи» кисәген «б»гә алыш-

тырсак (гарәп телендә шулай эшләнә), янә «Бәрде» килеп чыга. Ләкин бу «бәрде» балыкны түгел, ә хокүмәт яки җитәкче орган дигән мәгънәне бирә. Шуннан чыгып, без Барда (бүгенгесе генә түгел, ә археологик истәлеккә әверелгәннәрен дә кертеп) үзе тирәсендәге төбәк өчен мәркәз ролен үтәгән дип әйтә алабыз.

«Җиде газый» турындагы риваять безне Идел Болгарстанының чәчәк аткан чорына, ә бәлки аннан да ераккырак чорларга, Гәйнә тарихының чишмә башына илтеп чыгара кебек.

Барда район музеенда бүгенге Барда авылына 1740 елда нигез салынган дигән мәгълумат бар. Аз дигәндә йөз, йөз илле елга киметелгән (янсә Кишерть районындагы Бардага карый торган) сан бу. Барданың «яшен» билгеләү өчен аңа нигез салучыларны белергә кирәк. Халык телендә алар «унбер әхмәт» дип йөртеләләр. К.Маркс урамы элек Әхмәтләр урамы дип йөртелгән. Әлегә безгә бу данлыклы изгеләрнең тик берсенең исеме билгеле. Ул атаклы Гәйнә олысы старшинасы Туктамыш Ижбулатовның картатасы Байбулат. Бу исем миңа Габдулла Суяргулов сөйләп яздырган шәҗәрә-риваятьтән билгеле. Ләкин риваятьтә Байбулатның Бардага нигез салуы турында әйтелми. Бусын без башкорт галиме-язучысы Гайса Хөсәеновның 1995 елда чыгачак «Канлы илле биш» романыннан укырбыз. Бардага нигез салучыларның берсе Байбулат үзен «без Болгар иленнән, Камья аръягыннан», дип әйтә торган булган» (15).

Байбулат, югарыда телгә алынган Теребирде Алиев, Тукаебыз бабасы Зиннәтулла Әмировның картатасы Әмирхан баба һәм башка күпләр кебек, Казан ханлыгының үзәк төбәкләреннән, аның Идел, Кама, Иж сулары кебек зур су юлларында урнашкан шәһәр һәм авылларыннан Русия колонизаторлары тарафыннан куылган, чукындырудан качкан кешеләр. Байбулатның атаклы старшина, закон чыгару комиссиясендә депутат, рудачы-промышленник буларак бөтен Русиядә дан тоткан оныгы Туктамыш Ижбулатов 1720- 1780 елларда яшәгән дип исәпләсәк, Байбулат Тол буена XYII гасыр башында янсә урталарында килеп чыккан була. Шуннан чыгып, без Бардага ким дигәндә өч йөз ярым ел булырга тиеш, дип әйтә алабыз.

Хәер, Габдулла мулла (1877-1975) шәҗәрәсе белән танышкач, укучы үзе дә исәпләп чыгара ала. Менә ул, күп нәрсәләргә ачыклык кертә торган шәҗәрә: «Безнең нәсел Уралга Йәнәсәй якларыннан, Бату ханнан качып килеп чыккан. Башта алар байтак вакытлар урманнарда, кеше аягы басмаган җирләрдә качып яшәгәннәр. Аннан Себер тайгалары, Урал таулары аша чыгып, Ачар (Очер) заводы салыначак урынга килеп утырганнар. Руслар тарафыннан аннан да куылгач, Кама буйлап төшеп, Тол елгасы буенда тукталганнар. Миңа исеме билгеле Уракби бабай Тол буйлап

күтәрелеп, бүгенге Әрәмәавыл янындагы Күлбаш дигән җирдә йорт салган. Шуннан Ишәмәт авылы барлыкка килгән. Билгеле, Уракби бабай берүзе генә булмаган, ә берничә туганнар булганнар.

Уракбинең улы Камышби, Камышбинең улы Янгабышби, Янгабышбинең улы Байбулат, Байбулатның улы Ишбулат, Ишбулатның улы Туктамыш. Туктамыш Пугачау хәрәкәтендә катнашкан, хәрәкәт бастырылгач, аны кулга алганнар. Чабата табаныннан Пугачевның манифесты килеп чыккан. Шуңар аны Пугачев белән бергә Мәскәүгә алып киткәннәр һәм шунда җәзалаганнар—башын чабып өзгәннәр. Туктамыштан улы Әптрәй калган. Тулы исеме Габдрәхим буладыр, аннан Сәвәргол килә. Безнең фамилия әнә шушы бабабыздан киткән. Шул Сәвәрголның улы Әхмәтһади. Әхмәтһадиның улы булып мин туганмын.» (14)

Габдулла ага боларны әйтеп яздырганда туксанны узган, кайбер буыннар хәтереннән чыккан иде. Нәсел башы Уракбидән соң сигезенче буын булып дөньяга килгән Туктамыш Ижбулатов турында күп язылды (кара: 15. 256, 283, 295, 401-414 бб; 16. 304 б). Туктамыштан соң бишенче буын булып яшәгән һәм халык теленә «ваксу Нәпиш» булып кереп калган Габделнәфыйк озак еллар патша армиясендә хезмәт итеп, Бардага офицер киемендә кайтып төшә. Кешеләр кызыга, тел шартлата, ә Нәпиш үзе горурлана алмый, чөнки белә: мондый киемгә төренгәннәр, патша әмерен үтәп, нинди генә халыклар өстенә яу чапмый, кемнәрне генә кыерсытмый. Шуңар ул кайтып керү белән офицер киемен сала да, чормага менгезеп элә, һәм ул шунда чери.

Нәпиш (Габделнәфыйк)—Габдулла аганың картатасының атасы, исеме Барданың бүгенге картларына да билгеле атаклы Әхмәтһади хәзрәтнең бабасы.

Габдулла мулла шәҗәрәсенә охшаш тагын бер риваять бар. Бусын Үдиктә Сәлим Арзыев язып алган иде. Анда Батый ханнан качып килүчеләр Төркстан җиреннән төрки-башкорт кабиләләре дип күрсәтелә. Урал тау буйларында алар урманнарда хайван атып, суларда балык тотып ризыкланганнар, чолыкчылык белән шөгыльләнгәннәр. Күченә- күчөнә алар Ачар заводына җиткәннәр, авыл булып утырганнар. Камага төшеп, агым суда чүлмәк тотып алганнар, ул чүлмәктән үрдә руслар барын белгәннәр һәм Кама буйлап түбәнгә төшеп киткәннәр. Алты көн, алты төн барып, Толга килеп җиткәннәр, шунда яшәү өчен яраклы урын эзләгәннәр. Күлбаш дигән җирдә тукталып, янә балкорты карап, балык тотып, рипа (вак шалкан) чәчеп яши башлаганнар. Хайван тиресеннән кием теккәннәр.

Елгада йомычка күреп, үргә таба менеп китсәләр, ике авыл күреп кайтканнар—берсе Әрҗән, икенчесе Ар Башап икән.

Соңрак алар янына Әй, Дим буйларыннан башкортлар, Күңгер, Нократ (Вятка), Казан якларыннан татарлар килеп кушылган. Үдик, Бичура, Мостафа, Шәңгә, Тылай, Чидиш, Тоташлы, Кызылъяр (Оса ягындагы авыллар), Тауавыл, ике Каснавыл, (Түбәнге һәм Үрге), Куземьяр авыллары барлыкка килгән. Куземьярга Вятка ягыннан Байгилде исемле бик тә бай татар килгән, корты гына да мең умарта булып, һәркөн урманга барып, өч умарта күтәрә икән.

Узган гасырда Түбән карьясендә (Түбәнавылда) Гыймадетдин Хисаметдин улы Булатый-хаҗи (1834-1916) язып калдырган һәм бүгенге көндә аның оныгы Мөнирә Мохәммәткашшаф кызы Зимасовада сакланган риваятьтә «безнең иң әүвәлге бабаларыбыз—Җәрәзә, Зәбир, Мөнәвәрә—1300 нче еллар чамасында Сәмәрканд тарафыннан килгәннәр», диелә. Өч сәхәбә Болгар шәһәренә барганнар, исламны бәян иткәннәр. Болгар рәисе алардан дин- исламның хаклыгына бер хикмәт күрсәтүләрен үтенгән. Алар ханның күп еллар сырхау булып һичбер дәва табалмаган кызын мунчада каен яфрагы белән чабарга киңәш иткәннәр. Хан кызы шуннан шифа табып сәламәтләнгән.

Болгарлылар исламны хак дин дип кабул иткәннәр һәм иман китергәннәр, мөэмин вә мөселман булганнар. Безнең сәхәбәләр, Мәскәүгә барып, Тол суына нинди сулар төшсә, урманнарында нинди җанварлар вә шунда ни кадәр җан иясе бар, барчасына шуларны милек итеп, тереклек кыйлырга, дип падиша эт күненә язып, кулын мөһер итеп басып, падиша дүкәмит биргән».

Урыслар Казанны алгач, мөселманнарга Камага һәм дә Осага егерме биш чакрымнан да якын утыру тыелган. Бичура, Кызыльяр һ.б. авылларның кешеләрен урман эченә куганнар. Алар Озын Яланга, Әрҗәнгә күчеп утырганнар. Шул чордан Әрҗән авылы документларга ике исем белән (Краснояр- Кызыльяр һәм Әрҗән дип) кертелгән.

Үдик турында 1861 елда туган Нуртдин бабай Ибраһимов кырыгынчы елларда түбәндәгеләрне сөйләп калдырган (язма Үдик урта мәктәбе музеенда саклана): «Үдиктә элек дүрт төрле халык яшәгән. Авылның Бабылҗы дип аталган олешендә арлар, Тау башта чирмешләр. Гәйнәлеләр һәм типтәрләр белән бергә алар да мөселман динен кабул иткәннәр, бер телдә (татарча) сөйләшкәннәр. Безнең бабайлар «Без Ырымбур ягыннан»,—дип сөйли торганнар иде».

Алтмышынчы елларда авыл уртасындагы иске зиратта (хәзерге парк урынында) табылган баш сөяген мәктәп укытучылары Арзыев һәм Касимовлар Мәскәүгә җибәрәләр һәм аннан «Сөяк XY гасырда яшәгән европеоид типтагы кешенеке» дигән җавап алалар. Шул ук зиратта «1280» саны язылган таш та чыккан булган, ләкин аны саклый алмаганнар—югалтканнар.

Борынгырак чорларга караган язма чыганакларда һәм риваятьләрдә Каҗмакты исемен йөрткән авыл күренми. Перепись документларында ул беренче мәртәбә 1836 елда күрсәтелә. Каҗмакты авылы Бардадан күпкә яшь кебек тоелса да, без атаманың аннан алдарак тууын танырга тиешбез. Каҗмакты атамасы халык хәтерендә элгәргерәк исем буларак урнашкан. Бүгенге Барда өч авылны берләштергән булса кирәк. Башта елганың түбәнге агымында бер авыл (Каҗмакты) булган, соңрак Барда елгасы ярында икенче авыл барлыкка килгән, һәм ул да елга исеме белән аталып киткән. Елга үзе ул вакытта Чуен тавы астыннан Тулвинская урамы үткән урыннан аккан һәм Толга бүгенгесеннән түбәндәрәк кушылган. Илленче елларда моны күп картлар сөйли иде.Елгалар агышларын үзгәртми тормыйлар. Тол елгасы безнең гомердә генә ничә урында ничә төрле үзгәреш

ясады, шуларга өстән кешеләр дә бер үзгәреш кертteләр—турылап җибәрделәр. Каҗмакты елгасы узган гасырда мәчет тавы астыннан аккан, Ситдыйкъ мулланың йорт-курасы аның сул ягында, бакчасы уң ягында булган. Шулай булгач, безгә Барданың ике Каҗмакты авылы арасында барлыкка килүен һәм өч авылны берләштерүен факт итеп кабул итү авыр булмас кебек.

Каҗмакты-Башка 1822 елда Үдиктән Зәйнетдин Шәрәфкулов, 1831-1832 елларда Бардадан берничә гаилә, Тауавылдан Мөэминов Гыйләҗетдин, 1833 елда Куян (Кояново) авылыннан бер гаилә (Габидулла Солтанбеков) күчеп утырган. 1834 елда Каҗмакты-Башта барлыгы 39 ир-ат, 26 хатын-кыз теркәлгән (18. 575 нче санлы эш).

«Казым акты. Күп идеме? Бар да, бар да акты», дигән сүзләрне күпләр белә. Имеш, Каҗмакты һәм Барда исемнәре шуннан калган. Бусы соңгырак буыннардан бер шаяны уйлап чыгарган «этимология». Казмакты атамасының нигезендә казан, казакъ сүзләрендәге «каз» тамыры барлыгын сиземләве авыр түгел. Шараповның «Самоучитель» дигән китабында Казмакты сүзе түбәндәге кисәкләргә бүлеп тикшерелә: каз-ма-кты. Бередә «каз»—үзән, ма-мә—нәрсә (сүзалыштыргыч), «кты»—бүгенге телдә «лы» сүз ясагыч кушымчасына туры килә. Шулай итеп, «каҗмакты»дан «үзәнле» мәгънәсен бирүче сүз килеп чыга. Барданың Каҗмакты елгасы буендагы өлеше чыннан да түбән урында, үзәндә урнашкан. Каезлау сүзенең «каҗлау»га әверелгәне кебек, «з» авазының «җ»лаштырылуы безнең Гәйнә сөйләше өчен гадәти күренеш.

Н.А.Баскаков төрки телләр нигезендә барлыкка килгән рус фамилияләр арасында Казаков фамилиясен дә тикшерә. Аның нигезендә казак-казмак сүзләре ята, ди ул. Латин хәрефләре белән «казмак» сүзен китерә дә аны «скитаться, бродить, вольный» сүзләренең мәгънәсен бирә дип исбатлый (19). Н.А.Баскаковка ияреп, без Каҗмактыга каяндыр качып, куылып килгән кешеләр нигез салган дип әйтә алабыз. Бирегә килеп, алар үзләрен «без каҗмаклар», ягъни ирекле кешеләр дип белдергән, шуннан алар төзегән авылны Каҗмакты дип атаган булырга мөмкин.

Тарих фәннәре докторы Е.Бусыгин төрле тип общиналарны анализлауга багышланган «Борынгыдан килгән традиция» дигән мәкаләсендә язганча, Идел буенда качаклар бигрәк тә XYII гасырда артып китә. Е.Бусыгин мәкаләсендә язучы-этнограф Мельников-Печерскийның шундый сүзләре китерелә: «XYII гасырдан башлап үтә алмаслык Идел аръягы җирләренә яшәү өчен яңа кешеләр килә башлаган. Качак холоплар, күптән түгел кертелгән крепостное право белән килешә алмаган игенче крәстиәннәр, оброк һәм салым түли алмый интеккән бистә халкы, һөнәрсез посад кешеләре, качак рейтар, драгун, солдат һәм башка хәрби халык—болар барысы да Идел аръягына агылыпмы агылган... Нәкъ менә шул вакыт: «бурыч түләргә малым юк, Идел кичми хәлем юк» дигән мәкаль барлыкка килгәндер дә. Качак крәстиәннәр еш кына ясаклы татар, чуаш, мордвалар янына урнашкан...» (20.40 б).

Безнең Каҗмакты, Барда һәм алар белән бер чорларда барлыкка килгән бүтән авыллар әнә шушы чор һәм шушындый күченешләр җимеше.

XYII-XYIII гасырларда берән-сәрән генә йортлы вак җыен-чуклардан барлыкка килгән Таңып, Сараш, Бардабаш авылларының «безнең нәсел Минзәлә ягыннан, Ык, Иж елгалары буеннан килгән» дип сөйләүчеләрнең кайсының гына нәсел агачын тикшермә, аларның барысы да (Таңыпның Чурагулов, Туйгилдин, Гомәров, Нурмохәммәтовлары, Сарашның Ижбулатов, Тимганов, Таразовлары, Бардабашның Вахит Мәҗитов, Ханнан Яппаровлар белән бергә Минзәлә ягыннан күченеп килгән Әднәшев, Балтаев, Әмирханов, Әмировлары) шушы чорда чыгарылган патша указлары буенча Казан ханлыгының үзәк өлешеннән куылган кешеләр, типтәр исеме белән Гәйнәнең аборигеннары янына килеп сыенган, соңрак башкорт сословиесенә кереп, яңа төбәкнең үз кешеләренә әверелгән затлар.

XYII-XYIII йөзләрдә Казан ягыннан күчеп килгәннәр Гәйнә халкын сан ягыннан ишәйтеп кенә калмаганнар, ә, иң мөһиме, яңа күчмәннәр бирегә яңа сыйфатлар алып килгәннәр: алар белән бергә төбәккә күп зыялылар (зур җирләрдә укып белем өстәгән муллалар, мөгаллим-хәлфәләр, оста белгечләр (тегүчеләр, тула, киез итек басучылар, бүтән төр кәсәбәчеләр), сәүдә эшенә маһир кешеләр килгән. Алар килү белән авылларда мәчетмәдрәсәләр салу, төрле остаханәләр төзү башланган, эре авылларда кибетләр ачылган, кызыл тауар иляре вак авылларга да барып чыкканнар. Тол буе авылларына бермә-бер җанлылык кергән.

Авылларның искеләре киңәйгән, яңалары барлыкка килгән. Нинди генә үзгәреш булмасын, алар халык хәтеренә изге эшләр булып, авылларга нигез салучылар изге затлар булып кереп калганнар. Мәчет- мәдрәсәләрне бетереп, яңа тормыш төзибез дигән чорларда без аларны оныткан кебек булган идек. Авылларга нигез салучылар гына түгел, хәтта Гәйнә атамасы да телдән төшеп бара иде. Ярый, аңыбызга килеп калдык, «үзгәреш чоры» дип аталган сиксәненче елларда бер алдыбызга—бер артыбызга әйләнеп карап, үзебезнең кем икәнлегебез турында уйлана башладык. Әби- бабайларның яшьләр күзеннән яшереп саклаган хәтер язмалары яктыга чыгарыла, һәр авылда диярлек музейлар оештырылып, шунда куела башлады.

Музейлар, анда куелган әйберләр исә безне ерак үткәннәргә, үзебез дә белмәгән бабайлар үткән юлларга илтеп чыгара. Акбаш авылының тарихы, мәсәлән, мине скифларга, Үдик—болгарларга, Әрҗән—Алтай якларына, безнең эрага кадәрге чорларга алып китә. І Әрҗәннең иске зиратында «эре сөякле кешеләр» бүгенге удмуртларның еракгы бабалары җирләнгәнлеген беләбез. Пермь халыкларының бер тармагы булган удмуртлар әллә кайда яшәмиләр, ә менә Әрҗән атамасы мине еракка, Тува җөмһүриятенә алып китә. Беләм, Әрҗән—Арьян дигән сүздән, димәк ул арлар авылы. Ләкин Алтайда Уюк (татарча Һйык—елга) үзәнендә дә Әрҗән дигән авыл бар. Әнә шунда скиф чорына (безнең эрага кадәр YII гасырга) караган курган казыганнар. Курганның исеме Әрҗән—тувалылар минераль чыганакны, чишмәне шулай атыйлар (20. 193-194 бб).

Скиф чорына димәктән, алтмышынчы елларда безнең Акбаш авылында Мурзыевлар йортының нигезенә язулы таш салынганлыгын күреп алалар һәм бу турыда Казанга хәбәр итәләр. Акбашка Казан университетыннан ул вакытта яшь галим, хәзер академик Миркасыйм Госманов

җитәкчелегендә экспедиция килеп төшә. Баз казыганда чыккан таш берничә кисәккә бүлгәләнгән һәм ике йорт астына нигез итеп салынган, язулы өлеше нык бозылган була. Шулай да галим аның балбал таш икәнен исбат итә һәм бу турыда «Серле балбал» дигән китабында язып чыга (21). Рун язулы ташлар Кама буенда да, шул ук Акбашның Сәет тавы итәгендә Габдрахман бабай кое казыганда чыга. Искилде авылы янында да булган диләр андый ташлар. Кызганыч, андый нәрсәләргә «таш» итеп кенә карый торган еллар иде шул.

Рун язуы төрки-татарларда гарәп язуы кабул ителгәнче кулланылган. Язулы таш—ул безнең якларда X гасырга кадәр үк төрки телле мәдәниятле халыклар яшәгәнлеген исбатлаучы дәлил. Югарыда күреп үттек: төркиләрнең аңарчы да язмалары булган, Чардин тирәсендә Һун телендә язмалы алтын-көмеш әйберләр табылган. Һәм әле күпмесе табучысын көтеп ятадыр. Шуңа күрә безгә язулы таш, савыт-саба, иске китап тышларына язып калдырылган язуларга карата һич кенә дә ваемсызлык күрсәтергә ярамый.Әледән-әле без Чардин атамасына тап булабыз. Һәм бу очраклы гына түгел. Соңгы вакытта «Чардин ханлыгы» турында гәзитләрдә дә материаллар күренә башлады. «Белгәнебезчә, Пермь өлкәсенең төньягында урнашкан Чердынь шәһәре тирәсендә Казан ханлыгы белән һәрдаим элемтәдә торган Чәрдан дип аталган татар ханлыгы булган. Кызганычка каршы, унбишенче йөз башында швед юлбасарлары әлеге ханлыкны туздырып ташлыйлар». Бу юлларны язган Р.Фаязов (Казан) бу ханлык халкын «ботык» кабиләсеннән, «Пермь татарлары шул ханлыкның варислары булырга тиеш», дип исәпли (22).

Безгә атаклы һуннар каганы Атилланың улы Денгиззих турындагы ачыш, «Гәйнә» риваятеннән Гайнетдиннең, Танып авылы турындагы риваятьтән Биккул бабайның Чардин падишаһына барып йөрүләре, аннан үзләре биләгән җирләргә ярлык алып кайтулары билгеле. Димәк, Чардин Гәйнә тарихында очраклы гына телгә алынмый, аның аерым кешеләренә генә карый торган урын түгел, ә XY гасырларга кадәр Гәйнә иленең мәркәзе шушында булган дип әйтә алабыз.

Безнең күп авылларыбызның исемнәре иске төрки, гарәп телләрендә чыккан китапларда очрый. Шуңарга күпләр аларны гарәп-фарсы телләре аша аңлатмакчы була. Ә бит аларның һич кенә дә чит телләрдән булмыйча, үзебезнең борынгы телебез сүзләре булуына да дәлилләр күп. Сарашны болгар сүзе «сары аштан» дидек. Сүҗде шулай ук болгар теле аша җиңел аңлатыла: сөҗе—баллы эчемлек дигән сүз. Сөҗән дә (сөҗ-ән) шушы сүздән ясалган. Безнең гарәп-фарсыдан дип эзләгән күп атамаларыбыз, шулай итеп, алан сарматларның бер тармагы булган үзебезнең болгар бабалардан булып чыга.

Язучы-галим Нурихан Фәттахның 1990 елда «Шәҗәрә» дигән китабы басылып чыкты. Анда ул төрки-татарлар гел генә «алып торучылар» булмаганнар, ә үзләре дә күпләргә «биреп торучылар» булганнар дигән фикер үткәрә (23). Күреп киләбез, гәйнә кешеләре сүз-атамаларны гына түгел, ә материаль-икътисади байлыкларын да башкалар белән юмарт уртаклашкан.

Н.Фәттах әлеге китабында «Иллария» дигән җырны искә ала, Аның Тигр-Евфрат буйларында безнең эрага кадәр биш-алты мең еллар элек яшәгән шумерлардан килүен әйтә. Шушы кадәр меңнәрчә еллар элек читят халыклар тудырган булса, бу җыр безнең Урал татарларында шул кадәр популяр булыр иде микән? Безнең буын бу җырны илленче елларда да әле аулак өйләрдә, кичке уеннарда бик яратып башкара иде. Шушы җыр тәэсирендә күп яңа җырлар туды. Хәтерле картлар аларны әле бүген дә сагынып искә ала.

Безнең эрага кадәр YII-III меңъеллыкларда төркиләрнең шумерлар белән катнашып яшәүләре турында күп галимнәр яза. Аерым алганда гражданнар сугышы елларында безнең якларда да булып, Гәйнә ягын Башкортстанга кушу идеясе белән йөргән һәм соңыннан дөньяның атаклы тюркологы булып киткән Зәки Вәлиди «Төрк вә татар тарихы» дигән хезмәтендә грек тарихчысы Страбоннан, латик тарихчысы Өлкән Плинийдан күп нәрсә белүен, аерым алганда, бәҗәнәк, уран, гәйнә кабиләләре турында укуын әйтә. «Гомумтөрки тарихына кереш» дип аталган икенче хезмәтендә «гәйнә ыруы чуашлар, татарлар арасында хәзәр культурасын үзләштергән», дип яза. Зәки Вәлиди хезмәтләренә анализ ясап, Р.Г.Кузеев шундый нәтиҗә ясый: борынгы ураннар гәйнәләрнең күптәнге күршеләре булган (күрәсең, бу аларның Кавказда яшәгән заманнарыннан ук киләдер) (24.141 б).

Тол елгасы бассейнында гәйнәләләр килгәнче дә кешеләр яшәгән һәм алар ике тел группасына караганнар. Берәүләре угро-фин кабиләләреннән, икенчеләре—төркиләр. Фәнни нигездә расланган дәлилләрне (В.А.Оборин, А.Х.Халиков) куәтләп, өлкәбезнең яшьрәк галимнәре топонимиканы өйрәнүгә күп тырышлык салалар. Әрҗән, Сөҗән, Бөрежле, Үдик, Йөкшер, Әмҗе кебек атамалар угро- финнардан, ә Бичурино, Сүҗде, Сараш, Башап кебекләре—төркиләрдән, дип кырт кистерәләр. Тол елгасының иске атамасы Җеренҗе-Җирмечине дә шул тәртиптә пермь кабиләләре биргән исемнәр рәтенә кертәләр. Алар фикерен бөтенләй үк инкар итмәстән, профессор Ф.Гарипова тикшеренүләренә игътибар итик. Чирмешән гидронимының таралыш дәрәҗәсен тикшереп, ул «Чирмешән атамасы табылган төбәкләр йә Идел болгарлары дәүләте составында, яисә аның сәяси һәм икътисади йогынтысын үзләренә сеңдереп яшәгәннәр»—дип яза. Гарәп илчесе Ибн-Фадланда Җәрамсан формасында алынган Чирмешән сүзе майлы, сагызлы урман елгасы дигәнне белдерә. Ә телче-галим Р.Әхмәтҗанов бу сүзне «гаскәр җыела торган урынга ориентир»; ә Н.Исәнбәт «Чишү мәмшән—гаскәр йөртүче, гаскәр башы» дигәнне аңлата», ди (25.164 б).

Районның төп елгасы бу аңлатмаларның берсен дә кире какмый: ул да сагызлы урман елгасы. «Җиде газый» риваятен истә тотсак, аның гаскәр җыела торган урын икәнен дә инкар итә алмыйбыз. Исем- атамаларның бер ишеләре урында барлыкка килсә, икенчеләре еракларда, Алтай, Себер, Урта диңгез, Кавказ якларыннан,Идел буйларыннан килгән. Килгән һәм аталмышка берегеп калган. Тик бер Гәйнә генә никтер җисеменнән аерылган кебек.

Исем бар, ә шул исемдәге авыл юк. Урыны да билгесез. Ә бит ул булган. Бу турыда күп китапларда язылa, риваятьләрдә сөйләнә. «Откуда эти названия?» (Пермь, 1979) китабы авторы менә нәрсә ди: «Село Гайна, по ревизским сказкам, имелось и в Осинском уезде, оно было центром Гайнской или Гайнинской волости, где жили башкиры».

Этнограф С.В.Суслова, өлкә авылларында ишеткәннәргә таянып, Гәйнә һәм Барда авылларын ювелир әйберләр җитештерү үзәкләре исемлегендә күрсәтә. (26).

Безгә Коми-Пермяк округында район үзәге Гайны авылы билгеле. 1834 һәм 1850 елларда да әле Чердынь өязенә караган бу авылда торки исем-фамилияле гаиләләр (Булатов, Әндәров һ.б.) булган.

Башкортстанның Әлшәй районында, Свердловск өлкәсенең Ачит районында Гәйнә авыллары бар һәм анда яшәүчеләр ата- бабаларын Пермь ягындагы Гәйнәдән күчеп килгәннәр дип сөйлиләр. Әлшәй районының Гәйнә авылы аша аккан елга да (Димнең сул кушылдыгы) Гәйнә дип атала. Шул ук Башкортстанның Бакалы районында Гәйнә тавы, Бәләбәй ягында Гәйнә күле бар. Татарстан белән Башкортстанның чик сызыгы булып аккан Ык буенда да, Тол һәм Мулла елгалары буенда да XYIII гасырда Гәйнә олыслары булган (27). Кавказ якларыннан Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгына, аннан инде Тол,Чу суы буйларына килеп тупланган гәйнәлеләр әнә кайларда эзләрен калдырганнар.Болгар дәүләтенең тар-мар ителүен, монгол яуларын, Явыз Иван гаскәрләренең Идел-Кама буе шәһәр һәм авылларын канга батыруларын, көчләп чукындыруларны кичергән алар, әмма үз исемнәрен онытмаганнар, ата-бабалары рухына, гореф-гадәтләренә тугры калганнар, горурлык белән «Без—гәйнәлеләр!» дигәннәр.

XX гасырның илленче елларында да әле Гәйнә ягы дигән төшенчә Барда районы дигән төшенчәдән алда йөри иде. Пермь, Кояновода укыганнарның күбесе «Гәйнә ягыннан» булырлар, укуны тәмамлагач та безне Барда районына җибәрәләр диючеләрне өлкәннәр:

—Гәйнә ягына икән,—дип төзәтерләр иде.

1990 елның козендә Бардада яңа мәчет ачу тантанасы булды. Бу мәгърур бина Барданың һәр ягыннан күренеп, һәр тарафка иман өреп, һәркемне үзенә тартып тора. Җомга көнне моңлы азан тавышы ишетеп мин дә аны читләтеп үтә алмадым. Шәкертләр арасына кереп утырдым. Барданың яңа чор хәзрәте Җәүдәт хаҗи Батыркаев башта ураза җитүен хәбәр итте, аның кануннарын аңлатты, аннары картлар түр якка үтеп, Мөхәммәт пәйгамбәргә, Һава анабызга, аларның сәхабәләренә һәм ...«Җиде газиз»гә, «Унбер әхмәт»кә багышлап дога кылдылар.

Җиде газиз—бөтен Тол буеның, бөтен Гәйнә иле тарихының чишмә башы булса, унбер әхмәт—Барда авылының иң данлы, иң мактаулы изгеләре, аңа нигез салучылар.

Борынгы зур Гәйнә илен (бүгенге Пермь өлкәсенең көньяк чикләреннән Чу суына, димәк бүгенге Пермь каласы урнашкан параллельгә кадәр җәелгән зур төбәкне) тарих җилләре бер район күләменә генә калдырган. Шушы районның үзәге булган Барда да ничәмә-ничә тапкырлар юк

ителгән, колгә әверелдерелгән, шулай да ата-бабалары (Кыю Әхмәтләр) сайлаган бу җирне ташлап китмәгәннәр, илбасарлардан арыну белән янә йортлар торгызганнар, мәчет-мәдрәсәләр күтәргәннәр—тормыш дәвам иткән.

Гәйнәләләр яшәгән төбәкләрдә, Кама- Чулман, аның кушылдыгы Чу суы, Ирән, Солил, Тол буйларында күп изге урыннар бар. Соңгы елларга кадәр сәламәтлеккә туймаган карт-корыларның анда барып коръән чыгартуларын, Ыйык таш дип аталган тауларга менеп, изгеләрдән саулык-сәламәтлек сорап ялваруларын, хәер бирүләрен үз күзем белән күргәнем-ишеткәнем булды. Онытылып барган шушы йолаларның яңа мәчеттә яңартылуы мине нык дулкынландырды, йокыдан уяткандай итте, тирән уйларга салды. Болай булса, борынгы Гәйнә иленең үзәге булган Гәйнә авылы да табылмый калмас дигән өмет тудырды, шушы китапны язарга ашыктырды.

Мәчеттән кайту белән Археологик истәлекләр исемлеген алдыма җәеп салдым, утыз ел буена җыйган материаллардан Гәйнә иленең борынгы чорын «конструкцияли» башладым.

Борынгы Гәйнә иленә (олысына) караган Сидяха елгасы буенда археологлар биш шәһәрлек ачканнар, бу шәһәрлекләр безнең эрага кадәр Ү гасырдан башлап яшәгәннәр дип исбатлаганнар. Тол буе бассейнында шул ук чорлардан (безнең эрага кадәр Ү- III гасырлардан) Бардадан ерак түгел ике шәһәрлек, ике авыл урыны барлыгы билгеле. Археологлар аларны Барда исеме белән атаганнар һәм бу тикмәгә генә түгел дип уйлыйк. Барда атамасы бүгенге Бардадан күпкә олы. Шушы җирдә шушы исем белән теркәлгән археологик истәлекләрнең берсе безнең эрага кадәр ҮI гасырда (моннан 2600 еллар элек) барлыкка килгән һәм безнең эраның III гасырына кадәр яшәгән.

Үдик-Елпачиха авылында һәм аның тирәсендә берничә авыл урыны һәм бер шәһәрлек ачылган. Без аларның икесенә—авыл эчендәгесенә һәм авылдан 500 метрдагы авыл урынына игътибар итик. Икесе дә безнең эрага кадәр: авыл урынындагысы Ү- III гасырларга, авыл эчендәге шәһәрлек IҮ-II гасырларга карый. Шушы археологик истәлекләрдән, авылдан нибары 200 метрда ар зираты булудан чыгып, без Үдик авылы районның бүгенге авыллары арасында иң олкәне, Кама-Чулман буенда иң беренче барлыкка килгән тору урыннарыннан берсе дип әйтә алабыз.

Районның иң карт авылларыннан берсе Куземьяр атамасы Озын яр буе дигән төшенчәне бирә. Бу авылның борынгы чорларда чыннан да Олы Әмҗе буенда Чувашай-Ямантай (Яматай-шушы атаманың бозылган варианты) авылына кадәр сузылып утырган булуы турында күпләрдән, шул исәптән «Гайнетдин белән Әрменшаһ» риваятен әйтеп яздырган Мортаза ага Антуковтан ишеткәнем һәм язып алганым булды. Чувашай авылының көньяк очында археологлар тапкан авыл урыны шушы «Озын яр буе авылы»ның бер өлеше буларак күз алдына баса. Археологлар аны безнең эрага кадәр Ү гасырларда барлыкка килгән һәм ике йоз ел чамасы яшәгән дип исбат итәләр.

Эре су юлы булган Кама-Чулман елгасына якын тигез җирләр моннан да элегрәк чорларда үзләштерелгәннәр. Археологлар анда металл әйберләр җитештерү урыннарын, җайланма һәм эш коралларын табалар. Урман, таулар арасына куылганчы, гәйнәлеләрнең төп яшәү урыннары шунда булган. Бусын без археологлар язмаларыннан да, Кама буе топонимикасыннан, авыллар тарихы турындагы риваятьләрдән дә күрәбез.

Үз тарихыбызны өйрәнеп үсәчәк яшьләр киләчәктә күп нәрсәләргә ачыклык кертерләр. Алар Чардин каласы, Гәйнә авылы, ә бәлки шәһәре булган урынны да, әлегә без томанлы гына күз алдына китергән Яңа (Кече) Карьяу, Күлавыллар, Пичмән һәм Шабарка ягындагы Ермия таулары, әлегә аңлашылмый торган исемдәге башка урыннар турында да ни дә булса әйтерләр, дип өмет итәргә кирәк.

## Кулланылган чыганаклар


1. Пермь татарлары. Казан, 1983.

2. Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Казан, 1987.3. Башкорт халык иҗаты. Риваятьләр, легендалар. Уфа, 1980.

4. Археология и этнография Башкирии. Том 4. Уфа, 1971.

5. Д.Исхаков. Пермь татарлары. Казан утлары. 1991, 8.

6. В.Шишонко. Пермская летопись. III период. Пермь, 1884.

7. Писцовые книги Пермской губернии. Соликамский и Кунгурский уезды. Пермь, 1872.

8. Ф.Пшеничников. Карьево. Пермь өлкәсенең Орда районы газите—Верный путь. 1971, 28 и 30 декабрь; 1972 г., 4 һәм 6 январь.

9. Ә Фатыйхов. Адашулар. Халык чишмәсе. 1994, N 5.

10. Н.Блинов. Заселение Закамья. Исторический очерк. Сборник Пермского земства. 1898, N 34.

11. Ф.Пшеничников. Красный Ясыл. «Верный путь».

12. — // — .Село Ашап. «Верный путь»,

13. — // — . На земле Иренской. «Верный путь».

14. Ә.Фатыйхов. Габдулла мулла шәҗәрәсе. «Таң». 1993. 28 сентябрь.

15. Г.Хөсәенов. Канлы илле биш. Агыйдел. 1993, N 5-7.

16. Крестьянская война 1773-1775 гг. на территории Башкирии. Уфа, 1975

17. А.И.Андрущенко. Крестьянская война 1773-1775 гг., М., 1969.

18. Башкортстанның үзәк дәүләт архивы. Фонд 138. тасв. 2. арх. N 575.

19. Н.А.Баскаков. Русские фамилии тюркского происхождения. М., 1979.

20. Е.Бусыгин. Борынгыдан килгән традиция.—Татарстан. 1991, N 11.

21. Миркасыйм Госманов. Серле балбал. Казан, 1984.

22. Радмир Фаязов. Әле соң түгел... Шәһри Казан. 1994. 22 сентябрь.

23. Нурихан Фәттах. Шәҗәрә. Казан, 1990.

24. Р.Г.Кузеев. Зәки Валиди Туган. башкортларның килеп чыгышы турында. Агыйдел. 1991, N 11.

25. Ф.Гарипова. Тарихи каләмнарыбыз. Казан утлары. 1992. N 2. 163-168 бб.

26. Историческая этнография татарского народа. Казан, 1990.

27. Материалы по истории БАССР. Том IY. Часть I. 135 б; Часть II. док. N 419.

# III. Ханлыклардан - губернага

Бөек Болгар һәм Казан ханлыклары чорында «урман арты олысы» дип йөртелгән Гәйнә иле чагыштырмача мөстәкыйль, ясакны иң аз түләгән төбәк булган. Гәйнәлеләр IX йөздән XY гасырга кадәр яшәгән Болгар дәүләте күргән, Новгород һәм Мәскәү кнәзләре оештырган яуларны - авыл, калаларны талауларны ишетеп кенә белгәннәр, Алтын Урда ханнарының доньяның «астын өскә» китерүләрен, Булат Тимер, Туктамышларның Болгарны җан-җал мәйданына әверелдерү кебек мәхшәрләрне дә күрмәгән алар. Хәтта туктаусыз һөҗүмнәрдән соң хәлсезләнгән һәм икегә (Болгар һәм Җүкәтау ханлыкларына) бүленгән Болгар иленең 1431 елда рус кнәзе Василий II тарафыннан Русия җирләре дип игълан ителүен, үзләреннән җыелган ясакның ханнарга түгел, ә үзен «Владимир, Мәскәү, Новгород, Псков, Тверь, Югор, Пермь, Болгар, Смоленск һәм башка күп җирләрнең падишасы һәм бөтен Русия государе» итеп игълан иткән Иван III хөкүмәтенә, Мәскәүгә китеп торачагына да әллә ни исләре китмәгән, безгә барыбер дигән сыманрак кабул иткәннәр.

Безне дә урысларга буйсындырырлар, алар безгә дә житешерләр, Себергә үк үтеп китәрләр дип торганда, 1439 елда Гәйгә мөселманнарын тынычландырып, шундый хәбәрләр килеп ирешкән: еракларга йөреп сәүдә итүчеләре таркалып барган Алтын Урда ханнарының берсе Олы Мөхәммәд Болгар җирләрен яңадан бергә җыештырып, Казан ханлыгын оештыра икән, дип кайтып сөйләгәннәр.

Болгар-Казан ханлыгын торгызу урысларның көнчыгышка омтылышын йөз елга туктатып торган. Ләкин йөз еллык ара гәйнәлеләр өчен эч пошыргыч дәвергә әверелгән: моңарчы тыныч кына сәүдә итешеп яшәгән күршеләрен - коми-пермякларны чукындырулар башланган, 1465 елда Устюг воеводасы Василий Скрябин командалыгындагы Мәскәү кнәзлеге гаскәре алар өстенә яу чабып, югор кнәзләре Калпак белән Течикне әсир итеп Мәскәүгә алып киткәннәр, урыслар Чердыньне, Покчаны алганнар. 1472 елда Бөек Пермь иле тулысы белән Мәскәү дәүләтенә кушылган (1. 42-43 бб). Үрге Кама буе - төньякта Чусовой күленнән, көньякта шул исемдәге елгага кадәр һәм көнбатышта Камадан Урал тауларына кадәр җирләр, ягъни Болгар дәүләте белән сәүдә итешеп, зур күченешләр, бәрелешләр чорларында көньяк Уралдан кысрыкланган төрки кабиләләрне дә үзендә сыендырган легендар Вису иле, Чердынь крае руслар кулына күчкән. Һәм Гәйнә иленең төньяк читеннән,Чу суы буеннан, руслар Сөлилгә, аннан Ирән буена төшә башлаганнар. Алар белән бергә Казанга яу чабулар башланган икән, урыслар безнең кан-кардәшләребез турында ялган тараталар, ди, имеш алар татар- монгол калдыклады кебек шомлы хәбәрләр агылган.

1552 елның көзендә шуны раслап, Гәйнәгә чапкыннар килеп төшкән: «Казан камалышта, Казан сездән ярдәм көтә!» дип оран салган алар. Авылларда җыеннар җыелган, ашыгыч төстә җәя сөңгеләр белән корал-

ланган отрядлар оештырылган һәм Казан ягына озатылган. Ләкин гәйнәлеләр барып җиткәндә Казан инде алынган, аның кирмәндәге 33 меңлек гаскәре соңгы сугышчысына кадәр чәнчеп-суелып, шәһәр канга батырылган, ак патшаның солдатлары авыл-калаларга таралган була. Яндырылган- таланган авылларны күреп, башларын иеп кайтып кергәннәр безнең мәргәннәр. Гәйнәдә янә җыеннар җыелган, янә фәрман чыгарылган: иелгән башны кылыч кисмәс, урыс патшасына каршы торырлык көчебез юк, аңа баш орырга кирәк. Шушы карарны патшага җиткерү өчен аның хозурына ике илче җибәрергә килешкәннәр. Бу икәүнең Мәскәүгә ничек барулары, аннан нинди җавап белән кайтулары турында халык тудырган риваять тәфсилләп сөйли:

«1552 елның көзендә камалыштагы Казан ханына безнең Гәйнәдән дә ярдәмгә бардылар. Тик алар барып җиткәндә Казан инде алынган җимерелгән-таланган, безнең мәргәннәр, яндырып көлгә очырылган авыл калаларны күреп, хәйран булып кайтып кергәннәр. Гәйнәгә кайтып җыен җыйдырганнар һәм безнең урыс патшасына каршы торырлык көчебез юк аңа баш орсак кына исән калырбыз, дигәннәр. Җыен шулай карар кылган да: ак патшага ясак түләргә булып, баш орырга, Явыз Иван патша хозурына ике вәкил җибәрергә. Бу икәүнең берсе атаклы мәргән Уракби булып, алар аткан саен ныгый торган җәя, укларын алып, аякларына кондыз тиресеннән итек киеп, чаңгыга басып Мәскәүгә киткәннәр. Анда алар кош атып, балык тотып туенып барганнар. Күрән аюга, ут төлкегә очраганнар, икесен дә атып алып, тиреләрен патшага бүләккә алганнар. Шулай патша тора торган калага җиткәннәр. Исән- имин барып җитүләренә бик шатланышканнар. Уракби таудан калага бер генә аягында, бер генә чаңгысына басып төшкән. Аның җилдәй җилдереп төшүен күп халык күзәтеп торган. Халык җыелган, ләкин телләре бүтән булганга шундук сөйләшә алмаганнар. Боларны патшаның вәзирләре янына алып кергәннәр, тылмачлар табып, кем булуларын белешкәннәр. Уракби патша вәзирләренә әйткән:

- Без Чулман суының аргы ягыннан килдек,Тол дигән су буенда урманнарда яшәүче башкортлар булабыз. Кәсебебез аучылык, балык тоту корт үрчетү. Тамгабыз, сезнеңчә әйткәндә, фамилиябез - кош канат, - дигән, М хәрефенә охшаган тамгасын сызып күрсәткән. - Без укчылар, - дигән.

Шуннан аларны патшаның үзенә алып кергәннәр. Патша боларга әйткән:

- Укчылар булсагыз, халык алдында осталыгыгызны күрсәтегез.

Мәйданга халыкны җыйганнар, маяк өстенә ак флаг менгезеп кадаганнар. Боларның угы ак флагны үтәли тишеп чыгып киткән, ләкин җилдә җилфердәгән тукымада тишекләрне күрерлек булмаган. Шуңар боларга ышанмаганнар, алдыйсыз, дигәннәр.

- Алайса, - дигән Уракби иптәшенә, - без бу флагны атып төшерик. - Өченче тапкырында безнең мәргәннәр флагның таягына тозәп атканнар. Ак флаг җиргә мәтәлеп төшкән, дүрт тишегеннән җир күренеп торган. Флаг кадәр флагны мәтәлдерү-җиңү дигән сүз. Ләкин Уракбиләр канәгатьләнү тоймаганнар. Кайчандыр Чардингә барып йөрүләрне искә төшергәннәр һәм карап торучыларга әйткәннәр:

- Сез шушы маяк өстенә йөзек балдагы бәйләгез, без укны шул балдак эченнән чыгарырбыз, - дигәннәр.

Һәм шулай иткәннәр дә. Шуннан патша Уракбиләрне үз хозурына чакырткан, ни теләүләре белән кызыксынган.

- Сезнең кешегез булып, үзебезнең Тол буенда яшәргә телибез, - дигәннәр гәйнәлеләр. Патша боларга «владенный грамота» биреп кайтарган. Ә анда шундый сүзләр язылган ди: «Кама-Чулман елгасыннан башлап Агыйделгә чаклы, Тол, Таныш сулары буендагы бар җирләргә хуҗа булыгыз».

Шулай итеп, безнең гәйнәлеләр риваятьтә генә булса да сугышмый-нитми җиңү яулап, урыс патшасының флагын аяк астына мәтәлдереп, үз җирләренең хуҗалары булып кайтып кергәннәр.

Шул ук риваятьтә Гыйнвал, Ирәкте, Уран исемле кешеләрнең мөфтигә барып йөрүләре турында әйтелә. Гыйнвалга Тол буе, Ирәктегә Таныш суы буе, Уранга Яңавыл ягы, Бүә буе эләгә һәм алар өч тату күршеләр булып яши башлыйлар (2).

Болары - легендадан. Ә чынында иске стиль белән 1552 елның 2 октябрендә Казан алынганнан соң ханлыкның көнчыгыш яртысында әле байтак вакытлар (XYI гасырның ахырына кадәр) Явыз Иван гаскәрләренә каршы каты сугышлар барган. Бу сугышка Идел буе чирмешләре, чуаш һәм арлары да кушылган. Ләкин колонизаторлар, берни белән исәпләшмичә, урыс идеологы Иван Пересветов «оҗмах җирләре» дип атаган ханлыкны басып алуны дәвам иткәннәр, Уралга ук якынлашканнар, эре елгалар, шәһәр-калалар тирәсеннән җирле халыкларны 30-40 чакрымга эчкәрәк куып, анда урысларны күчереп утыртулар башланган. Шушы хәлләрне күреп-ишетеп торган башкортлар Русиягә «үз ирекләре белән» кушылырга булалар. Риваятьләрдә сөйләнгәнчә, дүрт башкорт ыруы кнәзләре - Үсергәннән Бикбау кнәз Таукачев, кыпчактан Мишәүле Кара Кушак кнәз, Бөрҗәннән Иске бей кнәз, Тамьян аймагыннан Шагали Шакман би, безнең Уракбиләр кебек үз теләкләре белән түгел (башкортлар үз теләге белән кушылды дип рус тарихчылары гына яза аны, риваятьләрдән башка моны раслаучы берниндн документ юк), ә 1554-1557 елларда Русия хөкүмәтенең Казандагы наместнигы янына чакыртып китерелләр, сугышмыйча, «төлке ясагы түләргә ризалатып, «үз теләкләре белән» кушылырга мәҗбүр ителәләр (3. 11б).

Гәйнә кабиләсенең рус подданныйлыгын кабул итүе турында икенче төрле риваять тә бар. Бусы Ык буенда калып, шунда яшәгән гәйнәлеләргә карый. Анда әйтелгәнчә, Гәйнә кабиләсе вәкилләре Мәскәүгә түгел, ә Казанга, рус патшасы наместнигына баралар. Илчелекнең башы булып гәйнәлеләрнең ыруг-кабилә башлыкларыннан берсе Айзуак-би бара һәм ул аннан грамота алып кайта (шунда ук).

Болай кушылуның бер файдасы була: башкортлар берникадәр вакытка өлешчә генә булса да үз җирләрен саклап калалар, Казан ханлыгының урыслар басып алган төбәкләреннән куылган татарларга, мари, чуашларга, Болгар дәүләте туздырылганнан соң күп тапкырлар булган кебек, алар

жирендә сыеныл, үзләре белгәнне алар белән уртаклашып, гыйлем таратып яшәү өчен мөмкинлекләр саклана.

Казан ханлыгы тар-мар ителеп, Мәскәү дәүләтенә кушылганнан соң, бөтен Урал, Идел буе һәм Себер жирләре басып алына һәм Бөек Русиянең өлешләре итеп игълан ителә, патша хөкүмәте тарафыннан идарә ителә. «Үз иреге белән» Русиягә кушылган башкортлар үзидарәләрен, эчке эшләрдә мөстәкыйльлекләрен саклыйлар. Безнең Гәйнә илен тәшкил иткән «Төньяк Башкортстан» тарханнары да башта ясак түләүдән азат булалар, Казан, Нугай ханнарыннан алган ярлыклары үз көчендә кала. Иске традицияне саклап, патша хөкүмәте башкорт феодалларына тарханлык грамоталары бирүне дәвам иттерә. Гәйнә кабиләләр берләшмәсенең төп өлеше биләгән Тол елгасы бассейны рәсми төстә 1597 елда бирелгән грамота нигезендә үзләренә беркетелә. Сүздә, кәгазьдә шулай. Ләкин чынлыкта XYII гасыр башында, 1616 елда гәйнәлеләр Толның сул ягында Үдиккә, уң ягында Тауавылга кадәр Кама буеннан, бүгенге Пермь, Очер, Оханск, Оса, Елово, Чайковск районнары урнашкан жирләрдән куылалар. Зур Иделдән Чу суына кадәр Каманың ике ягы да «инородецлар»дан чистартыла.

XYI гасыр ахырында, 1591-1592 елларда, Уфа төзелеп биш ел үткәч тә, хәзерге Оса шәһәре урнашкан урында Ново-Никольская бистәсе барлыкка килә. 1648 елда Күңгер каласына нигез салына, XYIII гасыр башында губерналар башкаласы булачак шәһәрләргә - 1723 елда Екатеринбургка, Ягошиха заводы һәм бистәсенә нигез салына. 1780 елда Ягошиха заводы һәм бистәсе Пермь шәһәре дип игълан ителә (шушы уңайдан туплардан атып анда зур бәйрәм үткәрелә). 1737 елда Ново- Никольская бистәсе Оса пригороды статусын ала, ә 1781 елдан шәһәр исеме алып, безнең тирә өчен хакимиять терәгенә әверелә.

Оса... Борынгы төрки-татарда бу сүз Усы формасында язылган һәм әйтелгән. һәм ул елга-су дигән мәгънәне белдергән. Осаның 400 еллыгына чыгарылган «Отчий край» (Пермь, 1991) дигән китапта бу атамага карата төрле фараз итүләр, риваятьләр китерелә.«Тайна веков» дигән бүлектә краевед Н.Устинов беренче итеп 1886 елда П.А.Шилов язып калдырган версияне китерә. Элегрәк бу тирәдәге урманнарда бал корты токымыннан булган шөпшә (русчасы «оса») күп булган, беренче килеп урнашучылар төп шөгыльләре итеп кортчылыкны сайлаганнар һәм беренче поселение дә оса-шөпшә исеме белән аталган, имеш. «Дәлиле - Осаның агачка эленгән корт умартасын тасвирлаган гербы».

«Оса шәһәре хант-остякларның элекке шәһәрлегендә нигезләнгән һәм ул «ос», «остяк» дигән атамага аваздаш (бусы - В.Южаковның 1936 елда «Красное Прикамье» газитендә бастырган мәкаләсеннән).

Икенче бер авторның язганнарына таянып, Оса атамасы вогул телендәге «оса- гуль»дән, хант телендәге «тишек» дигәнне аңлатучы «аса», «ас»тан дип ышандырмакчылар.

Орел шәһәреннән доцент И.Д.Дмитриев- Кельды моннан 700-800 еллар элек бу урыннан Болгар-Чердынь сәүдә юлы үткән, шәһәр урнашкан урын

юлның нәкъ уртасында булып, гарәп сәүдәгәрләре (?) аны «осат»(урта) сүзе белән атаганнар, ди (4. 28-30 бб).

Борын заманнарда барлыкка килгән исем- атамаларны бүгенге телдән эзләү. (Барданы - «бәрде»дән, Иранне - «әйрән»нән, Тәләсне - «тал асты»ннан китереп чыгарырга маташулар), җирле халыклар телендә булмаганны бөтенләй дә искә алмау, читләтеп үтү яхшы гамәл түгел, ә инде «Отчий край» авторларының Гәйнә илендәге атамаларның мәгънәсен кайдадыр Каф тау артында яшәгән халыклар теленнән китереп чыгарырга азапланулары безне, үз җирләреннән читкә этәрелгән Гәйнә халкын. тарихтан да читләштерергә, ә бәлки бөтенләй үк тарихсыз итеп күрсәтергә юнәлтелгән шовинистлар гамәле итеп кенә кабул итәргә мөмкин. СССР тарихында рус булмаган халыкларны 1917 елга кадәр тулысынча диярлек (97-98 процентка кадәре) надан булган, укый-яза белмәгән, аларның чын тарихлары Октябрь революциясеннән генә башлана дигән ялганнар да шушындый юллар белән тудырылды һәм ныгытыла килде, бар яхшы нәрсә урысныкы итеп игълан ителде (Рус Иделе, рус киңлекләре, урыс капкасы, урыс каены...).

«Отчий край» авторлары да безгә: «Әнә бит исеме дә сезнең түгел, шулай булгач, ничек инде Кама буе сезнең Гәйнә җирләре булсын», дип әйтәләр сыман. Әйе, Усы сүзе безнең бүгенге сүзлекләребездә очрамый. Ләкин ул билгеле заманнарда Алтай, Үзәк Азия якларында мәнгелләр белән аралашып, күршеләр булып яшәгән төрки-татарларда киң кулланылган һәм ул елга-су дигәнне аңлаткан.

Безнең борынгы Гәйнә җирендә урнашкан Осаны атаклы рус тарихчысы Н.М.Карамзин да игътибарыннан читтә калдырмаган. «История государства Российского» дигән күптомлы хезмәтенең 3 нче томында менә нинди сүзләр язып калдырган:

«1174 елда Новгород өлкәсенең кайбер кешеләре илләреннән читкә дә чыгып йөргәннәр һәм, Волгадан Камага кадәр йөзеп барып, аның ярында селение булдырганнар. Төньякка таба урманлы, табигать байлыкларына мул илдә кыргый халыклар көн күрүен белеп, бу юлчыларның күбесе Оса тамагына кадәр үрләгәннәр». Ни өчен зуррак елга тамагына, әйтик, Толга кадәр түгел? Н.Устинов та шундыйрак сорау куя: «Оса елгасы тамагында зур торак урыны булганлыкны аңлата түгелме бу?» - ди.

Алга таба «Отчий край»ны укып, без шуны аңлыйбыз: Оса бистәсенә руслар килеп урнашканчы ук әле (1591 елның 18 ноябренә кадәр) биредә йортлар булган, күчеп килгән беренче 12 гаилә шушы әзер йортларда урнашкан. Бу күчмәннәрнең ни максат белән күчерелгәнлекләре дә мәгълүм: Русия хөкүмәте Кама буендагы җирләрне «үзенә беркетергә карар итә, шуңа да «Федор Иванович грамотасы буенча», бистәче Калужниковны баш итеп яңа күчмәннәр җибәрелә».

Шулай икән, шәһәрнең исемен дә оса- шөпшәдән түгел, гарәп, остяк, вогуллардан да түгел, ә шушыннан куылган халыкның теленнән эзләү дөресрәк булмас идеме соң?

Юк, диләр китап авторлары, биредә башкортлар яшәгән, ә башкортлар алар күчмә терлекчеләр. иген икмиләр, ә биредә күптән түгел генә эшкәртелгән һәм иген чәчелгән җирләр җәйрәп яткан.

Осаның беренче күчмәннәре турындагы бүлекне язганда А.А.Дмитриевның «Пермская старина» дигән китабын куллану турында әйтелә. Бу чыганак башка бүлекләрдә дә искә алына. «Отчий край» авторлары Дмитриевның «Житие святого Грифона Вятского как источник сведений о Перми Великой» дигән хезмәте белән дә таныш. Ә ул бу әсәрендә Тол буенда башкортлар килгәнче үк әле татарлар һәм остяклар яшәгәнлеген бик тә аңлаешлы итеп әйтә, башкача уйларга урын калдырмый. Әйтеп үтү белән генә дә чикләнми, ә Тол буе татарлары һәм остяклары арасына килеп сыенган башкортларны Ирән-Сөлил буе кешеләре (татар-остяклары) белән якын мөнәсәбәттә итеп, алар белән бергә бәйләп карый.(5. 57 б.; 6. 20-41 бб).

Гәйнә халкының үткән тарихында һәвәскәр краеведлар гына түгел, ә галим дәрәҗәсенә күтәрелгәннәр дә абына. Аларның бу хатасы XYII-XYIII гасырлардан гәйнәлеләрнең җиргә мөнәсәбәтләрен, ягъни сословиеләрен белдергән башкорт сүзе белән аталып йөрүләреннән килә. Традиция буенча бу гадәт әле безнең көннәрдә дә дәвам итә. Һәм кайберәүләр аны милләтне белдергән төшенчә итеп кабул итәләр.

Оса—Болгардан Чердыньга илтүче (корыдан 20 көнлек, су буйлап 90 көнлек) сәүдә юлының нәкъ уртасында урнашкан тукталыш урыны (мәнзил). Шуннан чыгып, Орел галиме И.Д.Дмитриев-Кельды гарәпләр хант- остякларның «Осагуль»ен «Осат-ун» дип әйткәннәрдер, ди. Аның Оса атамасын болай аңлатуы дөреслеккә таянып эшләнгән кебек, безнең Барда атамасын аңлатуыбызга бик якын. Егерме көнлек юлның нәкъ уртасында бит. Ләкин ни очен гарәп, ә болгар-татар түгел?

Багдад халифәте илчесе Әхмәт-Ибн-Фадлан язмаларыннан аңлашылганча, Болгар сәүдәгәрләре Чәрдан-Вису ягына чит кешеләрне үткәрергә бик үк риза булмаганнар, аның куркыныч юл икәнлеген искәртеп, бу сәүдә юлы белән кызыксынучыларны гел куркытып-өркетеп торганнар. Шулай булгач, атаманы юл хуҗалары теленнән эзләү дөресрәк булмас идеме?

Ул чагында борынгы Гәйнә иле җирләрен биләгән бүгенге Оса, Оханск, Елово, Куеда, Чайковск, Пермь районнарындагы авыл-бистәләрне, елга-күлләрне, болын- тауларны болар ник болай аталалар дип баш ватасы да булмас иде. Безгә Оса районындагы Кечебаш, Чәрмәтә, Чокыр, Бәрхәт, Ирьяк (Арьяк), Төмәс, Шалкан, Оханск районындагы Чүраш, Казанка, Болгар, Юлышат, Олы Сасна районындагы Шамары, Туйкә, Ислам, Кызыл Яр, Чайковск районындагы Әтнәш, Бүкәр, Елово (юл сүзеннән, Оса шикелле үк сәүдә юлында мәнзил) районындагы Куштамак, Суган, Чулпаныш, Ятыш, Кашкалак, Барда һ.б. авылларның исеме аңлашылып тора, шуңар без нәрсә аңлата бу сүзләр дигән сорау куймыйбыз, чонки беләбез: алар Болгар, Казан ханлыклары чорында барлыкка килгән авыллар.

Әнә П.Рычков «Опыт Казанской истории древних и средних времен» дигән китабында нәрсә дип яза:

«А... в некотором улусе на высоком берегу Камы реки был небольшой каменный пустой город, остаток древних еще болгар» (7. 130 б).

Казан галимнәре бу сүзләрне Алабуга янындагы Шайтан шәһәрлегенә карый диләр. Мица калса, алар безнең Осага карата әйтелгән кебек. Шуны Шайтан каласы турында менә нинди юллар бар:

«Кама арьягында Уфа губернасының чиркәүле авыллары күренә, алар большнарга, чәчелгән басуларга, тау һәм урманнарга бай. Аларның барысы да күзләрне иркәләп тора» (8. 33-34 б).

Кама аръягыннан торып карасаң, безнең Тол буе үзәннәре дә шулай күренмимени? Ә Осаныкы кебек Еловоның да нигезе Болгар чорында салынганлыгына ышандыру өчен мица атаклы сәяхәтче П.П.Семенов-Тянь-Шанскийдан бер җөмлә китерү җитәр кебек: Алабуга монастыре турында сүз барганда аның миссионерлык максаты, ягъни чукындыру сәясәте ассызыклап үтелә һәм шул фикер болай тәмамлана: «алар (ягъни миссионерлар) аерым кешеләрне христианлыкка күчереп кенә калмаганнар, ә тулаем авылларны, әйтик: Мунайка, Гришкино, Елово һәм Умякны да христианлаштырганнар, анда яшәүчеләр әлегә кадәр кадимге чукындырылганһар дип атап йортеләләр» (9. 535-536 бб).

«Ирекле рәвештә» рус дәүләтенә кушылган башкортлар 1557 елдан русларга 25 әр тиен «тотен» налогы, юл тоту налогы түләргә, моннан тыш гошер бирергә, башка төр хезмәтләр башкарырга тиеш булалар.

1661 елда Тол, Солил, Ирән буйларында, Күңгер һәм Соликамск өязләрендә, Урал артында Исәт елгасына, Көнбатыш Себергә кадәр башкорт һәм ясаклы татарлар арасында безнең җирләрне дә тартып алалар, русларга бирәләр икән дигән хәбәрләр тарала. Шуны раслап, Идел буеннан, Кама аръягыннан яңадан-яңа күчмәннәр күчеп килә. Хөкүмәт грамоталар биреп, көчләп күчерелгәннәре өстенә Русиянең үзәк районнарыннан, Поморье дип аталган төньяк районнарыннан крепостнойлар, заводларга беркетелгән крәстиәннәр качып килә. Тирә-якта яңадан- яңа рус авыллары барлыкка килә. Хөкүмәт тарафыннан көчләп күчерелгәннәр янсә алар белән бергә Кама буенда «бушап калган» җирләргә җирсезлектән, салым түләүдән җәфа чиккән качкын крәстиәннәр дә агыла. 1647-1648 еллар кышында Новгород приказы Соликамск воеводасы Прокопий Елизаровка әнә шул качкыннарны җыеп, Ирән елгасына алып чыгарга боера. «Дәүләтнең прихожан крәстиәннәрен, - диелә аңа бирелгән кәгазьдә, - Вятка һәм Кайгородларны, Соль - Вычегодск һәм Бөек Устюг һәм бүтән калаларның вотченникларыннан һәм монастырьларыннан Соли-Камскига ясак түләүче Вознесенск монастырена язылган Күңгер елгасына һәм Степаново шәһәрчегенә алып чыгарга». Махсус оештырылган отрядлар Соликамск, Пыскор монастырьларында, Строгановларда һәм башка вотченникларда качып яткан 385 гаилә, 1222 ир-ат Күңгер елгасы буена китерелә, һәм елга исеме белән аталган шәһәр төзелә. Һәр гаиләгә 7,5 дисәтинә җир (4,5 дисәтинә сөренте һәм 3 дисәтинә чабулык) бүлеп бирелә. Хөкүмәт аларны өч елга салым түләүдән азат итә. Көчләп китерелгән күчмәннәрдән бередә тик сигез гаилә тупләнеп кала, калганнары уңайлырак җирләр сайлап, вак-вак авыллар булып утыралар. 1650-

1651 елларда аларга янә өч йөзләп гаилә килеп кушыла һәм Ирән буенда 26 рус авылы барлыкка килә. Күңгер каласында бу елларда 96 йорт исәпләнә. Яңа күчеп килгән руслар, патша хөкүмәтенең тыюына карамастан, җирле халыклар белән уртак тел табып, татар авылларында да урнашалар (10, 7-8 бб).

Тол буенда Ново-Никольск бистәсеннән кала рус авылларыннан беренче булып Крылово авылы салына. Аның тарихы болай:

Патриарх Гермоген оныгы, Смоленск, Мәскәү калаларын поляклардан саклауда катнашкан Андрей Семен улы Крылов 1618 елда Үдик түрәләреннән кешеләре куылганнан соң бушап калган Кызыл-яр авылы урынын сатып ала. Үдик авылында Сәлим Арзыев язып алган риваять бу «сатып алу»ның күз буяу өчен генә эшләнгәнен күрсәтә.

«Крылов Тодашлы авылының төньягында, Бәкин тау астында, Толның сул ягында бер ачык болында мәҗлес җыя. Анда ул Осадан ике мичкә бал китертә, симез кара үгез суйдырта. Ашап-эчеп кәефләнеп алгач, Пәчтин кантун әйтә:

- Йә, агайлар, кнәз безне зурлады, кунак итте, инде без аның бу хөрмәте өчен шушы үгезнең тиресе зурлыгында җир бүләк итик. Кнәз шулай сорый. Йә, бирәбезме?

Безнең агайлар, бераз уйлашалар да, «бирмәгә кәрәк», диләр. «Пртакул» төзелә, агайлар анда тамгаларын салалар. Ул арада Крыловның ялчылары үгез тиресен нечкә генә кыл итеп кискәлиләр дә, агачтан- агачка тарта-суза торгач, менә никадәр җирләр кереп киткән.

«Пртакулга» тамга салудан баш тартучылар да булган. Шулардан берсе Түбәнавылдан Фәтхулла старшина булып, ул Крылов өстеннән шикаять язып, патшага китәргә дип шаулаган. Аны үтерү өчен Крылов берничә кешене яллаган. Шул кешеләр кичен Түбәнавылга барып, Фәтхулланың тәрәзәсенә кычкырганнар:

- Әй, Фәтхулла, печәнеңне маллар таптый, кәртәсен ватканнар, - дип. Фәтхулла чикмәнен элдереп чыкса, алтатардан шарт моңа — мылтыктан аталар. Ярый ядрә аңа тимәгән. Фәтхулла чабулыгыннан өенә кайтырга куркып, күлдә камыштан сулап, су астында төн үткәргән».

Илленче елларга кадәр риваять шушылай сөйләнеп йөрде. Крылов бу кадәр җир өчен гәйнәлеләргә бер дә түләмәгәнмени? дигән сорауга риваять сөйләүчеләр: «Әйе, түләве шул сыйлау булган», - дип җаваплсалар, 1953 елдан соң риваятьнең ахыры үзгәрә. Һәм бүген аны болай тәмамлыйлар:

- Юк, алай булмаган. Крылов җир сатып алырга булгач, шундый шарт куйган: сез миңа үгез тиресе зурлыгында җир бирәсез, ә мин сезгә сигез айлык үгез тартырлык алтын алып киләм, дигән. Һәм шулай эшләгән дә, һич алдау булмаган. Рәхәтләнгәннәр Нигамәй кантунныкылар алтынга. Гражданнар сугышы чыгып, Колчакка ияреп китәсе булгач, алтынның калганын тимер тартмага тутырып, ике катлы йортларының аскы катында кирпечтән өелгән урта стенасына яшереп калдырганнар. 1953 елда Кытайдан, элекке кантон начальнигы Н.Адутовның оныклары булды микән, өч ир-ат, бер кыз-хатын килеп йөрде. Ул чакта Адутовлар йортының өске

катында колхоз идарәсе, астында җыештыручы тора иде. Сыйлаганнар моны бик әйбәт итеп Кытайдан килгән үз кешеләребезнең оныклары һәм әйткәннәр:

- Безнең монда алтын-көмешебез бар, без шуны алыйк, сиңа да өлеш чыгарырбыз, - дигәннәр. Әтиләре калдырган сызмага карап, кечкенә генә чүкеч белән суккалап тапканнар яшерелгән урынны, ачканнар һәм тимер тартманы тартып чыгарып капчыкка бушатканнар. Бушатканда бер уч алтынны җыештыручыга да биргәннәр. Әйбәт саклагансың дип мактаганнар да үзен. Кытайда югары бәягә йөргән мотоцикл, велосипед ише кыйммәтле әйберләр алып, болар Мәскәү аша Кытайга кайтып киткәннәр.

Ләкин атай малын үзләренә кире кайтардык дип сөенешкән кече Адутовлар Совет-Кытай чиген тоткарлыксыз гына үтә алмаганнар булса кирәк. Күп тә үтмәстән, Үдиккә КГБ кешеләре килеп тикшеренеп йөргәннәр.

1672 елда Гәйнә олысыннан Теребердей Алиев иптәшләре белән челобитный яза. Аларның бу шикаяте «Бөек государь, Падишаһ һәм Бөек кнәз Алексей Михайловичка (Бөек һәм Кече һәм Ак Русия самодержецына)» һәм шулай ук стольник һәм воевода Иван Тимофеевич Кондаревка адреслана:

«Безнең Агыйдел тамагыннан башлап, Тол елгасына кадәр, Кама буйлап, аңа коя торган елгалар буенда ата-бабабыз Килейко Акильдиннан мирас булып калган җирләребезгә чит кешеләр килеп урнаша һәм төрле башбаштаклыклар кыла» («чинят им всякие насильства разные люди»), дип язалар гәйнәлеләр һәм үзләренә саклык («Оберегательный») грамота бирелүен үтенәләр (11. 74 б). Билгеле, алар бернинди саклау һәм яклау таба алмыйлар, чөнки нәкъ шушы елда элек бирелгән тарханлык грамоталарын гамәлдән чыгару турында указ игълан итәлә.

Кама һәм аның кушылдыклары буенда урыс поселениеләре артканнанарта, җирле халык патша указы нигезендә калдырылган җирләреннән дә кысрыклана. Андрей Крыловның 4 чети дип «сатып алган» җире бернигадәр вакыттан Мәтәвәли, Гремячи буйларындагы (Тол-Торга кадәр) сөренте, чабулык, урман җирләрен үз эченә ала.

1623 елда Крылов шушылай алдап алган, үзлегеннән киңәйткән җирләргә «Оброчная грамота» юнәтә һәм оч ел буена 4 чети өчен икешәр сумнан ясак түли. Биш ел барган ызгыштан соң төзелгән документта 4 чети дигән участок 30га әверелә, «вдоль на полверсту» булып китә, ә инде «недоросль Алешка Петров сын да сестра девки Афинья да Кантелина»ларга төзелгән «дело» да Крылов дачасы «Толның сул ягыннан буйга 5 чакрым, аркылыга 3чакрым, уң ягыннан тагын 3 чакрымга сузыла».

«Недоросль Алешка Чурин владениесе» шул ук бер кәгазьдә буе 1 чакрым дип күрсәтелә дә, ахырга таба «агасы Прокопий Чуриннан калган поместье» 100 чиреккә җитә, тагын яңа арчылган җир 185 чирек, болын 120 чирек, буе алты чакрым, иңе 3 чакрым урман» булып әверелә.

«Тол-Тор һәм Үдик елгаларында ике авыл булып яшәгән Тол буе башкортлары... гомер-гомергә килешеп яшиләр, межа турында бәхәс булганы юк» (12. 328-459)

Крылов имениесе турындагы «дело» шундый тынычландыру сүзләре белән тәмамлана.

1661 елда Крылов имениесе аның ялгыз калган хатынына яздырыла, шул ук елны оныклары хуҗа итеп игълан ителә. Чуриннар бу имениене Нармацкиларга, ә алар 1722 елда Строгановларга саталар.

Гәйнә олысын көньякта Ирәкте, Уран олысларыннан аерып торган «буш җирләргә» дә, удмурт авыллары арасына, руслар килеп урнаша. Нәтиҗәдә Гәйнә иле Тол-Гәйнә, Мул-Гәйнә, Тор-Гәйнә дигән вак өлешләргә бүлгәләнеп, бөтенлегеn югалта, татарлар укмашып яшәгән Идел-Уралдан аерымланып кала.

Җиргә мохтаҗлыклары булмаганнар да, «буш яткан» җирләрне эләктереп, аларны акчага әверелдерү кәсебенә керешә. Мисалга беренче итеп Оса крепосте капитаны Прагерны күрсәтергә була. Ул шул юл белән «җир юнәтеп», зур суммага аны Васильев дигән кешегә сатып җибәрә. Күңгер ягында Кишерть авылын сатып алган Соликамск кешесе Елисеев зур табыш белән аны Строгановларга сата. Сатып алып та, хакимият кешеләренә ришвәт биреп, җирле халыкны алдап, көч кулланып та киңәйтәләр биләмәләрен Строгановлар. Уралда иң эре феодалга әвереләләр. Тол елгасыннан Чу суына кадәр Кама буйлап 10 млн. гектарга, нигездә Гәйнә олысы җирләренә хуҗа булалар.

XYII гасыр башында төньякта Строгановлар Түбән Мулланы басып алалар. Аның элекке хуҗалары Култай «с товарищи» елганың үрге агымына күчәргә мәҗбүр булалар. Биредә алар Култай авылына нигез салалар. Ләкин биредә дә аларга Строгановлар тынгылык бирмиләр. Култайның улы Шөгер Култаев, Михаил Федорович патшалык иткән чорда Мәскәүгә барып, саклык грамотасы алып кайта. Бу грамотада Түбән һәм Югары Мулла, Йог, Нытва һәм Очер елгалары буе Гәйнә олысы кешеләренең, Шөгер белән аның иптәшләренең җирләре икәнлеге, Строгановларга анда кул салырга кушылмавы турында әйтелә. Ләкин күп тә үтми, Строгановлар гәйнәлеләрне янә кысрыклый башлыйлар, тагын да көньяккарак күченергә мәҗбүр итәләр. Биредә алар Куян (Кояново) авылына нигез салалар. XYII гасыр ахырында Строгановлар аларны биредә дә килеп табалар. Шөгернең оныгы Тасим Маметов 1700 елда патшага челобитный (шикаять) язып, Строганов приказщигы Пронка Алексеевның кораллы кешеләр ияртеп килеп, бөтен авылны талап, тегермәннәрен сүтеп, мал-туарларын куып алып китүләре, сөрүлек җирләрен һәм хәтта йорт тирәләрен сөрүләре, чабулыкларын чабып, печәнен үзләренә ташулары турында зарлана.

1701 елда Казан Сарае Приказы Уфа воеводасына «башкортларга җиргә хокукларын раслаучы яңа саклык грамотасы бирергә» куша. Строгановлар, Приказ һәм воевода кушуын үтәүдән баш тартып, Посольский Приказга үзләре челобитный язалар һәм башкортларны «ялган шикаять язуда гаеплиләр». Патша хөкүмәте мәнфәгатен яклаучы Посольский Приказ Казан Сарае Приказының карары буенча башланган «эшне» (бәхәсле

җирләрнең яңа межаларын, китерелгән зыянны билгеләүне) туктата (13. 67-68 бб).

Бу туктатудан соң нинди гамәлләр кылынуы безгә билгеле түгел. Строгановлар белән тартышның ни дәрәҗәдә барганлыгы тулырак аңлашылсын өчен тәрҗемә итмичә генә патша исеменнән Уфа түрәләренә язылган документны китерәбез:

«От Великого государя, царя и Великого князя Петра Алексеевича всея великие и малые и белые России самодержца на Уфу стольнику нашему и воеводе Ефиму Панкратьевичу Зыбину. В прошлом 1700 году августа в день 5 бил челом Великому государю Уфимского уезду Осинской дороги Гайнинской волости деревни Куяновы Тасимко Маметов с товарищи: истари де прадедов, дедов и отцов их владенья вотчины по рекам от Камы реки с уст по Мулле и до вершины по обе стороны, а с устья Буртем речки по обеим сторонам до вершины по Кузульбаевскому пажню и по Чюзу речке пашенные земли и сеные покосы на той же их вотчинной земле прадеды и деды и отцы их они юртами поселились и пажни пахали и сена косили и городбами прочавечного себе владения разгородились, и с тех до своих угодейч платили они ясаку и ныне платят по двести по семидесяти по шести куниц по годы без доимки. А в прошлых де годах что их земли русские люди Усольскому уезду из вотчин именитого человека Григория Дмитриевича Строганова крестьяне его збили и житья их разорили и от того де они пошли жить и поселились деревнями на той же речке Мулле на самых вершинах и те крестьяне приезжая к ним в деревни и пашни их и усадебные земли пашут и городьбы ломают и разоряют и сено косят и к себе свозят и конских стада отгоняют и прикащики их Пронька Алексеевич с товарищи и со крестьяны приезжали к ним в деревню нарядным делом с ружьем и всех разорили и грабили. И нам Великому государю пожаловать бы их велеть в Уфимский уезд в те их старинные вотчины и в деревни послать... всякими угодья по прежнему, а тем русским людям отказать и впредь землю не владеть, а раззорстве и грабеже и в бою и в увечье указ учинить и о том к тебе дать им нашу Великого государя владенную грамоту...» (14).

Ирән һәм Солил буе остяклары һәм татарларының 1651 елда Ялган Дмитрийгә челобитный язулары мәгълүм. Ләкин Ялган Дмитрийгә юлланган бу хат та бернинди үзгәреш тудыра алмаган. Җирле халыкны кысрыклап килеп утырган руслар Күңгер воеводасы һәм стольнигы Тимофей Одинцовка ришвәт биреп котылып калганнар. Воеводага җирләрне яңадан бүлү үткәрергә һәм обводной кнәгәне Мәскәүдәге Новгород Приказына китерергә дип кушылса да, ул моны да эшләми. Шулай итеп, Ялган Дмитрийгә язган шикаять тә нәтиҗәсез кала.

Ирән һәм Солил буе татарлары һәм остяклары 1599 елга кадәр җан башыннан берәр сусар тиресе түлиләр, аннары аларны Верхотурье воеводасына беркетәләр һәм «по 12 сороков куниц» түләттерә башлыйлар, шуңа өстәп җан башыннан икешәр сусар, стрелецларга ун процентлы пошлина түләргә тиеш булалар. Строгановларның җәбер- золымын татыйлар, иске җирләреннән куылалар һ.б. (15).

Рус колонизациясе алып килгән җәбер- золымга чыдый алмаган халык коралга тотына, бөтен Урта Уралда, Вяткадан алып Урал артына кадәр крәстиән хәрәкәтләре башлана. Һәр яктан кысрыклана барган, урыннан урынга куылып, тәмам бөлгенлеккә төшкән гәйнәлеләр, Күңгер татарларын да үзләренә ияртеп, 1662 елда оешкан Күңгер өязен барып талыйлар, шәһәрне яндыралар. Бертуган Пиликиннар язып калдырган «Күңгер ельязмасы»нда бу вакыйга менә ничек тасвирлана: «Уфа башкортлары һәм Күңгер татарлары, үзара килешеп, бунт күтәрделәр... Элекке Күңгер каласы һәм башка торак җирләр Уфа башкортлары белән Күңгер татарлары аралыгында торганлыктан... бигрәк тә күп башкортлар һәм татарлар шәһәргә һөҗүм иттеләр... өяздә күп чиркәүләрне, авылларны калдырмаенча яндырдылар һәм күп кешеләрне үтергәнче тукмадылар... хатыннарын һәм балаларын алып киттеләр». «Күңгерне кыйратырга бармаган татарларның авыллары да зыян күрде, таланды...» (16).

Казан, Оса, Себер даругларында 1662-1664 елларда җәелгән бу хәрәкәт Мәскәүдән җибәрелгән зур гаскәр көче белән бастырыла. Күп җир биләүче башкорт феодаллары Уфа воеводасы кнәз А.М.Волконскийга баш орырга, гафу үтенергә мәҗбүр булалар (шунда ук).

Зәки Вәлиди 1661-1663 еллардагы хәрәкәт - ул зур территориягә җәелгән хәрәкәт, ди, аның башында Күчем ханның оныгы Гәрәй Солтан торганлыгын әйтә. Ул бу хәрәкәтне Кара-Калпак, Кырым, Кавказга җәелдермәкче булган, ди. Күңгер тирәсендә баш күтәрүчеләр колонистларның авылларын үртәп (яндырып), үзләрен Каманың уңъягына күченергә мәҗбүр иткәннәр. Биредә хәрәкәткә Сары Мәргән исемле каһарман җитәкчелек иткән, дип яза З.Вәлиди. Аңа каршы Волконский һәм кнәз Черкесский командалыгындагы күп санлы патша гаскәреннән тыш Себердәге гаскәр дә бирегә юнәлтелгән. Хәрәкәтне тәмам бастыру өчен бу гаскәрләр генә дә җитмәячәген сизеп, руслар калмыкларны котырткannар. Төркиләрнең бердәмлеген җимерү өчен бусы төп роль уйнаган (17. 177-178 бб).

1665 елда Күңгер каласы яңа урында, Ирән белән Сөлил елгалары бергә кушылган җирдә, ягъни хөкүмәт тарафыннан «чик буе җирләре», Вознесенск монастыре биләмәләре итеп расмиләштерелгән һәм күпме даулашып, шикаятьләр язып йөрсәләр дә, Карьяу олысы кешеләре куылыннан киткән җирдә яңартып салына. Анда көчле гарнизон булдырыла, крепость-кремль төзелә, өяз үзәге итеп билгеләнә, өяз үзе Казан воеводасына буйсындырыла.

1681 елда христиан динендә булмаганнарны «ипкә китерү», христианлаштыруны көчәйтү нияте белән Уфага «особый епископ» билгеләнә һәм, Идел буендагы кебек, безнең якларда да көчләп чукындыру башлана. Чукынудан баш тартучыларга өстәмә налог салына, җирләре тартып алына. Кама-Чулман буенда татар, удмурт сүзләре белән аталган рус авыллары әнә шушы сәясәтнең нәтиҗәләре.

Туган төбәкләреннән куылган халыклар 1682 елда янә баш күтәрәләр, янә Күңгерне, Кишерть острожегын, Уфаны камап алалар, Самарага юнәләләр. XYIII гасыр башында «башкортлар Каманың уң ягына чыгалар».

Алдар, Кучем, Уразай, Исмәгыйль мулла, Домәй җитәкчелегендә үч алучылар Казан тирәсендә, Нугай һәм бөтен Оса дәругына җәелеп хәрәкәт итә башлыйлар.

Уралда җәелгән бу хәрәкәттән файдаланып, Себер ханы Кучем, Кырым белән элемтәгә кереп, Казан өчен үч алырга, Себер дәүләтен Уралның бу ягына җәелдерергә уйлый. Шушы мәсьәләне карау өчен 1639 елда Себер дәругында башкорт җитәкчеләренең корылтае уздырыла. Казан ханлыгы җирләре Казан губернасы дип игълан ителүгә татарлар яңа баш күтәрү белән җавап бирәләр һәм бу көрәш бөтен XYIII гасыр буена тукталмый.

Шушындый туктаусыз яу-көрәшләрнең сәбәбен өйрәнү, утемле чаралар эшләү өчен рус булмаган халыклар яшәгән төбәкләргә әледән-әле яшерен тикшерүчеләр җибәрелә. Менә шуңа бер мисал:

Генерал-майор Генинг инструкциясе буенча Күнгер бургомистры Юхнев сәүдәгәр кыяфәтендә 1725-1726 елларда Уфа өязенең дүрт дәругын да йөреп, халыкның рухын- сулышын күзәтеп-өйрәнеп кайта һәм Оса дәругы башкортлары турында шундый мәгълүматлар бирә: «башка төбәкләрдән аермалы буларак, биредәге башкортларның чәчүлек җирләре күп, җәен күченеп йөрмиләр. Мал-туарлары күп түгел. Гәйнә олысында бай яшиләр, Уфа судьяларын тыңламыйлар, үзләре хөкем итәләр. Башка дәругларның башкортлары кебек гел генә сугышып йөрмиләр, ләкин кораллары күп. Бәрелешләр була калса, аларны тиз генә тота торган түгел. Киләчәктә баш күтәрүләр булмасын өчен, аларны мөмкин кадәр рус җирләренә таратырга, христиан диненә алырга, бушап калган әйбәт җирләргә русларны күчерергә кирәк» (18. N 546, 483-487 бб).

1739 елда Тол буе бассейнындагы авылларда 214 хуҗалык, 4744 кеше теркәлсә, 1772 елда, Кама буйларындагы җирләре (Чайковск, Куеда, Елово, Пермь районнарына кергән территория) тартып алынып, Тол буе бассейнының да дүрттән өч өлешенә генә калдырылган Гәйнә олысында хуҗалыклар саны 795 кә җитә. Бу көньяктагы өч күрше — Ирәкте, Югары һәм Түбәнге Уран олысларындагыннан 214 хуҗалыкка күбрәк. Халкы күбрәк, димәк, җан башына җире кимрәк. Шуңа карамастан, һәрьяктан кысрыклау-кыерсытулар тукталмаган. Бу бәладән аларны башкорт булып язылулары да коткармаган. Ә башкорт сословиесенә күчүләр переписьтән-переписька арта барган.

Казан губернаторы А.П.Волынский 1730 елда «Россия империясендә башкорт мәсьәләсенең торышы турында» патшага җибәргән рапортында «моннан егерме ел элек башкортларның саны 35 меңне якса ахыр чиктә 40 меңне артмый иде, ә хәзер качаклар белән 100 меңне артып китте, - дип яза. — Казан, Сембер ясаклы татарларының яртысыннан күбрәге башкортка күчте... башка диндәге бүтәннәр дә мордва, чуаш, чирмеш, вотяклар да авыллары-авыллары белән ясактан шунда күчтеләр», «үзләрен башкорт дип атаганлыктан, аларны тануы да кыен» (11. 302 б). Телләрен, милли үзенчәлекләрен белмәгәч, кыен булыр шул.

1735 елда И.К. Кириллов «хәзер бу килмешәкләр башкортлардан ике тапкыр күбрәк» дип, ә В.Н.Витебский «җир өчен түләүдән котылырга тырышып, күп типтәрләр хәтта христиан диненнән баш тарттылар һәм

магометанлыкны кабул иттеләр һәм, тыюга карамастан, башкорт дип атала башладылар», дип зарлана (18. 340 б).

Губерна түрәләренең язганнары безнең Гәйнә өчен аеруча характерлы. Перепись вакытында күпләр «безнең ата-бабалар гомер-гомергә шушында яшәгән, алар беркаян да килмәгәннәр», дип әйтә торган булганнар һәм, шулай итеп, И.К.Кириллов зарланганча, «күрә торып табигый башкортка әверелгәннәр».

Мондый күчешләр турында «Пермь елъязмасы» дигән хезмәтендә В.Шишонко да яза. «Ирән һәм Сөлил татарлары, Нугай татарлары, Казан татарлары исеме белән йөртелгән татарлар Пармия иленә һөҗүм иттеләр, ди ул һәм 1688 елда Оса даругының Уран олысында 50 татар, мари, удмурт авылы (37се - 1662 елга кадәр, 13е - аннан соңрак) барлыкка килүен әйтә.

1859 елда Оса өязенең 22 типтәре 10 нчы ревизия вакытында башкорт булып языла, ди Шишонко. Шул ук елны Таныл олысында 442 кеше (ир-ат), Красноуфим өязендә 1506 кеше «типтәрдән» башкортка язылган (21).

Патша хөкүмәте, налог җыюның кимүеннән куркып, берничә тапкыр (1782, 1812 елларда) махсус закон нигезендә башкортка күчүне тыеп та, ә аннан алда, 1745 елда II ревизия вакытында һәр сословиене (типтәр, мишәр, башкортны) аерым исәпкә алырга маташып та караган, ләкин нәтиҗәсе булмаган. Алай гына да түгел, яңа күченеп килгәннәр ясак кнәгәләренә яисә теркәлмәгәннәр һәм ясак түләмәгәннәр, яисә шактый вакыт аны элеккечә Казанга түләүләрен дәвам иткәннәр. Андыйлар Уран һәм Гәйнә олысында аеруча күп, дип язып калдырганнар патшага «аңлатма» язучылар.

1850 елгы перепись буенча, мәсәлән, Пермь губернасының Оса өязенә караган Гәйнә олысы Таныл типтәр командасында нибары алты авылда: Таныпта 240, Солтанайда 19, Бардабашта 24, Бардада 8 (1098 кешедән), Күчтәнтидә 70, Башапта 98 типтәр теркәлгән. Ә олыс буенча ул вакытта барлыгы 7766 ир-ат, 7280 хатын-кыз перепись үткән. Узган гасыр уртасында, ягъни Барда, Сараш, Үдик олыслары оештырылганчы, бөтен Гәйнә олысында (рус авылларын кертмичә) 15046 кеше яшәгән булып чыга, аларның 938 е генә ниндидер сәбәпләр аркасында (әллә чыгышларын яшереп күрсәтә алмаганнар, әллә түрәләргә ришвәт тортерлек рәтләре булмаган) башкорт булып языла алмаганнар (20).

1841 елда YIII ревизия буенча I Башкорт кантонында (аның Мул-Гәйнә: Кояново һәм Баш-Култай авылларында), Тол-Гәйнә төбәгендә, Кара-Таныл олысының Кайпан төбәгендә (Иске һәм Яңа Кайпанда), Ирәкте олысының Мәмәт авылында 6849 ир-ат, 6601 хатын-кыз (барлыгы 13450 кеше) перепись үткән. Перепись кәгазьләренә кантон начальнигы Адутов, писаре Кобелев кул куйган. Шушы переписька нигезләнеп язылган «Южноуральский археологический сборник»та Барда һәм Бардабаш авыллары «милли яктан катнаш милләтле авыллар» дип күрсәтелгәннәр.

Искәрмәдә 2нче юртадан Ермия (38 ир-ат, 28 хатын-кыз), 6 нчы юртадан Искилде (54 һәм 48), 8 нче юртадан Шлик-Түз (67, 49), 4 нче

юртадан Иткульская Давыдова (5, 5), Нигаметево (75, 75) һәм Үтәбәево (25, 19) авылларының төшеп калуы әйтелә (20. 340 б).

Бу переписьтә припущенниклар һәм вотчинниклар аерым исәпкә алынган. Елпачихада 517 ир-ат һәм шул кадәр үк хатын-кыз булып, «земля собственная, живут постоянно в селении», Усть-Тунтор (277 ир-ат, 255 хатын-кыз) - «на кочевья не выходят» дип, ә Искир (97, 90), Конюково (110, 111) авыллары турысында «К какой волости принадлежат» дигән графада «2 деревни этой юрты отнесены к Пермской губернии», дип искәртелгән (20. 199 б).

1754 елның 16 мартында указ чыгып, башкортлар тормышына зур үзгәреш кертелә - алар җир өчен ясак түләүдән азат ителеп, шуның бәрабәренә хәрби хезмәт башкарырга тиеш булалар. Бу хезмәтне алар Ырымбур линиясе дип аталган чик буенда регуляр булмаган гаскәр формированиесендә үтәргә тиеш булалар. Регуляр булмаган бу гаскәр кантоннарга, кантоннар юрталарга, юрталар авылларга бүленә, һәр авыл армиягә билгеле санда аты, коралы белән солдат бирергә тиеш була. Бу елына туксанышар тиен ясак түләүдән күп тапкырлар авырга төшә.

Безнең гәйнәләләр Русия дәүләтен Коньяк Себердән, Тубыл елгасыннан Урал елгасы буйлап Каспий диңгезенә кадәр, 1780 чакрымга сузылган Ырымбур линиясендә генә сакламаганнар. Аларны сәракларга ясалган походларда да, полякларга, шведларга, хәтта төрекләргә каршы сугышларга да җәлеп иткәннәр. Мәсәлән,алар 1805-1807 һәм 1812-1814 елларда Наполеон гаскәрләренә каршы сугышларда катнашканнар. 1836-1839 елларда, ягъни 24-27 ел үткәч алынган исәп буенча гына да Гәйнә олысыннан 1812 елгы Ватан сугышында ундүрт кеше катнашкан һәм «1812 елгы сугыш истәлеге» медале белән бүләкләнгән. Менә алар:

Үдиктән Ибниәмин Гаптыкаев,
Уймуждан Мөхәмәтрәхим Якшиев,
Федоркидан Солтанбәк Габдуллин,
Тауавылдан Каһарман Әширов (зауряд- хорунжий),
Бардадан Сәйфелмолек Мәхмүтов,
Сүкседән Тәхәви Сакаев,
Каенавылдан Әмкәй Муракаев (зауряд- йозбаш),
Яңа Бичуринодан (Озын Ялашан) Габделвәли Илмакачев,
Акбаштан Хәбибулла Акбашев,
Аклыштан Габдулла Савин,
Төнгүктән Габдулла Канчурин,
Сараштан Гаделша Әҗманов белән Хәбибулла Адилов.

20 нче санлы башкорт полкы составында алар 1812 елның ноябрь аенда Днепр арьягында Украина җирләрен дошманнан саклап торалар (22. 20, 26, 30 бб).

Башкортлар мәҗбүри хезмәткә алына башлаганчы да үз ирекләре беләнме, көчләпме төрле походларга йөртелгәннәр. Бу уңайдан Әхмәтзәки Вәлиди Туган Истамбул университетында укыган лекцияләрендә шундый кызыклы фактлар китерә. 1756-1763 елларда булган «җиде еллык сугыш»

заманында, мәсәлән, ук-җәя белән коралланып килгән башкортлардан, 15 мең кешедән, 12 башкорт полкы оештырыла. Алар беренчеләр сафында Берлинга керәләр, аларны анда мәхәллә һәм чиркәүләрдә тәртип саклауда файдаланалар. Боларын нишләп болай коралландырдыгыз, дип гаҗәпләнгән немецларга бер рус офицеры «Алар әле генә өйрәтелгән ерткычлар, мылтык бирсәң, сезне шундук үтерә башларлар», дип җавап биргән.

1798 елга кадәр башкортлар патша армиясенә үз ирекләре белән яисә көчләп солдат итеп кушылдырылсалар, моннан соң 17-45 яшьтәге барлык башкортлар хәрби хезмәттә булып исәпләнәләр. Аларга утлы корал бирелми, үз киемнәре саклана. Башларына графин рәвешле калфак, читләре өч җирдән теленеп, өскә бөкләнгән бүрек, өсләренә кулдан нәкышләп чигелгән кафтан кигәннәр.

Наполеонга каршы сугышта да алар милли киемнәрдә йөргәннәр. Борынгы һуннарны хәтерләткән бу «рус солдатлары» турында немец һәм француз язучылары кызык-кызык тасвирламалар язганнар, мәҗмуга һәм гәзитләрдә рәсемнәрен басып чыгарганнар. Башкорт солдатларын туган шәһәре Веймарда күрү атаклы немец шагыйре Һенрих Һейне өчен шәрыкъның килүе кебек тәэсир иткән, шул кызыксынуыннан Коръәннең бер өзеген немецчага тәрҗемә иткән, аңлаешсыз булса да, андагы каллиграфия язуына охшатып, рәсемен күчертеп эшләткән. Һейне башкортларның җитәкчеләре белән дә очрашкан, аларны театрда тәбрикләгән, башкортлар аңа ук-җәя бүләк иткәннәр. Бу бүләкне ул һәрвакыт өендә тоткан, хәтта 75 яшенә җитеп картайгач та бакчасында шул ук - җәядән атып кызык ясаган.

Шулай да Русия хөкүмәте башкорт гаскәрләренә һәрвакыт шикләнеп караган, күп тапкырлар аларны таркатырга уйлаган, ләкин никтер бу уен кичектереп килгән, санын киметү белән чикләнгән. 1840 елда гына күп кантоннар, шул исәптән безнең Гәйнә олысы да кергән I нче кантон, хәрби хезмәттән бушатылган. Ә 1872 елда аларны регуляр патша гаскәренә рекрутлыкка ала башлаганнар. (17. N 7. 178-181 бб).

## Файдаланылган чыганаклар:

1. История Урала. Том 1. Пермь, 1976.

2. Гайналеләрнең Мәскәүгә барулары. Риваять.

3. А.Н.Усманов. Добровольное присоединение Башкирии к русскому государству. Уфа, 1982.

4. Отчий край. Пермь, 1991.

5. А.А.Дмитриев. Пермская старина. Вып. 8. Пермь, 1900.

6. Его же. Житие святого Трифона Вятского как источник сведений о Перми Великой. Пермь, 1904.

7. П.Рычков. Опыт Казанской истории древних и средних веков. СПб, 1767. 8. Н.И.Шишкин. История города Елабуги. М., 1871.

9. П.П.Семенов-Тянь-Шанский. Россия. Полное географическое описание нашего Отечества. СПб., 1901.

10. С.Ф.Николаев. Кунгур. Пермь, 1958.

11. Материалы по истории Башкирской АССР. Том 1, ч.1. М-Л., 1936.

12. В.Шишонко. Пермская летопись. III период. Пермь, 1884.

13. И.Г.Акманов. Башкирские восстания. Уфа, 1993.

14. Г.Хөсәенов. Батырзар киссаһы. Уфа, 1986.

15. Н.Блинов. Заселение Закамья. Исторический очерк.
Сборник Пермского земства. 1898. N 34.

16. Кунгурская летопись Пиликиных. Пермь, 1886.

17. Зәки Вәлиди Туган. Башкортларның тарихы. «Агыйдел», 1993, N 1-3, 6-7.

18. Материалы по истории Башкирской АССР. Том 3. М-Л., 1949.

19. Оренбургская казенная палата. ГАРБ. Ф. 138, оп. 2. Арх. N 575.

20. Южноуральский археологический сборник. Вып. 2. Уфа, 1976.

21. В.Шишонко. Пермская летопись. 1-й период. Пермь, 1881.

22. Любезные вы мои. Уфа, 1992. Составитель А.З.Асфандияров.

# IY. Крылов утарын туздырудан Батырша хәрәкәтенә

Явыз Иван яулары Казанны басып алганнан соң татар-башкорт халыклары өчен чын- чынлап Ватан сугышы башлана. Баштагы чорларда бу сугыш Гәйнә иленә кагылмас кебек тоелса да, колонизаторлар якынлашканнан-якынлаша барып, якын- тирәләрдә крепостьлар төзелә башлагач, ягъни Русиягә кушылуның ни-нәрсә икәнлеген үз язмышларында татыгач, биредә дә коралга тотыну, каршылык күрсәтү турында уйлана башлыйлар.

Русия чикләрен киңәйтүдә, яңа җирләр «үзләштерүдә» чик-чаманы белмәгән Петр- патша хакимият башына килеп, көнчыгышта бөтен Азияне, көньякта Кавказны, Кырым, Төркияне, Иран, Һиндстан, көнбатышта Польша, Швеция, Норвегия, Италия, Франциянe яулап алу, бөтен дөньяга ия булу, башкаланы Истанбулга күчерү турында ниятләр корып, һәрьяктa сугышлар алып бара башлагач, бу каршылык тагын да көчәя. (Петр 1 нең бу ният-планнарын 1725 елда үзе язып калдырган һәм 1992 елда Русия гәзитләрендә мул басылган «Васыятнамә»сеннән укып белергә була). (1).

Ил эчендә дә, чик буйларында да крепостьлар төзү, зур армия тоту һәм туктаусыз сугышлар алып бару зур чыгымнар таләп итә. Төпсез казнаны тулыландыруның бүтән юлын белмәгән Петр патшага электән җыелып килгән салымнар гына җитми. 72 пункттан торган указын тоттырып, 1703 елда ул Казан сарае Приказына буйсындырылган халыклардан өстәмә салым җыярга дип Казан, Уфа һәм «бүтән ераккы калаларга» эмиссарлар, «прибыльщиклар» җибәрә. Мәет күмгәндә имән табут, калаша, мунча миллеге кулланган өчен, төтен чыккан һәр морҗадан, мәчеткә йөргән, никах укыткан, ясин чыгарган өчен, көтүдәге һәр малдан, ат-тай тиресеннән, дуга, камыт, тәртә, тегермән, бәке, капка, тәрәзә, баз... Нәрсә өчен генә салым җыймый Петр 1 җибәргән эмиссар- прибыльщиклар. Патша кушып җибәргәннәре өстенә алар үзләре дә берничә төр салым уйлап чыгаралар: сакал-мыек йөрткән өчен, күзләренең төсе өчен: соры күзлеләрдән—алты, кара күзлеләрдән—сигез алтын...(2, 31 б).

Патша указын аңлату өчен хөкүмәт вәкилләре Уфа янындагы Бәрсуан (Чесноковка) елгасы буена Минзәлә, Уфа, Исәт воеводалары старшиналарын җыялар. Указ тыңлаучыларда ачу һәм нәфрәт уята, ярсыган старшиналар указны ерткалап Агыйделгә ыргыталар, эмиссарларны куып җибәрәләр. Буйсынырга теләмәгән старшиналарны гаскәр көче белән алдырмакчы булалар. Гаскәр башлыгы Сергеев аларга әүвәл көчләп шәраб эчертә, исереп кар өстенә ауган кешеләр өстенә дары сибеп ут төртә. Бу вәхшилек өстеннән патшага шикаять язып, сигез старшина аны Мәскәүгә алып китә һәм... үзләре үк җәзага тартыла. Сигезнең берсе—Дөмәй

Ишкәев асып үтерелә (2, 33 б.). Бу исә яңа күтәрелеш кузгата, халыкның патшага булган ышанычын җимерә.

Һәм чит илләр, һәм үз иле халкы белән туктаусыз сугышлар алып барган, берсе белән дә килешүгә килә алмаган Петр патша тирән хафага төшә, җитмеш төрле салымнарның кайберләрен җыюны туктатып торырга мәҗбүр була. Ләкин татар һәм башкортларга карата репрессив чаралар, патшаның «башкорт халкын кырып бетерергә» дигән карары үз көчендә кала.

1718 елда 15 яшьтән 60 яшькә кадәрге морзаларны һәм йомышлы татарларны кораблар төзүгә (лашманчылыкка) язалар, салым түләүдән дә азат итмиләр, 1722 елда 10-12 яшьлек малайларны хәрби хезмәткә (кантонистлыкка) чакыру, массовый чукындырулар, яңа керәшен конторы оештырып, кораллы отрядлар белән халыкны канга батырулар, «татар тауарлары» белән сату итүчеләрне сәүдә эшеннән читләштерү, тимерчелек белән шөгыльләнүне (пычак, кылыч, хәтта дага һәм кадак ясауны ) тыю һ.б. Идел-Урал татарларын тәмам бөлгенлеккә төшерә, илсез-көнсезләргә әверелдерә. Һәм шундый шартларда, 1719 елда, Русия тарихында беренче мәртәбә халык санын алу (ревизия) башлана. Дөрес, бу эшне патша хөкүмәте элегрәк тә үткәрергә маташып карый, ләкин бөтен илдә җәелгән халык хәрәкәте моны ачыктан-ачык һәм бөтен ил буенча эшләргә ирек бирми. Салым җыю өчен үткәрелә торган бу кампанияне Гәйнә халкы көчләп чукындыру, җирләрен тартып алу өчен исемлеккә теркәү дип кабул итә. Казан өязеннән Каманы кичеп Уралга күчүләр башлана. Патша властьлары качкыннарны эзләп табып кире кайтарырга маташа, ләкин җирле халык Идел буеннан килеп сыенган оста һөнәрчеләрне, гыйлем таратучы зыялыларны хөкүмәт отрядларына бирми (3. N 21, N 134).

1723 елда Уфа провинциясе, шул җөмләдән аның составындагы Гәйнә олысы, Казан губернасыннан алынып, турыдан-туры Сенат идарәлегенә буйсындырыла. Патша бу төбәк халкын буйсындырып-изеп тоту өчен махсус программа эшләп китерергә боера. Мондый программаны патшабикә Иоанна остәленә беренче булып Себер һәм Казан губерналарындагы казна заводлары башлыгы В.Татищев (мөселманнарны чукындыру турында), аның артыннан 1730 елда Казан губернаторы А.П.Волынский китереп сала. «Россия империясендә башкорт мәсьәләсе турында язма» дип аталган бу программа халыкларны (татар-башкортларны, калмык һәм кара-калпакларны) үзара сугыштыру, кулына мылтык алган мөселманны үлем җәзасына тарту, башкортларны төрле походларга, хөкүмәт эшләренә җәлеп итеп, аларны сан ягыннан киметү, алар җирендә регуляр гаскәр урнаштыру кебек чаралар тәкъдим итә. (4.142 б).

Алардан соң чукынган татар морзасы сатлыкҗан Алексей Тәвкилев (Котлымөхәммәт Тәвәккәл улы Мәмәшев) белән Сенат оберсекретаре Иван Кириллов, Волынский программасын тагын да киңәйтеп, шундый проект тәкъдим итәләр:

—Казах һәм башкорт җәйләүләре арасыннан аккан Ур (Орь) елгасы буенда көчле крепость төзергә, соңыннан Җаек елгасының бөтен буен хәрби крепостьлар һәм гарнизоннар белән ныгытырга;

—татар һәм башкортлар белән Урта Азия мөселманнары арасында ызгыш-талаш тудырырга, шулай итеп аларның һәркайсын сан ягыннан киметергә;

—Уфа провинциясендә аяусыз чукындыру сәясәте алып барырга;

—татар-башкорт старшиналарын вак-төяк бүләк бирү юлы белән хөкүмәт ягына аударырга, алар арасында да дошманлык уятырга;

—заводлар төзүне тизләтергә (2.45 б).

1734 елда шушы программаның авторлары «Ырымбур экспедициясе» дигән исем астында колонизация походының олы түрәләре итеп тәгаенләнәләр. Август аенда Мәскәүдән чыгып, ноябрьдә экспедиция Уфага килеп җитә, шунда Кириллов белән Тәвкилев провинциягә караган барча олысларның старшиналарын үзләре янына җыялар. Экспедиция түрәләре төп максатларын күпме генә яшермәсеннәр, старшиналар серне белеп алалар. Аны Петербургтан тышкы эшләр коллегиясендә тылмач вазифасын үтәгән башкорт старшинасы Токчура Әлмәк улы астыртын ым белән болай хәбәр итә: «Бодайны (халыкны, гаскәрне) буш орлыктан һәм чүп-чардан (хыянәтчеләрдән) аралап, язга кадәр дүрт юртакны да (провинциянең 4 даругын да) походка әзерләп куегыз».

Шундый кисәтү алыну белән һәр тарафка җәбер-золымга каршы оешырга дигән боерык тарала. Кириллов-Тәвкилев командалыгындагы экспедицион корпус кая гына юл тотмасын, һәркайда каршылыкка әзерләнкләүгә очрый.Экспедициянең хәлен ике тапкыр министрлар кабинетында кинәшмә җыеп тикшерәләр һәм Уфа провинциясен яңадан Казан губернасына кушарга мәҗбүр булалар. Экспедицион корпуска өстәп өч регуляр полк оештырыла, Мусин-Пушкин урынына губернатор итеп А.И.Румянцев билгеләнә һәм аңа чикләнмәгән вәкаләтләр бирелә.

Кириллов, Тәвкилев, Татищев командалыгында җәза отрядлары теркәлеп, Тәвкилев җитәкчелегендәгесе безнең якка—Оса дәругына җибәрелә. 1736 елның гыйнварында ул Бөре крепостеннан ерак түгел Саянтусы авылында 105 карт-корыны, хатын-кыз һәм бала-чаганы амбарга тутырып яндыра, меңләп кешене кылыч белән чапкалап үтереп, Тол буена килеп чыга. Июль аенда полковник Мартаков отряды (шул ук Тәвкилев командасыннан), Оса тирәсендә хәрәкәт итеп, урыс авылларына һөҗүм иткән, Осаның үзен камалышта тоткан Төлкечура Алдагулов отрядларын әзерләкләп, Барда елгасына кадәр килә һәм шунда үзе дә яраланып һәм пушкаларын ташлап качарга мәҗбүр була (3).

1735 - 1738 еллардагы баш күтәрүләр турында Татищев 1739 елның 2 февралендә патшабикә исеменә шатлык һәм горурлык хисе белән шундый рапорт бирә:

«Уфа провинциясенең иң куркыныч ике юлы (урыс кешесе «дәруг» сүзен үзенчә «дорога» дип аңлаган һәм урысча китапларга ул шулай кереп киткән): Нугай һәм Казан юллары шул тикле туздырылды, анда элек яшәгән халыкның хәзер, мөгаен, яртысы да калмагандыр. Оса һәм Себер юлларында халык ул кадәр үк кырылмаса да, аларның һәркайсы диярлек атсыз һәм мал- туарсыз калды, авыллары яндырылды, анарларына булмау

сәбәпле халык ачлыктан үлеп бетте. Бу кадәрле югалтулардан соң мондагы халыкның яңа фетнәгә күтәрелә алуы бик икеле. (2, 3, 5).

Урысларның булачак тарихчысы В.Н.Татищев шулай мактанган. Шушы кыска гына чорда Казан губернасында меңнәрчә авыллар яндырылган, кырык меңләп кеше үтерелгән. Бу саннарның күпмесе Гәйнә иленә карыйдыр - бусын ачыклыйсы бар.

1730 елда Уфа провинциясе кәнсәләре төзегән реестрда бәян ителгәнчә, Тол буендагы Гәйнә олысы әз-мәз чәчүлек җирләре булган, урманнарга бай төбәкне хасил иткән. Урман артындагы бу төбәккә Уфа ягыннан 60 чакрымлап арба юлы да булмый, шуңар провинция үзеннән анда кадәр ничә көнлек юл булуын камердинер Ф.Жилин белән Уфа кешеләре С.Третьяков, И.Гавренев әйтә дә алмыйлар. Ләкин калын урманнар, таулар һәм сазлыклар да гәйнәлеләргә үзләренчә, тыныч яшәү мөмкинлеге бирми. Килергә юлы булмаса да, патша чиновниклары аларны эзләп табалар, писцовый кенәгәләргә кертәләр һәм, ничек җан асраулары белән исәпләшеп тә тормастан, ясагын да, мең төрле бүтән салымын да каерып алалар, зарлануларга колак салучы да булмый.

«Башкортстан АССР тарихы буенча материаллар» да XYIII гасыр уртасында Ырымбур комиссиясе начальнигы В.Н.Татищевка Оса даругының барлык олыслары старшиналарының Доношениесе басылган. Бу Доношениегә Гәйнә олысы старшинасы Баряс Табанаев та тамгасын салган. Доношениедә урыс чиновникларының һәртөрле кыерсытулары, тиеш булмаган салым җыюлары, талаулары санап кителә. Һәм шушы Доношениешикаятьтән соң ук Уфа воеводасы кенәз А.П.Волынский Себер һәм Оса даруглары башкортлары остеннән үзе доношение яза:

«...Бөек государебез Алексей Михайловичка хыянәт итеп, алланы онытып, - дип зарлана кенәз, - алар чиркәүләрне, авылларны яндыралар, дошманлык кылалар» (3).

1736 елның 11 февралендә Уфа өязендә һәм башкорт авылларында тимерлекләр булдыруны тыю турында исемле Указ (XYIII гасырда икенче тапкыр) чыга. Баш күтәрүчеләрне коралсыз итүгә юнәлтелгән бу Указ да халыкның ачуын гына көчәйтә. 1737 елның җәендә янә крәстиәннәр хәрәкәте башлана. Янә Крыловога, Рождественскийга һөҗүм ясала, Осадан ун чакрымда 200 солдат һәм гренадердан торган отрядка каршы сугыш булып ала. Ганлей авылы янында ун урядник һәм солдат үтерелә, отряд «зур кыенлык белән, төнләрен генә хәрәкәт итеп, яңа һөҗүмнән котыла». Янә бөтен Тол буе хәрәкәткә килә. Күңгер ягының «баш караклары» Бепеня, Мәндәр һәм Төлкечура белән элемтәгә кереп, алар урысларга хезмәт итүче мишәрләр яшәгән авылларны яндыралар. Тол буе баш күтәрүчеләренә Әй буеннан ярдәмгә киләләр, юл уңае алар да урыс авылларын яндыралар. Түбән Мол буена, Строгановлар приказына, Юговской, Ягошиха заводларына һөҗүмнәр ясала.

1739 елның җәендә Искәвыл (Карьяу) четверте татарлары «башкортлар Урал аръягында, теге чактагы (1639 елдагы) җыелган урыннарында яңадан очрашырга үзара килешкәннәр» дигән хәбәр алганнар.

Уфа провинциясе кәнсәләре Гәйнә олысын хөкүмәт армиясенә азык-төлек, фураж җыю өчен иң уңай район итеп исәпли һәм бөтен провинция ихтыяҗларын аның өстенә аударырга уйлый. Мондый карашның реаль түгеллеген гади халык кына түгел, ә күп җир биләүче феодаллар да белә һәм алар да моңа ризасызлыкларын белдерәләр. Туктамыш Ижбулатов закон чыгару комиссиясенә тапшырылган бер наказында, бу кадәр азык-төлекне һәм фуражны бер олыстан гына җыеп булмасын раслап, крәстиәннәрнең бер олыстан икенчесенә күчеп йөрүләренә зарлана. Бигрәк тә көньяк олыслардан төньякка таба күчүчеләр күп була. 1739 елда Гәйнә олысында 214 хуҗалык булса, 1772 елда ул 795 кә җитә, ә күрше Уран олысында исә 678 дән 226 га кала. Бер олыста исәптә торып, икенчесендә налог түләүчеләр күп, дип зарлануын дәвам итә Туктамыш Ижбулатов, бу исә команда эшләрен башкаруны, налог җыюны кыенлаштыра, ди ул. Мондый хәлдән котылу өчен ул, үзенең закон чыгару комиссиясендә депутат булуыннан файдаланып, хөкүмәткә һәр 200-300 хуҗалыкка бер старшина билгеләүне үтенеп наказ белән керә (6.31 б). Ләкин аның бу үтенече кабул ителми, олыс белән идарә итү авырлашканнан-авырлаша, крәстиәннәр хәрәкәте кызганнан-кыза бара.

1735 елда Килмәк абыз, 1740 елда Карасакал җитәкчелегендә хәрәкәтләр башлана. Патша гаскәрләре аларны коточкыч катылык белән бастыралар: 1735-1740 елларда восстаниедә катнашкан 696 татар һәм башкорт авыллары, шул исәптән, Гәйнә олысының унбер авылы яндырыла, 16893 кеше үтерелә, 9194 хатын-кыз һәм бала-чага алпавытларга коллыкка таратыла. 3406 кеше каторгага җибәрелә. Штраф итеп 18359 баш терлек, 9828 сум 29 тиен акча алына. Безгә бу мәгълүматларны урыс галиме П.М.Рычков язып калдырган. Шул ук галим, ул чакта Карасакал җитәкчелегендәге хәрәкәтне бастыру комиссиясе секретаре, кенәз Урусов белән башкорт кешесе алдында мактанып та алалар:

— Бүтән халыклар (татар-башкортлардан кала) сезнең шикелле беркайчан да мондый олы яу кубармады. Шунысы дөрес: жалу язырдай укый-яза белгән башкортларның берсен дә калдырмый кырып бетердек. Хәзер һәрбер башкорт үзенә-үзе дошман һәм халыкны харап итүче (7).Ачлык, хәерчелек, кимсетелүләрнең соңгы чигенә җиткерелгән халыкка карата мондый явызлык вә вәхшилек Көнчыгышның төрки халыкларында көчле ачу һәм нәфрәт тудыра, һәркайдан урыс хөкүмәтенә каргыш-бәддога ява.

1735 елда үз җирләреннән куылган, качып киткән кешеләрне солдатка алу, 1736 елдан мишәрләрне, 1739 елдан типтәрләрне башкорт общиналарына оброк түләүдән азат итү, 1735 елда татар һәм башкортларның үзара никахка керүен, дуслашу-туганлашуын булдырмаска тырышу, чикләү-тыюлар, башкорт җирләрен урысларга сатып алырга рөхсәт итү, урыс булмаган крәстиәннәрдән икмәкләтә салымны ике мәртәбә арттыру, алардан чукынганнар өчен дә налог түләтү һ.б. турында указлар чыгу, мәчет- мәдрәсәләрне җимерү, чукынырга теләмәгәннәрне кыйнау, йорт-

ларын җимерү һ.б. халыкны тәмам бөлгенлеккә төшерә, чарасыз калдыра (9).

1742 ел 19 ноябрь указы белән бер Казан өязендә генә 536 мәчеттән 418 е ватып- җимереп ташлана (10.44 б). Бу вәшхилек 1733-1743 елларда Тайсуган (Татарстанның хәзерге Әлмәт районы) һәм Ташкичү (Арча районы) авыллары мәдрәсәләрендә укыган Абдулла Гали улы кебек шәкертләргә, күрше губерналар мөселманнарына нык тәэсир итә. 1736 елның җәендә күп мишәр авыллары, Строганов вотчиналары яндырыла. Бөтен Оса өязе кайный, шәһәр үзе камалышта тотыла. 1737 елда бу хәрәкәткә старшиналар да кушыла. 1754 елда болай да кызган атмосфераны ахыр чигенәчә кыздырып, халыкларны үртәгәндәй патша хөкүмәте тозны хөкүмәттән сатып алырга мәҗбүр иткән указ чыгара. Бу исә ачык ярага тоз салу кебек роль уйный.

Башкорт һәм татарлар моңа кадәр тозны алла биргән күлләрдән һәм таулардан налог түләмичә алганда барысы 4392 сумнан артык ясак түләгән булсалар, яңа закон буенча тозны казнадан сатып алып, алар 14-15 мең сум чыгым ясарга тиеш булалар (10, 51 б). Халыкның түземлеге текәнә, һәркайда көрәшкә өешү, кораллану башлана.

Гәйнә олысыннан ерак түгел Себер дәругына караган Карыш авылында балалар укытып яткан Абдулла Гали улы «Бу тикмәгә генә түгелдер, монда бер хикмәт бардыр, бу серне мин аңламак тиешмен», дип нәтиҗә ясый һәм балалар укыткан мулла 1754 елда ил-көн арасына халык рухын өйрәнергә чыгып китә, Исәт провинциясе Мөслим авылында, күрше Салйогыт олысында була. Ике ай чамасы ялгызы гына да, 60-70 атлы мишәрләр белән дә авылдан-авылга йөреп, халыкның яуга әзерләнүен үз күзе белән күреп кайта. Җәй җиткәч, аның үзенә төрле өяз һәм олыслардан вәкилләр, шул исәптән ике тапкыр ике-өч юлдашы белән Гәйнә олысыннан Исхак мелла Морзалиев килеп китә. Мирас малы бүлү сылтавы белән халыкны көрәшкә өндәү өчен Батырша янә авылларга чыга, шул җөмләдән Гәйнә олысының Төңгүк авылында әлеге Исхак меллада «кунак» булып кайта. Кайта да халыкка өндәмәләр язарга утыра. Батырша аларны «Тәхризнамә - кыздырмак вә үгетләмәк язуы» дип атый. Бу өндәмәтәхризнамәләрне ул үзе йөреп тә, шәкертләре ярдәмендә дә бөтен Урал төбәкләренә тарата.

Ә кем соң ул халыкта Батырша (Батыр шаһ) буларак дан алган Абдулла Гали улы? Башкорт галиме И.Акманов аның исеме Гобәйдулла (12. 13 февраль), А.Дмитриев фамилиясе Мязгилдин булырга тиеш ди (11. 100 б.). Абдулла-Гобәйдулла Гали улы Мязгилдин 1709-1715 еллар тирәсендә Уфа провинциясенең Себер дәругына кергән Карыш авылында туган (Башкортстанның Балтач районы Карышбаш авылы). Башлангыч белемне Абдулла үз авылындагы мәдрәсәдә ала. Аннары Казан губернасы Зәй елгасы буендагы Тайсуган авылында Габделрахман мулла мәдрәсәсендә, соңрак Алат юлындагы Ташкичү авылында мулла, азак ахун дәрәҗәсенә күтәрелгән Әпсәләм Ураев мәдрәсәсендә укый. Укуын тәмамлагач, 1744-1745 елларда Гәйнә олысының Илеш мулла мәдрәсәсендә (Байавылда),

1741-1749 елларда Исәт провинциясендә мишәр старшинасы Мөслим авылында балалар укыта һәм муллалык итә. Балалар укыту өчен ул үз авылында да мәдрәсә тота. 1754 елда аны Себер даругына ахун итеп билгеләмәкче булалар, ләкин Батырша моңа риза булмый, сатлык җаннар рәтенә басып, халык җилкәсенә утырудан курка.

Батырша гомумән күп йөргән, Казан, Уфа, Ырымбур, Троицк якларында күп мәртәбәләр булган, старшиналар аркылы хокүмәт органнарының нинди чаралар күрүен өйрәнгән. Халык күтәрелгәнче үк әле аларның хәрәкәтне бастыру өчен коралды отрядлар оештыруын белгән, ләкин анда да куркып калмаган, коралланса, аннары халык ягына чыгарлар, дип өмет иткән.

«Тирән белеме, үткен фикере өчен халык аны галим дип йөрткән. Ул батыр йөрәкле, физик көчле, диспутларда да, көрәшләрдә дә җиңелмичә торган кеше булган. Дошманнарына каршы көрәштә үзен батыр оештыручы итеп таныта алган. Шуның өчен халык аны Батыр шаһ (Батырша) дип атаган», дип яза аның турында мәшһүр галимебез Сәләм Алишев (10. 46 б).

Батырша хәрәкәтенең бер учагы Нугай даругында, Бөрҗән якларында булса, икенчесе безнең Гәйнәдә булган. Шушы ике төбәк күтәрелүгә бөтен Казан, Оса, Себер,Нугай даруглары хәрәкәткә кушылыр дип уйланылган.

1755 елның март аенда Батырша бөтен Урта Урал, Идел буе халыкларын восстаниегә чакырып программа төзү эшенә керешә. Ике ай утырып язган программасы әзер булгач, ул янә юлга чыга, Исәт, Нугай якларын урап кайта, янә Гәйнәгә килә. Бирегә ул «Мирас малы бүлү өчен» Төңгүк авылына чакырылган була. Җаен чыгарып, бер аулак өйдә Чурагол мулла Миңлебаев, элекке шәкерте Исхак Морзалиев (Аклыш), Әндәрша улы Акбаш, Теребирде улы Мостай (1 Әрҗән) һәм тагын берничә якын танышы белән очрашу-мәҗлес үткәрә, үзенең өндәмәсе белән таныштыра. Мәҗлес яуга күтәрелү көнен, ул көнне кемнең ни нәрсә эшләргә тиешлеген билгели (13. 355 б). Гәйнәлеләр билгеләнгән көндә (3 июльдә) күтәреләчәкләренә ышандыралар. Батырша аларга сезнең олыстагы хәрәкәткә үзем җитәкчелек итәрмен дип вәгъдә бирә.

Шушы киңәшмәдән соң Батыршаның ярдәмчеләре, үгетләүчеегетләүче (агитаторлары) Чурагол Миңлебаев, Исхак Морзалиев, Акчура Ягутеев, Нури Боскунов, Мостай Теребердин һәм Акбаш Андрушев (Әндәрша улы), авылларга таралып, халыкка восстаниенең бурычларын аңлаталар. Солтанай авылында Сәгыйть Чубаркин ратницалар әзерли, сугыш уеннары оештыра.

Тол буе авылларында барган бу эшләрне Ирән буе авылларында да ишетеп, белешеп торалар, күреп кайту өчен үз кешеләрен җибәрәләр. «Гәйнә иләүендә Быково авылы урыслары, йортларын ташлап, бала-чагалары белән Ачит кальгасына качканнар, Ирән буе татарлары Уинск бакыр заводына һөҗүм иткәннәр, Торговиж һәм Сокольск хәрби ныгытмаларын камаганнар», дигән хәбәрләр таралган (13. 355 б).

Июль башында Чурагол Исхак белән Көчекбайны «Гәйнә ягы күтәрелергә әзер» дигән хәбәр белән Батыршага җибәрә. Батырша аларга

ашыкмаска, үзенең Ырымбурга йөреп кайтуын котәргә куша. Нугай юлында хәрби командалар йөрүе беленгәч, Исхак, акчура Ягутеев белән Нури Боскуновны няртеп, янә Батыршага китә. Чурагол аларга бу юлы күтәрелү конен ачыклау белән бергә Солтанайдан Әмир Суримовның, Бишмәчедән (Өчметче) Хәсән исемле кешенең шундый үтенечен дә тапшырырга куша: безнең гәйнәләләр мишәрләрнең яуга күтәрелүләренә ышанып бетмиләр, сез безгә халыкны күтәрергә ярдәм итү өчен үз кешеләрегезне җибәрегез.

Шушы очрашу вакытында восстаниегә күтәрелү көне итеп 1 сентябрь билгеләнә. Батырша, гәйнәләләрнең бу торкеменә няртеп, дүрт шәкертен (Исмәгыйль Апкин, Әхмәр Кучумов, Ураскол Исламов, Мәсгут Айсины) җибәрә. Бу дүрт вәкил Тоңгуктә Чурагол мулла өендә туктала. Алар артыннан ук восстаниечеләр җитәкчеләре Мостай белән Акбаш та килеп керәләр. Алар үзләренең Абдюк Хуҗагол старшинаны үтерүләрен хәбәр итәләр. Билгеләнгән көннән иртәрәк һөҗүм башлауларын Абдюкның баш күтәрүчеләр өстеннән Осага һәм Уфага донос ясавы һәм үзләренә каршы отряд туплауга йөрүе белән аңлаталар (12, 13).

Г.Хосәенов бу үтерүне Башап белән Сараш арасындагы елга аша салынган күпер янында булган итеп тасвирлый. 27 август көнне Абдюк старшина губернатор указын укып аңлату һәм шул тирә авыллардан отряд туплау нияте белән Сарашка барырга чыга. Башап күпере янында аның юлына бериччә коралты чапкын аркылы төшә һәм аны, арбасыннан өстерәп төшереп, хәнҗәр белән чәнчеп үтерәләр. (14. 57-63 бб.)

Җәмит Рәхимов романында Абдюкка үлем карары олыс үзәге Кызыльярда (1 Әрҗәндә) баш күтәрүчеләр җыенында кабул ителә, һәм ул шунда кызу кулдан ясалган дар агачына асып үтерелә (13. 356-358 бб).

Указ дип, чиратлы-чиратсыз походларга кузгаткан, шул сылтау белән тиешеннән күпкә артык акча җыйган старшина халыкта күп ризасызлыклар тудыра. Абдюкка кадәр байтак еллар старшина булып торган Ишбулатны-кылар да күралмый аны. Башта алар аны үз якларына аударырга маташып карыйлар. Бу эшләре барып чыкмагач, аңа үчле кешеләрне үз тирәләренә җыялар, сабантуй исеме астында ярым яшерен җыен җыеп, халыкны Абдюкка буйсынмаска өндиләр. Абдюк шулай да Туктамышның анда ниләр сөйләгәнен белә һәм халыкны патшага каршы котырта дип, өяз һәм губерна түрәләренә донос ясый. Туктамыш та тик ятмый - Өфе приказына рапорт бирә (14. 59 б).

Абдюкның үтерелү хәбәрен ишеткәч тә, 28 августта Туктамыш Ижбулатов Каҗмактыда җыен җыя, үзен старшина итеп сайлата. Бу җыенда ул:

— Сараш, Солтанайлар яуга җыена. Безгә анда кушылмау хәерле. Яу-фетнә белән элек тә уңмадык, фәкать зыян күрдек. Мал- мөлкәтебезне саклап, безгә бу яуны туктатырга, иләүне үз кулыбызга алырга кирәк,— дип чыгыш ясый һәм 150 ләп коралты җайдак белән баш күтәрүчеләр җыелган урынны камап ала.

Нури Боскуновның Уфада сорау алганда биргән җавабыннан бу җыенда Солтанайдан Күчем һәм Таңгилде исемле кешеләр, Сараштан алты кеше, Аклыштан Мостай,Башаптан Акчура Ягутеев, Сояргол һәм Теленбай Иман-

голов, Кызылъярдан (ягъни 1 Әрҗәннән) Акбаш белән Мостайларның (барлыгы кырыклап кеше) катнашканлыгы билгеле. Җыен төнлә уздырылганлыктан Нури Боскунов аларның барысының да йөзләрен күрә алмаган. Җыен Батыршага ярдәмгә барырга, Яныш старшинаның восстаниечеләрне бастырырга дип туплаган отрядын тар-мар итәргә дигән фикергә килә. Оса, Күңгер юнәлешендә походка әзерләнү турында сүз алып бара һәм һич көтмәгәндә «Коралларыгызны ташлагыз, өйләрегезгә таралыгыз!» дигән боерык ишетә. Бу Туктамыш Ижбулатовның боерыгы була (13.359 б).

— Нишлисең син, Туктамыш! Безне сатлык җаннарга каршы котырттың да инде үзең дә Абдюк кебекләр ягына авасыңмыни? Әллә шаяртасыңгынамы?

Юк, шаяртмый икән олысның яңа старшинасы. Башта көндәше Абдюк старшинаны болачылар кулы белән юк итү өчен генә алар яклы булып йөри ул. Туктамыш старшинаның асылы, уникe елдан соң, әби патша Екатерина-Саниянең законнар чыгару комиссиясенә депутат булып сайлангач, аннан да бигрәк Пугачев хәрәкәте чорында тәмам аңлашылыр. Әлегә ул баш күтәрүчеләр җыелышын тарату белән чикләнә. Дөрес, шул вакытта хәрәкәт җитәкчеләренең берсе — кызу канлы Мостай үтерелә, ләкин ыгы- зыгыда аңа кем угы килеп кадалганын белүче булмый.

Гәйнәдәге бу хәлләрне Батырша да белми. Үзе җибәргән дүрт шәкерте суга төшкәндәй юк була. Ни булганын белешү өчен җибәргән ике шәркерте дә уң конлән кайтмый. Әнә шундый борчулы көннәрнең берсендә Гәйнәдән Карышка бер чапкын килеп төшә һәм Батыршага хат тоттыра. Ул хатта гәйнәлеләрнең икегә бүленүе, «динсез монафиклар»ның Батыршаны кулга алырга чамалаулары, аңа йә «бик тизлек берлә яшеренеп торырга, йә 50-60 кешелек отряд белән ярдәмгә килергә» киңәш ителгән була.

Батырша бу киңәшләрнең беренчесен — «башыгызны коткарырга җәһәтләнегез» дигәнен сайлый: восстаниегә җитәкчелек итәсе урынга, ул өч баласы белән хатыны Зөлхәбирәне һәм берничә шәкертен ияртә дә урманга кача. Моның сәбәбен ул кулга алынып, Мәскәү төрмәсендә ятканда Елизавета исеменә язган хатында болай аңлата:

«Ул төнне йокламадым. Таң атканда күрдем: йортым тирәсе, авылым тулы халык. Йөз илле микдаре кеше кораллар белә хәзер торалар. Хәвефкә төштем: бу кадәр халыкның эчендә миңа дошманлык итәр кешеләр дә бардыр, дип... Ахыр начар улып, бер ходаема тәвәккәл итеп, җәмәгатем вә талмидларым (шәкертләрем) илә алты садак, бер сөңге коралларымызны алып, ул халыкның уртасыннан чыгып киттем. Алты чакрым урманга еткәнче сәламәтлек берлә озаттылар. Без урманга кердек, алар кайттылар. Белдем: ул халык арасында безгә дошманнар юк икәндер» (14, 15, 16, 17).

Урманда, мәчет аслары һәм түбәләрендә кыш уздырып, коры сөяккә һәм ялгызлыкта калган Батырша патшага бармакчы була, моның өчен ул Сөләйман старшина яшәгән Әҗәк авылына (Башкортстанның Борай районы авылы) барып, 1756 елның 8 августында властьлар кулына бирелә, үзе турында Уфага хәбәр итүләрен сорый. Бик каты сак астында аны

Уфага, Уфадан Ырымбурга озаталар. Юлда саклап алып баручылар аңарга гәйнәләләрнең аны коткарырга дип куа чыгуларын, ләкин бер кичүдә өлгерә алмауларын сөйлиләр. Икенче бер чыганакларда Чурагол җитәкчелегендәге төркемнең Батыршаны урманнарда эзләп йөрүе, ләкин аның эзенә төшә алмавы, урманнан чыккач, каратлар (карательләр) кулына эләгүе турында әйтелә. Чурагол әнә шунда тотылып, Осага кайтарылган булса кирәк.

Батыршаны коткарырга дип юлга чыккан, ләкин бер кичүдә өлгерми калган төркемдә без Чурагол Миңлебаев, Исхак Морзалиев, Мостай Теребердин, Акчура Ягутеев, Нури Боскуновлар булгандыр дип әйтә алабыз.

Батырша хәрәкәтендә катнашучылар арасында шулай ук Күңгер өязе кешесе Дәүләтбай Хуҗаголов, Таныптан зур гына төркем (Баскын Юртбагишев һ.б.) күрсәтелә. Җ.Рәхимов романында язылганча, Дәүләтбай Хуҗаголов (автор аны Кәҗәголов дип ала), Көчекбай Имәнколов, Нури Боскунов, Чурагол Миңлебаевлар Батырша белән бергә урманнарда качып йөриләр, Чурагол «азык- төлек юнәтергә дип авылга җибәрелә һәм шул сәфәреннән Батырша янына әйләнеп кайтмый. Акчура аты-ние белән качып китә» (13. 368 б.)

Ырымбурда Батыршаны губернатор Неплюев алдына бастыралар, аннары кул-аягын богаулап, иллегә якын драгун һәм атлы казаклар сагында 24 олау белән Петербургка озаталар. Юлда Батырша патшага үз иркем белән барырга тиешмен дип, богауларын өзеп, качарга да уйлый, ләкин төшендә күргәнчә, бер ачык җирдә зур елгага туры килә, тәкъдиремә туры килгәне шулдыр дип, артыннан килүчеләрне көтеп ала һәм, юлда авырап, ә бәлки шушы урында кыйналыптыр, берникадәр вакыт Мәскәү төрмәсендә тотыла. Шунда утырганда 1756 елның 4 ноябреннән 24 ноябренә кадәр патшага бирү өчен 150-160 биттән торган хат яза. Бу хатны укып, патшабикә халыкның чын хәлен аңлар, аны җиңеләйтү чарасын күрер, дип өмет итә ул. Ләкин аның бу хаты патшага җиткерелми, Батыршаның өмете акланмый (15, 16, 17).

Шулай да Батыршаның бу хаты зур әһәмияткә ия: узган гасыр рус тарихчысы С.М.Соловьев аны «үз мажараларының кызыклы хикәясе» дип атый. Юк, ул гади хикәяләү генә түгел. Ул безгә XYIII йөз урталарында булган халык күтәрелешенең сәбәпләрен аңларга ярдәм итә. Без - гәйнәләләр өчен «зар еларлык,-гыйбрәт алырлык» бу хатның үзгә әһәмияте бар: анда безнең яклар турында күп мәгълүматлар, кыю егетләре турында күп мактау сүзләре әйтелгән. Менә бер мисал: Уран ягында (Уртавылда) җыелып сөйләшкәндә «урман ягы кешеләре» (Чурагол, Исхак, Акбаш һәм Мостайлар) безнең як кешеләре турында Батыршага болай дип сөйлиләр:

— Безнең урман тарафлы халаекларымыз... гаять пәһлеваннардыр вә һәм ук атарга гаять мәргәннәрдер. Кыркар-иллешәр тиеплек җәйәләремез ялан башкортларының унар, егермешәр сумлык әдернә җәйәләреннән дә артыкдыр, аның өчен никадәр эссе көн булса да, атышкан саен куәтләнәдер, аткан укларымыз һәр гиз кейеккә туктамайдыр. Вә һәм чаңгы

берлә йөрергә шул кадәр осталар, урман эчендә качкан киек котылмайдыр. Алдында аркылы яткан ат биеклеге агачларны сикереп чыгалар, юлдан җилгән чаңгылы кешеләремезгә җитмәйдер» (14, 15,16).

«...Ел ярым микдаре Гәйнә илендә Илеш мулла авылында тордым», дип яза Батырша хатында. Илеш мулла авылы - ул Байавыл- Куземьяр. Биредә Батыршаның күп дуслары, сердәшләре булган.

Батыршаның бу хаты безгә халык телендә сөйләнеп йөргән күп вакыйгаларга ачыклык кертә. Мәсәлән, ул бер урында, Гәйнә кешеләренең ишеткәнен кабатлап, болай яза: «Узган еллар мәгркәсендә Гәйнә иләүенең уртасына меңләгән урыс булкы (полкы) килеп, арбадан кәлгә сукуп ятдылар, Гәйнәне чабар өчен. Шул вакытта безнең гәйнәләр түрт йөз кадәре кеше ук- сөңге берлә урысның өстенә чабып, кәлгәсен алыб, тәмам урысны кырдылар вә тубларыны кулга төшерделәр. Ярашу булганнан соң тубларыны килеп алдылар. Урман халкы пәһлеванлыкка ялан халкы булмас имди» (16. 140 б).

Батырша биредә Зимас Абдалов отряды турында сүз алып бара. Бу отряд 1737 елда Осаны камалышта тота, аның тирәсендә татар-башкорт авыллары урынында салынган рус авылларын яндыра, Барда елгасында үзен эзәрлекләгән җәза отрядын тар-мар итә.

Батырша гәйнәлеләргә зур өметләр баглаган. Чыгышларында «Гәйнә ягында биш йөз мишәр вә мең типтәр атларга менәргә әмер генә көтә», дип сөйләп йөргән. Шуннан, Гәйнәдән торып, ул баскынчы- кяфырларга каршы көрәш утын Кама буйлап Казан ягына күчерергә хыялланган. Ләкин аның бу планы тормышка ашмый: билгеләнгән көнне көтеп алырга халыкның түземлеге җитми, һәр очракта оешмаган төстә, билгеләнгән көннән алда күтәрелеп чыга.

20 сентябрьдә Оса дәругына, Гәйнә олысына хокүмәт көчләре килеп тула, хәрәкәттә актив катнашканнарны кулга алулар, аларның игенпечәнен яндырулар, мал- туарын тартып алулар башлана (6).

Батыршаның иң якын көрәштәшләре Чурагол Миңлебаев, Нури Боскунов, Исхак Морзалиев, Акчура Ягутеевлар кулга алына, баш күтәрүчеләрнең иң актив җитәкчеләреннән 15 кеше (Исхак мелла Морзалиев, Кочекбай Иманголов һ.б.) кочле сак астында Петербургка, яшерен кәнсәләргә озатылалар. Чурагол Оса төрмәсендә сорау алу вакытында кыйнап үтерелә. «Тикшерү барышында Чураголның өендә Батыршаның үз кулы белән восстаниегә чакырган язуы табыла», анда аның Бардадан Рахманкол Итеев һәм Атҗимас Абдаловны баш күтәрергә өндәве ачыклана. Батырша белән Чурагол арасында элемтәче ролен үтәгән Исхак Морзалиев Уфада сорау алу вакытында Чураголның фетнә күтәрү хакында бик күпләр белән — Сараштан Мирас, Каҗмактыдан Арслан Сөенголов һәм Рахманкол Итеев, Төңгүктән Чура Юнысов һәм Мостафа Үпәнкәев, кайчандыр Батыршадан дәрес алган Бәшир Илеманов, Абделхәер Камакаев, Абдерразах, Солтанайдан Әмир Суримов, Бишмәчедән Хәсән исемле кеше белән очрашып сөйләшүе һәм аларның барысын да үз ягына аударуы турында сөйли (9).

Батырша, Балтик диңгезендәге Шлиссельбург крепостендә биш ел утырганнан соң, камерасыннан чыгып, каравылчылар бүлмәсенә үтеп керә, йокымсырап утырган сакчының балтасын эләктереп, кул-аягы богаулы хәлдә дүрт палачны тураклап (капрал Никитин, Хомутов, Епифанов һәм Лазарев фамилияле солдатларның башына җитеп), крепость ишегалдының нәкъ уртасында «бернинди җәрәхәтсез» аягурә көрәшеп җан бирә - йөрәге шартлый (8. 270-271 бб; 10. 65 б. 19. 67 б). Бу хәл 1762 елның 24 июль коненда була.

1756 елның сентябрь азагында Батыршаның гаиләсе дә тотыла һәм Уфага озатыла. Җиде яшьлек улы Таҗетдин шунда төрмәдә үлә, хатыны Зөлхәбирә ике кызы (бер яшьлек Сәлиха, өч яшьлек Зөләйха) белән Мәскәүгә озатылалар һәм чукындырылалар. Зөлхәбирәгә Наталья, Сәлихага Вера исеме бирелә. Дүртенче яше белән барган Зөләйха 1757 елның 22 гыйнварында авырап үлә. Әнисе белән сеңлесенең шуннан соңгы язмышлары билгесез.

* * *

Хәрәкәт бастырыла. Анда катнашканнарның ике меңкибән игене, 300 мең чүмәлә печәне яндырыла, алты мең баш аты тартып алына. Бер Оса дәругы крәстиәннәре генә казнага хәрәкәтне бастырырга җибәрелгән солдатларны туендыру өчен 2034 сум 96 тиенлек төрле ашамлык әйберләр тапшырырга тиеш булалар. Ләкин хакимият органнарын хафага салган хәбәрләр тиз генә басылмый. Хәрәкәтне бастырырга килгән җәза отрядлары хәбәр арты хәбәр алалар:

«Оса өязен бөтенләе белән диярлек таладылар һәм күп кешеләрен чапкаладылар һәм чәнечкеләделәр, эскерт һәм чүмәләләрдәге бөтен игенне яндырдылар, урылмаганын таптадылар, изделәр, мал- туарны урладылар һәм хәзер ясаклы Арзинский олысына, Касево һәм Березовка, Кама аръягындагы бүтән авылларга ябырылырга ниятлиләр».

Күңгер воевода кәнсәләре хәбәр итә:

«Караклар башлыгы Бепеня, Мәндәр һәм Төлкечура барысы да Тувлядан һәм Тол ягыныкылар белән бергәләп сүз йөрттеләр... Аю (Әй) елгасыннан да Тол елгасына киттеләр, урыс авылларын яндыралар һәм крәстиәннәрне суялар».

Пермь тау начальствосы хәбәр итә:

«Оса шәһәрендә тотылган 4 башкорт кешесе допроста шуны әйттеләр: имештер, Оса янында ике мең талаучы йөри, урысларны талый һәм йортларын яндыра, Тасимовка (Кояново) авылы аша Түбән Мол һәм Строгановлар приказы һәм авылларына өч мең кеше юл тота...»

Строгановлар вотчинасы идарәсе Осадан һәм Беляевкадан яза: «Ышбу караклар барлык авылларны яндырып бетерделәр, тотылганнары без биш йөзләп кеше, өч йөз кеше Тасим ягына Мулны яндырырга киттеләр, ди. Күзәтеп кайтырга җибәрелгән солдат Оса тирәсендә ике меңләп кеше җыелуын, тагын өч меңе Югары Мул ягына Строгановлар вотчинасына, Күңгер өязенә теш кайрый («ярятся на вотчину») дип кайтып сөйли.

Осадан, имештер, Балахчы йөзбашы Исмәгыйль яза:«бу олыс яныннан ике меңләп башкорт, алары артыннан тагын биш йөз кеше үткән, кая юл тотуларын белми».

Татар кешесе Тобай Китяпов хәбәр итә: «Оса шәһәреннән ерак түгел Солтанай авылында башкортлар тупланган һәм алар Аспа юлыннан Сүде острогына, Күңгергә барырга җыеналар. Югары Ирән четверте авылларыннан татарлар хатыннары һәм балалары белән острогта җыелганнар, ә бу башкорт караклары төнлә белән Константиново авылында булачаклар, әйтүләренә караганда, имештер, аларның 3300 кешесе бар...»

Караклар Санкт-Петербургтан килгән солдатны үтергәннәр, кулга алынган бер карак «безнең Бусләман Мулканаев атлы ханыбыз бар, зур гаскәр җыеп, ул Красноуфим, Күңгер һәм Екатеринбургны таларга барачак» дип мактанган.

Караклардан качып котылган татар хатыны Анбия Серга олысы татары Тулыбай Аннышев җитәкчелегендәге отрядта 350 кеше булып, аларның өч байрагы бар, дип хәбәр итә.

Күңгер воеводасы кәнсәләреннән шундый хәбәр бирелә:

«Ишим авылында (бу авыл ул чакта татар авылы булып йөргәнгә охшый, югыйсә башкорт башкортны үтермәс иде - Ә.Ф.) башкортлар Кадырмәт Акбатыревны кыйнап үтерделәр, хатынын, балаларын, әйберләрен алып киттеләр. Осадан алар Тол буйлап күтәреләләр, аларның вожатыйлары (озатып йөрүчеләре) Гәйнә олысы башкорты Зимас Абдалов».

Яшерен эзәрлекләү эшләре, поход кәнсәләрендә төзелгән «дело»ларда ата- бабалары җиреннән куылган, кимсетелгән- җәберләнгәннәр — «бурлар», «бунт күтәрүчеләр» итеп, ә аларга яңа урында да тыныч яшәргә ирек бирмәгән эзәрлекләүче- җәзалаучылар - законлы тәртип урнаштыручылар итеп күрсәтелә. Допрос протоколларында бу мыскыллау-яманлау сүзләре кулга алынганнарның үзләре тарафыннан әйтелгән итеп бирелә. Үз иле халкыннан көлүдә бу кадәр түбәнгә тәгәрәү тагын кайсы ил түрәләрендә булыр икән?

Алтын Урда үрнәге буенча дөньяда иң зур империя төзүгә тотынган урыс хөкүмәтенең үзенә каршы баш күтәрүчеләрне кызганып тормасы аңлашыла. Ләкин киләчәк өчен сабак та алырга кирәк бит әле. Алганмы соң ул аны, бирәр нәтиҗә ясаганмы?

1758 елның 4 мартында Ырымбур комиссиясе начальнигы В.Н.Татищев, башкорт эшләре буенча комиссия начальнигы Л.Я.Соймонов катнашында үткән киңәшмә Билгеләмәсенең 9нчы пункты итеп шундый карар кабул ителә:

«9. Уфада иноверецларны урысча укыту өчен школалар ачарга, анда укып, алар христиан һәм гражданлык законнарын өйрәнеп усаллык эшләүдән тыелырлар».

Узган еллардан калган бурычларны, яңа төр налогларны җыю, өстәмә рәвештә рекрутка алу туктатыла, 200-300 ир заты булган, чукындырылган кешеләре күп булмаган авылларда мәчет салырга рөхсәт ителә.

Восстание вакытында ат һәм акча белән ярдәм иткән Гәйнә олысы башкортларына, ягъни Туктамыш Ижбулатов ягына басканнарга, Осада ашарларына һәм орлыкка дип һәр хуҗалыкка 2 пот арыш һәм бодай сатып алырга рөхсәт ителгән, старшина һәм йөзбашларга «бурларга икмәк сатмаска, тәмам баш ормый торып, аларның атаманнарын азат итмәскә» дип боерылган. Бу боерыкны үтәмәүчеләр үтерелергә тиеш булганнар (18).

Шулай итеп Крылов имениесен туздыру белән башланган хәрәкәт зур территориягә тарала, патша хакимиятенең барлык органнарына курку сала.

Ләкин канәчкеч самодержавиенең куркасы, чын-чыннан өркәсе көннәре әле алда булыр. XYIII гасыр урталарында булган Сәет бунтыннан, Алдар Күчем, Килмәк-Карасакал, Батырша хәрәкәтләреннән күп тапкырларга көчрәк җәеләчәк, Русия самодержавиесен дер селкетәчәк Пугачев яулары булачак әле.

Батыршаның патшабикәгә бирү шарты белән язган хаты аңа барып җитмәсә дә ул бөтенләй үк эзсез дә калмый. Башкортларның үз ихтыяҗлары белән турыдан-туры дәүләт башлыгына мөрәҗәгать итү хокукы кайтарыла, башкорт һәм мишәрләр казна кешеләрен Ырымбурга йөртүдән азат ителәләр, башкортлар аз яшәгән коньяк-көнбатыш районнарда почта авыллары бетерелә, властьлар башкорт җирләрен басып алуны туктатырга вәгъдә итәләр.

1759 елның сентябрендә Сенат башкорт вәкилләренең язма мөрәҗәгатенә (гаризасына) түбәндәге җавапны бирә: «киләчәктә кемгә булса да башкорт халкын җәберләү һәм кыерсыту, җирләренә башка халыкларны күчереп утырту тыела, алга таба аларны яклау гына түгел, аларга яхшы мөнәсәбәттә булырга кушыла» (12. 19 февраль)

Яңа чукындырылганнар өчен салынган, ләкин түләнми килгән недоимкалар бетерелә, мөселманнарны чукындырылган кешеләре булган авыллардан куу-күчерүләр туктатыла. Мәчет-мәдрәсәләрне җимерүдә, мөселманнарны чукындыруда зур тырышлык күрсәткән Казан архиепископы Лука Канашевич (Аксак Каратун) һәм Тобол митрополиты Сильвестр Гловатский башка районнарга күчереләләр. Махсус указ белән Казан, Түбән Новгород, Себер губерналарында мөселманнарга мәчет салырга рөхсәт ителә (12. 19 февраль).

Патша заманында гына түгел, ә совет чорында да байтак еллар Батырша фанатик-диниче итеп, аның исеме белән бәйле хәрәкәт милләтчелек хәрәкәте итеп күрсәтелеп килде. Шул сәбәпле «Башкорт АССР тарихы буенча материаллар» җыентыгының Батырша хәрәкәтенә багышланган китабы чыкмый калды һәм бүгенге көнгә кадәр Башкортстан Фәннәр Академиясе архивында кулъязма хәлендә тузанланып ята. Ә бит Батыршаның мөселманнарга адресланган мөрәҗәгатьләренең нигезендә татар, башкорт, кыргыз, казахларга мөстәкыйльлек таләп итү ята; алар таркалган СССР халыкларының бүгенге көрәшләре белән аваздаш.

## Файдаланылган әдәбият:


1. Яшерен васыять. - Казан утлары, 1992, N 1.
2. Равил Әмирханов. Вахит Имамов. Татарларның Ватан сугышы. Казан, 1993.
3. Материалы по истории Башкирской АССР. Том 1. М.-Л., 1936.
4. Очерки по истории Башкирской АССР. Том 1, ч. 1. Уфа, 1956.
5. П.И.Рычков. История Оренбургская. Оренбург, 1896.
6. А.П.Чулошников. Восстание 1755 года в Башкирии. М. - Л., 1940.
7. Яныбай Хаммат. Тарих сабагы. Башкортостан, 1993, N 4-5.
8. Н.Дубровин. Пугачев и его сообщники. Том 1. СПб. 1884.
9. Марсель Хәйретдинов. Батырша восстаниесе. Таң йолдызы (Чаллы), 1990, 6 март.
10. С.Алишев. Каһарман бабайлар. Казан, 1976.
11. А.Дмитриев. Пермская старина. Вып. YI. Пермь, 1895.
12. И.Акманов. 1755-1756 еллардагы башкорт восстаниеһы һәм Батырша Галиев. - Башкортостан, 1993, 13, 16, 17, 18, 19 февраль саннары.
13. Җәмит Рәхимов. Батырша. Тарихи роман. Казан, 1994.
14. Гайса Хөсәен. Канлы илле биш. Агыйдел, 1993, N 5-7.
15. Г.Хөсәенов. Батыршаның патшага язган хаты. - Агыйдел, 1970, N 10.
16. Башкорт әдәбиятенең текстологияһы мәсьәләләре. Уфа, 1979.
17. Батыршаның императрица Елизавета Петровнага хаты. Төзүчесе Г.Б.Хөсәенов. Уфа, 1993.
18. Материалы по истории Башкирской АССР. Том 1. М-Л., 1936. «Экстракт» - 336-338 бб., «Определение» - 365-368 бб.
19. Кыям Миңлебаев. Батырша. Мирас, 1994, N 4.

# Ү. Ширәмәт бакыр заводы

Россиягә ирекле кушылган төбәкләрдә, аерым алганда башкорт җирләрендәге «инородецларны» чукындырмаска, җирләрен тартып алмаска, дип вәгъдә ителгән булса да, бу вәгъдәләр йөз елдан соң «онытыла», җәбер-золымнан котылу өчен шушы исем астына яшеренгән татарларны һ.б. халыкларны яңадан чукындыру, төрле салымнар түләтү башлана. Дөресрәге, бу гамәлләр үзгәрешсез дәвам итә. Налог түләүгә акча табу өчен халык имана җирен, ул да җитмәсә, үзен, хатынын, балаларын сатарга мәҗбүр була. Моңа мисалларны бихисап китерергә мөмкин.

Танын олысында Килмәт Бикбов дигән кеше «на расплату долгов» Чурагол мулла Туйгильдиннан уп сум акча ала һәм улы Рәҗәп белән «Чурагол хуҗа күпме теләсә, шул кадәр аңа эшләп торырга, бернинди дә сүзгә килмәскә, йортын, мал-туарын карап торырга, начарлык эшләмәскә, урлашмаска һәм качмаска», дип 1714 елның 10 мае көнне «Житейская запись» яздырта (1. N 155, 112 б). 1715 елның 17 февралендә шул ук Чурагол Туйгильдиннан, балалары һәм хатыны белән 10 ел аңа эшләргә булып, Нияз Кильметов дигән кеше 40 сум акча ала (шунда ук, N 169). Уфада булганда крепостнойлар эше буенча кәнсәләрдә Гәйнә олысыннан Яубатыр Алаусиновтан Акзигит Якшибаев «үз кирәк-ярагына һәм бурычларын түләүгә» дип 70 сум акча ала һәм хатыны Уразбикә Чураголова, 4 яшьлек кызы Зөлхия, 3 яшьлек улы Агабит белән бер ел Алаусиновта торып эшләргә сүз бирә. Бер елдан, эшләгәне өчен 8 сум чигерелеп, Акзигит 62 сумны кире кайтарырга, әгәр моны эшләмәсә, акча закон нигезендә ел саен 5 сум штраф өстәлеп түләнергә тиеш була (2. N 132. 315-316 бб).

1701 елда Гәйнә олысының Исәнгол Маркушев, Шамбай Чупин 6 сум «Мәскәү көмеш акчасын» бурычка алып, Үдиктән Федор Айметов Ижбулат Камышевтан 11 сум алып, Аклыштан Абдрахман Уразов, Төңгүктән Солтангол Ищеев өч атнага 40 сум бурычка алып, «заемная кабала» төзетәләр, ягъни бурычка акча алып, коллыкка сатылалар. Ногайбикә Бимашева, Абдулла Тләнчиевтән 10 сум бурычка алып, Кызгыча исемле кызын бирә. «Заемная кабала»да язылганча, «Кызгыча урлашмаска, качмаска тиеш», ә Абдулла теләсә аны «крепостноена хатынлыкка бирә ала» (1. NN 6, 54, 91, 95).

1736 елга кадәр башкортларга җирләрен сатарга рөхсәт ителми. Каян да булса күчеп килгән кеше алар җиренә «припущенник», «типтәр» булып урнаша ала.1736 ел 11 февраль указы белән башкорт җирләренә идарә итү үзгәртеп корыла. Старшина һәм руханиларны сайлау хөкүмәт күзәтүе астына күчә: алар билгеле бер срокка, хөкүмәт сәясәтен яклаучылардан гына сайлана ала. Һәр даругка берәр генә исәбеннән сайлана торган ахуннар хөкүмәткә тугры булырга ант итәргә тиеш булалар. Махсус патша указыннан башка мәчет-мәдрәсә салу, старшиналарның үз теләкләре

белән корылтайга җыелулары тыела, моннан ары алар Уфа янында елга бер мәртәбә генә җыела алалар. Шушы ук указ Русия чикләрен саклауны һәм русларның көчеп килүен көчәйтү чараларын да билгели. Моңарчы җир общинаның гомум милке булып, җан башына бүлеп бирелсә, моннан соң аны ирекле рәвештә рус дворяннарына һәм йомышлы мишәрләргә сатарга мөмкин. Указда русларны күчеп килергә кызыксындырган, крепостьлар төзү, аларны саклау өчен хәрби частьләр тоту буенча пунктлар да була (3.145 б).

Указның Батырша кебекләрне иң нык ярсыткан өлеше - халыкның укымышлы кешеләрен, зыялыларны, аеруча мулла һәм абызларны үзгә күзәтү астына алу турындагы пункты була. «Узган еллардагы буталышларда, диелә хөкүмәт карарында, «махометан руханилары һәм укымышлылары бигрәк тә явыз бурлар булдылар» (4. 36 б).

1736 елгы бу указ нигезендә җир сатулар XYIII гасыр уртасында массовый төс ала. Бер яктан моңа салым түләү өчен акча кирәклеге, икенче яктан күченеп килүчеләрнең арта баруы, җирле халыкның биләмәләренә рөхсәтсез-нисез килеп урнашулары этәрә.

Без биредә рәсми кәгазьләрдә теркәлеп калган иң эре «купчилар»ны гына китерәбез. 1758 елда Уран олысы ышанычлыларыннан - Уртавылдан Кинзә Азналин, Исәнгол Хөсәеновлардан, Эткенә авылы кешесе Абдал Йосыповтан, Яңавылдан Исән Ямметовтан Казан өязе Арча дәругы монастырь крәстиәннәре Василий Кустов, Андрей һәм Семен Коровкиннар 25 ел срокка дип ике ташлы тегермән, тегермән янында каралты-курасы белән ике йорт салырга дип Сайгатка елгасы буен сатып алалар. Төзелеш өчен кирәкле агач җир сатучылар дачасыннан алынačак. Һәм шушы «оброчное владение» өчен алар елына 80 ешәр тиен түләү, аны да тегермәннәр ходка җибәрелеп, доход бирә башлагач кына, шушы чорда тегермәннәр окладка куелса, җир өчен ясакны «Кинзә белән иптәшләре» үзләре түләргә, «Василий һәм иптәшләренә, аларның хатыннарына һәм балаларына сүз әйтмәскә, зыян китермәскә», төзү эшләрен тоткарлапмы, бүтән юл беләнме зыян китерелсә, бөтен зыянны җир сатучылардан түләттерергә, «Василий һәм аның иптәшләре ни әйтсә, шуңа ышанырга» кушыла (2.165 б).

Шул ук 1758 елда (10 мартта) Яңа һәм Иске Кайпан авыллары кешеләренең ышанычлылары Ырдуган Солтанов белән Кинзә Чугалаевлар Гәйнә олысы Кызылъяр (I Әрҗән) кешеләре Тойчибай, Иткол Сабанаевларга, Үртәми һәм Уразай Бииндыковларга «дусларча килешү буенча» үзләренең Тол һәм Барда елгалары буендагы иске биләмәләрен саталар. Ел саен 30 тиен түләү шарты белән 30 елга бирелгән бу җирләрнең күләме шулай билгеләнә: «Тол елгасының уң ягыннан Пычрак чишмәнең башына, ә башыннан Барда урманына, ә Барда урманыннан Барда елгасына, аның буендагы күл һәм сазга, ул саздан Барда елгасы буйлап түбәнгә... уң ягыннан Тол елгасына... Пычрак чишмәгә, шул межадан Күгәрчен елгасына кадәр... Иске умарталарны тотарга, яңаларын куярга, җирен сөрергә, печәнен чабарга, комалак җыярга», әгәр шушы җирләргә чит кешеләр

кереп, Тойчибайларга зыян салса, аларны аннан куу, зыянны каплау — бусы Ирдуган һәм аның иптәшләренең бурычы (2.168, 446-449 бб).

1760 елда шушы ук тәртиптә, ел саен 4 сум түләү шарты белән Сарапул ягыннан күчерелгән дәүләт крәстиәннәренә (биш йортка) 20 елга Бөҗ һәм Усы елгалары буе, 10 елга Кама буе арендага бирелә һәм шуннан соң кире кайтарылмый.

1760 елда Уран олысының Иманай (Иванай), Иткинин (Эткенә) һәм Уртавыл авылларында исәптә торып, күптән инде Гәйнә кешеләренә әверелгән Иманаев, Иткинин һәм башкалар да, үзләре файдаланмаган җир өчен ясак түләүдән котылу өчен, Кама буенда кулларыннан китеп барган биләмәләрен саталар (2, 184 б).

1767 елда Твердышев дигән дворян-алпавыт 483,5 кв. чакрым җир били һәм аның өчен нибары 400 сум акча түли. Камбарка заводын салу өчен Демидовлар 36 мең дисәтинә җирне нибары 120 сумга сатып алалар. (2. 228-229 бб).

Бу «сату-алулар»ның ни нәрсә икәнен Кояново (Куян) авылыннан Мәмәтколовларның Строгановлар белән, Гәйнә олысы старшинасы һәм йөзбашларының Ширәмәт (Шерменка) бакыр заводы хуҗалары белән алып барган талаш-көрәшләре бик ачык күрсәтә. Тасим Мәмәтколов һәм авылдашлары Строгановлар өстеннән ак патшага шикаять язалар, яңа ярлык алуга ирешәләр. Ләкин үзләрен хөкүмәттән дә өстен санаган Строгановлар беразтынып торалар да Кояново кешеләрен янә кысрыклый, җирләренә керә башлыйлар, авылны яндыралар. Тасим Мәмәтколов һәм авылдашлары йөреп алган ярлык шунда янып юкка чыга. Без югарыда күргән ярлык шул документның күчермәсе. Мәмәтколовлар аны Уфадан, воевода кәнсәләреннән ясатып алып кайталар һәм авылны яңадан төзиләр. Бүгенге Куян (Кояново) авылы әнә шулай тартыш-ызгышларда кабат аякка бастырылган авыл.

Ширәмәт заводына килгәндә, ул бернинди «купчи»сыз салына башлый. Завод пробирщигы завод салу өчен җиргә документны биш елдан соң гына алып кайта. Анда да махсус барып түгел, ә юл уңае Уфада булганда эшләтеп алып кайта. Түбәндә шул документның кыскача эчтәлеге бирелә:

«Обер-прокурор галиҗәнапләре Александр Иванович Глебовның яңа салына башлаган Ширәмәт заводы пробирщигы Иван Антон улы Попов, Оса юлы Гәйнә олысының түбәндә язылган вотчинниклары старшина Токтамыш Ижбулатов, Илеш Әтнәшев, Аббис Сәйдәшев, писарь Алексей Абдулов, йөзбаш Салих Хөсәенов, Рангул Юрбагишевларның 1758 ел 20 ноябрь числосында биргән ризалык белдерүләре белән Уфада булып, Тау командасы берггешворены Осип Андреян улы Стадухинга крепостнойлар эше буенча кәнсәләрдә ошбу купчины бирделәр шул хакта: Ширмяик елгасына тошкән чишмә буенда элек вотяклар яшәгән иске дачаларын... чишмәнең тамагыннан башына кадәр өч, аркылысы ике яктан да өч чакрым булган җирләрне чабулыклары, йорт һәм теләсә нинди башка төзелешкә кисәрдәй урманы белән Осипкә саттылар. Моннан соң Осип, хатыны без саткан бу җирдә авыл төзергә һәм крәстиәннәрен урнаштырырга, җир

сөрергә, печән чабарга, йорт салу өчен агач кисәргә, кабык төшерергә... Туктамыш һәм иптәшләре аның белән бәхәскә кермәскә һәм бернинди комачаулык итмәскә. Ә алдык без, Туктамыш иптәшләре белән, сатылган ышбу җир өчен Осиптан 10 тәңкә акча... Бу купчины ясаткачны безнең бу вотчина җире беркемгә дә сатылмады, закладка салынмады һәм бернинди крепостька да беркетелмәде... Әгәр дә берәрсе бәйләнә калса, берәр төрле зыян салса, кысрыкласа, без, Туктамыш иптәшләре белән, биргән акчаны һәм китерелгән зыянны тулысы белән, шулай ук хәзерге бәя белән төзегән йорт-кураның хакын түләрбез... Осип нәрсә әйтсә, шуңа ышанырга, бездән бернинди аклану кабул итмәскә» (2. 181-182 бб).

Буталчык тел белән, җирле түрәләрнең исемнәрен дә юньләп белмичә (Туктамышның исеме өч урында өч төрле, Хөсәенов Усаинов, Рангул Ирамгул дип бирелгән) язылган бу ялган купчи төзелгәннән соң күп тә үтми, 1759 елның декабрендә, «Гәйнә олысы йөзбашы Рангул һәм иптәшләре» тарафыннан О.А.Стадухин өстеннән шикаять языла. «Аның (завод шихтмейстеры Стадухинның) боерыгы белән, диелә анда, безнең исемнән дип Поповтан үз белдеге белән ялган купчий эшләткән... Моннан алдарак Стадухин бу җирдә аракы заводы төзетте» (2. 396 б; 5. 229-230 бб).

«Завод төзелү уңаеннан кайбер үтенечләр белән» олыс старшинасы Туктамыш Ижбулатов үзе Сенатка бара, «купчи язылганда мин өйдә булмадым, Санкт-Петербургта закон эшләү комиссиясендә булып калдым, старшиналык вазифаларын йөзбаш Салих Хөсәенов башкарып торды. Бу вакытта ул да каядыр киткән булган», дип аңлата.

Уфа провинция кәнсәләре ялган кәгазь («Подложной доверенность») нигезендә эвәләнгән купчины, дөресрәге, башкортлар җирен басып алуны дөрес дип бәяли (6. 229-230 бб). Мәсьәләне югарырак инстанциядә, Сенатта, караганда да сүз Глебовның дөрес эш йөртмәве турында түгел, ә «башкортлар завод өчен эзләп табылган (вновь обысканные) җирләрне бирүгә каршылык күрсәтәләр» дигән формада алып барыла. Сенаттан Берг-Коллегиягә бирелгән 1760 ел 7 ноябрь указының исеме ук ялган документ төзүчеләрне түгел, ә җирле халыкны гаепләү булып яңгырый: «Башкортларның А.И.Глебов заводына җир бүлүгә каршылык күрсәтүләре хакындагы эшне тикшерү» дип атала ул. Шушы указ нигезендә Сенат Берг-Коллегиягә «бу җирләрне отвесть и отмежевать» дигән боерык бирә һәм заводны салу ничек барган булса, шулай дәвам иттерелә.

Обер-прокурор, генерал-крикамисар һәм Изге Анна ордены кавалеры Александр Иванович Глебовка «бүленгән» җир башта аркылысы-буе 3 чакрымнан 5 чакрымга, завод эшли башлагач, 50 чакрымга җитә. Шулай итеп, «Шермяика елгасы тирәсен узмаска тиешле участок» Тол, Еркул, Сеп елгалары буена җәелдерелә һәм моны, имеш, «башкорт старшиналары челобитный язып үзләре теләде».

Завод хуҗалары җитештергән продукциянең күләмен дә дөрес күрсәтмиләр; барлык еллык отчетларда диярлек бакыр кою мичләре тулы куәтенә эшләмәде (алтыдан икесе-өчесе генә эшләде) дип күрсәтәләр.

Сәбәпләре: «отсутствие припасов», «надежных людей не было», «поставки руды не было». Ә билгеле, «башкортлар договорны үтәмәү сәбәпле поставки руды не было» дип күрсәтелгән 1763-1766 елларда да заводның үз рудникларыннан руда килеп торган. 1762 елда, мәсәлән, 165 мең пот, 1764 елда «яшерен рәвештә» (потаенно) 50 мең пот руда китерелгән һәм моның өчен завод 2 процентлы рента тосендә Уфага бер тиен акча түләмәгән.

Завод үзендә эшләүгә җәлеп ителгән һәр«җан башыннан» 70 тиен налог түләргә тиеш булып, ул бу налогны да тулы күләмдә түләми, заводта эшләүчеләр санын һәрчак киметеп күрсәтә. Мәсәлән, Пермь тау начальствосы җибәргән эшчеләрнең бер өлешен отчетка кертми яшереп йортә. 1766 елда заводка китерелгән руда өчен 8194 сум 20 тиен акчаны яшерә, «волокита ясый һәм разорение китерә».

Завод десятинный налог буенча хөкүмәт алдында да бурычлы булып йори: 1768 ел өчен, мәсәлән, 3495 сум 38 тиен, 1767 ел өчен 1696 сум 35 ярым тиен бурычы була. Шулай итеп, завод хуҗалары җир хуҗаларын гына түгел, ә үзләрен яклаган хөкүмәтне дә алдыйлар, хәтта шул яшерен, отчетта киметеп күрсәтелгән продукция өчен дә түләргә теләмиләр (6. 175-178 бб).

Шулай да нинди куәте булып, күпме нәрсә җитештергән соң Ширәмәт бакыр заводы?

Завод 1759 елда төзелә башлап, 1761 елда беренче продукциясен бирә. Заводны төзү һәм эшләтү өчен Глебов Нижгород губернасындагы Мухоедово авылындагы крепостнойларын (барлыгы 196 җан) күчереп алып килә. Заводның алты миче, 2 фабрикасы, 2 горны (тимерче учагы) булып, анда беренче елны 196 крепостной, ягъни заводның үз эшчеләре эшли. Шулар өстенә төрле елларда Екатеринбург тау экспедициясе, Пермь провинциаль кәнсәләре үз территориясендәге заводлардан эшчеләр җибәрә. Завод каршында торып эшләүчеләр саны 252 гә җитә. Моннан тыш эретелгән һәр пот бакырга 4,5 тиен түләү исәбеннән җирле халыктан кем ат, кем иңенә салып капчыклап руда ташый. Андыйларның саны кайбер елларда ике меңне узып китә.

Бер эшләп, бер тукталып, Ширәмәт бакыр заводы ун ел эчендә 8640 пот чамасы бакыр эретеп чыгара:

1761 елда - 290 пот 7,5 кадак,

1762 елда - «выплавки не было» дигән елда - 165.500 пот руда эшкәртелә,

1763 елда - 765 пот 28 кадак бакыр,

1764 елда - 1694 пот бакыр, «яшерен рәвештә 50.000 поттан артык руда ташылган»,

1765 елда - 883 пот 10 кадак бакыр,

1766 елда - 2008 пот 18,5 кадак бакыр,

1767 елда - 1769 пот 15 кадак бакыр,

1768 елда - 1224 пот 22 кадак бакыр (6. 335-338 бб).

1769 елда Глебов заводын топ имениесеннән күчереп китергән крепостнойлары белән бергә Савва Яковлевка сата. 1800 елгы атластан күренгәнчә, яңа хуҗага күчкән завод елына 1500—2500 пот бакыр коя. Анда 355 крепостной, 392 хатын-кыз эшли. Бу чорда Шермейкада 48 йорт исәпләнә. Эшләвенең соңгы елларында Ширәмәт бакыр заводы «Адмиралтействога артиллерия снарядлары һәм тимер дә биргән» (7. 681 б).

Завод ходка җибәрелгәндә аның бакыр эретү һәм чималны тою буенча икс фабрикасында 6 мич, 2 горн була. Шул ук елның 3 августында тагын 3 мич, 1761 елда яңа горннар эшли башлый. Заводта 12 эретүче, 12 чимал салып торучы, 12 ташучы, бакыр чистартучыларның 4 ярдәмчесе, 8 өйрәнчеге, 4 чимал-чүп тояп торучы, 8 тимерче, 2 күрек тартучы өйрәнчек, 2 буш эшче, аларның 2 өйрәнчеге, 4 колосник, өйрәнчекләре белән бергә 3 күмер ташучы, 3 каравылчы, 15 ат караучы, 105 башка тор эшчеләр эшли.

Нижгород губернасыннан күчереп китерелгән крепостнойлардан тыш заводка аерым указ буенча 2 штейгер, 1 подштейгер, 1 буа мастеры, 1 эретүче мастер, тимерче һәм слесарь уставщигы, маркшейдер, пробирщик, 42 руда казучы китертелә. Аларның кырыгы Екатеринбург алтын производствосы тау экспедициясеннән, 9-ы Пермь тау начальствосыннан, Чернышевның Йог заводыннан бер кеше, «не праздно живущих церковников» - ике кеше.

Моннан тыш заводка 56 җирле крәстиән беркетелә. Шулай да эшчеләр җитми. Сәбәбе: Глебовның «казнадан акча алмыйча фәкать үз чыгымнарына», ялган документлар нигезендә төзелгән заводына әледән-әле башкортларның һөҗүм итеп тора. Шул сәбәпле ирекле ялланып эшләүчеләр күп вакытны заводка эшкә йөрергә куркалар һәм завод бер елны да бөтен куәтенә эшләп китә алмый. Уфа провинциаль кәнсәләре сержант Игличинин командалыгында махсус сак отряды да җибәрә, ләкин һөҗүм итүләр туктамый, заводны тәмам эштән чыгарганчы дәвам итә. Глебов үзе белән Нижгород губернасыннан алып килгән 196 крепостное 6 мичнең нибары икесен туктатмыйча эшләтә ала. Завод тулы куәтенә эшләмәү сәбәпле ирекле яллanып эшләүчеләр генә түгел, ә крепостнойлар да гаиләләрен тукландыра алмыйча, ач утермәс өчен төрле якка эш эзләп таралышырга мәҗбүр булалар. Качакларны эзләп табып, кире кайтару өчен Уфадан янә отряд чакыртыла. Тик бу отрядның да эше мактанырлык булмый.

Әнә шулай үчен ала Гәйнә халкы үзен алдаучылардан. Глебов заводын сатып котыла. Ә Яковлев?Башта завод Уфа провинциясенә карый, аннары аны Ырымбур тау начальствосына буйсындыралар. 1768 елның 19 сентябреннән «якынрак булу» сәбәпле (по состоянию близости) Пермь тау начальствосы карамагына тапшыралар.

* * *

Глебовның Ширәмәт, башкаларның Йог, Ягошиха заводлары тирәсендә Гәйнә олысының «үз промышленниклары» барлыкка килә. Тол-Гәйнәдә алардан иң зуры Туктамыш Ижбулатов булса, Мул-Гәйнәдә Исмәгыйль Тасимов була. Бу соңгысы, урыс промышленникларының Ягошиха, Мото-

вилиха, Йог заводларына руда ташып, шул кадәр байый һәм тәҗрибә туплый ки, промышленник булярак, Тасимов бөтен Уфа һәм Пермь провинциясендә танылa һәм атаклы Чернышев, Савинков кебек эре промышленниклар белән көрәш алып бара. 1770 елда аның императрица Екатерина указы белән Берг-Коллегия аша И.Г.Чернышевтан 70 мең сум акча даулап алуы билгеле (6. N 446, 323-330 бб).

Булачак Пермь губернасының байтак территориясе рус колонизациясе чорында ике эре промышленник (Строганов һәм Демидовлар) кулына эләгеп, Уралның урыс булмаган халыклары җирсез-сусыз калып барган бер мәлдә Тасимовлар патшага җитәләр, Строгановларның комсызлыгын берникадәр басып торуга ирешәләр. Строганов әнә шуңа үч итеп, 1736 елгы хәрәкәт вакытында аларның тегермәннәрен җимертә, махсус отрядлар җибәреп, авылларын яндырта, 102 кешесен үтертә. Урыс промышленниклары белән бер кампаниягә кергән рудачы Исмәгыйль Тасимов шулай да алар кысуыннан бөтенләй үк котыла алмый. 1764 елда ул алар белән судлашып йөри, Санкт-Петербургка җитә, үзенең рудникларын басып алган граф Чернышевны завод идарәчесе Сапников белән бергә Берг-Коллегиягә (безнеңчә әйткәндә, промышленность министрлыгына) чакырттырып, күргән зыянны түләттерүгә ирешә. Бу көрәштә ул берүзе генә булмый, ә үзе кебек үк курку белмәс кыю промышленник, рудниклар тотучы Якуп Адпагулов уң кулы булып йөри. (6. шул ук документ).

Исмәгыйль Тасимов - Кояново (Олы Мул, Тасимка авылы дип тә йөртелә) авылы кешесе, М.Кайсаров кнәгәләрендә (1623) китерелгән Уразмәтнең этисе Тайса, ә тагын да ераграк китсәк, Чу суы буенда зур биләмәләре булган Мәмәтоллар нәселеннән. Тайсаның бирелә күчепеп йөри торган җирләре булган, тегермәннәре эшләп торган. Һәм менә хәзер Тасимов - эре рудниклар хуҗасы, меңнәр белән эш итә, Ырымбурда үз акчасына уку йорты ача, бөтен Русия өчен Петербургта тау академиясе ачу тәкъдиме белән йөри.Тау промышленносте өчен югары квалификацияле кадрлар (җитәкчеләр, инженерлар) әзерләү проекты, «Исмәгыйль Тасимовның башкортлар өчен тау эше буенча махсус уку йорты ачу киргәклеге турындагы юллама» 1773 елның 31 октябрендә Сенатта тикшерелә. Сенат Тасимов тәкъдиме буенча Екатерина II гә доклад белән керә.

«Башкортлар - Исмәгыйль Тасимов иптәшләре белән, дип башлана бу мөрәҗәгать, 1771 елда Берг-Коллегиядән үзләре чыгарган руданы Йог бакыр заводына тапшыруны һәм казна рудникларын үзләре карамагына бирүне сорап, ...бу промыселны камилләштерү, аңа куәт бирү һәм шуның аша үзләре һәм нәселдәшләре, шулай ук җәмгыять өчен мөмкин кадәр файда китерү өчен төп җитәкчеләрдә ихтыяҗлары барлыгын бәян итәләр һәм кадет корпуслары булдырган кебек, шул ук нигездә офицерлар школасы булдыруны үтенәләр». (6. 598 б).

Тасимов тәкъдим ясап кына калмый, ә шул ук юллавында уку йортын тотуга үзе чыгарган һәр пот рудадан яртышар полушка, янсә елына 2250 сум акча бүлеп барырга әзер торуын белдерә.

Пермь губернасында 360 лап татар-башкорт рудачы-промышленниклар булып (Бардада Туктамыш Ижбулатов, Күңгер өязендә Арслан Идрисов

«иптәшләре белән» һ.б.) арасында иң атаклылары һәм эшлекләләре Кояново промыселчылары, шул исәптән Тасим Мәмәтколов, соңрак аның улы Исмәгыйль Тасимов була. Алар җирендә иң күп рудниклар ачылып, Кояново рудачылары 1736 елның 5 мартында ук Казан, Себер һәм Ырымбур заводлары баш идарәсе начальнигы В.Н.Татищевтан рәхмәт сүзләре язылган указ алалар (6. 598 б, 8. 264-265 бб).

Кояново кешеләренең руда чыгару эшенә зур өлеш кертүләрен исәпкә алып, патша хокүмәте аларга кайбер ташламалар да ясый. 1736, 1741 һәм 1745 елларда, мәсәлән, алар Җаек буе чиген, Себер нығытма сызыгын саклауга солдатлар җибәрүдән, Ырымбурга тоз ташудан азат ителәләр (10. 169 - 170 бб).

Шуңысын да белсен укучы: безнең Гәйнә промышленниклары бакыр, тимер җитештерү заводларын чимал белән тәэмин итеп, завод хуҗаларының боерганын үтәп кенә йөрмәгәннәр, ә үз җирләренең күз-колаклары да булганнар, завод хуҗаларының кырын эшләрен күреп, аларны фаш иткәннәр, иң югаргы инстанцияләргә җитеп, аларны җавапка тарттырганнар. Туктамыш Ижбулатов, мәсәлән, Чалклы (Бакчавыл), Сеп авыллары, Ширәмәт заводы тирәсендәге яңа ачылган рудниклардан кала башкаларының начар файдаланылуын, казып чыгарылган, заводка ташып бирелгән бакыр комының да юньләп эшкәртелмәвен, аның өчен промыселларга дөрес түләнмәвен, ә кайбер айларда бөтенләй дә түләнми калдырылуын, 1763-1766 елларда чимал булмау аркасында завод эшләмәде, дип ялганлауларын конкрет саннар китереп фаш итә, һәм Ырымбур тау конторы завод хуҗаларыннан «тулы расчет» эшләтә, «нигезле аңлатма бирүләрен» таләп итә» (6. 335-338 бб).

Кояново рудачылары Исмәгыйль Тасимов белән Якуп Аднагуловлар Йог заводы начальнигы граф Чернышевтан китергән зыян өчен акча түләтеп кенә калмыйлар, ә Берг- Коллегия алдында тез чүктереп, гафу да үтендертәләр (6. 324-330 бб).

Кызыклы шәхес Исмәгыйль Тасимов турында тулырак белергә теләүчеләргә Гайса Хөсәеновның «Рудачы Исмәгыйль» дип исемләнгән тарихи хикәясен тәкъдим итәргә була (9).

Атамалар хакында берничә сүз: Йог-Ык, ыйык сүзләре белән бер тамырдан, елга, су дигәнне белдерә һәм аның Юго-Осокино атамасындагы «юг» (коньяк) белән берниди бәйләнеше юк.

Ширәмәт - кызу канлы атка әйтелә торган торки сүз. Шуннан Шереметьев фамилиясе барлыкка килгән. Безнең очракта руслар аны шиктер «Шермяиц»кә әверелдергәннәр. Елганы Шермянка дип, ә заводны Шермяицкий медеплавильный дип атаганнар һәм кәгазьләргә ул шулай кереп калган. Завод бистәсен, бүгенге Шермейка авылын, байтак вакытлар, завод

бетерелгәч тә әле завод исеме белән йорткәннәр, анда яшәүчеләрне «завод каршында яшәүчеләр» дип йорткәннәр һәм язганнар.

Гәйнә иленда барлыкка килгән бүтән заводлар каршындагы авыллар да шулай завод исеме белән - Ашап завод, Осокин заводы дип йортелгәннәр. Ашап авылын Башаның олы яшьтәге кешеләре әле бүген дә Ашап завод дип йортәләр. Кая барасың? дип сорасаң, алар «Ашап зауатка» дип җавап бирәләр.

## Файдаланылган әдәбият:

1. Материалы по истории Башкирской АССР. Том III. М.-Л., 1949.
2. Материалы по истории Башкирской АССР. Том IY, ч. первая. М.-Л., 1956.
3. Очерки по истории БАССР. Том I, часть первая. Уфа, 1956.
4. А.П.Чулошников. Восстание 1755 г. в Башкирии. М.-Л., 1940.
5. Н.К.Чупин. О некоей исторической будто бы записке.
Сборник статей, касающихся Пермской губернии. Пермь, 1882. Н.Чупин, составитель. Географический и статистический словарь. Пермь, 1873.
6. Материалы по истории Башкирской АССР. Том IY, часть вторая. М., 1956.
7. Материалы по истории Башкирской АССР. Том Y. М., 1960.
8. А.П.Усманов *Добровольное присоединение Башкирии к русскому государству*. Уфа, 1982.
9. Гайса Хосаенов. Рудасы Исмәгыйль. Тарихи проза. «Башкортостан», 1983. 8 - 13 саннар. «Батырзар киссаһы». Китап. Уфа, 1986.
10. Н.Колбахтин. Гәйнә башкортлары. Агыйдел. 1994, N 9.
Горнозаводская промышленность Урала на рубеже XYIII-XIX вв., Своди., 1958.
Труды Пермской ученой архивной комиссии. Пермь, 1902.

# YI. Гәйнәлеләр Пугачев хәрәкәтендә

1773 елның сентябрендә Гәйнә илендә Ырымбур ягында «яңа патша» килеп чыккан, ул хөкүмәт гаскәрләрен тар-мар итеп, Уфаны алырга җыена икән, дигән хәбәрләр тарала. Октябрь аенда «шатлыклы хәбәр»не җыелышып тикшерүләр башлана. Хакимият органнары пошаманга төшә. Пугачевны самозванец дип атаган указ чыга, Пермь провинциясенә керүчыгулар катгый тыела, паспортсыз чит кешеләрне кулга алып Күңгергә яисә Йог хөкүмәт заводына озатырга, урман юлларын егып томаларга, олы юлларга каравыл куярга боерыла (1, 2, 3).

Патша хөкүмәте ничек кенә тырышмасын, Гәйнә башкортлары һәм татарлары «иркенлек» вәгъдә иткән яңа патшага баш ияргә әзер торуларын белдереп, старшиналар тирәсендә отрядларга оешалар. Тауавылдан старшина Габди Абдулов командалыгында бер отряд Ырымбур ягындагы патша лагерена җибәрелә. Отряд Уфаны алуда катнашырга теләк белдерә. Пугачев ставкасыннан аны Канзафар Усаев янына юллыйлар. Мишәр старшинасы Усаев алар алдына тагын да зуррак бурыч куя: Уфаның алынуын көтмәстән, Пермь ягына кайтырга һәм бөтен провинция халкын көрәшкә күтәрергә, Күңгер һәм Соликамскига, заводларга һөҗүм башларга, аларны «Петр III»гә буйсындырырга, моның өчен Пермь краеның бөтен 40 меңлек халкын хәрәкәткә җәлеп итәргә (3.42-43 бб.).

«Яңа патша»ны үз күзләре белән күреп кайтканнарны да көтмәстән, Тол буенда яңа отрядлар оеша, алар янына башка төбәкләрдән депутацияләр килә, үзләре дә төрле якка агитаторлар җибәрәләр. Габди Абдулов отрядының Уфа ягыннан кайтуын Гәйнәләр генә түгел, ә күрше олысларда да кызыксынып көтәләр.

Тол буе башкортлары һәм татарларының бердәм булып күтәрелүе Оса земский ызбасын нык куркуга сала. Аның воеводасы Пироговскийга, Гәйнә ягыннан һөҗүм була калса; Осадан халыкны Йог заводына куарга кушыла. Әнә шул эшне кайчан башкарырга икәнен, гәйнәлеләрнең күпме көче барлыгын ачыклап кайту өчен сабанчы (пахотный) солдат Степан Кузнецовны Осадан илле чакрымдагы, Ырымбурдан кайтып килешли Габди Абдулов тукталган Бичурино (Озын Ялан) авылына җибәрәләр. Ул әйләнеп кайтуга шәһәр староcталарын, сайланмыш кешеләрен җыеп «кемдә ни булса, халыкны шуның белән коралландырып», шәһәрне сакларга әзерләргә боералар. Староста һәм сайланмыш вәкилләр исә «крәстиәннәр шәһәрне саклаудан баш тарталар, злодейны каршылык күрсәтмичә каршы алырга ризалар» дип белдерәләр һәм үзләренең дә злодейларга каршы корал күтәрмәячәкләрен әйтәләр. Ул гына да түгел, воеводаның үзен сак астына алалар һәм берникадәр вакыттан соң аны Пугачевның яңа ставкасына, Уфа янындагы Чесноковкага, Чика-Зарубин лагерена озаталар (шунда ук, 455 б).

Оса старостасы Илья Дьяконов, земский писчик Михайло Голдобин, йөзбаш Козлов, Поварницын һ.б. халыкны җыялар. Җыен янә Абдулов хозурына депутация җибәрергә дигән карар чыгара. Бу юлы Габди Абдулов

Оса депутациясен Бардада каршылый. 18 декабрь көнне биредә аларга Пугачев Манифесты тапшырыла, протопопның «Петр IIIнең чынлыкта үлүе мәгълүм» дигән сүзенә Абдулов «бүгенгә аның нинди сәбәптән исән булуы билгесез, безгә шунысы мәгълүм, ул Дон һәм Җаек казакларыннан торган күп санлы отрядлары белән Ырымбур янында тора», дип җавап бирә. Манифестта әйтелгәннәргә өстәп, Абдулов агитаторлары Осадан килгән вәкилләргә «Петр III патша халыкка җан башыннан акча җыюда, рекрутка алуда җиңеллек бирәчәк, аракы һәм тоз бәяләре киметеләчәк, барыбызга да иркенлек булачак», дип аңлаталар.

Шушындый эчкерсез сөйләшүдән соң Оса депутатлары бөтен шәһәр исеменнән яңа патшага буйсыну турында белдерү ясап кайтып китәләр. Кайту белән авылларга вәкилләр җибәрәләр, аңлату эше җәелдерәләр, гәйнәлеләрнең Күнгергә, Соликамскига ясалачак походларына кушылу өчен отряд туплау, аңа юлга азык-төлек, фураж җыю эшенә керешәләр.

Хакимият башында утыручылар, тау-завод чиновниклары башланган хәрәкәтне «башкортлар чуалышы», 1737, 1755 елларда булган хәрәкәтләр сыман, «башкортларның бер селкенүе генә» дип күрсәтмәкче булалар. Бардада булып, эшнең нинди колач алуын, крепостьларга каршы нинди көчләр күтәрелүен үз күзләре белән күреп кайткан осалылар аларга ышанмыйлар. Заводларга барып чыгып ясыйлармы, аларга беркетелгән авылллардамы, Оса агитатор-үгетчеләре һәркайда «башкорт полковниклары алар Рәсәй байрагын күтәрүчеләр», дип патша- крепостник куштаннарының авызын каплыйлар (шунда ук, 47 б).

Габди Абдулов отрядыннан тыш Тол буенда Тауавыл старшинасы Батыркай Иткинин, Үдиктән Сәйфулла Сәйдәшев отрядлары хәрәкәт итә. Иткинин отряды беренче эше итеп Ширәмәт бакыр заводын ала, завод кәнсәләрендә сакланган 12.530 сумлык бурыч кәгазьләрен яндыра, заводка 21.317 сумлык материаль зыян китерелә, завод кассасында булган бар акчаны баш күтәрүчеләр кассасына ала (4).

1773 елның 21 декабрендә «күп байраклар, фузеялар, турка һәм винтовкалар, ук, сөңге һәм кылычлар белән коралланган» Габди Абдулов, Батыркай Иткинин отрядлары штурмсыз гына Осаны алалар, шәһәрнең земский ызбасын баш күтәрүчеләр штабына әвереелдерәләр (3. 49 б).

24 декабрьдә Батыркай Иткинин, йөзбаш Абдулкәрим Айтуганов, Киндәй Чугалаев һәм Абдулла Шәриповлар Оса старостасы Илья Дьяконов белән земский писарь Михаил Голдобинга шәһәр һәм олыс белән идарә итү буенча түбәндәге боерыкны («наставление») эшлиләр:

«Шәһәрдә барлык обывательләр дә император галиҗанәпләре Петр Федоровичның подданныйлыгына керделәр, аның күрсәтмәсеннән башка беркемне беркая үткәрмәскә, Казанга юлны үз кулыгызда тотарга, патша галиҗанәпләренең язма рохсәтеннән башка, нинди званиеле кеше булуына карамастан, Казанга һәм Казаннан беркемне дә үткәрмәскә, каршылык күрсәтсә, аны тиешле урынга озатырга, аракы һәм тозны яңа указ булганчы элеккечә сатарга, аларны сатудан кергән доходны яшермичә государебез милке итеп сакларга, государь мәнфәгатьләрен бозуның һәр

очрагы буенча оч көн саен армиягә рапорт бирергә, тыңламаучыларны, андыйлар бигрәк тә Казан юлында тотылган булсалар, армиягә китереп тапшырырга, юкка-барга беркемне үпкәләтмәскә һәм кыерсытмаска...» (5. N 204).

25 декабрьдә Иткинин приказы белән казна тозын урлауда гаепләнгән Оса сабанчы солдатлары командиры Кобелев ат чыбыркысы белән суктырыла, милке конфискацияләнә, үзе Чесноковкага озатыла, аның урынына яңа командир сайлана.

Шул ук 25 декабрь көнне пахотный (сабанчы) солдатларга командир сайларга, Земский ызбага 1649 елгы Уложениене кабул итәргә приказ бирелә. Осада яңа власть урнаштырып һәм аны саклау өчен походный полковник званиеләре алган Габди Абдулов белән Өдеһет Төмәсовны калдырып, Батыркай Иткинин атлылары Күнгерне штурмларга китәләр. Аларга Осадан, Күнгер өязенең Карьяу олысы авылларыннан йөзләп кеше кушыла. 27 декабрьда алар Осокинның Йог заводын алалар, конторасында булган бөтен кәгазьләрне, шул исәптән 6426 сумлык бурыч кәгазьләрен яндыралар, заводның 33 эшчесен үзләренә кабул итәләр, мастеровой Гаврил Ситниковны заводка атаман итеп сайлаталар. 29 декабрьдә отряд бөкре Никита Демидовның Ашап бакыр заводында була, 8335 сумлык бурыч кәгазьләрен яндыра, заводка бушлай эшләргә теләмәгән бар крестьяннарны үзенә казак итеп ала. Ә андыйлар тик бер Карьяу олысы авылларында йөзне узып китә.

Тол буеннан йөзбаш булып походка чыккан Иткинин 31 декабрьдә мең кешелек отряды белән Кече Башап, Ясыл-Покровск аша Ордага барып җитә, шунда Ирән һәм Тол буе авылларыннан Савва Яковлевның Ширәмәт, Осокинның Йог заводлары эшчеләре һәм шушы заводларга беркетелгән рус авыллары крәстиәннәреннән төзелгән күпсанлы отрядлар белән очраша.

1773 елның декабрь азакларында шул ук Ашап заводы ягыннан һәм шушында ук Салават Юлаев, Канзафар Усаев отрядлары килеп чыга. Орда острогы (ныгытмасы) тулы камалышта торып кала, анда кереп тә, аннан чыгып та булмый. Ә керергә кирәк, шунсыз Күнгергә үтеп булмый. Штурмга күчәр алдыннан восстаниечеләр пушкалардан залп бирәләр. Һәм аннан шундук тәреләр тотып килеп чыгалар. Үзләре белән бергә Күнгердән җибәрелгән ике священникны да тотып алып чыгалар. Аларның ни максат белән җибәрелгәнлекләрен, Ордада ни сөйләгәннәрен белгәч тә шул ук чиркәү мәйданында аларны асып үтерәләр. Һәм шушы көннән Орда пугачевчылар станына әверелә, шушында Күнгергә поход әзерләнә (15).

Бу вакытта Габди Абдулов отряды Кама буйлап Соликамскига таба хәрәкәт итә. Аның составында да төрле халыкларның вәкилләре - Барда, Озын Ялан, Үдик һәм Крылово крәстиәннәре (иллеләп кеше), Ширәмәт заводы эшчеләре (Матвей Мазжерин һ.б.), Юго-Камск заводыннан егерме биш, Рождественский заводыннан ун мастеровой һ.б. - барысы оч йөз кеше. Култай авыллары кешеләре дә кушылгач, Абдулов отряды биш йөз кешегә

житә, аның дүрт чуен пушкасы, ике пот дарысы була, иллеләп кешесе винтовка, калганнары ук- җәя, сөңге белән коралланган.

Декабрьнең соңгы көннәрендә борыңгы Гәйнә олысының иң төньяк чиге булган Пермь шәһәре, Ягошиха заводы тирәләрендәге татар авыллары кешеләренең үтенече буенча Габди Абдулов Югары Мул авылын алмакчы була. Биредә аның сугышчылары җирле хакимият органнары һәм заводлар идарәләренең Казанга, Мәскәүгә, Санкт- Петербургка юлланган почталарын кулга төшерәләр. Осадан тылмач Заруцкий аларны татарчага тәрҗемә итә һәм эчтәлеге белән бөтен отрядны таныштыра.

Максатына кан коймыйча гына ирешмәк булып, Абдулов Югары Мул авылын саклаучыларны сугышсыз гына бирелергә үгетли, ләкин кнәз Голицын һәм Йог заводы идарәчеләре Варокин белән Берглин авылда зур көчләр туплап өлгерәләр, үзләрен 4 көн камалышта тоткан восстаниечеләрне Югары Мул тирәсеннән пушкалардан атып куалар.

Югары Мулны саклаучылар арасында Куян (Кояново) авылыннан рудачы-промышленник Исмәгыйль Тасимов та үз отряды белән була.

1773 елның октябрь аенда Бирдә бистәсендәге Пугачев ставкасында булып, яңа падишаһның ышанычын яулаган, полковник исеме алган һәм Кама буе заводлары эшчеләрен көрәшкә күтәрү өчен махсус эмиссар итеп җибәрелгән тагын бер батыр якташыбыз булган. Ул - Күңгер өязеннән Бакый мулла Абдулов. Әлегә безгә аның кайсы авылдан булганлыгы мәгълүм түгел. 1773 елның октябрендә ул зур гына отряд туплый һәм бер-бер артлы Рождественский, Камбарка, Аннинск заводларын ала, бу заводларның эшчеләреннән отрядлар оештырып, аларны Зарубинга ярдәмгә озата. Бакый Абдулов 1 гыйнварда Юскәй Кудашев һәм башкаларның отряды белән берлектә Ижевск, 10 гыйнварда Воткинск заводларын ала, ләкин соңгысын фетнәчеләр озак тота алмыйлар - Ижевск, Воткинск түрәләре туплап өлгергән җәза отрядлары басымы астында алар гыйнвар ахырында Сарапулга таба чигенәләр. Бакый мулланың шуннан соңгы язмышы билгеле түгел (2; 5; 17. 412-413 бб).

Пугачевчылар планында Пермь провинциясенең үзәге булган Күңгер аерым урын тота. Бу административ үзәкне алмый торып, аларга төньякка үтү мөмкин түгел. Шуңа күрә Осадан һәм Красноуфим ягыннан баш күтәрүчеләр шунда юл тоталар. Пугачевчыларның бу планнарын хакимиятчеләр дә белгәннәр, күрәсең, Күңгер түрәләре алдан халыкны кисәтү, восстаниечеләргә кушылудан тыю өчен тирә-якка шомчы-үгетчеләр җибәргәннәр. «Үтерүчеләр һәм талаучылар килә, ватанга һәм патшага кул күтәрүче динсезләргә бер нәрсә бирмәгез», дип баш күтәрүчеләр турында төрле ялганнар тараткannар. Шулай да, күргәнебезчә, халык хәрәкәткә кушылудан баш тартмаган, шомчы-священникларның коткысына бирелмәгән, ә үзләрен восстаниечеләргә тотып биргән.

Орда острогын алып, пугачевчылар бердәм көч белән Күңгерне алырга әзерләнәләр. 2 гыйнварда Батыркай Иткинин Күңгернең иске посадыннан шәһәр түрәләренә шундый эчтәлектәге хат белән мөрәҗәгать итә:

«Күңгер каласының Благовещен соборы атакае протопоп Иоанн Пантелейманов һәм бүтән дәрәҗәдәге адәмнәре! Император галиҗәнапләре

исеменнән һәм аның күрсәтмәләрен үтәп, Сезне, изге чиндагыларны да, башкаларны да килешүгә чакырам!»

Хат кала түрәләренә Степаново острожегы (ныгытмасы) священнигы Афанасий Колесник аша тапшырыла.

4 гыйнварда Батыркай Иткинин Күңгергә беренче һөҗүмен ясый, шәһәр диварларыннан чигенгән булып, аны саклаучы Посохов командалыгындагы йөз кешелек казаклар отрядын засадага эләктерә. Отряд, командирын, берничә солдатын югалтып, кире крепостька кереп бикләнә. 5 гыйнварда крепостьны сакларга 400 кешелек секунд-майор А.Папав отряды килеп җитә. Фетнәчеләр сафы да ишәйгәннән-ишәя. 9 гыйнварда Канзафар Усаев, 15 ендә Салават Юлаев, 20 сендә И.Кузнецов отрядлары килеп кушыла.

Күңгер тирәсендә бу вакытка ике мең атлылар, чаңгычылар, 7 пушка һ.б. төр корал туплана. Иткинин ясаган чакырудан соң тагын ике кисәтү ясала: 19 гыйнварда С.Юлаев, К.Усаев, атаман М.И.Поповлар, 20 гыйнварда янә С.Юлаев, И.Кузнецов һәм М.Мальцев кала түрәләрен үз ирекләре белән бирелергә чакыралар. Өч атна эчендә барлыгы биш кисәтү җибәрелеп, шәһәргә биш штурм ясала. 23 гыйнварда русларны берләштергән Кузнецов отряды Орда ягыннан, татар-башкортлардан торган отрядлар каланы Воскресенск ягыннан штурмлыйлар (6. N 100).

Штурмга күчәр алдыннан шәһәргә 17 пушканың һәркайсыннан 35әр ядрә очыртыла. Күп урыннарда крепость диварлары, капкалары җимерелә. Ядрәләр урамнарга төшеп тә шартлый. Һөҗүм иртәдән кичке караңгыга кадәр дәвам итә, иртәгесен янә кабатлана.

Шул көнне, ниһаять, бер урында кала диварларын җимереп, капкаларын ачып, К.Усаев һәм С.Юлаев атлылары Күңгер урамнарына бәреп керәләр. Ләкин ядрә һәм дары җитмәү сәбәпле кире чигенергә мәҗбүр булалар. Иртәгесен Салават Юлаев яралана, гаскәре белән җитәкчелек итүне ике ел Гәйнә олысы старшинасы булып торган 35 яшьлек Чура Рәсүл улына (-Әрҗән авылыннан) тапшырып, үзе туган ягына кайтып китә (7. 76-77 бб.; 16; 17).

Пугачев ставкасыннан (Бирдәдән) «бөтен урыс һәм азиат гаскәрләренең юлбашчысы» итеп җибәрелгән Иван Кузнецов «падишаһ (ягъни Пугачев) полковнигы» Канзафар Усаевны һәм тагын бер җитәкчене кулга ала (алар И.Кузнецовның плансыз һәм коралсыз һөҗүм башлавы белән риза булмыйлар), ә үзе ярдәм сорау өчен Чесноковка лагерена китеп бара.Шул ук 26 гыйнвар төнендә камалыштагы шәһәргә секунд-майор Д.О.Гагринның 400 кешелек җәза отряды килеп җитә. Фетнәчеләр Ордага таба чигенәләр, баштанаяк коралланган гаскәргә каршы сугышуның нәтиҗәсез бетәчәген аңлап, Чура Рәсүлев белән Собхангул Килтәковлар карательләргә каршы яуга керүдән баш тарталар. Шуның өчен И.Кузнецов урынына калган Иван Сукошиков (Чесноковкада Зарубинның сәркатибе) аларны кулга ала һәм Суксун заводына илтеп, идән астына яба. Алар шунда карательләр кулына төшәләр һәм, Күңгергә кире кайтарылып, 17 февраль көнне дарга асып үтереләләр (17. 267 б).

30 гыйнварда Орда янында булган бәрелештә фетнәчеләр йөздән артык кешеләрен югалталар. Орда краеведы биредә «ике яктан да йөз кырыгар кеше һәлак була. Аларны ике каберлектә җирлиләр», дип яза (15). Пугачев ставкасы документларында Орда тирәсендә фетнәчеләрдән 113 кешенең үлеп калуы турында әйтелә (5; 17. 267 б).

Күңгергә ясалган уңышсыз походтан соң пугачевчылар килгән якларына таралыша башлыйлар. Ләкин күпчелек, шул исәптән гәйнәлеләр, Тол буена, Осага таба юл тоталар. Бу вакытта инде Осаны саклау да кыенлаша бара. Шәһәргә атаман итеп калдырылган С.Я.Кузнецов Солтанай авылыннан Рождественский заводы есаулы В.М.Завьяловка нык торырга, җәза отрядларына бирешмәскә, Пугачев килеп җиткәнче көрәшергә чакырып хат яза (5. N 267).

1774 елның язында, март ахырында, Оса юнәлешендә берничә җәза отряды хәрәкәт итә: 400 кешелек Яковлев отряды, Аннинск заводы идарәчесе Берглин җитәкчелегендә карательләр экспедициясе, 862 кешедән торган кнәз Голицын отряды килә.

Крепостьне сакларга калдырылган восстаниечеләр, үзләренә каршы зур көчләр ябырылуын күреп, төрле якка хәбәр салалар, вәкилләрен җибәрәләр. Ярдәмгә килүчеләр табылмагач, тәвәккәл адым ясыйлар: Осадан чыгып, берләшеп өлгермәгән җәза отрядларына ташланалар. 9 апрельдә Крыловодан 4 чакрымда зур сугыш булып ала. Өч сәгать дәвам иткән бу алышта карательләрнең 12 сугышчысы үтерелә, 3 солдаты яралана, гәйнәлеләр исән-имин котылалар, тик ике кешеләре карательләр кулына эләгә.

Көчләр тигез булмаганлыктан гәйнәлеләр Бардага таба чигенәләр. Берглин отряды, аларны эзәрлекли барып, баш күтәрүчеләр үткән авылларда булып, крәстиәннәрне талау, асу-кисүләр алып бара. Билгеле, барлык сәламәт кешеләр чигенеп барган восстаниечеләргә иярәләр янсә урманнарга качалар. Күп авылларда карательләр юл сорашу, баш күтәрүчеләрнең кай тарафка китүләрен белешү өчен бер кеше таба алмыйлар. Бардада, мәсәлән, алар йорттан- йортка йөреп эзләнә торгач, бер йортта бер сукыр белән бер телсезне табалар. Икесеннән бер сүз йолкып алалмагач, карательләр, болар безнең белән үч итеп сөйләшмиләр дип, башларын чабып өзәләр һәм авылга ут төртәләр. Бу 1774 елның 11 апрелендә була.

Оса-Барда арасында Берглиннең ун пушка, 270 мылтык, 168 турка, 174 винтовка, 563 җәя, 323 сөнге һәм кылыч белән коралланган 1400 кешелек отряды 6 апрельдән 12 апрельгә кадәр, ягъни җиде көндә, унбер авылны яндыра: Аръяк, Мостафа, Бичура, Үдик, Байавыл, Каенавыл, Антоново (?), Куян авыл, Тауавыл, Барда - берсен ачыклап булмады.

«Утта 800 хуҗалык юкка чыгарылды. Баш күтәрүчеләрнең 18 башлыгы кулга алынды», дип отчет бирә кире Осага кайткач карательләр командиры (3,8).

Берглин Оса тирәсеннән китеп бер атна да үтми, Тол буе авылларын «буйсындырырга» 600 кешелек Яковлев отряды чыга. Ул да Бардага кадәр килә һәм шунда, көлгә әверелдерелгән авыл янында, баш күтәрүчеләрнең засадасына очрый. Сугыш тәүлек буена бара, карательләр куыла. Карательләрне куып җибәргәч, баш күтәрүчеләр елгаларда ташу беткәнче сугыш хәрәкәтләрен туктатып торырга булалар.

Тол буенда гәйнәлеләрдән тыш урыс Тауавылы (Горы), Шабарка, Комарово, Городище һ.б. авылларның крепостнойларыннан төзелгән Иван Тарасовның 400 кешелек отряды хәрәкәт итә. Хөкүмәт армиясенә каршы зур һөҗүмнәр ясый алмаса да, халыкка карательләр килүен хәбәр итеп, ул да ярыйсы гына гамәл кыла. 29 апрельдә бу отряд Толны кичәргә әзерләнгән Яковлев отрядын атып куя.

Яковлевның крепостьтан торып крәстиәннәрне баш иярга чакырып язган хатлары йә җавапсыз калдырыла, йә Яковлев үзе килсен дигән җавап алына. Килсә, пугачевчылар тарафыннан кисәтелгән халык авылны ташлап урманнарга сибелә, карательләрне ышык урыннардан атып куа.

Чарасыз калган хөкүмәт түрәләре җәза отрядларына авылларны яндырудан туктарга, вак төркемнәр белән йөрмәскә, бөтен көчне Осада тупларга дигән боерык төшерәләр. Гәйнәлеләр белән аларның үз кешеләре аша эш йөртеп карарга булалар. Уфа провинция кәнсәләре, хәрәкәтнең башлангыч чорында юк булып торган Туктамыш Ижбулатовны табып, 1774 елның май аенда аны шундый нният белән кире үз олысына кайтара. Хөкүмәт манифестын тотып, ул гәйнәлеләрнең пугачевчылар лагерена килә, походный атаман Өдеһет Томәсовны карательләргә каршы көрәштә катнашудан баш тартырга, Гәйнә старшиналары исеменнән Осага «помилование» сорап хат язарга ризалаштыра. 23 майда Ижбулатов бу хатның эчтәлеге белән восстаниечеләрне таныштыра. Старшиналарның сугышны туктатырга, хөкүмәткә баш иярга, дигән тәкъдимен восстаниечеләр кабул итми. Киресенчә, шул ук көнне хокүмәт армиясенә каршы сугыш яңа көч белән башланып китә. Көндез башланган бәрелеш караңгы төшкәнче дәвам итә. Төнгә бөтен юлларга да каравыл куела, иртә белән көчле һөҗүм ясап, Яковлев отрядын янә чигенергә мәҗбүр итәләр, 15 чакрым аны эзәрлекли баралар. Алларына төшеп, оч урында күперләрне җимерәләр. Яковлев карательләрен тәмам тар-мар ителүдән восстаниечеләрнең пушкалары булмау гына коткара.

Шушы җиңүдән соң гәйнәлеләр яңадан Осага һөҗүм башларга әзерләнәләр. Яковлев 300 кешегә калган отряды белән крепостька кереп бикләнә. Шуннан торып авылларга хатлар яза. Крыловодан ярты чакрымда

юл остендә Якуп Атнагулов белән Әпсәләм Усаев казыкка беркетелгән гартмага «үгет- нәсихәт язуы» калдыралар. 1 июньдә Яковлев күзәтчеләре аннан оч җаван хаты - оч кисәтү алалар. Иртәгесен гәйнәлеләр өч меңлек отряд белән Гамицы авылы янына килеп туктыйлар һәм карательләрдән сөйләшүгә начальникларын җибәрүне сорыйлар. Ләкин Истомин белән Манаков сөйләшүгә килүдән баш тарталар, «солых килешүе ясау өчен» үзләреннән «первостатейный» кешеләрен Гамицы авылына җибәрүне таләп итәләр (3, 75).

Баш күтәрүчеләр вакытны сузарга, Уфа ягыннан ярдәм көтәргә булалар, шулай да Гамицы авылына Туктамыш Ижбулатов белән Мәүлет мулла Ермаковны җибәрергә ризалык бирәләр. Риза булалар булуын, ләкин Ижбулатовның үзләре файдасына сөйләшәчәгенә ышанып ук бетмиләр. Ике арада барачак сөйләшүне күзәтү өчен бу ике «парламентарий»га Күңгер ягыннан ике татар кешесен ияртәләр. Истомин чын сөйләшү алып барылачагына ышанмый, хәйлә- тозактыр бу дип уйлый һәм киңәшү өчен ашыгыч тостә Осага кайтып китә.

Шуннан соң гәйнәлеләр Яковлевның үзенә хат язалар: «команданы яхшылык белән Оса шәһәреннән алып чыгып Юго-Камск заводы ягына чиген», дип тәкъдим итәләр. Уйлары изге: корбаннар булдырмау, командадагы бар кешене «исән-имин өйләренә, элекке тормышларына кайтару». Гамицы авылы янында восстаниечеләр делегациясе хатны Яковлевка тапшыра. Яковлев ярдәм сорап язган үз хаты белән бергә ашыгыч рәвештә аны Казан губернаторы Я.Л.Брандка җиткерү өчен Пермь провинция кәнсәләренә озата.

Ул арада Осаның хәле баш күтәрүчеләр файдасына үзгәрә башлый: торле яктан Осага пугачевчылар хәрәкәт итүе турында хәбәрләр килә. Башмаков (җәза отрядының баш командиры) Яковлевка отрядын Осадан чыгарып, Аннинск заводына алып китәргә боера. Пугачевчылар, урманнардан чыгып, Гамицы авылына керәләр. Карательләрнең утта кыздырылган ядрәләр белән атуыннан Гамицы һәм аның белән күрше тагын ике авылда янгын чыга. Юлларны тотен баса. Шуннан файдаланып, баш күтәрүчеләр Осага таба хәрәкәт итәләр.

14 июнь коние Осага оч чакрым кала кичке алтыдан унга кадәр карательләр белән баш күтәрүчеләр арасында каты сугыш булып ала. Яковлев отряды яңадан крепостька кереп бикләнә. Шулай итеп, гәйнәлеләрнең оешкан тостә эш итүләре нәтиҗәсендә Башмаковның җәза отрядларын Осадан күчерү планы өзелә. Шулай да Казаннан аларга ярдәмгә җибәрелгән Скрипницын отряды Каманы кичеп крепостька үтәргә олгерә.

Казан губернаторы Бранд Мәскәүгә губернада тынычлык урнаштырылды, дип хәбәр итсә дә, Оса тирәсендә сугышлар әле кыза гына. Тол буе татарлары һәм башкортлары, Гамицы авылыннан торып, Оса крепостен саклаучыларга 1774 елның 15 июнендә шундый ультиматум җибәрәләр:

«...акылсызлык һәм ялгышлык эшләүдән баш тартыгыз, бернинди кан коюларсыз император галиҗанәпләре хакименә буйсыныгыз. Бу очракта государь Петр Федорович сезне кичерер. Әгәр дә инде баш орырга теләмәсәгез, үзегезнең өстегезгә аның каты ачуын («праведный от него гнев») алган булырсыз, һәм без сезләргә каршы ут һәм кылыч кулланырга мәҗбүр булырбыз» (10. 393 б).

Яковлев, җавап урынына воеводасы Пироговский һәм берничә йөз кешесе белән крепостьтан чыгып, Гамицыга һөҗүм ясый һәм оч меңгә якын пугачевчыны чигенергә мәҗбүр итә. Баш күтәрүчеләр килешү сорыйлар. Яковлев аларга Пироговский, мулла Атнагулов һәм татар кешесе Усаев составында делегация җибәрә.

Ике арада «көч сынашу», «сөйләшүләр» барган арада Күңгер ягыннан С.Кузнецов, С.Сәйдәшев, 11 июньдә Красноуфимскине алган Иван Белобородов һәм Салават Юлаев отрядлары, алардан алдарак Бөре ягыннан Бәхтияр Канкаев, Красноуфим аша Күңгергә барышлый Ф.П.Поповның җәза отряды белән бәрелешеп алган Пугачев та Орда, Ашап һәм Бөрмә авыллары аша 18 июньдә шулай ук Осага килеп чыга. Н.Дубровин «Пугачев һәм аның сообщниклары» дигән китабында (10. 392; 11) шулай яза. «Отчий край» дигән китаптагы очеркында А.Кобелев Пугачевның Осага килүен бүтәнчәрәк тасвирлый: «13 июньдә Пугачев Ирга заводына килде, ә 16 июньдә Уинск заводында аның армиясен 300 Тол башкорты каршы алды. Аннан Пугачев гаскәре белән Толга һәм Осага юл тотты. 17 июньдә инде ул Ширәмәт заводында була», дип яза (3. 78).

Пугачев килгәч, Оса крепостена янә хат җибәрелә. Бу юлы да аннан атыш һәм һөҗүм белән җавап бирәләр. Пугачевның үзе белән алышканнарын сизенмәгән крепость сакчылары, 80 солдатларын әсирлектә калдырып һәм үзләре дә бер әсир эләктереп, янә крепостька кереп бикләнәләр. Крепостьтан һөҗүм берничә тапкыр кабатлана. Һәр һөҗүм күп солдат һәм корал югалту белән тәмамлана. Гади солдатлары гына түгел, ә командирлары да кораллары-ниләре белән Пугачев ягына чыгалар. Төнлә белән яшеренеп чыгучылар да була.

19 июнь көнне Җаек казаклары крепость тирәсендә «Патшамыз Петр Федорович үзе килде, бирелегез!» дип кычкырып йөриләр. Майор Скрипницын аларга «Сезнең Пугачев бернинди патша түгел, ә разбойник!» - дип җавап бирә.

Бу көнне «самозванец ничего не предпринял, ә старшиналары белән Камага төшеп, аны кичәр урын гына карап йөрде», - дип яза «Пугачев һәм аның сообщниклары» авторы Н.Дубровин (11. 69 б). Кичү өчен билгеләнгән урынга кадәр сазлыклы урыннарга күперләр салырга, юлны төзәтергә булалар. Лагерьга кайткач, Пугачев атаманнарына шундый сорау бирә:

— Йә, инде нишлибез?

Пугачев үзе дә, башкалар да яхшы аңлый: 1100 яхшы коралланган солдаты, 13 тубы булган крепостьны алмасаң, ул Каманы иркенләп кичәргә ирек бирмәячәк, Казанга юлны бикләп тотачак. Димәк, алырга. Ләкин ничек?

Белобородов Утка заводын алганда үзе кулланган кызыклы план тәкъдим итә. (Ул аны Казанны алганда пушкаларны дошманга күрсәтмичә алга күчерү өчен дә куллана): арбаларга бастырыклап печән-салам төяргә, йөкләрне тоташ фронт итеп тезеп, арттан ышыкланып этеп барырга, крепостька якынлашкач, арбаларга ут төртергә, ут-төтен астында стеналарга баслыклар куеп, штурмга күчәргә (12).



Оса крепосте (Көнчыгыштан күренеш). XYIII гасыр гравюрасы.

Оса крепосте замана өчен нык кына корылма була. Осинка елгасының текә ярында төзелгән крепостьның стеналары ике катлы, 8 метр биеклектә булып, текә түбәләр астында укчылар өчен бүлмәләр дә эшләнгән була. 800 метрга сузылган стеналарның дүрт почмагында күзәтү башнялары, көнчыгыш стенаның уртасында күтәрелмә капкалы зур башня. Көньяк стена тирән чокыр буйлап үтә, көнчыгыш стена да чокыр артында, чокырдан соң - аркылы-торкылы утыртылган казык-киртә, аннан балчык өеме, янә аркылы-торкылы казык-киртә. Эчтә казарма йортлары, чиркәү, магазин, корал складлары, башка төрле корылмалар (3.39-40, 78 бб).

Иван Белобородов үзенең әлеге тәкъдимен ясаганчы крепостьны яхшылап өйрәнгәндер, ут-төтен астында штурмга күчү өчен кирәкле һәр нәрсәне (баслык һ.б.) алдан әзерләткәндер, дип уйларга кирәк.

Безгә Белобородовның кем һәм кайсы яктан булуын белү кызыклы.

**Белобородов** Иван Наумович (1741-1774) Күңгер өязе Медянка авылында (хәзер бу авыл Орда районына карый) туган. Бакыр кою, дары җитештерү заводларында эшләгән. Унсигез яшеннән патша армиясендә хезмәт иткән, артиллерист-канонир чинында отставкага чыгып, Богородич авылында урнаша, корт карау белән шөгыльләнә, бал- балавыз сатып көн күрә. Пугачев хәрәкәте башлангач, аны баш күтәрүчеләрне күзәтү командасына алалар, ләкин ул анда озак тоткарланмый, команданы ташлап китә. Нәкъ шул көннәрдә, 1773 елның декабрендә, Богородск заводы тирәсендә Пугачев тарафыннан Екатеринбург ягына җибәрелгән Канзафар Усаев отряды туктала. Базар мәйданында Пугачев манифестын укыйлар. Авыл сәүдәгәре Иван Белобородов аны игътибар белән тыңлый, отряд командирын өенә алып кайтып кунак итә. Манифест уку белән барган табында башка авыллардан старшиналар, старосталар да, татар авыллары зыялылары да катнаша. Шунда ук яңа отряд оеша, аңа йөзбаш итеп Белобородов билгеләнә. К.Усаев белән бергә ул Екатеринбург, Чиләбе якларында бик күп заводлар, крепостьлар ала, 1774 елның җәендә туган авылы Медянка, Уинск, Сүде, Шермейка аша Осага килеп чыга. Осадан соң Иван Наумович Пугачевның төп ярдәмчесе-киңәшчесенә әверелә. Идел аръягында Пугачев армиясе җиңелү арты җиңелүгә дучар ителгәч, гаиләсе белән өч көн урманда качып йөри, дүртенче көнне Казанга килеп, Иван Шеклеев исеме белән властьларга бирелә. Ләкин аны таныйлар һәм үлем җәзасына тарталар. 1774 елның 5 сентябрендә Мәскәүдә асып үтерелә.

Тыйнак кына исәпләүләр буенча И.Белобородов отряды белән өч мең чакрым юл үтә. (12).

1774 елның 20-21 июнь көннәрендә И.Белобородов беркайчан булмаганча эшлекле кыяфәттә була. Аның кушуы буенча унбишләп арбага печән-салам тоялә, крепость стеналарына меңү өчен кемнең нәрсә әзерли алуы ачыклана. Шундый әзерлек эшләре алып барган арада тиктормас Җаек казаклары крепостьтагыларны яңа патшага бирелергә өндәп, бирелмәсәләр, кырып бетерү белән куркытып йөриләр.

Камалыштагы Оса кешеләре кондезләрен һөҗүмгә чыкканда әсир төшеп, төннәрен яшеренеп чыгып, крепостьта ниләр булуын сөйләп торалар. Шундыйларның берсе крепостьта отставкадагы бер сержантның моннан унике ел элек Петр Федорович патшаны күргәнлеге белән мактанып йөргәнлеген әйтә. Әлеге Җаек казаклары, шуннан файдаланып, крепость стеналарына якын ук килеп:

— Чын патша безнең белән, ышанмасагыз безнең янга аны күреп-белгән отставкадагы сержантыгызны җибәрегез, — диләр.

Крепостьта берәүләр сугышырга, икенчеләр бирелергә өнди. Уртак фикергә килә алмагач, Петр Треногин исемле әлеге отставной сержантны җибәреп кайтарырга булалар. Пугачев парламентарийны егерме солдатын сафка тезеп каршылый. Гади солдат киеме киеп, үзе дә шулар арасына баса. Парламентарий сафтагы һәр солдатка текәлеп карый. Пугачев янына житкәч, Пугачев аңа кор тавыш белән:

— Нәрсә, бабакай, таныдыңмы мине? — дип сорый. Кинәт дәшүдән каушап калган гвардеец:

— Алла белсен, — дип җавап бирә. — Теге чакта син яшьрәк идең, сакалың да юк иде, ә хәзер...

— Кара, бабакай, әйбәтләп кара, бәлки танырсың, — ди ана Пугачев.

— Миңа калса, Сез государьга охшыйсыз кебек.

— Алайса бар әйт үзеңнекеләргә, карышып тормасыннар, югыйсә бит мин барыгызны да теге доньяга озата алам.

Карт сержант Петр Треногин крепостька кайта һәм әйтә:

— Чәче охшаган, ә менә йөзе охшап бетми кебек...

Яхшылап танып кайту өчен Пугачев янына аны кабат җибәрәләр. Бу юлы сержант икеләнми:

— Галиҗанәп офицерлар, каршылык күрсәтмәгез, ул безнең чын государебез Петр Федорович, — ди.

19 июньдә пугачевчылар коне буена киңәшләшәләр, крепостьтан җавап котәләр һәм иртәгесен, печән-салам төялгән арбаларга ат җигеп, башта ат белән, аннары фронт булып, тезелешеп үзләре этеп баралар. Крепостьтагылар белә: бирелмәсәләр, алар утта янып үләчәк. Шуннан куркып, крепостьның гарнизон начальнигы итеп билгеләнгән Скрипницын һөҗүм итүчеләргә башнядан кычкыра:

— Ашыкмагыз, иртәгә кадәр туктап торыгыз, сугышмыйча гына бирелергә уйлыйбыз.

Печән-салам төялгән йөкләр, аларга ышыкланып атулар туктатыла. Скрипницын Пугачев янына янә парламентарий җибәрә. Бу юлы аны үзләре бирелгән очракта аларны пешләтәчәкләре борчый. Коралларыгызны ташласагыз, бер нәрсә эшләтмәбез, командирлар үз постларында калырлар, дип җавап бирәләр аңа.

21 июнь коне иртә белән Оса крепостенда чаң кагалар, капкалар ачыла, шәһәр халкы һәм хәрбиләр Пугачевны ипи-тоз белән, тезләнешеп каршы алалар, ә Скрипницын байракны иеп тотарга боера (Оса музеенда РСФСР халык рәссамы Е.Данилевский ясаган диорамада Осаны алу вакыты нәкъ шушылай тасвирланган да).

— Бог и государь тебя прощают, — ди гарнизон начальнигына Пугачев һәм аның шпагасын алмаска куша.

Осаны саклаучылардан присяга алына һәм аларга «Казан полкы» дигән исем бирелә. Полкның командиры итеп Скрипницын үзе билгеләнә. Пугачев аңа да полковник званиесе бирә (11. 69-72 бб).

Югарыда күрсәтелгән хезмәтендә Н.Дубровин һәм «Отчий край» җыентыгында басылган мәкаләсендә А.Кобелев Осаның пугачевчылар тарафыннан алынуын шулай тасвирлыйлар. Икенче бер авторлар крепостьның җиңел бирелүен шәһәр халкының восстание күтәреп, солдатларны коралсызландыруы белән аңлаталар. «Пермский сборник. Источники и пособия для изучения Пермского края» дигән китап авторы Д.С.Смышляев Оса крепостен саклаучыларның восстаниечеләргә ныклы каршылык күрсәтүләре турында яза: «1774 елның июнендә Урал казакларыннан,

башкорт, качкын крэстиэннәрдән һәм мастеровойлардан торган Пугачев өере майор Скрипницын һәм прапорщик Минеев җитәкчелегендәге махсус отряд тарафыннан сакланган пригородны камап алды. Ныклы каршылык күрсәтелде («Отпор был отчаянный). Һөҗүм вакытында... камалыштагылар туктаусыз аттылар, фетнәчеләр өстенә кайнар сумала агыздылар, бүрәнәләр ташладылар, кыскасы, үрнәкле тырышлык күрсәттеләр. Кызганычка каршы, осалылар, биргән антларын онытып, ахырда злодейга бирелергә булдылар... Пугачев китеп олакканнан соң Оса тирәсе куркыныч тәртипсезлектә иде»(13. 60-61 бб).

Казанның яшерен комиссиясендә Пугачев хәрәкәте бастырылгач алып барылган тикшерү вакытында Оса воеводасы поручик Ф.Д. Пироговский сорау алучыларга шундый җавап бирә:

— Петр һәм Павел бәйрәмнәре алдыннан злодей полковниклар Белобородов белән Соловатко Юлаев җитәкчелегендә унике меңләп башкорт һәм урыслар өере Оса пригороды янына килеп, бөтен тирә-якны чолгап алдылар» (10. 68 б.).

Ә безгә билгеле, Осаны алып, яңадан мобилизация үткәргәч тә әле Пугачев армиясендә 8-9 меңнән артык кеше булмый. Кем әйтмешли, «курыкканга куш, койрыгы белән биш» күренгән шул.

Крепостьтан коралларны, шул исәптән сигез пушканы, башка кирәк-яраклы чыгаргач, Пугачев: «Яндырыгыз, анда тагын ниндидер дошман керүе бар!» — ди дә үз палаткасы янына чаптырып китеп бара һәм шунда суд оештыра. Тол буенда, Оса тирәсендә, Күңгер өязендә бер гаепсез кешеләрне кырганы, авылларны яндырганы өчен Яковлев үлем җәзасына хөкем ителә, отряды коралсызландырыла һәм присяга кабул итә, ә Яковлевның ярдәмчесе Манаковны пушка һәм дарының күпме булуын әйтергә, Пугачевны патша итеп танырга теләмәгәне өчен утка ташлыйлар. Авырулар һәм яралылар, дин әһелләре өйләренә кайтарыла. Андыйлар арасында Осаны алганда яраланган Салават Юлаев та була.

Осадан китәр алдыннан гына Казан полкы командиры итеп билгеләнгән Скрипницынның җәза отрядларының баш командиры Башмаковка ярдәм сорап яшерен хат язуы ачыклана. Пугачев аны, Смирновны, Бахманны һәм Строганов приказчигы Клюшниковны асарга әмер бирә.

23 июнь көнне Осадан ун чакрымдагы Неволин авылы янында Рождественский заводы эшчеләре булышлыгы белән Пугачев армиясе Каманы кичә. Аның составында Казан походына Пермь краеның биш мең авыл кешесе, завод эшчесе, шул исәптән ике йөзләп Тол буе һәм Култай авыллары кешеләре, 300дән артык Күңгер ягыннан Карьяу четверте кешеләре алына. Алар арасында хәрәкәтнең башыннан алып ахырына кадәр катнашучылар да, яңа мобилизация буенча җәлеп ителгәннәр дә була. Яңа мобилизация буенча гәйнәлеләр һәр йорттан берәр, ә өч ир-аты булган гаиләләр походка ике кеше әзерләп җибәрәләр. Казанга җиткәнче Пугачевның тулыландырылган гаскәре Воткинск, Ижевск заводларын ала. Казанны алу Пугачев гаскәренең иң зур җиңүе булып тора. Ләкин шуннан соң, Иделнең уң ягына кучкәч, Пугачев җиңелү арты җиңелүгә дучар ителә, гаскәре вак төркемнәргә бүлгәләнә, иң ышанычлы ярдәмчеләрен

югалта. Гәйнә иленең исән калган кешеләре кире әйләнеп кайта. Алар турында А.И.Андрущенко болай яза:

«Казан тирәсеннән бик күп Тол буе, Урал башкортлары... бетмәс-төкәнмәс таланган әйберләр алып кайттылар. Тол буенда яшәгән урыс авыллары әүвәлгечә бунтта булды» (4. 294 б.).

Рус Тау авылы (Горы) тирәсендә Оса олысының «тынычлыкны иң нык бозучысы» Иван Тарасов отряды хәрәкәт итә. Панов командалыгындагы карательләр отряды Тарасовның үзен үтергәч тә әле отряды 20 августта Шабарка авылын ала, Ширәмәт бакыр заводына һөҗүм итәр өчен Оса һәм Тол буе восстаниечеләре белән берләшә. «Бунт күтәрүчеләр баш ияргә җыенмыйлар. Шабарово, Беж, Пещера, Горы авыллары патшага тугры булырга ант иттеләр, ә башкортлар килми», дип зарлана карательләр командиры Панов.

Килмиләр, чонки аларның килер-китәр урыннары калмаган, авыллары колгә әверелдерелеп, җилгә очырылган, ә үзләре «карательләр ат менеп тә барып җитә алмаслык» җирләрдә, Осадан еракта урнашкан авыллар тирәсендәге урманнарда качып ятарга дучар ителгәннәр. Алар өчен старшиналар гына ант итә, имзаларын куеп, «моннан ары берничи бунт ясалмаячак», дип сүз бирә.

Патша хөкүмәте үз асылын танырга теләмичә, үзе кылган явызлыкларны да халыктан күрергә теләп, пугачевчыларны талаучылар итеп күрсәтергә тырыша. Ә без күрдек: алар патша гаскәрләре кебек явызларча кыланмаганнар, тәртип бозып, халыкны кыерсыту, армияне тәэмин итү өчен җыелган азык-төлекне үзләштерүчеләр, билгеләнгән күләмне арттырып җибәрүчеләр шундук җавапка тартылган, пугачевчылар хәтта дошманга карата гуманлык күрсәткәннәр. Гәйнәлеләрнең Оса горнизонына язган хатлары - шуның бер үрнәге. Ә аларны күп китерергә мөмкин. Менә Чернышевның Оса атаманы С.Я.Кузнецов һәм есаул Д.К.Юсуповка «Наставление»сеннән бер өзек: «поступать вам, яко верным и ко всем непременным рабам». Атаман Чика-Зарубинның боерыгыннан: Үдик авылыннан Семен Илишев Рождественский заводы ягында «разбойникларча эш иткәне, 2017 сум казна акчасын, 67 солдат фузеен, господский атларны үзләштергәне өчен» җәзага тартыла: берничи сүзсез бары да аннан тартып алына, бирми маташса, кулын-аягын бәйләп тиешле урынга озатылырга тиеш була. Ләкин ул алай каршы килеп маташмый.

Казна тозын урлауда гаепләнгән Оса воеводасы Кузнецовны сак астына алалар, Пугачев ставкасына озаталар. Ләкин ул үз гаебен таный һәм тиздән кире әйләнеп кайта, һәм аңа үз вазифасын башкарырга рөхсәт ителә.

Батыркай Иткининың Оса олысы старостасы И.И.Дьяконовка «Наставление»сеннән: «деньги принимать и хранить без утайки, никому напрасно обид не причинять». Йог заводы конторасына приказыннан: «Бермә авылыннан восстаниечеләрне ашату өчен ун йөк пешкән икмәк, һәр хуҗалыктан берәр каравай җыеп китерергә». Патша армиясе кебек, кырып-сыпырып түгел, ә һәр йорттан берәрне генә!

Пугачев хәрәкәтендә **Гәйнә олысыннан** меңгә якын (төгәлрәге 900 дән артык) кеше катнашкан. Без Гәйнә илендә хәрәкәттә катнашмаган, читтә торган, аңа теләктәшлек күрсәтмәгән, нинди дә булса формада булышлык итмәгән авыл булмаган, дип әйтә алабыз.

Пугачев ставкасында төзелгән авыллар исемлегендә Гәйнә олысының түбәндәге авыллары бар: Барда, Каенавыл, Куземьяр, Сүҗде, Үдик, Әрҗән, Кодаш, Бичурино, Солтанай, Усман, Тауавыл, Антоново, Ширәмәт бакыр заводы, Ишим авылы, Ирьяк, Куян авылы (Кояново), Бардабаш (ул вакытта бу авыл Ирәкте олысына караган).

«Крестьянская война 1773-1775 гг. на территории Башкирии» дигән китапта Уфа провинциясе авылларыннан Пугачев хәрәкәтендә ничә кеше катнашканлыгын күрсәткән «Ведомость» басылган. Шул «Ведомость»тан без Оса дәругындагы Гәйнә олысыннан: старшинасы Туктамыш Ижбулатов булган авыллардан 532 кеше, ясаклы татарлардан: Таныптан - 63, Бардадан- 20, Солтанайдан - 30, барысы - 113 ясаклы татар, Көчекбай Абдуллин старшина күзәтүендәге авыллардан (исемнәре күрсәтелми) хәрәкәттә 263 кеше, Ирәкте олысына караган Барбадаш авылыннан Пугачев хәрәкәтендә 7 кеше катнашкан. Ирәкте олысыннан барлыгы хәрәкәттә 352, Уран олысыннан 226 кеше катнашкан (10. 283 б.). Болары - Гәйнә олысының көньяк күршеләре. Төньяк күршегә килгәндә, Оса олысы Пугачев армиясенә 100 кеше коралландырып җибәрергә дигән карар чыгара, ләкин ул бу карарын үтәми, йөздән утыз кеше генә кулына корал тотып көрәшкә кушыла. Югарыда телгә алынган «Отчий край» авторлары моны Оса олысы старшиналарының һәм старосталарының авылларны, крәстиән хуҗалыкларын саклап калу линиясен тотулары белән аңлаталар. Шулаен шулайдыр. Оса олысы авылларын махсус ут төртеп яндырулар да булмый. Һәрхәлдә Пугачев хәрәкәте турындагы китапларда һәм архивларда андый мәгълүматлар очрамый. Югарыда утта кыздырылган ядрә атудан чыккан янгыннар турында әйтелде, анысы да бит аның Гамицы авылын юкка чыгарырга теләүдән түгел, ә анда җыелган гәйнәлеләрне кырабыз дип тырышуның нәтиҗәсе.

Түбәндә төрле чыганаклардан җыелган восстаниечеләрнең исем-фамилияләре китерелә:

Батыркай Иткинин (Иткинов, Иткининов дип тә очрый) - Тауавылдан, старшина, Пугачев аңа полковник дәрәҗәсе бирә;

Өдеһет Томәсов - Үдиктән, йозбаш, мулла, походный старшина, Пугачев хәрәкәтендә полковник, отряд командиры;

Карабай Әшмәнов - Үдиктән, полковник;

Ейәп Каштиянов - Кызылъяр-Әрҗәннән;

Мөхсин Мәдияров - Кызылъяр-Әрҗәннән;

Чура Рәсүлев - Кызылъяр-Әрҗәннән;

Шәфи Байчурин - Кызылъяр-Әрҗәннән.

Акбашев - Бормә авылыннан, 9 кешелек төркем белән Б.Иткинин отряды составында Йог заводына баруы мәгълүм;

Адулла Мостаев - походный старшина;

Сәйфулла (Сәйфел-Мәүлет) Сәйдәшев - Үдиктән, мулла, походный старшина, Габди Абдулов отрядында Кама буйлап Югары Мулга кадәр бара, Култай авыллары кешеләрен отрядка җәлеп итүдә зур тырышлык күрсәтә. Күңгер тирәсендә барган сугышларда отряд командиры буларак телгә алына; утрак полкка гомерлеккә хезмәткә җибәрелә;

Әмир Каймасов - Бардадан, «очерлылар һәм обвинлылар тарафыннан тотыла» һәм Башмаков отрядында пугачевчыларга каршы сугышып йөри, Беляковка янында янә баш күтәрүчеләр ягына чыга;

Гадел Ашменев (Ишманов?) - Үдиктән, хәрәкәткә 1773 елның декабрендә кушыла, 1774 елның октябрендә кулга алынып, Казандагы яшерен комиссиягә озатыла. Кинәт сукыраюы сәбәпле өенә кайтарыла;

Мокач Сютеев (Мөхәммәди Чүтиев?) - йөзбаш, хәрәкәттә актив катнашучы буларак билгеләнә. 1774 елның октябрендә кулга алына һәм.Казанга озатыла;

Кузнецов Степан Яковлевич - пахотный (сабанчы) солдатлар командиры, Осага атаман итеп сайлана, җәза отряды килгәч, урманнарда качып, гаиләләрдән яңа отряд оештырмакчы булып йөри;

Хәсән Сафаров - Усман авылы мулласы дип күрсәтелә, Б.Иткинин белән бер авылдан дип тә күрсәтелә, һәм шуннан Усман авылының Тауавыл булуын аңлыйбыз;

Юсупов Дмитрий Корнилович - Осага есаул итеп сайлана. Чукындырылган татар.

Габди Абдулов - Тауавылдан, мулла, походный старшина, полковник, Пугачевның Казан походында Сарапулга кадәр бара;

Абзакай Абдулов - Габдинең туганы, Үдиктән;

Җумакай Әскәров - старшина, Тауавылдан;

Илишев Семен - Рождественский заводы ягында походта йөрүе билгеле;

Абдулкәрим Айтуганов - йөзбаш;

Киндәй Чугалаев - йөзбаш;

Абдулла Шәрипов - йөзбаш;

Сәйдәш Даутов - Үликтән, Семен Илишев һәм Акбаш авылы кешеләре белән Рождественский заводында 2017 сум акча, 17 фузей, 6 ат, 200 балта, 20 көрәк, 27539 пот тимерне үзенеке итә һәм җаванка тартыла;

Роман Ардуганов - Үликтән, походный старшина;

Әбүбәкер Әҗмәтов - «баш күтәрүчеләр командиры» дип күрсәтелә, пикетта тора, Әрҗән авылыннан;

Әүбакый Әҗмәтов - алты кешелек торкем белән Нугай юлы Җамак авылында йөрүе турында язылa;

Абдулҗәлил Мәсәгутов - Усман авылыннан, Пугачев ставкасыннан килгән боерык буенча Чесноковкага аракы алып баруы билгеле;

Калинка Булатов - кайсы авылдан икәне билгесез;

Морат Булатов - Бардадан;

Гамил Даутов - мулла, кайсы авылдан икәнлеге күрсәтелми;

Әбрәшев Калин (Хәлим, Хәлил?) - кайдан икәне билгесез;

Бәшир Мокъсинов - Каенлык авылыннан дип күрсәтелә, Каенавылдандыр;

Шулепов Алексей - Шермейка бакыр заводыннан;

Мәсәгут Сулиев - поход оештырыласы тобәккә разведкага йөрүе мәгълүм;

Т.Зимасов - восстаниечеләр командиры дип күрсәтелә, 1737 елда Осаны камалышта тоткан, Барда елгасында җәза отрядын тар- мар иткән Абдаловның оныгы түгел микән дигән фикер бар;

Әзил Әҗмәнов - Үликтән, Габди Абдуловның Пермь ягына походында катнаша;

Сергей Рәсүлев - Гәйнә олысыннан, кайсы авылдан икәне билгесез;

Бу исемнәрнең күбесе «Крестьянская война 1773-1775 гг. на территории Башкирии» дигән китаптан алынды. Башка чыганаклардан алынганнары да бар.

**Күңгер өязеннән** Пугачев хәрәкәтендә катнашканнар һәм теркәлеп калганнар (5):

Акбай Кинзибаев - ясаклы татар, Тор авылына нигез салган, Кинзибайның улы яисә оныгы;

Габдел Бутиев - Абдулла-авылыннан;

Бикбов, Таһиров;

Әлмөхәммәт Мостаев -

Аракай - башкүтәрүчеләр командиры дип күрсәтелә;

Асылбай Касимов - старшина;

Асылбай Мәмәткулов -

Байчура Мостафин -

Бакый Абдулла улы - мулла, 1767 елгы закон эшләү комиссиясе депутаты;

Иман Әһлетдинов - йөзбаш;

Иманай Алачинов - йөзбаш;

Ишали Куралиев - йөзбаш;

Ишмәт (Ишмөхәммәт) Маметов - йөзбаш;
Купакхуҗа.
Кузнецов Федор - Кушай (Кошаево) авылыннан;
Сәгыйть Янбарисов.
Тупач Упапачев - Кишерть тирәсеннән, «Күңгер татары»;
Копулбай Юмин - Старсу (Сары Су?) авылыннан, полковник;
Толай Сәитов - йөзбаш;
Үтәш Үтәев - Коры Мойчәж авылыннан;
Чурагол - Торыш авылыннан;
Яффар Смаилов (Исмәгыйлов) - старшина;
Ситников - Йог заводыннан йөзбаш;
Мәүлет Аитов - Караяр авылыннан, полковник, Красноуфим-Күңгер арасында барган бәрелеш-хәрәкәтләрдә катнашуы турында языла; Күңгер өязеннән, Гәйнә башкорты;
Аткул Канбулатов -
Арслан Рангулов - атаман, Әтер, Барда юлларында барган сугышларда катнаша;
Буләк Якупов - старшина;
Гамил Даутов - полковник, Күңгер өязе баш күтәрүчеләренә таныклыклар бирүче итеп телгә алына;
Ишман Иткулов - полковник;
Шул ук «Документы ставки...» (5) дигән китапта «Указатель географических названий» дигән бүлешмәдә Алтынное, Аманеево, Башкирцево, Буколи, Гамицы Иренская волость, Орда, Турыш, Тюбенеково, Черный Яр, Чукулчи, Брехово, Старсу (Ирен. вол. Сиб. дор.), Кошаево (недалеко, видимо, д. Ключи) - (8).
Бу исемлеккә без Байчын (Байсино) авылыннан Габдуллаҗан исемле йөзбаш җитәкчелегендә Күңгерне камалышта тотуда катнашкан һәм «Яхшылар Йорты» дип аталган җирдә җәзалап үтерелгән төркемне дә кертергә тиешбез. Ышанам, туган ягыбыз тарихы белән кызыксынучылар бу исемлекне әлегә билгесез күп яңа исемнәр белән тулыландырырлар.
1773-1775 еллардагы крәстиәннәр хәрәкәтендә барлыгы 1373 башкорт, 263 мишәр, 9435 ясаклы татар һәм вотяк, шул исәптән Гәйнә олысыннан рәсми теркәлгәннәре генә 915, ә теркәлми яшәп, хәрәкәттә вакытлы гына катнашканнары да булганлыгын истә тотсак һәм Шермейка заводы эшчеләрен дә кушсак, бу сан меңне артып китәчәк. Ә бакыр заводыннан, А.И.Андрущенко язуынча, 166 кеше катнаша (4), калганнары - хатыннары һәм балалары белән бергә 487 кеше Пугачев армиясе Каманы кичкәндә үзләрен туган якларына, Нижгород губернасы Мухоедово авылына кайтаруны үтенәләр. Пугачевчылар аларны судноларга төяп озаталар (14. 151 б). Шулай итеп, Шермейка авылына нигез салган, завод төзегән һәм 14 ел бакыр койган Нижгород крепостнойлары үз якларына кайтарылалар. Пугачев армиясенә кушылганнардан 14 кеше бәрелешләр вакытында вафат була яисә билгесез юкка чыга. Үз авылларына кайтарылганнар кайтып җиткәннәрдер дип әйтеп булмый, патша армиясенә, качкыннарны эзләү

отрядларына юлыгып, аларның-кире Шермейкага кайтарылган булулары да мөмкин.

Пугачев җитәкчелегендәге крәстиәннәр хәрәкәтендә гәйнәлеләрнең нинди тырышлык, оешканлык күрсәтүләрен һәм шуның өчен нинди югалтуларга дучар ителүләрен күрдек. Беренче көннәрдән үк алар Батыркай Иткинин белән Габди Абдуловлар тирәсендә тупланалар, С.Яковлевның Ширәмәт бакыр заводын алалар, Сарапулны алуда, Күңгерне камалышта тотуда катнашалар. Патша самодержавиесе оплоты, Гәйнә олысы җирләрен колонизацияләү үзәге булган Осага һөҗүм ясап, аны ике тапкыр алалар, патша армиясенә сизелерлек югалтулар китерәләр.

Пугачев хәрәкәтендә күп старшиналар һәм старосталар да катнаша. Алар арасында без дәүләт закон чыгару Уложение комиссиясе әгъзалары (депутатлары) Базаргул Юнаев белән үзебезнең Гәйнә олысы старшинасы Туктамыш Ижбулатовны да күрдек. Алар икәүләшеп башкортларның наказларын эшлиләр, аларны җыеннарда тикшерүгә чыгаралар. Бу наказларда алар башкортларның икътисади хәлләрен, салым, мәдәни мәсьәләләрен хәл итү буенча таләпләрен куялар. Туктамыш Ижбулатов закон әзерләү комиссиясенә биргән бер хатында писарьларны читтән китерүне туктатырга дигән тәкъдим дә ясый, чөнки аларның урыс администрациясенең күз- колагы, ягъни яшерен агенты булуын аңлый. Наказлар җыеннарда каралганнан соң Петербургка җибәрелә. Вакыт үтә, ә берни дә үзгәрми. Халык әби патшаның Уложение комиссиясе төзүен күз буяу өчен генә эшләнгән нәрсә икәнен, патша хокүмәтенең халык өчен уңай бер нәрсә эшләмәячәген, ирек һәм хокукларны тик даулап, көрәшеп кенә алырга мөмкин икәнен аңлый, коралга тотына. Ике депутатның берсе - Исәт провинциясеннән Базаргул Юнаев көрәшкә күтәрелгән халыкның алгы сафына баса, аның җитәкчесе, Е.Пугачевның иң тугры ярдәмчесе була, аңа фельдмаршал дигән иң югары чин бирелә. Җыеннарда тикшереп кабул ителгән наказлар крәстиәннәр сугышы чорында халыкны яуга өндәүче Пугачев манифесты төсендә халык арасында тарала.

Уложение комиссиясенә башкортлардан сайланган ике депутатның берсе - Базаргул Юнаев шушы наказ-манифестны тормышка ашыру өчен көрәштә вафат була. Күңгер өязеннән сайланган ясаклы татар Бакый мулланың язмышы билгесез. Аның да исән калуы икеле. Ә менә Туктамыш Ижбулатовны без көрәш кырында күрмәдек. Пугачев хәрәкәте турында язучы авторлардан берәүләре аның ролен уңай бәяләсә, икенчеләре көрәшнең читендәрәк йөргән итеп сурәтли.

Пугачев хәрәкәте бастырылгач, провинцияләр кәнсәләрләре анда катнашканнарның исемлекләрен төзиләр. Ырымбур губернасында 200 мең кеше (90 меңе рус булмаган халыклар) исемлеккә кертелә.

Җәза гаскәрләре башкомандующие генерал- аншеф П.И.Панин төзегән исемлек буенча 14 меңнән артык двордан (42 мең ир-аттан) башкортлардан нибары 54 двор (163 ир-ат) хәрәкәттә катнашмаган. Уфа провинциясендә 133 старшинадан нибары унбере патша хокүмәте ягында калган.

Меңнәрчә кешеләр җәзага тартыла, иң төп «гаеплесе» - Пугачев эшафотка мендерелә, аннан кала «иң усал злодейлар» Соловатко Юлаев,

аның әтисе Юлай Азналин, Канзафар Усаев, 71 яшьлек Остафий Долгополов, Иван Почиталин, Емельян Тюленев, маңгайларына утлы тимер белән тамга салынып, борын пәрдәләре, колаклары өзелгән хәлдә Оса, Күңгер һ.б. урыннарда 25әр камчы алганнан соң Балтик диңгезендәге Рогервиккә мәңгелек каторгага озатылалар.

Еллар үтә, җәза отрядлары йөргән юлларда, кала-крепость тирәләрендә һәм мәйданнарында халыкны «баш күтәрүләрдән тыеп тору өчен» дип калдырылган дар агачлары, элмәклә аркан-чылбыр, тимер ыргаклар, аларга аскан гәүдәләр таркалып төшкәч тә асылынып торуларында булалар.

«Әсир төшкән восстаниечеләрне муеннарыннан һәм җилкәләреннән дә, кабырга сөякләреннән дә асалар, үле гәүдәләре таркалып төшкәч тә җыештырырга ашыкмыйлар... Шәһәр мәйданында кабырга сөягеннән тимер ыргакка асылынган татар кешесе тере килеш өч тәүлек асылынып тора... Пугачев Манифестын таратканда тотылган ике писарьның берсен Ирән тавында җилкәсеннән, икенчесен Кадошниково авылында кабырга сөягеннән асалар... Хәрәкәттә катнашканнарны гына түгел, ә аларга теләктәшлек күрсәткәннәрне дә вәхшиләрчә җәзалап үтерәләр» (9).

Күпләрне Ырымбурда, Уфада, Казанда җәзалыйлар. Габдулла ага миңа яшь чагымда безнең Туктамыш та җәза отрядына эләгеп Казанда асып үтерелгән дип сөйләгән иде. Аның бу сүзләрен Бардада тагын берничә кешенең кабатлаганы булды. Ләкин күпме эзләнсәм дә мин аны андыйлар исемлегендә таба алмадым.

«Башкортстан территориясендә 1773-1775 еллардагы крәстиәннәр сугышы» дигән китапта 1774 елның 4 августында Бөгелмәдә Канзафар Усаевтан сорау алу үткәрелүе әйтелә. Протоколда шундый сүзләр укыйбыз: «Близко Уфы злодейски же полковник Токтамыш Ижболатов всем вместе зделать на Уфу нападение и разбивать везде воинские команды, а в коликом числе те толпы, - я подлинно не знаю» (10. 222 б).

Шушы документка бирелгән искәрмәдә укыйбыз: «Токтамыш Ижболатов, Оса дәругының Гәйнә олысы старшинасы, 1767 елгы Уложение комиссиясе депутаты, 1774 елның җәендә Башкортостанның төньяккөнбатыш районнарында восстание хәрәкәтләрендә катнаша» (шунда ук, 401 б).

1774 елның 1 ноябрь числосы белән Уфадан Ырымбурга җибәрелгән Ведомостьта Туктамыш Ижбулатов турында «узган кышны Ырымбурда үткәрде, аннан өенә кайтарылды» диелә. Шунда ук кайткач «участие в злодействе неизвестно» дигән сүзләр дә бар (10. 256 б).

Димәк, безнең атаклы старшина һәм рудачыбыз Пугачев Осаны алырга әзерләнгән, чорда «бәладан башаяк» дип үз олысыннан киткән, хәрәкәт тәмамлангач та әле исән булган. Моны раслаучы тагын бер документ. 1774 елның октябрь аенда Күңгер гарнизоны командиры подполковник А.В.Папав генерал-майор П.М.Голицынга биргән рапортында 957 баш күтәрүченең тәүбәгә китерелүе турында яза. Андыйлар арасында Гәйнә старшиналары Туктамыш Ижбулатов белән Көчекбай Абдулинның да булуы әйтелә (10. 405 б).

Менә тагын бер документ — 1775 елның 16 февралендә төзелгән Ведомость. Аны да Уфа провинция кәнсәләре төзегән. Төзегән һәм шул ук көнне төзәтмә биргән. Төзәтелгән Ведомостьта шундый юллар бар : «хотя и показан Ахмер Шерыпов... Шерып Кииков, Туктамыш Ижбулатов, Кулы Болтасев... в продолжении злодейского замешания к той их шайке не приставали, а находились в непоколебимой верности, как-то: Ахмер, Шерып и Кулый здесь в Уфе, а протчие по разных воинских командах во искоренении злодеев, кому где по тогдашним обстоятельствам случай быть подал» (10. 295 б).

Яңартып төзелгән бу Ведомость буенча безнең Туктамыш восстаниечеләр ягында булмыйча, хөкүмәт армиясенә хәрәкәтне бастыруда ярдәм итеп йөргән булып чыга. Кайсыбер чыганакларда Пугачев хәрәкәтен бастыруда «Т.Ижбулатов өч меңлек отряд белән катнашты» дигән сүзләргә тап буласың. Югарыда искә алынган А.И.Андрущенко китабыннан янә бер мәгълүмат: «Бу вакытта подполковник Пановка Райкин олысында 551 башкортның баш оруы турында хәбәр иттеләр», баш оручылар арасында Уложение комиссиясе депутаты Туктамыш Ижбулатов белән Көчекбай Абдуловның да булуы әйтелә (4). Аңлашылып бетми: хәрәкәттә восстаниечеләр ягында катнашкан булсалар, алар ничек җәзасыз калганнар, хәрәкәтне бастыруда катнашсалар, тәүбәгә китерүнең ник кирәге булган?

Бер-берсенә каршы килгән бу документларның кайсы дөрес, кайсы ялган, әйтүе кыен. Ләкин без ялгышмыйча шуны әйтә алабыз: Пугачев хәрәкәте буларак тарихка кергән Крәстиәннәр сугышы Гәйнәнең бер кешесен дә битараф калдырмаган, Гәйнә иле бөтен Пермь крае өчен оештыручы мәркәз ролен үтәгән.

Хәрәкәт бастырылгач, анда катнашканнарны кулга алганнар, сөргөн, каторгаларга озатканнар. Халыкка мөрәҗәгать язып таратучыларның башта кулын, аннары башын чабып өзгәннәр, кабырга сөякләреннән асканнар, казыкка утыртканнар. Исән-имин котылганнар Крылов, Строганов, Яковлев кебек дворяннарга китергән зыян өчен җавап бирергә тиеш булганнар. Оханскида оештырылган суд карары буенча алар «китерелгән зыянны» иң әйбәт җирләре белән түләргә, Иван Грозный Казанны алгач зур шәһәрләр һәм елга буйларыннан куылулары өстенә яңа тергезгән авылларын да ташлап китәргә мәҗбүр ителәләр. Шушы суд карары белән Тол-Түздән Үдик һәм Тауавылга кадәр барлык авыллар - Бичура, Чәрмәтәбаш, Чәрмәтә Түз, Кызылъяр, Чокыр, Мостафа (Мостовая), Мәтәвәли, Арьяк, Томәс, Чалклы (Чалково), Коптяк, Камчура, Иске йорт һ.б. авылларның халкы тагын да эчкәрәк, Гәйнә олысының урман-таулы җирләренә «күчерелгән» (дөресрәге, куылган). Бу авылларның кешеләре үз чиратында анда яшәгән арларны (удмуртларны) кысрыклап, Әрҗән, Ар Башап, Искир, Сөҗән, Сүҗде, Йөкшүр авылларына килеп утырганнар. Арларның күп өлеше бүгенге Куеда районы территориясенә (Шөгерт, Гожан, Гондырь һ.б. авылларга) күчеп киткәннәр. Китмәгәннәре, ислам динен кабул итеп, үз авылларында торып калганнар һәм татарлашканнар. Иске Башап, Башап Түз авылларындагы Алешкин, Ижгузиннар, Үдикнең Арзыевлары әнә шушы чорда ассимиляцияләнгән аборигеннарның варислары.

1773-1775 елллардагы крэстиэннэр сугышын зур көч белэн бастырып, эби патша хокүмэте моңдый хэлне килэчэктэ булдырмас өчен кисэтү чаралары күрергэ мэжбүр була. Иң беренче эше итеп ул җирле хакимият органнарын ныгытуга тотына. 1775 елның 7 ноябрендэ «Бөтенроссия империясендэ губернага идарэ итү учреждениелэре» турында карар кабул итэ. Аның нигезендэ губерналар яки наместничестволар өязлэргэ, өязлэр олысларга бүленэ. Гэйнэ олысы Уфа наместничествосының Оса өязенэ кертелэ.1781 елның 18 мартында Ырымбур губернасы буенча чыгарылган исемле указ нигезендэ губерна ике өлкэгэ - Ырымбур һэм Уфа өлкэлэренэ бүленэ. Оса өязе Пермь наместничествосына күчерелэ. 1796 елда Уфа наместничествосы бетерелеп, Ырымбур губернасы торгызыла. Губернага губернатор яки генерал-губернатор, өязгэ капитан- исправник идарэ итэ. Бу вазифаларга дворяннар сословиесеннэн булган кешелэр генэ куела.

1798 ел 10 апрель указы белэн административ реформа үткэрелэ - кабилэлэр олысы урынына территориаль олыслар төзелэ, э алар кантоннарга берлэшэ.

1736 ел 11 февраль указы нигезендэ старшиналарга 200, есаул, писарь һэм йөзбашларга 100, гади халыкка 50шэр чирек җир бүлү каралган була. Община җире җитмэгэндэ буш яткан казна җирлэрен бүлешү рөхсэт ителэ. Мишэрлэр һэм типтэрлэр башкортлар белэн килешү нигезендэ, килешэ алмасалар, казна җиренэ күчерелергэ тиеш булалар. Бу алар өчен зур югалту һэм кыенлыклар тудыра, хокүмэткэ күп хатлар, үтенечлэр явуга китерэ. Шуларны истэ тотып, 1793 елның 1 сентябрендэ Сенат припущенникларга моңарчы яшэгэн урыннарында калырга рөхсэт итэ торган указ кабул итэ. Лэкин низаглар кимеми, бэхэслэр чыгып тора. XYIII гасыр ахырында Ырымбур губернасында җирлэрне яңадан бүлү (генераль межалау) үткэрелэ. Припущенникларга да, урысларга да 15 дисэтинэ җир бүлү карала. Бу чара да күп каршылыклар тудыра. Өстэвенэ башкорт һэм мишэрлэр элегрэк сигез йорттан бер хэрби җибэрэ торган булсалар, моннан ары ат, корал, азык-төлек белэн тээмин итеп, өч йорттан бер солдат койлэп җибэрергэ тиеш булалар. 1794 елдан гэйнэлелэр җан башыннан алына торган 70 тиен налогны 1 сум итеп, оброк налогын 1 сум урынына 3 сум итеп түлэргэ тиеш булалар. Боларның барысы да халыкның хэлен начарлатканнан начарлата бара.

Пугачев хэрэкэте бастырыла, лэкин аны тудырган сэбэплэр кала.

## Файдаланылган әдәбият:


1. История Урала. Том 1. Пермь, 1976.

2. Крестьянская война в России в 1773- 1775 годах. Восстание Пугачева. Под редакцией В.В.Мавродия. Л., 1966.

3. Отчий край. Пермь, 1991.

4. А.И.Андрущенко. Крестьянская война 1773-1775 гг. М., 1969.

5. Документы ставки Е.И.Пугачева, повстанческих властей и учреждений 1773- 1774 гг. М., «Наука», 1975.

6. Центрархив. Материалы по истории революционного движения в России XYII- XYIII вв. Пугачевщина. Том II, М-Л., 1929.

7. М.Иделбаев. Юлай улы Салават, «Шоңкар» журналы, 1994, N 2(4).

8. Исторические документы о шайках Пугачевского бунта. Рукописная книга из фонда библиотеки Казанского педагогического института. ВО 332205.

9. В.Варзаков. Странички истории. Пугачевцы под Кунгуром. Кунгурская городская газета «Сельская новь». 1964 24 января.

10. Крестьянская война 1773-1775 гг. на территории Башкирии. Уфа, 1975.

11. Н.Дубровин. Пугачев и его сообщники. Том III. СПб., 1884.

12. М.Н.Мартынов. Пугачевский атаман Иван Белобородов. Пермь, 1958.

13. Д.С.Смышляев. Пермский сборник. Источники и пособия для изучения Пермского края. Пермь, 1869.

14. С.Алишев. Татары Среднего Поволжья в Пугачевском восстании. Казань, 1973.

15. Ф.Первов. Орда - стан пугачевцев. Орда район гэзите «Верный путь», 1965. N 81.

16. И.М. Гвоздикова. Салават Юлаев. Өфө, 1984.

17. Вахит Имамов. Татарлар Пугачев явында.

(Сәет батыр. Яр-Чаллы, 1994).

# YII. «Рус тарихының яңа чоры»

«Якынча XYII йөздән рус тарихының яңа чоры башлана», дип яза В.И.Ленин (1.153- 154 бб). Шушы чордан Русия ике кыйтгага - Европа һәм Азиягә - канатын җәйгән трансконтиненталь державага әверелә. Гәйнә иле, Болгар һәм Казан ханлыклары чорында да, губерналар чорында да гел чит-окраина булып йөргән олыс, державаның уртасында торып кала. Кайчандыр Каф тау артларыннан кысрыкланып, озын-озак юллар үтеп, мең төрле язмышларга юлыгып, тыныч яшәү өмете белән Каманың урта агымына, Тол, Чу суы буйларына килеп чыккан гәйнәләләр, алар ягына килеп сыенган бүтән халыклар моннан ары инде беркая да ычкына алмаячаклар.

1591 елда Тол тамагында, гәйнәләләрнең олы капкасы урынында Новоникольская слобода барлыкка килгән, 1738 елдан ул Оса бистәсе дип атала, ә 1781 елда шәһәр статусы ала. Шушы чордан Мәскәү, урыс дәүләте шушыннан торып ни боерса, гәйнәләләр шуңа риза булып яшәргә тиеш булалар. Бу «яңа чорда» алар инде топ сәүдә юлыннан - Кама буеннан 30-40 чакрымга урман арасына куылганнар, үзләре күптән сизенгәнчә, алар инде башкорт сословиесен дә югалтканнар, гади рус крәстиәне дәрәҗәсенә төшерелгәннәр, аларны рекрутка алулар, хакимият кешеләренә ризасызлык белдерсәләр, аларны сөргеннәргә сөрүләр, төрмәләргә ябулар, кыйнап үтерүләр башланган.

1835 елдан 1850 елга кадәрге чорда гына да Гәйнә олысыннан «төрле гаепләре өчен» егермеләп кеше Себергә озатылган. Андыйлар арасында 1848 елда Таныптан сөрелгән 69 яшьлек Абдулхәер Мансуров та, 1838 елда Солтанайдан сөрелгән Зәйнетдин Вәлитов та, һ.б. да бар (2).

XIX гасырда үткәрелгән халыкны исәпкә алу документларында авыл саен диярлек «фәлән гаебе өчен Себергә сөрелде», «рекрутка, солдатка бирелде» дигән сүзләргә тап буласың.

Кама буендагы иркен болынnарыннан, чәчүлек җирләреннән мәхрүм ителгән гәйнәләләр XYIII гасыр урталарына кадәр нигездә урман кисү, сал агызу, сумала кайнату, мунчала хәзерләү, аучылык һәм чолыкчылык белән шөгыльләнәләр. Күршеләре, Себер дәругы Красноуфимнән көньяктарак урнашкан авыллардан аермалы буларак, гәйнәләләр бу чордан тулы утрак тормышка күчкәннәр, XYIII гасырның 30 елларыннан янә игенчелек белән чын-чыннан шөгыльләнә башлаганнар. Һәм оста игенчеләр буларак, аларның даны бөтен Уралга таралган. 1680 елларда ук әле һлар электәге традицион тауарлары - балавыз, җәнлек тиресе, кул эшләре әйберләре белән бергә базарларга ашлык-икмәк тә алып чыкканнар, шушы тауарлары белән Соликамск базарларында да күренгәләгәннәр. Ә 1696 елда алар ашлык белән Эрбит ярминкәсендә сәүдә иткәннәр. (3.75 б). XIX гасырда кирәк кешеләр аларның бу тауарын үзләренә, Барда, Сараш базарларына һәм ярминкәләренә килеп алып киткәннәр. Игенчелек Гәйнә кешеләре өчен XYII гасырдан ук тормыш итүнең төп тармакларыннан берсе булган, терлекчелек исә ярдәмче тармакка әверелгән. 1850 еллардан биредә уртача һәр гаиләгә нибары 1,5 - 2 дисәтинә иген чәчәрлек җир туры килгән. Шуңа да карамастан, гәйнә олысы «икмәкле як» булып танылган.




XIX гасырда пермь татарлары кулланган җир эшкәртү кораллары: а — ике тешле сука, б — Курашим сукасы, в — ярым сабан, г — рамалы тырма, д — Кече Башап авылында ботаклы агачтан эшләнгән тырма, е — Танып авылында кулланылган үрелмә тырма, ж — оч почмаклы тырма. («Пермские татары», 24 б).

«Башкортстан археологиясе һәм этнографиясе» дигән китапның У томында бирелгән бер таблицага күз салыйк. Бөтен китапка бер таблица, Оса өязенең Гәйнә олысы авылларында 1841 елда күпме иген чәчелеп, нинди уңыш алынганлыгын күрсәтүче таблица ул (4.143 б):

| Авыллар | Чәчүлек (чирек) арыш | бодай | арпа | солы | Уңыш (чирек) арыш | бодай | арпа | солы | Хуҗалыклар саны | һәр хуҗалыкка чирек белән | дисәтинә белән |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Үдик | 395 | 33 | 88 | 50 | 1185 | 9 | 32 | 200 | 148 | 2,7 | 2,45 |
| Уймуж | 122 | 2 | 4 | 17 | 366 | 6 | 16 | 68 | 45 | 2,7 | 2,45 |
| Федорки | 91 | 1 | 3 | 12 | 273 | 3 | 12 | 48 | 38 | 2,4 | 2,18 |
| Тауавыл | 150 | 2 | 6 | 32 | 450 | 6 | 18 | 96 | 102 | 1,47 | 1,33 |
| Әрәмәавыл | 60 | 1 | 3 | 13 | 18 | 3 | 9 | 39 | 40 | 1,5 | 1,36 |
| Ишмән | 3 | 1 | 3 | 6 | 90 | 3 | 9 | 18 | 26 | 0,11 | 0,1 |
| Кәкирче | 60 | 1 | 3 | 13 | 180 | 3 | 9 | 39 | 32 | 1,87 | 1,7 |
| Куземьяр | 245 | 1 | 4 | 24 | 735 | 3 | 16 | 96 | 103 | 2,38 | 2,16 |
| Чуашай | 40 | – | 1 | 6 | 120 | – | 6 | 24 | 15 | 3,63 | 3,3 |
| Кодаш | 60 | – | 2 | 6 | 180 | – | 8 | 24 | 31 | 1,93 | 1,75 |
| Акбаш | 190 | 1 | 2 | 9 | 570 | 3 | 8 | 36 | 64 | 2,99 | 2,7 |
| Ишим | 210 | 2 | 4 | 15 | 630 | 6 | 16 | 60 | 15 | 15 | 12,7 |
| Чалклы | 82 | – | 2 | 9 | 246 | – | 8 | 36 | 34 | 2,41 | 2,2 |
| Яңа Бичурино | 150 | 4 | 4 | 150 | 450 | 12 | 16 | 200 | 87 | 1,72 | 1,56 |
| Бардабаш | 23 | – | 1 | 12 | 69 | – | 4 | 48 | 18 | 1,28 | 1,16 |
| Сүҗде | 60 | – | 1 | 6 | 180 | – | 4 | 24 | 38 | 1,58 | 1,43 |
| Каенавыл | 261 | 4 | 10 | 25 | 783 | 12 | 40 | 100 | 108 | 2,4 | 2,18 |
| Барда | 250 | 10 | 20 | 60 | 750 | 30 | 60 | 180 | 243 | 1,02 | 0,91 |
| Әрҗән | 106 | 8 | 16 | 30 | 318 | 24 | 48 | 90 | 188 | 0,56 | 0,41 |
| Чат | 45 | 4 | 6 | 15 | 135 | 12 | 18 | 45 | 12 | 3,75 | 3,4 |
| Аклыш | 140 | 2 | 4 | 8 | 420 | 6 | 12 | 32 | 86 | 1,62 | 1,45 |
| Шлик | 10 | – | 1 | 2 | 30 | – | 3 | 8 | 70 | 0,7 | 0,63 |
| Иске Башап | 12 | – | 1 | 2 | 36 | 2 | 3 | 8 | 18 | 0,66 | 0,6 |
| Сараш | 220 | 2 | 5 | 30 | 660 | 6 | 15 | 90 | 200 | 1,1 | 1 |
| Солтанай | 220 | 2 | 4 | 15 | 660 | 6 | 12 | 45 | 106 | 2,07 | 1,9 |
| Сөҗән | 72 | 1 | 2 | 3 | 216 | 3 | 6 | 9 | 31 | 2,32 | 2,1 |
| Батырбай | 68 | 2 | 2 | 2 | 204 | 6 | 6 | 6 | 33 | 2,06 | 1,9 – |
| Танып | 38 | 1 | 2 | 5 | 114 | 3 | 6 | 15 | 80 | 0,47 | 0,42 |
| Яңа Башап | 70 | 3 | 4 | 10 | 210 | 9 | 12 | 30 | 34 | 2,06 | 1,9 |
| Башап Баш | 14 | – | 2 | 3 | 42 | – | 6 | 9 | 7 | 2 | 1,81 |

XIX гасыр башына Тол һәм аның кушылдыклары буенда эшкәртү өчен уңайлы җирләр үзләштерелеп беткәч, күп авылларда ул җан башына бүләргә дә җитмәгән. Эшсезлектән күпләр, тәрәзәләренә аркылы- торкы-

лы такта кагып, гаиләләре белән читкә чыгып китәргә, «яңа чор» Рәсәе буйлап сибелергә мәҗбүр булганнар. Бардада гасыр башында һәр өченче йортның тәрәзәләре кагулы булган. Бусы китаплардан укылган нәрсәләр түгел, әле бүген дә исән картларның әтиләреннән ишеткәннәрне үз балаларына сөйли торган сүзләре.

Патша хөкүмәте салган күп төрле салымнар белән изелгән халык үзенә юньле йорт та салып керә алмаган. Күпләр землянкаларда, тәрәзәсез куышларда җан асраган. Кырыкка илле сантиметр зурлыктагы сыңар тәрәзәле, җиргә иңгән берничә йорт, ярымземлянка Бардада илленче елларда да бар иде әле. Шул елларда исән картлар күп авылларда морҗасы тышка чыгарылмаган йортлар булуын, узган гасыр ахырында андый бер йортның Барданың олы урамында, бүгенге Ленин-Совет урамнары чатында, икмәк магазины урынында булуын искә алалар иде.

Ә ул илленче еллардан тагын да илле-алтмыш елга артка чигенсәк, В.И.Ленин «яңа чор» дип атаган дәвергә үк барып чыксак, анда инде без өлешенә тигән иманa җирен эшкәртергә, йортына пыяла тәрәзә куярга хәленнән килмәгәннәрне берән-сәрән түгел, ә адым саен, урам һәм авыл саен күрер идек. Төтен налогы түләмәс өчен күпләр шулай мичен морҗасыз итеп суккан, үзен күп нәрсәләрдән мәхрүм иткән. Алай да яшәр чамасы калмагач, читкә чыгып киткән.

«Яңа чор»да көчәеп киткән капитализм менә нинди «рәхәтлекләр» алып килгән Гәйнә халкына.

Ә күп булганмы соң бу чорда Гәйнә халкы?

1834 елгы сан алу вакытына Гәйнә иләндә 44 татар-башкорт авылы булып, алар ике олыска буйсынган. Башкорт сословиесендә йөргәннәр Гәйнә олысында 8 юртага бүленеп йортелгән һәм халкы түбәндәгечә булган:

I юртада: Үдик - 1034, Уймуж - 417, Федорки - 568. Барысы - 2019 кеше.

II юртада: Ишмән - 133, Әрәмәавыл - 221, Тауавыл -532, Искир - 177. Барысы - 1063.

III юртада: Ишим - 163, Чуашай - 83, Чалклы - 179, Акбаш - 314, Йөкшур-Кодаш (1832-1833 елларда Ишим, Чалклы, Куземьяр, Чуашай авыллары кешеләреннән барлыкка килә) - 110, Куземьяр - 545. Барлыгы - 1394.

IY юртада: Барда - 223, Сүҗде - 190, Каенавыл - 523, Яңа Бичурино - 537, Бардабаш - 76, Иткуль-Давыдово - 10, Үтәбай - 44, Нигъмәт - 130. Барысы - 1733.

Y юртада: Барда - 916, Югары Каҗмакты (1831 елда Барда, Тауавыл, 1832 елда - Үдик, 1833 - Куян авылы кешеләреннән барлыкка килә) - 65, Әрҗән - 400. Барысы - 1381.

YI юртада: Аклыш - 437, Тоцгук - 360, Иске Башап - 121, Шлик Баш - 102, Мәмәтәй (1831 елда барлыкка килә) - 67, Әрҗән - 584, Яңа Чат - 53. Барысы - 1724.

YII юртада: Сараш - 568, Солтанай - 525, Сожәп - 177, Батырбай (1814 елда Чалклы, Үдик, Тауавыл, Ишим, Барда, Аклыш авылларыннан күченгәннәр нигез сала) - 160. Барысы - 1430.

YIII юртада: Сараш - 660, Таныш - 127, Югары Башап - 63, Шлик Түз - 116. Барысы - 966.

XIX гасыр урталарында уздырылган сан алуларда ике юртада - YII һәм YIII юрталарда ике Сараш авылы күрсәтелә. YII юртада Солтанай, Сожәп, Батырбай белән күрсәтелгәне, Сараш елгасының сул ягындагысы, үзенә бер авыл - Сараш I, Таныш, Югары Башап белән күрсәтелгәне икенче авыл - Сараш II булып йөри һәм гасыр ахырына таба гына бер авыл итеп күрсәтелә.

Типтәрләрне берләштергән Таныш олысында бу переписьта 899 кеше (442 ир-ат, 457 хатын-кыз) исәпкә алына: Танышның үзендә - 427, Солтанайда - 32, Бардабашта - 33, Бардада - 14, Күчтәнтидә - 100, Башапта 114 кеше типтәр булып исәпкә кертелгән. Ул вакытта бүген Башкортстанның Тәтешле районына караган Акъәет белән Сикәш тә Таныш олысында йөргән.

Таныш олысы аз санлы булуы сәбәпле юрталарга бүленмәгән.

1841-1842 елларда кантон начальнигы Адутов, писарь Кобелев имзалары белән бирелгән мәгълүматларда «Тауавыл, Искир авыллары Пермь губернасына карыйлар, Мәмәтәй, Иске Кайпан, Яңа Кайпан авыллары Боре оязеннән күчерелделәр, җирләре буенча Мәмәтәй Ирәкте олысына, Иске Кайпан Кара-Таныш олысына, Куян, Култай авыллары Гәйнә олысына карыйлар, элек Пермь губернасына карыйлар иде», дип искәртелгән. Бардабаш, Барда авыллары турысына «милләтләре буенча катнаш авыллар» дигән сүзләр язылган.

Китапта аерым бирелгән искәрмәдә мондый аңлатмалар бар: «2. Гәйнә олысында ике түбә: Мул-Гәйнә һәм Тол-Гәйнә түбәләре. 3. II юртадан Җермия авылы төшеп калган. 8 ревизия (1834 ел) буенча анда 38 ир-ат, 28 хатын-кыз яшн иде. 4. YI юртадан Яңа Чат төшеп калган. Анда 53 ир-ат, 52 хатын-кыз яши иде. 5. YII юртадан Искилде (54+48 кеше). 6. YIII юртадан Шлик Түз (67+49 кеше). 7 - 8. IY юртадан Иткуль Давыдово авылы (5+5). 10. IY юртадан Нигъмәт (75+55), Үтәбай (25+19) авыллары төшеп калган» (7. 340 б).

Шулай итеп, Гәйнә олысында, ягъни бүгенге район территориясендәге татар-башкорт авылларында, узган гасыр урталарында, Ведомостька кертелмәгән Күчтәнти белән Сосновка-Толбаш (1965 елдан Уни районында) авылларыннан кала, 14073 кеше яшәгән. 1739 елгы белән чагыштырганда халык саны 1,5 мәртәбә үскән булып чыга. Шул ук чорда бөтен Русиядә халык саны 131 процентка, Вятка, Пермь губерналарында 117 һәм 128 процентка үскән. Гәйнә халкының кызурак артуын табигый үсеш итеп түгел, ә миграция хисабына барган арту дип аңларга кирәк (7; 8. 145-146 бб).

1798 елның 10 апрель карары белән Ырымбур губернасында башкортлар өчен идарә итүнең кантон системасы кертелә, кабилә олыслары урынына территориаль олыслар оештырыла. Кайбер үзгәрешләр белән бу система 1865 елга кадәр яши. Губернада барлыгы 13 кантон оештырылып, Пермь һәм Оса өязләре, Шадрин һәм Екатеринбург өязләре өчен берәр кантон булдырыла. Губернаның башка өязләреннән аермалы буларак, Пермь провинциясе типтәрләре һәм мишәрләре граждански власть органнарына буйсындырылмыйча, әлегә шул аз санлы булулары сәбәпле, башкортлар белән бергә хәрби сословиегә кертеләләр, ләкин искәрмә төсендә 1835 елга кадәр алар өчен Танып олысы саклана һәм, югарыда күрсәтелгәнчә, бер үк авыл кешеләре ике олыска буйсына.

Указ буенча 50-75 йортлы юртага (берничә авылга) бер старшина, аның бер ярдәмчесе, есаулы, йортлар саны йөзгә җитсә - бер йөзбаш, йөзне артса - хорунжий вазифасы карала. Ике юртага бүленеп йөртелгән Сарашу авылында, мәсәлән, бер хорунжий - Әхмәди Таразов, биш урядник булган. Алардан тыш походный старшина да каралган. Кантон начальникларына халыкның хуҗалык эшләренә дә катышу хокукы бирелә, ә халыкка хәтта провинция, губерна эчендә дә ерак китеп йөрү тыела. 1833 елда кантон халкы җыен үткәрү хокукыннан мәхрүм ителә. Кыскасы, Гәйнә халкы урыс крепостнойлары дәрәҗәсенә төшерелә.

1835 елда барлыгы 17 кантон булып, алар 6 округка бүленеп йөртеләләр. Һәр округка попечитель (кайгыртучы, опекун), берничә округка кантон фатиры билгеләнгән. Безнең Гәйнә иле беренче кантон дип йөртелгән, аның үзәге булган Үдик авылында кантон фатиры тотылган. Попечитель итеп гадәттә урыс милләтеннән булган штаб-офицерлар билгеләнгән. Аларның һәркайсына хәрби губернатор писмоводитель һәм тәрҗемәче җибәрә торган булган. Моннан тыш башкортларны хөкемгә тарту өчен стряпчий билгеләнгән. Күрәсез, башкорт, типтәргә урыска буйсынудан, аның алдында баш июдән башка чара калмаган.

1798 елгы указ буенча һәр 10, соңрак һәр 4-5 йорттан бер кеше, юрта старшинасы билгеләгән чират буенча, армия хезмәтенә җибәрелергә тиеш булган. Бу кеше «төзек сөңге, кылыч, балта, мылтык, җәя һәм бер сайдак ук, яхшы киенгән хәлдә, 4 баш ат белән» тәэмин ителергә тиеш булган. Әлеге ун, дүрт-биш йорт солдатка 16 майдан 6 сентябрьгә кадәр җитәрлек ашамлык, 4 сумнан 25 сумга кадәр акча җыеп бирелергә тиеш булган. Хезмәткә китүче үзе, муллалар, кантон начальниклары, аларның ярдәмчеләре, юрта старшиналары бу «подмога»га өлеш кертүдән азат ителгәннәр.

Башка кантоннардан аермалы буларак, Гәйнә кешеләре урман кисүдә, сал агызу, почта йөртү, Себер трактын төзек хәлдә тоту кебек бурычлар да үтәгәннәр. 1834 елдан Себер трактында эшләү җан башыннан 23 тиен белән түләүгә алмаштырылган.

1754 ел 16 март указы нигезендә хәрби хезмәт үтәргә тиешле кеше Ырымбур корпусына буйсынган башкорт гаскәренә җибәрелгән. 1874 елда 8 юртага бүленгән 44 авылда 9252 кеше исәптә торуын истә тотсак, анда байтак кеше җибәрелгәнен аңлавы кыен түгел. Шушы ук 1874 елда

Александр II «Гомум хәрби хезмәт кертү турында» манифест чыгара, хәрби хезмәт турында устав раслый. Һәм яз көне аларны җыеннарда тикшерүләр, хезмәткә чакырыласы кешеләрнең исемлеген төзеп игълан итүләр башлана. Сословиесенә бәйсез рәвештә 21 яше тулган барлык ир-егетләр коры җир гаскәрләрендә 6, флотта 7 ел хезмәт итәргә тиеш булалар.

Яңа закон Гәйнә олысында зур каршылыкларга очрый. Яңача хезмәт иттерү «башкортлыктан чыгару, яңа уставны яклап чыккан кеше башкорт түгел, ә «яңа крәстиән» дип аталачак» дип кабул ителгән. 4 апрельдә Сарашта үткән җыенда халык бертавыштан «без казаклар булып калырга телибез» дип белдерә. Метрикә исемлегенә пичәтен суккан староста Таразовны тотып кыйныйлар, пичәтен, староста билгесен тартып алып, үзен арестант йортына кертеп биклиләр. Старостаны яклап маташкан старшина Дускаевны, утырган урындыгын йолкып алып, аягурә тыңларга мәҗбүр итәләр. Олыс писаре Емельянов куркуыннан чыгып кача. Старостаны кыйнаган Шәмсетдинов, Ризванов, Малхитов, Байдашевлар Дускаевка: «Сез укыган кәгазьләр алар ялган, без патшаның үзенә барачакбыз»- дип яныйлар. Җыен Шәмсетдиновны югары түрәләр белән сөйләшү өчен ышанычлы итеп сайлау һәм аңа «юллык акча җыярга» дигән карар чыгару белән тәмамлана (10).

Сарашта башланган чуалыш башка авылларга тарала. 11 апрельдә Үдик олысында старшина вазифасын үтәүче Әмиров Акбаш авылына бара. Кучеры Абдулвахитовның ник килүләрен әйтеп, әлеге устав турында сүз башлавы була, Әмировны шундук тышка алып чыгып кыйный башлыйлар. Ул коч-хәл белән котыла.

24 апрельдә Барда олысындагы җыен да старостаны һәм йөзбашларны кыйнау белән тогәлләнә. «Җәнҗал куптарган» Габитов белән Габделнафыйковлар «эшен» тикшерү өчен Бардага пристав килеп йөри.

Җыеннар һәркайда нәтиҗәсез тәмамлана. Мөхәммәтрәхимов дигән кеше авылдан-авылга йөреп, Минһаҗетдин Шәмсетдиновны «хәрби бурыч үтәүдән коткаруны юллаучы итеп сайлау турында приговорга» имза җыеп йөри.

Төрлечә куркытулардан соң 15 июньдә губерна начальнигы Н.Е.Андриевский катнашлыгында Төнгүктә үтәргә тиешле җыен да ямьсез тәмамлана. Шуннан соң түземлеге беткән губернатор «чуалышларда активлык күрсәткән барлык фетнәчеләрне кулга алырга» дигән боерык бирә. Аларны Оса төрмәсенә җыялар һәм суд оештыралар. Өяз түрәләре бер үк вакытта эшне зурга җибәрүдән дә курыкканнар бугай, адвокат Чихачовның «башкортлар надан» дигән версиясе белән килешеп, губерна прокуроры товарище (шундый вазифа да булган) Филиппович Акбаштан Г.Мөхәммәтов- Кучукбаевны, Х.Гыйльметдиновны, Тоңгүктән Т.Габитов, Г.Габделнафыйков, М.Абделхәеров, М.Хәйруллин, М.Абдулхарисовларны, Әрҗәннән Н.Габдушевны 4 айга, тагын 11 кешене 7 конгә төрмәгә утыртырга дигән карар чыгару белән чикләнгән.

«Котыртучылар» дип тамгаланган муллалар - Акбаштан Г.Мөхәммәтов, Тоңгүктән Я.Габитов Ырымбур магометан руханилары җыелышының 1874 ел 3 август указы белән, Тауавылдан З.Зәйнәгабдинов, Искирдән М.Габ-

делгафуров бериниди указсыз ботенләйгә, Өшметче (Федорки), Каепавыл, Әрҗән, Барда, Сараштан 5 мулла берәр елга муллалыктан мәхрүм ителәләр. Озын Яланнан Мөнәсыйпов ахун дәрәҗәсен югалта һәм мәхәллә имамы итеп калдырыла. Чуалышлар булган барлык олысларның муллаларына да шелтә белдерелә. «Иң топ котыртучы» илле бин яшьлек Минһаҗетдин Шәмсетдинов «ботен хокукларыннан һәм молкәтеннән мәхрүм ителеп, Себернең иң еракка җирләренә» сөргенгә озатыла.

Крепостное право бетерелгәннән соң башкорт сословиесенең дә бетерелүе, хокуксыз крепостнойлар хәленә тошерелү белән килешә алмаган гәйнәлеләрнең патша указын үтәргә теләмәүләре әнә шулай тогәлләнә.

Кантон системасы яшәгән чорда (1798-1865 елларда) 1798 елгы законга кертелгән һәр үзгәреш халыкта ризасызлык, чуалышлар тудыра, халык аны башкорт сословиесен бетерү, гади урыс крәстиәненә тиңләп җирсез калдыруга илтү дип кабул итә. Бигрәк тә XIX гасырның 30 нчы елларында, Русия чикләре Урал арьягына күчеп, башкорт гаскәренә ихтыяҗ беткәч, хәл тагын да кискенләшә. Гәйнә олысыннан бер торкем крәстиәннәр үзләрендә кантон бетерелеп, хәрби хезмәт налог түләү белән алыштырылгач (1864 ел) Красноуфим өязе чиновнигы Мокровка: «Без күрәбез, барысы да башкортларны дәүләт крәстиәннәре итүгә таба бара, безне дә җирсез ясап, бездән дә рекрут алырлар дип куркабыз», дип белдерәләр (9. 154-155 бб).

Күп тә үтмәгән, «падап башкортлар»ның алдан сизенүен раслап, «Земский учреждениеләр турында положение» килеп чыга һәм шуның нигезендә земский реформа үткәрелә (1864 елның 1 гыйнвары). 1869 елның 10 февралендә яңа закон кабул ителә, башкортлар яшәгән районнарда җирне яңадан бүлүләр, «артып калган» җирләрне кочләп сату яисә арендага бирүләр башлана.

Шулай итеп, Гәйнә илендә дә капиталистик мөнәсәбәтләр ныгый, тирәнәя.

1850 елгы халык санын алу вакытында Гәйнә илендә татар-башкорт авылларында 15.046 кеше перепись үткән. 1859 елгы перепись документлары, 1795, 1816 елгылары кебек үк, тулы сакланмаган. Гәйнә - Сараш олысы Оса өязе Красноуфим кантонында дип күрсәтелә һәм анда тулы булмаган мәгълүматлар буенча 24 авылдан (Сараш, Танып, Күчтәнти, Барда авылларын юк) үп меңләп кеше перепись үткән.

1987 елның мартында Уфа архивында эшләгәндә чукындыру сәясәтенең безнең якларга да килеп җиткән булуын белдергән бер документка юлыктым. 1859 елгы сан алу кәгазьләренә кушымта итеп бирелгән бер кәгазь артында «Имянной список» булып, 11 авылның егермеләп кешесе «святое крещение принял и освобожден от всех видов денежных сборов» дигән язуны күргән идем. Тик менә бер үкенеч: «Перечневая ведомость»та китерелгән бу исемлекне күчереп алырга баш җитмәгән. Соңыннан бу документны соратуларым нәтиҗә бирмәде: ул топләмә

һәрчак урынында булмады. Хәтердә, ул кәгазьдә авыл саен бер йә ике чукынган кеше күрсәтелгән иде. (2).

Билгеле ки, перепись документлары ярдәмендә, халык санының үсү-кимү тенденцияләрен ачыклау аша хуҗалык итүнең үзгәрүен, шул үзгәрешнең яңа миграцияләр китереп чыгаруын күзалларга мөмкин. Халык санының артуы яки кимүе, күченеп йөрүе һәрчак материаль тормышның үзгәрүе белән бәйле.

Бу яктан карагында XIX гасыр аеруча характерлы. Аның беренче яртысында Гәйнә олысында халык саны күзгә күренеп арта, күп яңа авыллар барлыкка килә: гасыр башында, 1814 елда - Батырбай, 1820 елда Толбаш (Сосновка), 1831-1833 елларда - Кодаш, Каҗмакты-баш (Чат), 1841-1842 елларда ике Искилде авылы, Яңа Чат, Ермия, Күгия, 1843 елда Актыбай-Толач, 1849 елда Актай (Актаево), 1850 елда - Яңа Башан, Бардада - Каҗмактыбаш (шуннан соң Чат авылы үз исеме белән, ләкин Иске сүзен ияртеп, Иске Чат дип йөртелә башлый), 1869 елда - Үтәй (бу авылга Үтәй исемле чуаш нигез салган дип әйтүчеләр бар, ләкин перепись документлары белән бу расланмый), 1891 елда Зязелга, 1892 елда Печмень һәм аның тирәсендә эреле-вакды рус авыллары барлыкка килә (5;6).

Йөз ел эчендә Гәйнәнең төп халкы 4585 кешегә (67,2 процентка) арта. Нигезе 1757 елда салынган Шермейка һәм Ширәмәт бакыр заводы бистәләре буларак барлыкка килгән Шабарка, Зайцево, Антуфьево, Малково авылларын кертеп исәпләгәндә бу сан, бу үсеш ике тапкырны арткан булып чыга. Ә менә алга таба халык саны артмый. 1874 елга, ягъни 40 ел үткәч, ул 1834 елгы дәрәҗәгә төшә - 9250 гә кала. Бу хәлне халыкның җирсезләнүе, аны закладка салуы, сатарга мәҗбүр булуы, читкә чыгып китүе белән аңлатырга кирәктер.

Гәйнәлеләр рус авыллары барлыкка килү аркасында күп җирләрен югалталар. Бу хакта хакимият органнарына шикаять язулар, телдән зарланулар күп булган, күп суд эшләре кузгатылган. Үдик авылының электән күп җирләргә хуҗа булган кешеләре Уймуж, Федорки, Ишәмәт, Әрәмәавыл, Акбаш, Куземьяр, Барда, Сүҗде, Әрҗән, Танып авыллары кешеләре өстеннән язган җир бәхәсе турындагы язмалары хәтта Борынгы документлар үзәк дәүләт архивына (БДҮДА) барып эләккән. «Жалованные грамоты утеряны, - дип язганнар үдиклеләр, - а ныне нам, башкирцам, и русские, которые живут на той их земле, чинят немалое утеснение и обиды» (11. лист 2).

Чыннан да, XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башы безнең Гәйнә иле сәүдә капиталы, капиталистик предприятиеләр барлыкка килү белән аерылып тора. Авылларда еракларДан килгән кырык тартмачылар йөри башлауга әле анда, әле монда кибетләр ачыла, кечәге игенче-терлекче крәстиән сәүдәгәргә әверелә, төрле гильдидагы сәүдәгәрләр үсеп чыга. Оса сәүдәгәрләре Гаделгәрәй Әмирханов, Вахитов, Мәҗитовлар тирәсендә безнең «үзебезнекеләр» - Әхмәдиевлар, Мансуровлар, Корбангалиевлар,

Зиннур Мөхәммәтшиннар мая туплый һәм акрынлап үзләре дә мөстәкыйль «хуҗалар»га әверелә. Бардада 11, Әрҗәндә 12, Сарашта 4 эре һәм 10 вак кибетләр барлыкка килә.

1870 елларда Бардада пыяла заводы төзеп карыйлар, ләкин аның беренче продукциясе начар сыйфатлы булып чыга, тиздән бу эшне ташлыйлар. Сәйфелмөлек исемле берәү бер интәше белән парзимит сугу производствосы оештырып карый...

Оса сәүдәгәре Әмирханов 1891 елда Барда елгасы тамагында карабодай ярмасы эшләү өчен тегермән сала, Барда белән Әрҗән арасында мал симертү базасы төзи. «Үзебезнекеләр» дә тик ятмый: Солтанайдан Гата хәзрәт Башап елгасы тамагында вальцовый тегермән, Иске Башап белән Төңгүк арасында 5 катлы салат җитештерү заводы, Осада чәй төрү фабрикасы төзи, Пермь, Ирбит, Бөре, Оса шәһәрләрендә кибетләр ача.

Һәр елгада, һәр авылда диярлек тегермәннәр салына һәм эшли.

Беренче Әрҗәндә 1907 елда Алапановларның күн заводы эшли башлый. Ике йөзләп эшче эшләгән бу завод көнгә 150 тире эшкәртеп, сарыга дуплап чыгара. 1914 елдан хөкүмәт заданиесе алып, армия өчен итекләр тегә. Солтанайда Әбүбәкер Кариев, Каенавылда балавызчы Хуҗап-хаҗи, Бардада Муллаҗан Корбангалиевлар зур коммерсантлар булып үсеп киләләр.

Базарларда чит ил товарлары: Франциядән кайтарылган «Зингер» тегү машиналары, сепараторлар, Германиядә эшләнгән «Штейнгард» компаниясе ургычлары һәм суккычлары, әмерхан калушлары, француз яулыклар. Швециядән кайтартылган тукымалар, Испания әфлисуннары, Һинд, Кытай, сәйлүн чәйләре, борыч, канәфер ише әйберләр, шулар белән рәттән үк үзебездә җитен тукымадан тегелгән алача ыштан-күлмәк, тула оеклар сатыла. «Зингер» машиналарын ике ел срок белән кредитка да алырга мөмкин булган. Бардада бу эшне «Зингер» компаниясе агенты Шакир Даутов башкара.

Авылларда эре сәүдәгәрләрнең арадашчылары йөреп тора. Алар тире, йомырка, май, мунчала, кап, чыпта ише әйберләр җыя. Алардан баераклары Осада ашлык сатып ала, аны баржаларга төяп, Рәсәйнең үзәк губерналарына озата.

Атнаның билгеле көннәрендә эре авылларда базарлар булып тора, елның уңайлы вакытларында ярминкәләр уза. Барда һәм Сараш базар-ярминкәләренең даны өяздән, губернадан еракларда да билгеле булып, анда бөтен Урта Урал сәүдәгәрләре җыела торган була. Осталыкларын күрсәтеп, акча эшләп кайту нияте белән бу ике авылга базар көннәрендә артистлар, фокусчылар, кара аюын ияртеп, атаклы кәмитче Гыймран да килә. 1912-1913 елларда Аклыш, Уймуж, Акбаш, Озын Ялан авылларында базарлар, «Куштамак» ярминкәсе уздыру гадәткә кертелә, ләкин беренче империалистик сугыш чыгу белән боларын үткәрү туктатыла (12).

1905-1907 елгы революцион күтәрелешләр Тол буен да читтә калдырмый. Зур шәһәрләрдә барган кузгалышларны гәйнәлеләр кызыксынып күзәтәләр. Үдик, Солтанай, Барда, Сараш кебек зур авылларда халыкка ирек, азатлык турындагы мәсьәләләрне аңлату өчен җыеннар үткәрелә, «Җәмгыяте хәйрия» (мохтаҗлар җәмгыятьләре), алар каршында китапханәләр, уку йортлары оештырыла.

Үдиктә уздырылган бер җыелыштан соң Казанда нәшер ителгән «Йолдыз гәзите 1906 ел 29 гыйнвар санында **«Гәйнә йорты»** дигән мәкалә басып чыгара. Анда менә нәрсәләр языла:

«Пермь вилаятендәге Оса өязендә 40-50 мөселман авыллары бардыр ки, алар Гәйнә башкортлары дип мәшһүрләрдер. Шул авыллардан Үдик исемле волость авылында мәҗлесләргә иркенлек булганнан бирле өч мәртәбә гомуми мәҗлес ясалмыш. 2 декабрьдә вакыйга булган соңгы мәҗлесләрдә башка берничә матдәләрдән соңра ошбу ике матдәнең булуына иҗтиһат кылынырга да карар бирелмеш:

1) Үдик хөрриятсендә аракы вә сыра сатыла торган кибетләр булмаска;

2) мөселманнарга махсус бер хөрриятханә ачылып, һәр төрле ислам китаплары вә төрле гәзитләре җәмагать суммасыннан алынырга.

Бу хәлләр иркенчелекләрнең чәчәкләредер. Җимешләре исә, Үдик хөрриясеннән мәйханәләр бетеп, урыннарына хөрриятханәләр вөҗүдкә килгәч күренәчәктер.

Хөрриятханәләр исә, үзе бер бостан булып, анда үсәчәк җимешләр тагы да башка булачактыр». (13).

1905-1907 еллардагы революциягә кадәр Гәйнә иленең биш олысында 52 меңнән артык кеше яшәгән, йөздән артык авылга югары типтагы биш (Таныш, Үдик, Барда, Байавыл, Солтанай) мәдрәсә эшли, 1909-1910 елларда аларга 7 земство мәктәбе, 54 мәчет каршында шул кадәр үк мәдрәсә, мәптек дип аталган 30 лап шәхси мәктәпләр өстәлә. Тик бер Солтанай мәдрәсәсендә генә дә бу елларда 500 дән артык шәкерт укый. Узган гасыр урталарында Мансуровлар тарафыннан ачылган бу мәдрәсәдә, атаклы Бохара мәдрәсәсен тәмамлап кайткан Ширван Зябаловта соекле шагыйребез Габдулла Тукайның бабасы (картатасы, әниенең әтие) Зиннәтулла Әмиров укыган. Солтанай мәдрәсәсен тәмамлап, ул Уфа губернасының Аргаяш кантонында Ташир авылында балалар укыткан, янә дә белемен арттыру нияте белән Казан ягындагы Кышкар мәдрәсәсендә укыган, аны тәмамлагач, Өчиле авылына мөәзин итеп җибәрелгән. Шунда ул гаилә корган, аның беренче баласы - Тукайның анасы Бибимәмдүдә туган (14. N7, 165-167 бб).

Солтанай мәдрәсәсе соңгы елларында өч бинада эшләгән. Һәр шәкерт елына 2 сум түләп укыган, кышка утын китергән. Идәнгә утырып укыганнар, идәнгә ятып йоклаганнар. Атнаның һәр пәнҗешәмбесендә тәртип бозучыларга суд ясалган: намазга йөрмәүчеләрне камчы, таяк белән «сыйлаганнар», идән юдырганнар, бәдрәф чистарттырганнар. Шәкертләр чиратлап кизү торганнар.

Солтанай мәдрәсәсе Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенекенә якын программа буенча эшләгән: дин дәресләреннән тыш алгебра, геометрия,

физика, химия укытылган. Гата хәзрәт «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең хуҗасы Галимҗан Баруди белән элемтә тоткан.

1912-1913 елларда Солтанай мәдрәсәсе каршында рус мәктәбе ачылган. Аның беренче сыйныфында Солтан Мөхетдинов, икенче сыйныфында атаклы шагыйрь Сәгыйт Сүнчәләй укыткан.

Урта Уралда киң билгеле Солтанай мәдрәсәсендә шау-шулы революция елларында зур гына китапханә булдырылып, анда айга 1 тиен акча түләп, Рәсәйдә нәшер ителгән, гарәп илләреннән яздырып алынган китап, журнал һәм гәзитләр укырга мөмкин булган. Бередә әдәби кичәләр (1913 елдан алар Тукай кичәләре дип аталган), яшерен җыелышлар үткәрелгән, прокламацияләр таратылган. Шуларның берсе турында хакимият органнарына да билгеле булып, Солтанайга Аряждан пристав килеп тикшереп йөри. Солтанайда туып-үскән Нурулла ага Ягъфәров белән шунда укыган Әндәр абый Батыркаевның шул турыда сөйләгәннәре хәтердә:

— Ару гына (яхшы ук) хәвефле нәрсә китереп чыгарасы иде пристав. Ну Гата хәзрәт аны шулай ук ару гына сыйлаган да, тегенең актындагы «прокламация укыганнар» дигән сүзләрен «дикламация укыганнар» дигәнгә төзәттереп, үзенең губернатор иие түрәләргә барганда гына җигә торган фаэтонына салып озаткан (12).

Бөтен Урта Уралның белемгә сусаган егетләрен үзенә тартып торган Солтанай мәдрәсәсен, Гата хәзрәтнең төзек, җыйнак хуҗалыгын (ике катлы, калай түбәле, акка буялган йортын, абзар-сарайларын) искә алганда Солтанай кешеләре бу тырыш һәм ярдәмчел затның Башан Түздәге дачабакчасын да онытмыйлар. «Оҗмах иде ул. Ап-ак койма белән уратып алынган. Түгәрәк күл уртасында алма бакчасы, күлдә Камадан китереп җибәрелгән балык... Гражданнар сугышы елларында бөтенесе юкка чыкты: мәдрәсәсен, биш катлы тегермәнен ут төртеп яндырдылар,» - дип ачынып сөйлиләр авылдашлары.

Гата Мансуровның игелекле эшләре, төзек- матур хуҗалыгы турында укытучы-пенсионер Рәис Габтукаев зур очерк та язып чыкты (15).

Мәчет каршында оешкан Солтанай мәдрәсәсе XX гасыр башына 16 сыйныфлы мәдрәсәгә әверелә. 1910 елда хәзрәт үзе яшәгән йортка каршы төзегән кызлар мәдрәсәсе дә зурлап искә алуга лаек. Анда мөгаллим булып Әмин Мансуров турында «Урал улы» дигән повесть язган Кәрим Әмири эшли. Районның атаклы шәхесләре Касимә Казанбаева, Кәримә Ягъфәрова, Хәмдия Габтукаевалар шунда белем алган затлар иде.

Шунысын да әйтеп үтик: Гата хәзрәтнең Совет хакимиятенә, революциягә карата үз фикере булган (ул аларны өнәмәгән). «Гражданнар сугышы елларында аны тотып, кызыллар алдына бастыралар һәм сорыйлар. «Хәзрәтне нишләтергә?» Солдатлар белән авыл халкы арасында сөйләшү ике көн дәвам итә. Әмма аны җәзага тартмыйлар. Авыл халкы аны яклап кала. Ә инде үзе үлгәч, аны җирләргә бөтен тирә-як авыллардан кешеләр килә. Мәрхүмне бөтен авыл буена тезелгән тере коридор буенча озаталар» (16).

Таныш мәдрәсәсе Солтанай мәдрәсәсеннән дә олкәнрәк. Бу авылның мәдрәсәсе турында мина 1760 елларга караган язмалардан укырга туры

килгәне булды. 1840-1849 елларда Таһынта, Хәирзаман Габди угылы мәдрәсәсендә атаклы татар мәгърифәтчесе һәм шагыйре Гали Чокрый әл-Болгари укый, шунда укыганда иҗат эшен башлый, «Тәһзибе мантыйкый» (Логика укыту китабы) кебек калын китаплар күчереп яза. Йөздән артык әсәр яза, бин мәдрәсә бетергән Гали Чокрый Таһыпта остазының вафатына (1843 ел), әнисе Гөлбәдәрнең якты истәлегенә багышлап мәрсияләр яза (17).

Барданың беренче мәхәллә мәчетендәге мәдрәсә дә шундый ук озын тарихлы. Безгә Барданың ике тапкыр - 1735-1737 елларда һәм Пугачев хәрәкәтләрен бастырганда яндырылуы мәгълум. Озак та үтми, көлгә әверелдерелгән авыл урынында мәчет- мәдрәсәле яңа авыл калкып чыга. Барданың 1750 елда төзелгән мәчете каршында 1760 елда мәдрәсә эшли башлый. Унбиш елдан, Пугачев хәрәкәтен бастырганда авыл янә яндырыла.Бардада гына да булмый мондый хәл. Екатерина II патшалык иткән чорда гына дин тотучыларга үз оешмаларын булдырырга рөхсәт ителә. Авылларда яңадан мәчет һәм мәдрәсәләр эшли башлый. Яндырылган, җимертелгәннәре урынына яңалары төзелгәч, гарәп илләреннән башка күп тауарлар белән бергә XIX гасыр башында Гәйнәгә китаплар да кайтарыла башлый. Шушы җанлануны, һәр авылда мәчет, мәдрәсәләр ачылуны күреп, чукынганнар да үз диннәренә кайта башлыйлар. 1860 елда Үдиктә мәчет һәм аның каршында мөселман мәктәбе, 1870 елда рус-башкорт мәктәбе, Акбашта мәчет һәм мәдрәсә ачыла.

Югары типтагы Таһын, Солтанай, Барда, Байавыл, Үдик мәдрәсәләрендә укып чыккан укымышлылар үз авылларында мәктәпләр ачканнар. Ә 1917 елгы Октябрь революциясеннән соң алар беренче совет укытучылары, совет хезмәткәрләре булып киткәннәр.



Тол буе авылларында революцион идеяләр таратуда, яшьләргә төпле белем бирүдә земство мәктәпләре аеруча зур роль уйнаган. 1909-1915 елларда Сарашта эшләгән Шәриф һәм **Сәгыйт Сүнчәләйләр,** Бардадан Габдулла Ижбулатов, Аклыштан Хәлим Әмиров, Әрҗәннән Сәмигулла Шәфиев һәм кызы Рәйханә, Каенавылдан Латиф Мостафин, Үдиктән Хәким Адутов, Гата Байкиев һ.б. бик күпләр Казан, Уфа зыялылары, Г.Камал, Г.Тукай, Ф.Әмирханнар белән элемтә тотканнар, Хөсәен Ямашевны яхшы белгәннәр, ул чыгарган «Урал» гәзитен алдырганнар (12; 18).

1905 елда башланган революцион хәрәкәтләр белән Барда кешеләре шәһәрләрдә эшләгән якташлары ярдәмендә дә танышып барганнар. Мотовилиха эшчеләренең кораллы восстаниесе турында, мәсәлән, аларга Пермь сәүдәгәре Вәли Гайсинда приказчик булып эшләгән, эшчеләрнең губернаторны кулга алып, аңа чабата, чыба кидереп Казан тракты буйлап йөртүләрен үз күзләре белән күргән Әмирҗан Фаюрша улы Кантуганов (1889-1960) кайтып сөйли. (19).



**Ә.Ф.Кантуганов** - беренче империалистик сугышта катнашкан, коньяк-конбатыш фронтта мөселманнар арасында революцион эшләр алып барган. Уфа реввоенсоветы кушуы буенча 1918 елның февралендә Борайдагы контрреволюцион чуалышларны бастыруда катнашкан, Бөре өяз башкарма комитетында инструктор-агитатор, гражданнар сугышыннан соң Әрҗән (Барда), Сараш волбашкарма комитетлары рәисе, 1936 елдан 1945 елга кадәр колхоз рәисе булып эшләгән кеше. Гомеренең соңгы елларында потребкооперация системасында эшләде һәм шуннан пенсиягә чыкты.

Беренче рус революциясеннән соңгы чор Русия тарихында Столыпин реформалары белән билгеле. Бу реформалар Гәйнә ягында шактый сизелерлек эз калдырган. Шуның нәтиҗәсе буларак, Тол буенда Барда, Сараш, Үдик, Шермейка олысларында утыздан артык яңа авыл барлыкка килгән. 1907-1908 елларда Йокшур, Карман, Барда елгасы буенда Куштамак, Ятыш, Уймуж ягында Ольховка, Шермейка ягында 7-15 ишегалдыдан торган Ключи, Подказармица, Гребновский, Караул, Чекурка бистәләре, Межшермеек, Сараш елгасында Дектярка, Ермия буенда Талый Ключ, 17-24 хуҗалыгы булган Большой һәм Малый Саргуль, Чекурка авыллары барлыкка килгән. Казан ягыннан күченеп килгән һәм берникадәр вакыт Йокшур авылында яшәгән 15 гаилә, килмешәк исеме йөртүдән гарьләнеп, 1915 елда Тоңгук кешеләреннән җир сатып алып, үзләренә бер авыл - Казанка авылын төзегәннәр. (20).

1907-1915 еллар эчендә барлыкка килгән бу авылларның бүгенге көндә нибары дүртесе генә (Суганка, Ольховка, Карман, Казанка) исән.

Столыпин реформасы тудырган авыллардан иң зурысы — **Карман авылы**. 1904-1905 елларда Чәпчелде һәм Карман елгалары буена I Әрҗәннән Габдушев, Ибраев, Иманаев, Юртаев, Рангулов, Мөрсәлимов, Гамилов, Сараштан Габдрәшитов, Адилов, Тимганов, Әндәров, Таразовлар, Таныптан Туйгильдин, Мөнәсыйпов, Нурбаков, Озын Яланнан Яхиннар, Бардадан Сарманаев, Аклыштан Сабитовлар күчеп утыра. Йортлар сала башлаганчы алар Усак тауны арчыйлар. Күченеп килүнең өченче елында ук алар мәчет турында сүз кузгаталар, аның проектын эшләтәләр, 1909 елның 14 декабрендә губернатордан рохсәт алып, агач эше осталары Мансур Мөрсәлимов җитәкчелегендә эшкә дә тотыналар, бер ел эчендә тозеп тә куялар (21). 1910 елда эшли башлаган мәчет 1936 елга кадәр, нәкъ Пермь шәһәрендәге таш мәчет эшләгән кадәре, эшләп кала.

Яңа авыллар пигездә урманлы җирләрне арчып утырганнар. Җир сатып алынган. Шулай да бу процесс каршылыксыз гына бармаган. Күп очракларда зур шау-шулар килеп чыккан, чөнки якында яңа авыл барлыкка килү иске авылларның көтүлек җирләрен, чабулыкларын кысрыклауга китергән. Бу вакытта әле Гәйнә кешеләре борынгыдан килгән йола буенча 10-15 гаилә берләшеп, тайларын бер табынга җыеп, көзгә кадәр иркенгә җибәрә торган булганнар. Ә моның өчен ышык урыннар, болынлыклар кирәк булган. Урманнарны яндыру, топләп чәчү җире эшләү көтүлек өчен уңайлы урыннарның чиктән тыш кимүенә китергән. Шуның аркасында иске авыллар белән яңа авыллар арасында киеренке хәлләр, хәтта кеше үтерүләр дә булган.

Гәйнәлеләрнең болай да авыр тормышы 1914 елда сугыш башлану белән тагын да катлауланган һәм бу яңа низаглар тудырган. Күчтәнти авылында, мәсәлән, халыктан налог җыеп йөргән чагында Сараш олысы старшинасы Әбүбәкер Мәүлетовны кыйнап ташлыйлар, Үдиктә түләнмәгән салымнары өчен дип самавыр, ястык-мендәр, казаннарын кубарып алып чыгып киткән староста Бөке Мөхәммәтҗанны тотып кыйныйлар, олыс идарәсенең йозагын, казначей сандыгын ватып, халыктан җыелган акчаны кире кайтаралар. Әрҗәндә урядникны кыйнап, текә ярдан ташлыйлар. Тәртип сагында торучы жандармны янсә полицейскины базар коенда тотып кыйнаулар гадәти хәлгә әверелә. «Ватанны саклау» кебек сүзләрне халык ишетергә дә теләми, үзен мыскыллау итеп кенә кабул итә (12).

Халык көче белән халыкка каршы алып барылган сугыш халыкта патшага каршы нәфрәт тудыра.

## Чыганаклар:


1. В.И.Ленин. Полное собрание сочинений. Том 1.
2. Ревизские сказки 1859 года. БР УДА. Фонд 138. тасв. 2, арх. 782, 783, 784.
3. Материалы по истории Башкирской АССР. Том 1. часть 1. М. - Л., 1936.
4. Р.З.Янгузин. Земледелие башкир в 30-40 гг XIX в. Археология и этнография Башкирии. Том Y. Уфа. 1973.
5. Оренбургская казенная палата. БР УДА. Фонд 138, тасв. 2, арх. 692. лист 25-44. Ревизские сказки 1850 года. ГАПО. Фонд 111, оп. 1. эш 2005, 2009, 2012, 2013, 2014, 2071, 2077.
6. Ревизская сказка 1834 года. БР УДА. Фонд 138, тасв. 2, арх. 575, 576, 584.
7. Южноуральский археологический сборник. Вып. II. Уфа. 1976.
8. Я.Е.Водарский. Население России за 400 лет (XYI-начало XX вв.). М., 1973.
9. Очерки по истории Башкирской АССР. Том 1, часть вторая. Уфа, 1959.
10. На Западном Урале. Пермь, 1974.
11. Спорные межевые дела в дачах Гайнинской волости. БДУДА (ЦГАДА). фонд1327. тасв. 2, эш 6610.
12. Ә.Г.Батыркаев, Н.Ягъфәров истәлекләреннән.
13. Йолдыз (Казан). 1906. 29 гыйнвар.
14. Ә.Фатыйхов. Туган илем Кожамакты кәрьясеңдер. - Таң. 1983. 13 гыйнвар; «Казан утлары». 1986, N 7.
15. Р.Габтукаев. Татар миллионеры. Кызыл таң. 1992, 19 март. Халык чишмәсе. 1992. 16 апрель.
16. Г. Мәсәгутова. Авылым тарихы, - Таң. 1993. 25 февраль.
17. Татар әдәбияты тарихы. II том. Казан. 1985: Казан утлары. 1986, N 11 (164-168 бб).
18. Ә. Фатыйхов. Алар калдырган моң. - Халык чишмәсе, 1993, N 13-14.
19. Ә.Ф. Кантуганов (Барда) истәлекләреннән.
20. Список населенных мест Пермской губернии. Соликамск, 1908.
21. Х.Тякин (Күчтәнти), М.Мөнәсыйпов (Солтанай), М.С.Иманаев (Барда) истәлекләреннән.

# ҮIII. Революцияләр, революцион үзгәрешләр чоры (1917-1922)

Февраль революциясе җиңгәннән соң Вакытлы хөкүмәт власть органнарының исемен үзгәртте. Өяз һәм олыс идарәләре (управалары) земстволар дип, олыс старшиналары рәис дип йөртелә башлый. Исемнәре алышына, ә дәүләт органнары һәм идарә кешеләренең эшчәнлеге үзгәрми. Патша төшерелү белән элек яшерен эш алып барган революцион фирка һәм оешмалар иреккә чыга, үз эшләрен ачыктан-ачык алып бара башлыйлар, җыелышлар үткәрәләр, халыкка үз идеяләрен аңлаталар. Халыкның тормышын җиңеләйтү нияте белән кооперативлар төзелә, үзара ярдәм кассалары оештырыла. 1905-1907 елгы революция чорында барлыкка килгән «Җәмгыяте хәйрия» җәмгыятьләре активлаша. Үдик, Барда, Сараш авылларында шушындый җәмгыятьләр каршында ачылган китапханәләрдә укытучы-мөгаллимнәр алып барган аңлату эшенә фронтта чыныгу алып кайткан солдатлар кушыла. Балтик диңгезендә хезмәт иткән «Слава» крейсеры морягы, Петроградта Октябрь революциясе конпәрендә почта, телеграфны, тимер юл станциясен алуда катнашкан Иван Емельянович Назаров (Никольск), Петрозаводскида солдат депутаты булган Хәйдәрхан Ибраһимов, Герман фронтында большевик- агитаторлар булган Барый Адутов, Мөэмин Мозаффаров (Үдик) һ.б. РСДРП алып барган эшләр, аның бурычлары (Устав һәм программалары) белән таныштыралар.

Халык арасында шулай ук империалистик сугыштан кайткан Әмин Мансуров (Солтанай) Хөсәен һәм Бижан Адутовлар, Хәлфәт Абдалов (Үдик), Хәлим Әмиров, Габдулла Ижбулатовлар актив эш алып баралар, халыкны коралланырга чакыралар һәм әдәбият белән тәэмин итәләр. Искәвыл мәктәбе укытучысы Солтан Абдусәләмов, Аклыштан Хәлим Әмировлар кебек стеналарда эленеп торган патша рәсемнәрен утка ыргытырга батырчылык итмәсәләр дә, өязнең татар эшмәкәрләре, промышленник һәм сәүдәгәрләре Әмирханов (Оса), Мансуров (Солтанай), Корбангалиев (Барда) һ.б. да февраль революциясен хуплап каршы алалар.

Осаның иң эре милли промышленнигы Гаделгәрәй Әмирханов, Петербургта революция булуын ишеткәч тә үз өендә мәҗлес җыеп, «Патшаның төшерелүе ул безнең өчен азатлык дигән сүз», дип белдерә, кунакларын шуннан файдаланып калырга, татар телендә мәктәпләр ачарга чакыра. Шул ук елны ул Вахитов белән бергәләп шәхси мәктәп ача, унар ятим бала алып, аларны киендерәләр, укыталар. Дин әһелләре дә җанлана. Алар, руслардагы кебек, мәктәп-мәдрәсәләребез дәүләт хисабына эшләрләр, дип өмет итәләр.

Губерна һәм өяздә «Милли шура» булдыру буенча тәкъдимнәрне хуплап каршы алалар. Учредительное собраниегә сайлауларга әзерлек җәелдерелә. Эре промышленник һәм сәүдәгәрләр анда кандидат итеп эсерлар фиркасе әгъзасы Фатих Төхфәтуллинга зур өметләр баглыйлар.

Ләкин алар теләге тормышка ашмый — җыеннарда большевиклар кандидаты Мулланур Вахитовка өстенлек бирелә. Аны күрсәтү һәм пропагандалауда Сараш олысы зыялылары, аерым алганда Әмин Мансуров, Иван Яковлевич Горбунов, Солтанай мәдрәсәсе хәлфәләре активлык күрсәтәләр, һәм шуның өчен мәдрәсәгә бишенче еллардагы кебек янә Бикбардадан пристав килеп, хәлфәләр өстеннән эш кузгата. Алар барысы да кулга алыналар, Оса төрмәсенә озатылалар. Аннан аларны Октябрь революциясе генә коткара.

1917 елның декабренә кадәр Осада һәм өяздә эсерлар партиясе оешмаларыннан башка бүтән фиркаләр булмый. Эсерлардан күпләр большевикларга охшаш эш алып баралар. Җирле халыкка Рәсәйнең үзәк губерналарыннан революцион эш өчен сөрелгән промышленность эшчеләре зур йогынты ясый. Алар Никольск, Үдик, Сараш һ.б. авылларда байтак булалар. Гражданнар сугышы башлану белән алар Уралны аклардан саклау эшенә актив кушылалар, беренчеләр булып ирекле отрядларга язылалар. Үдик кешеләре Сормово эшчесе Яков-дәдәй турында якты истәлекләр саклыйлар. Авылның Оса ягында яшәгән Искәндәровларның ике катлы йортында яшәп, безнең якны Колчак басып алгач та, ул шул йортның идән астына телефон урнаштыра, кеше күзенә күренмәслек итеп линиясен суза һәм шуннан Әрәж-Оса линиясендә барган сөйләшүләрне тыңлый, кызыллар өчен әһәмияте булганнарын кәгазьгә төшереп, фронт аша озатып тора.

Никольскида яшәгән ссыльныйларда Пермьнең профессиональ революционерлары еш була. Шушы авылда туып үскән, күп еллар район оешмаларында эшләгән, районның беренче коммунистларыннан берсе, Елово, Буй, Ошья, Белогорск монастырендә кулак фетнәләрен бастыруда катнашкан, гражданнар сугышы һәм Бөек Ватан сугышы елларында күп юллар үтеп, 1919 елда Мәскәүдә Кызыл мәйданда Путилов полкы командиры Окуловка Кызыл Байрак ордены тапшыру тантанасында катнашып, В.И.Ленин чыгышын тыңлау бәхетенә ирешкән Александр Николаевич Ездаков 1967 елда миңа менә нәрсәләр сөйләп яздырган иде:

— Бервакыт безнең авылда күн куртка кигән матрос тукталды. Кунарга безнең туганабыйга, Алексей Трофимовичларга кергән. Шушы абый миңа атын җигеп бирде дә, аны Гондырь авылына илтеп куярга кушты. Авыр саквояжы өстенә мул итеп печән салдык та, икәүләшеп чанага сузылып яттык. Юл буе һич туктамый сөйләшеп бардык. Бу безнең авылда сөргендә яшәгән барлык кешеләрне дә белә икән. Шулар турында сорашуыннан мин шуны аңладым: кичтән ул аларның күбесе белән күрешкән. Искилдегә җиткәч, укытучы йортына кагылабыз. Матрос абый дигәнем аңа әлеге саквояжыннан бер пачка гәҗитләр алып тоттыра, үзара нидер пышылдашып та алдылар, һәм берни булмагандай минем янга килеп утыра да «Әйдә, ку атыңны», ди, «монда тукtавыбыз турында беркемгә ни гу-гу», дип кисәтә. Әрәждә Горожанин дигән кешеләрдә тукталдык. Анда ике бармак калынлыгы пачка калдырды. Гондырьга караңгыда гына барып җиттек. Анда ялгыз гына яшәүче бер хатынга кердек. Тамак туйдырып йокларга яттык. Төнге өчләр тирәсендә берәү килде дә моны үзе белән алып китте.

Берме, икеме айдан соң бу тагын бездә тукталды. Шунда үзенең кем икәнен дә сөйләде:

— Беләсең киләме минем кем икәнне? Мин Пермьнән, большевик, дүрт ай өйдә булмадым. Гондырьдан кайтып килешем, җыелыш үткәрдем, ох-и шау- шулы булды, арыдым. — Иске дусты белән очрашкандай сөйләште. — Тик инде куркыныч түгел, яшеренеп йөрисе юк, власть үзебезнеке! — дип җилкәмнән кагып куйды.

**А.Н.Ездаков** (1899-1978) - Никольск авылында туып үскән, 1920-1921 елларда өлкән оперуполномоченный, гражданнар сугышында чабаталы акларга, 3 нче Кама полкы составында Пермь-Н.Тагил-Омск юнәлешендә Колчакка каршы сугышларда, Буденныйның атлылар армиясендә Врангельгә каршы сугышларда катнаша, 1928 елның гыйнвар аенда туган авылында «Бедняк» колхозын оештыра һәм рәисе була, 1929 елдан госбанкта, райфода эшли, Бөек Ватан сугышында катнаша, аннан соң промсоюз рәисе, юл бүлеге мөдире, 1960 елдан пенсиядә.

Вакытлы хөкүмәткә ышаныч кимегәннән кими барып, 1918 ел башында инде Тол буе крәстиәннәре җирне үз кулларына алу өчен көрәшкә кушылалар. Яз көне Крылово олысы крәстиәннәре Голицын урман дачасын басып алалар. Аларга Үдик, Уймуж, Акбаш кешеләре ияри. Башка авылларда да урманны рөхсәтсез кисүләр башлана. Ялчылар байларга буйсынмый, боерыкларын үтәми. Мондый тәртипсезлекләргә, «милләтне бозуларга» каршы Гата Мансуров өяз хакимияте органнары алдына «фронттан бозылып кайткан бунтовщикларны җыеп, халык алдында җәзага тартырга» дигән таләп куя. Ләкин ни өяз, ни олыс органнары берни эшли алмый — власть алар кулыннан ычкына бара. Шулай да иске хакимият тарафдарлары «коткы таратучы» укытучы Хөсәен Адутовка Совет власте урнашканчы эш бирмәүгә, Үдиктә Хәким Гайсин, Шәйхуҗа Ибраһимовны, Озын Яланда Ахун Ремизовны, Әхмәтсафа Абдуловны, большевикларга ияреп йөргәннәре өчен дип, җәзалап үтерүгә ирешәләр (1).

Оса өяз комиссары П.Н.Горшков 1917 елның 28 мартында Пермьгә губерна комиссары Калугинга шундый телеграмма суга: «Үдик, Оса, Воскресенск, Баскино, Рябки, Крылово һәм Тәвеш олысларында тәртипсезлекләр булды, кибетләрне ваттылар, башка күңелсезлекләр булды, өяздә гомумән тыныч түгел, яңа кырылышлар һәм тәртипсезлекләр булуы көтелә. Олыс милициясе начальникларын алмаштыру буенча җыеннар үткәрелә». Өяздә тәртип урнаштыру өчен өяз комиссары ярдәмгә ике офицер белән йөз солдат җибәрүне сорый (2).

Халык үз сәгатен көтә. Һәм ул килә. Петроградта 1917 елның 25 октябрендә (7 ноябрьдә) Вакытлы хөкүмәтнең бәреп төшерелүе турындагы хәбәрләр, власть органнары күпме генә яшерергә тырышсалар да, шул ук көнне урыннарга барып җитә. 28-29 октябрь көннәрендә Тол буе авылларында җыелышлар башлана. 16 декабрьдә Пермьдә эшче һәм солдат депутатлары Советларының 1 губерна съезды ачыла. Анда сайлан-

ган башкарма комитет губернаның барлык Советларына мөрәҗәгать белән чыга, эшче-крәстиән хөкүмәте кабул иткән декретларны кичекмәстән тормышка ашыру эшенә керешергә чакыра.

1918 елның 25 гыйнварендa губерна башкарма комитетының административ бүлеге өяз Советларына урыннарда кичекмәстән совет властен оештыру эшен башлау турында хат җибәрә. Ләкин Оса шәһәр думасы халык комиссарлары Советын танудан баш тарта, Совет власте декретларын үтәмәячәген белдерә. Шәһәр думасы карарын земство идарәсе дә яклап чыга. Ул хәтта олыслар, күн заводы эшчеләре һәм солдат гарнизоны вәкилләре съездын үткәрү өчен бина бирүдән баш тарта.

Шулай да съезд була, 1918 елның 28 гыйнварендa ул Оса аракы заводы складында үтә. Съезд өяз башкарма комитетын, аның рәисен (коммунист Н.М.Кобелевны) сайлый. Осада шул ук көнне манифестация үткәрелә (2,3,4).

5 февраль көнне бертуган Кибардиннар һәм Кобелев тарафыннан төзелгән кызылгвардиячеләр отряды земство идарәсенә ультиматум белдерә. Идарә начальнигы Горшков хәрби часть чакырту белән яный. Гвардеецлар аны икенче каттан тәрәзәдән ташлыйлар. Бөтен идарәдән тик бер кеше — өяз мәгариф бүлегенең милли мәктәпләр буенча бүлекчә җитәкчесе сул эсер Солтанморат Абделман улы Абдусәләмов кына яңа власть органында эшләргә ризалык белдерә.

Олыс идарәләре дә үз теләкләре белән хакимиятне тапшырырга ашыкмыйлар. «Властьны Советларга кайчан тапшырасыз?» дигән сорауга алар «Барысы да учредительный собраниедә хәл ителер», дип җавап бирәләр.

Учредительный собраниегә иске власть тарафдарлары гына түгел, ә революцион демократлар да, милли-азатлык хәрәкәте лидерлары да зур өметләр баглыйлар. Крәстиәннәр анда җир алу һәм аннан файдалану мәсьәләсе иң гадел юл белән хәл ителер дип көтәләр.

Учредительный собраниегә сайлауларга әзерлек Вакытлы хөкүмәт заманында ук башлана, сайлаулар исә Октябрь революциясе җиңгәннән соң, 12 ноябрьдә генә үткәрелә. Россия буенча анда барлыгы 44 млн. 443 сайлаучы катнаша. Аларның күпчелеге, 59 проценты (26 млн.374 мең) эсерлар, меньшевиклар һәм төрле милли партияләр кандидатлары өчен, 24 проценты (10 млн. 649 мең сайлаучы) большевиклар өчен, 17 проценты (17 млн. 420 мең сайлаучы) кадетлар һәм алардан да уңдарак торучы партияләр кандидатлары өчен тавыш бирә (6).

Әле Октябрь революциясенә бер ай кала В.И.Ленин большевиклар эсерлар һәм меньшевиклар белән берләшә алсалар гына гражданнар сугышын булдырмый калырга, властьның кичекмәстән Советларга күчүенә ирешергә мөмкин булачак дигән нәтиҗә ясый (5. 137 б). Революция барган көннәрдә Ленинның бу сүзләре исәпкә алына, сул эсерлар һәм меньшевиклар хөкүмәткә дә чакырыла. Тик менә Учредительный собраниегә карата, анда Оса өязеннән үткән большевик депутат Мулланур Вахитов кебекләр 703 депутат арасында 168 генә, эсерлар исә алардан байтакка күбрәк (229) булуга карамастан, төрле юллар белән ышанычлы потенциаль союзникларын үзләренә якынайту юлларын эзлисе урынга, аларны

үзләреннән читләштерү. Учредительный собраниедә көчләр нисбәтен үзләре файдасына үзгәртергә маташып, собраниене җыю срогын үзләренә уңай, башкаларга уңайсыз вакытка кичектереп, кадет депутатларны Совет властена дошманлыкта гаепләп кулга алу һ.б. чаралар күрәләр (6).Нәтиҗәдә 1918 елның 5 гыйнваренда эшли башлаган собрание көн тәртибен дә кабул итмәстән куып таратыла. Ныклап уйламыйча башкарылган шушы эш илдә гражданнар сугышы башлануга китерә.

Тол буендагы биш олыстан Совет властен урнаштыруга Үдик авылы крәстиәннәре беренчеләр булып тотына. Шәһәр эшчеләре үрнәгенә ияреп, Герман фронтыннан большевик исеме алып кайткан утызлап фронтовик Хәлфәт Абдалов җитәкчелегендә башта кораллы дружина, оештыру комитеты төзи, олысның барлык 21 авылында да җыелышлар үткәреп, делегатлар сайлата һәм 1918 елның 2 мартында съезд үткәрүне планлаштыра. Оештыру комитеты рохсәтсез- нисез земство бинасының яртысына кереп урнаша, дружинаның коралын саклау өчен шул ук земство идарәсенең склад бинасын басып ала.

Үдикнең Оса очындагы кызыл кирпеч бина ул көннәрдә бөтен Гәйнә төбәгендә иң кайнар, иң киеренке ноктага әверелә: аның эчендә бер яртысында тәҗрибәсез оештыру комитеты әгъзалары иртәдән кичкә кадәр ыгы-зыгы килә:булачак съездга карарлар әзерли, яңа хакимият органында кемнең нинди вазифа үтәячәген билгели, гражданнарны кабул итә; бинаның икенче яртысында иске власть тарафдарлары күрер күзгә бернинди ыгы-зыгысыз үз эшләрен башкаралар. Тыштан караганда алар өчен бер нәрсә дә үзгәрмәс кебек. Урамда, идарә алды мәйданында ярлы һәм җирсез крәстиәннәр мәш килә, сайланган делегатларның килүен күзәтә. Кыюраклар идарә бинасына кереп, анда утырганнарның ниләр майтаруы белән кызыксына, съезд уздырачак Хәлфәт Абдаловка уңышлар теләп, бер уңайдан земство идарәсе начальнигы Нигъмәтҗан Арзыев кабинетына да кагылып, аңар да бер соравын биреп чыга.

— Нигъмәтҗан әфәнде, инде сез нишләрсез, власть башына кемне сайларлар?

Хәлфәт Абдаловтан аермалы буларак, аның җавабы кыска: илдәге хәлнең үзгәрүенә борчылу күрсәткәннәргә ышанычлы төстә «Ярдәм килергә тиеш, үзегез дә әзер торыгыз», дип пышылдый, инкыйлап дип сөенешеп йөрүче ярлы-ябагага мыек астыннан елмаеп: «Кемне сайласалар, власть башында шул торыр», дип җавап бирә. Йомшак бәрхет тавышлы иске идарә түрәсенең ни бу көнне, ни соңыннан да байтак вакытлар күпләр кайсы якны үз итүен аңлый алмыйлар. Икейөзлелеге белән ул ике як өчен дә «үз кеше», «закон буенча эш итүче» булып кала.

Ә «үз кеше» тик ятмый: съездны булдырмау өчен ул да көч түплый, комитетчыларга сиздерми генә Әрҗән белән элемтә тота, андагы хәлләр белән танышып, үзе дә Үдиктәге хәлләр белән таныштырып тора. Ә иске тормыш тарафдарлары җыелу урыны итеп юкка гына Әрҗәнне сайламаганнар: Үдикнең үзендә фронтта чыныгу алып, корал белән кайтканнар күп, шәһәргә якын. Әрҗән исә бу яктан имин: бередә Гәйнә иле

вәкилләрен генә түгел, ә Уфа губернасына кергән кан кардәшләрне дә җыярга була. Шулай да, саклангнаны саклармын дигән, олыс идарәсенә чит кеше үтәрлек түгел: урамнан ук сакчылар белән уратып алынган, коридорга да мылтыклы кеше бастырып куелган, телефонда - «үз кеше». Доклад ясауны Солтанайдан эсер Фазыл Әминевка кушканнар. Ул Идел-Урал штаты тирәсендә берләшергә чакыра.

— Шунсыз без Советларга каршы көрәшә алмыйбыз. Үзәк власть алар кулында, без совет төзүне тоткарлап кына тора алабыз. Иң мөһиме, аларга большевикларны сайлатмау.

Фазыл Әминев, мөмкин булса, большевиклар белән берләшүгә дә каршы түгел.

— Безгә иң мөһиме — мөстәкыйльлек алу, милли үзбилгеләнү хокукына ия булу. Шуны эшли алсак, нишләргә белербез. Безнең лозунг — «Долой алласызларны, долой большевикларны!», «Бердәм Идел-Урал штатына берләшик!»



*Рәсемдә:* Әрҗән (Красняр) төп мәктәбе бинасы. 1905 елда олыс идарәсе өчен земство салдырган бу бина күп шау-шулы вакыйгаларны күргән. Биредә искә алынган җыелыш та шушында уткән. 1918 елдан анда олыс Советы башкарма комитеты, партия һәм комсомол олыс комитетлары. 1924 елның гыйнвареннан октябрь аена кадәр (район үзәге Бардага күчерелгәнче) район Советы башкарма комитеты, РКП(б) һәм РКСМ район комитетлары урнаша.

Жыен тон чыккачы кораллы отряд булдырырга дигән карар кабул итә. Анда язылып, Үдиккә барырга риза булганнарга Гата Мансуров, Алапановлар конена унар сум түләргә, үзләрендә эшләүчеләргә хезмәт хакын арттырырга вәгъдә итәләр.Алар акчасына корал сатып алырга дип килешенә. Жыелыш моның белән генә канәгать була алмый, Алдан әзерләнгән карарга шундый пункт та өстәлә: «Оса сәүдәгәре Гәрәй Әмирхановка мөрәҗәгать итәргә, кораллы отряд төзү өчен массовый акча җыюны оештырырга». Почта начальнигы Могыйн Хәлилов, Габдулла мулла Киеков, Гарифулла Исмаков, Каенавылдан Хуҗан-хаҗи һәм аның улы, Мортаза Аптуков, Тауавылдан Хәсән-Гата һ.б. үзләреннән ярдәм тәкъдим итәләр.

Жыен «халыкны алласызларга каршы көрәшкә күтәрү өчен авылларга вәкилләр җибәрергә» дигән карар кабул итә.

Иртәгесен әнә шулай җыелган отряд, 1918 елның 2 мартында (иске стиль белән 16 февральдә) ак флаглар күтәреп, «кяферләргә каршы изге походка» чыга. Юл буенда аларга Барда һәм Каенавыл кешеләре дә кушыла. Үдиктә бу турыда санаулы гына кешеләр: патша заманында олыс старшинасы булып эшләгән Мөхәммәтҗан Абдалов, Вакытлы хөкүмәт тарафыннан земство начальнигы итеп куелган Нәгъмәтҗан Арзыев һәм аларның якын кешеләре генә белә.

Вакыт төшлеккә җитеп килә. Сайланган 32 делегаттан берничәсе генә килеп җитмәгән, ә делегатларга ияреп һәр авылдан берничә бүтән кызыксынучылар да килгән. Үдик авылының өяз үзәгенә илтүче трактовый урамы базар мәйданын хәтерләтә: 1905 елгы инкыйлабтан соң төзелгән волость бинасы бу кадәр халыкны беренче күрүе.

Съезд ачу мәшәкате белән мәшгуль комитет әгъзалары бинаның икенче ягында земство рәисенең әледән-әле телефон трубкасын күтәреп, кемгәдер «Әйе, киләләр» дип хәбәр салуына игътибар да итмиләр. Шул мәшәкать белән алар аның беркемгә сиздермичә корал складын бушатуын да сизми калалар, аның бик тә итагатьле булып оргкомитет рәисенә:

— Барысы да килеп бетмәгән бит әле, алай законлы булмас, ашыгасы җир юк, әбәд ашап килсеннәр, ул арада килмәгәннәр дә килеп җитәр, — дигән киңәшендә дә берниди хәйлә күрмиләр.

Дружиначы Әхмәтсафа Мәсәгутов залда съезд ачылуын көтеп утыручылар янына керә дә: «Иптәшләр, килеп җитмәүчеләр бар, барыгыз, тамак туйдырып килегез», — дип белдерү ясый.

Кешеләр таралыша. Идарәдә өч кенә кеше: карабин тоткан дружиначы Сәет Кадермәтов, делегатларны каршы алып, теркәп утыручы Гатаулла

Ибраһимов белән Шәйморат Гвбдрахманов кына кала. Берникадәр вакыттан телефон янында торучы Шәйморатны Гатаулла алыштыра. Һәм нәкъ шул минутта иңенә тиң ишек ачыла, бинага кайсы мылтык, кайсы балта, сәнәк тоткан ачулы ташкын кереп тула. Иң беренче алар Гатаулланы телефон яныннан алалар һәм анда үз кешеләрен бастыралар.

— Йә, кайсыгыз бәлшәүник, кил якынрак, үтерәбез! — дип авыз ера үзен атаманга санаган Гафи Хәлилов. Дружиначы Сәет Кадермәтов югарыга атып фетнәчеләрне туктатмакчы була, ләкин шундук аның кулыннан карабинын тартып алалар, үзен типкәләп тышка алып чыгып китәләр.

Ашап утырган җиреннән волость бинасын фетнәчеләр басуы турында ишетеп, комитет рәисе Хәлфәт Абдалов арт яктан корал складына йөгерә, анда бер винтовка да юклыгын күреп, түбәгә менмәкче була (бәлки шунда күчергәннәрдер). Ләкин аны өстерәп төшерәләр, Алапанов аңа карабиннан атып җибәрә. Хәлфәт, корал складын кемнәр талаганын белмәкче булып, егылып барган җиреннән артына борыла. Шунда аны ике фетнәче эләктереп алалар һәм: «Влач кәрәк булдымы? Менә сиңа влач!» — дип аны башы белән стенага бәрәләр.

Әрҗәннән килгән төркемгә Үдикнең үз кешеләре: Әрҗәндә күн заводы тотучы Дәүләтша Алапановның кияве Мортаза бай Адутов, элекке волость старшиналары М.Абдалов һәм Х.Тюмисов, шулай ук элемтәче Гапләхәт Кантуганов һ.б. кушыла. Үтерешне туктатырга дип ашыккан Сәет Искәндәровны авылдашы Шакирҗан Абдалов булә, каршысына сикереп чыгып, Сәетнең кылычын тартып ала һәм кизәнеп аңа бер чаба.

— Нишлисез? — дип ачы кычкырып, алар арасына Закир мулла Арзыев килеп керә. — Илебезнең иң яхшы улларын үтерәсез бит!

Дежурда торучылар белән эшне бетереп, фетнәчеләр авыл буйлап сибеләләр. Алар Низаметдин Кәримовны өстерәп китереп ыргыталар, аның өстенә муены борылган Шәйхуҗа Шакманаевны китереп ташлыйлар. Әрҗәгә тотырып оргкомитет әгъзасы Габдулла Юрбагишевның гәүдәсен алып киләләр. Бер гаепсезгә Шәмсетдинов, Аитов, бертуган ике Ибраһимовлар үтерелә. Үсмер егет Габдел Иртугановны, капка төбендә өнсез басып торган Сафа Ибраһимовны балта белән чабып үтерәләр. Хуҗакай Искәндәровны танымаслык хәлгә китергәнче кыйныйлар һәм әвен базына ташлыйлар.

Фетнәчеләр телефон линиясенә, юлларга каравыл куялар, төрле якка телефоннан хәбәрләр оча: Үдиктә большевиклар бетерелде, үз советлары-бызны сайлыйбыз, безнең үрнәккә иярегез!

Ләкин фетнәчеләргә тантана итәргә иртәрәк була. Юлларны ничек кенә күзәтмәсеннәр, Бәдретдин Абдусаләмов, Шакирҗан Әбүбәкеров, Таһир Абраков, Мулланур Шакманаев, Мөэмин Мозаффаровлар чаңгы киеп авылдан чыгып китәләр, Гамицы авылыннан Осага хәбәр итәләр. Ә аннан инде хәбәр Пермьгә җиткерелә. Ике көн үткәч, Үдиккә Зайцев җитәкчелегендә Мотовилиха эшчеләреннән төзелгән отряд килеп җитә. Фетнәдә иң актив катнашучылардан Әхмәй Тюмисев, Госман Ибраһимов, Рәхмәтҗан Мөрсәлимов, Әхмәтхан Әмиров (ярлы) атарга хөкем ителәләр, башкалары (Шакирҗан Абдалов, Әхмәр Адутов, Гата Кәримов, Фәтәү Тюмисов, Габделхәй Арзыев, Хикмәт-аксак Адутов) июнь-июль айларына кадәр Уймуж урманында качып яталар, аннары Шлик-Баш, Озын Ялан якларында качып йөргән «күңелле роталар» белән берләшеп, Суфый Нигъмәтуллин ярдәме белән Ижевск-Воткинск ягында хәрәкәт иткән акгвардиячеләр белән элемтәгә керәләр һәм, Хикмәт Адутов командалыгында бер полк тәшкил итеп, «Халык армиясе»нә барып кушылалар. Чабаталы аклар (сәнәкчеләр) чорында ике ай Тол буе авылларында хәрәкәт итеп, бу полк ике йөздән артык кешене җәзалап үтерә. Ноябрь аенда полк Күңгер тирәсендә Колчакка барып кушыла.

Үдик олысы Советының съезды шулай да үткәрелә, башкарма комитеты сайлана, рәисе итеп Хисами Искәндәров сайлана. Зайцев отряды Әрҗән, Сараш авылларында да булып чыкканнан соң ул авыллардагы волость идарәләре дә бетерелә һәм аларда да Советларга сайлаулар үткәрелә, съездлары уздырыла. Шундый ук эш Печмень, Шермейка олысларында да эшләнә. Тиздән волбашкарма комитетлар ревкомнар итеп үзгәртелә, алар каршында хәрби, игенчелек, мәгариф һәм агарту, финанс комиссарлары вазифалары кертелә.

Сараштa рәисе Казанбаев булган земство идарәсе бетерелеп, Рәхмәтулла Хәлилов (рәис), Габдулла Ижбулатов (мәгариф бүлеге мөдире), Нурулла Ягъфәров (земотдел) составында волбашкарма комитет сайлана.

Әрҗәндә Совет властен урнаштыру эшенең башында Петроградта Октябрь коралды восстаниесендә катнашкан, элекке Кронштадт матросы Иван Малафеевич Ханжин тора. Волбашкарма комитет рәисе итеп Газиз Хөсәенов сайлана, бүлек мөдирләре булып Газиз Кантуганов, Иван һәм Игнат Ханжиннар эшли.

Шермейкада волбашкарма комитет белән Л.А.Крылов җитәкчелек итә.

Җәй көннәрендә ярлылар комитетлары (комбедлар) төзелә. Бардада ул Газиз Хөсәенов, Сафа Аптуков, Габделҗан Сәитовлар составында билгеләнә. Аларга коммунистлар Хәбил Юсуфкулов, Газиз Кантуганов, Әмирҗан Бухаров, улы Кашшаф белән Мостай бабай һ.б. ярдәмләшә.

Печменьдә комбед төзү өчен 14 августта 500 кеше катнашында халык җыены үткәрелә. Олыс һәм авыл комбедлары төзелә. Олыс буенча комитетка Печменьнән Захар Григорьевич Голодков (комбед рәисе), Зя-

зелгадан Григорий Лаврович Кочин, Самселяктан Федор Васильевич Шихов сайлана.

Байларга контрибуция салына, предприятиеләр эшенә күзәтчелек итү өчен комиссарлар билгеләнә. Алапановларның күн заводына комиссар итеп Газиз Юртаев, ә гражданнар сугышыннан соң Саттар Габитов билгеләнә (7).

1918 ел башына һәр олыста ике-өч коммунист булса, ел уртасына аларның саны унга җитә. Яңа властьны яклаучылар ак чехларга, «Халык армиясе» дип аталган берләшмәгә каршы көрәшү өчен ирекле отрядларга язылалар, партиягә керәләр.

Бу урында Барда төбәгенең беренче коммунистларын атап китү урынлы булыр. Менә алар: Шермейкада Крылов Афанасий Афанасьевич (1918 елның августыннан), Крылов Левонтий Абрамович (ВИК рәисе), Драчев С.Т. (1918 елдан).

Сарашта — Горбунов Иван Яковлевич, Хәлилов Рәхмәтулла, Сарманаев Шәрифҗан, Варзаков Н.И., июнь аеннан А.И.Ездаков.

Әрҗәндә — Ханжин Иван Малафеевич, Газиз Хәбибрахманов, Хәбил Юсуфкулов, Газиз Кантуганов.

1919 ел ахырында РКП(б) өяз комитетында секция урынына татар-башкорт бюросы төзелә һәм аның секретаре итеп укытучы, мәгариф бүлеге инструкторы Мөгыйн Кәбиров раслана (8).



**Мөгыйн Кәбиров** (1885-1934) - Яланаер- Иштирәк авылында туа. Янапай авылында укый, Күлбайчын һәм Иске Иренбаш авылларында балалар укыта, туган авылында мәктәп салдыра, 1910-1915 елларда шунда укыта. 1906-1909 елларда армиядә атлы гаскәрдә хезмәт итә. 1911 елда балаларга тыелган нәрсәләр сөйли дип аны судка бирәләр, штраф салалар. 1918 елда Байчын волбашкарма комитет рәисе итеп сайлана. Авылны чабаталы аклар басып алгач, урманга кача, ләкин тотыла, Воскресенск тормәсенә илтеп ябыла, асып яисә башын кисеп үтерергә дигән карар чыгарыла, ләкин кызыллар килеп, карар үтәлмичә кала. Гражданнар сугышыннан соң М.Кәбиров гаиләсе белән Осага күчеп килә, политкурста укыта, 1922 елда Татарстан наркомпросында инспектор, Мамадыш кантон мәгариф бүлеге инспекторы,

1927-1928 елларда Пермьдә детдом мөдире, гомеренең соңгы елларында Бардада укытучы. 59 яшендә авырудан үлә. Кабере - Барда зиратында (9).

РКП(б) өяз комитеты бюросының 1921 ел 29 май карары белән татар-башкорт бюросы Әрҗәнгә күчерелә һәм 3 июньдә райком итеп үзгәртелә, составына Костицын, Горбунов И.Я. (Сараш), Артемов, Крылов (Шермейка), Н.Айсин сайлана. Әрҗән райкомына шушы олыстагы ячейкадан тыш Сараш, Печмень һәм Шермейка олысларындагы оешмалар да буйсына. Үдик коммунистлары Оса райкомына буйсындырыла.

Бу чорда Сараш ячейкасы иң зурлардан була (7 коммунист). Шермейка һәм Печменьдә 4- 5әр, Әрҗәндә 3 коммунист.

Партия оешмаларының бу формасы озак яшәми. 1922 елның 15 июленнән райкомнар бетерелә, ячейкаларда штатлы инструкторлар, ә берләштерелгән ячейкаларның эшен политсекретарьлар җитәкли. Сараш, Үдик, Әрҗән ячейкалары берләшмәсенең политсекретаре итеп Газиз Кантуганов раслана. Печмень коммунистлары Аспа, шермейкалылар Ашап ячейкасы белән берләштерелә. Шушы ук чорда авыл советлары һәм административ-территориаль районнар оештыру мәсьәләсе тикшерелә. Үдик олысы авылларында биш авыл Советы оештыру һәм аларны Оса районына, Әрҗән олысында 6 совет, Печменьдә 2, Шермейкада 4, Сараш олысында 7 авыл Советы оештырылып, аларны Әрҗән (яисә Барда) районы составына кертү карала.

Партячейкалар белән бергә комсомол ячейкалары да барлыкка килә. 1918 елның апрелендә укытучы Гаплахәт Хосәенов инициативасы белән Әрҗәндә «Социалистик яшьләр түгәрәге» оештырыла. Аны районда коммунистик яшьләр хәрәкәтенең башлангычы итеп санарга мөмкин (10).



1919 елның 3 ноябрендә партячейка секретаре Иван Яковлевич Горбунов тырышлыгы белән волбашкарма комитет һәм хәрби комиссариатта эшләүче яшьләрдән комсомол ячейкасы оештырыла. Аның секретаре итеп хәрби комиссариатта эш башкаручы вазифасын үтәгән Владимир Цаплин сайлана. Беренчеләр булып биредә комсомолга Александр Горбунов (ячейка секретаре да була), Шәрифулла Үзәкаев, Александр Тригубов, **Фазыл Назаров,** Александр Шаров, бертуган Хомяковлар, школа-коммунадан Гәрәй Мөстәкыймов, Хоснимәрдән Сарманаев, Галишан Шакманаев, Касим Исмәгыйловлар керә.

Ноябрь-декабрь айларында Аклыш, Тонгук, Озын Ялан, Барда авылларында ячейкалар барлыкка килә һәм РКСМ төзелә. Аның рәисе итеп Фазыл Назаров, секретаре итеп Александр Шаров сайлана.

Сараштa комсомол ячейкасы беренче елны ук утызлап егет һәм кызларны берләштерә, тагын бер елдан бирeдә 86 комсомолец була. Беренче комитет секретаре булып Мөсәбих Адилов, әгъзалары Зариф Букаев (соңрак секретарь), Зәйнетдин Биктимеров, Шаһит Ибәтуллин һ.б. була.

Үдиктә беренче комсомолларга Кәрим Мәсәгутов, соңрак Газиз Абдусәләмов, Печменьдә Иван Голдобин җитәкчелек итә.

Шермейкада яшьләр белән эшләү сүлпән бара. Комсомол оешмасы биредә 1921 елда, РКСМ райкомы оешып бер ел үткәч кенә булдырыла. Күп тә үтми, ул да таркала һәм тик 1925 елда гына яңадан оеша.

1920 ел башында РКСМ өяз комитеты каршында татар-башкорт бюросы оештырыла, татар авылларында яшьләр белән эшләүне активлаштыру максатында бу бюро 1921 елның июль аенда Осадан Әрҗәнгә, РКП(б) райкомы янына күчерелә. Бюро җитәкчесе Мәлик Шәрипов белән бергә бюро әгъзалары Әсхәт Мансуров һәм Сәлим Габдрәшитов та Әрҗәнгә күчеп киләләр. 1922 елда бюро базасында РКСМ райкомы төзелә. Административ-территориаль районнар барлыкка килгәнче РКСМның Әрҗән райкомы өяз комитеты функцияләрен үти, Әрҗән, Печмень, Шермейка, Үдик, Сараш олысларыннан тыш аңа Искәвыл (Кәрьяу) һәм Уинск олыслары татар авыллары яшьләре арасында да эш алып бару бурычы йөкләтелә. Тат-башбюрода, Әрҗән РКсында 1922-1924 елларда Барый Адутов (М.Шәриповтан соң җаваплы секретарь), Мөхетдинов, Хисмәт Сарманов (Аклыш), Шәфик Адутов (эш башкаручы), Мансур Халитов (укытучы) һ.б. эшли.

1921 ел башына район авылларында йөздән артык комсомол исәпләнә. Коммунистлар белән бергә алар бандитизм, наданлыкка каршы көрәш алып баралар, хәрби өйрәнүләр, клублар оештыруда, яшьләрне үзешчән сәнгатькә җәлеп итүдә башлап йөриләр. Районның беренче комсомоллары Фазыл Назаров (I Әрҗән), Мөхетдин Әширов (Байавыл) үз теләкләре белән Беренче Татбригада составында Төркстанда; Мөкыйм Мөсәгыйтов, Нургали Батыров, Мәрдән Сарманаев, Нәкый Абдалов, Габдулхан Акбаевлар гражданнар сугышының төрле фронтларында барган сугышларда катнашалар. Үдиктән Сәет Искәндәров Польша фронтында вафат була. Өйдә үтерелүчеләр дә аз булмый. Сараштa Зәйнетдин Биктимеровны, мәсәлән, тәрәзәдән атып үтерәләр, Бардада Гөлфия Назарова, Әрҗәндә Рәхим Мөрсәлимов, Шәрифулла Үзәкаев үтерелә, Мөнир Алдаровны мунчада буып үтерәләр (8; 10).

Янә 1918 елга әйләнеп кайтыйк. Җәй көннәренең берсе. 20 июнь. Осада сул эсерлар партиясе әгъзалары (мөселманнар) совет властена карашларын белдерү өчен съездга җыелганнар. Кызу бәхәсләр булачагын белеп, укытучылар әзерләү курсында укучы партиясезләр дә килгән (шушы кызыксынулары аркасында аларның күпләре 1937-1938 елларда репрессия корбаннары булырлар). Съездда рәислек итүче Солтан Абдусәләмов,

бәхәсне туктата алмаячагын, күпләрнең Совет властен танырга теләмәячәген аңлап, үзен эсерлар оешмасына җитәкчелек итүдән азат итүләрен сорап, РКП(б) өяз комитетына китә. Мондый үтенеч белән ул элегрәк тә мөрәҗәгать иткән була, сул эсерларның крәстиәннәр арасында йогынтысы зур булуын исәпкә алып, аларны чын революцион юлга алып чыгу өчен дип, өяз комитеты С.Абдусәләмовның гаризасын кире кагып килә. Бу юлы да аны ашыкмаска, түземле генә тагын бер тапкыр тырышып карарга үгетлиләр. Һәм чыннан да, съездда В.И.Ленин җитәкчелегендәге хөкүмәтне танырга чакырулар була, ләкин тавышка куйгач, күпчелек каршы кул күтәрә. Сул эсерлар партиясенең Оса өяз бүлеге таратыла, Совет властен танырга чакыручылар коммунистлар партиясенә керәләр, РКП(б) өяз комитетының татар- башкорт секциясен тәшкил итәләр.С.Абдусәләмов секциянең рәисе итеп сайлана. Аларга иярмәгән сул эсерлар террор юлына басалар. Беренче һөҗүмнәрен «хыянәтче җитәкчегә» юнәлтәләр: Оса мөселман комиссариаты урнашкан һәм аның җитәкчесе яшәгән бинаны шартлату өчен Үдиктә бомбалы олау оештыралар. Бәхеткә фаҗига булмый, Үдик коммунистлары Тылай елгасы янында олауны туктаталар (11).

Совет властен танырга теләмәүчеләр Озын Яланда урам уртасында Ахун Ремизовны балта белән чапкалыйлар, Үдиктә Әхмәтсафа Абдуловны үтерәләр.

Авырлык белән булса да Советлар тәҗрибә туплыйлар, халык белән элемтәне ныгыталар, армиягә мобилизация, хәрби өйрәнүләр үткәрәләр, мәктәп эшләрен яңача оештырырга әзерләнәләр. 1918 елның 10-12 июлендә Осада мөселманнар съезды үткәрелә. 58 делегат катнашкан бу съездда төрле комиссияләр: Габдулла Казанбаев, Габдулла Суяргулов, Ганләхәт Хосәенов, Нурулла Ягъфәров, Хәлим Әмиров, Әхмәдия Мәхмүтов, Гата Бәширов, Габдулла Усмановлар составында мәдәни-агарту, оештыру-финанс һ.б. комиссияләр төзелә. Съезд өяздә 67 милли мәктәп ачарга дигән карар чыгара. Беренче совет мәктәпләре нигездә 1-3 сыйныфлы, Бардада 6, Үдиктә 7 еллыклар, Сарашта алдан билгеләнгән югары башлангыч училище урынына укытучылар әзерләү өчен семинарий ачарга, моңарчы эшләп килгән икееллык курсларны өчъеллыкка әверелдерергә, мөгаллимнәр өчен һәр елны айлык курслар үткәрергә, мәктәпләр буенча инструктор вазифасы булдырып, шул ук елны аны (Ә.Г.Батыркаев) Мәскәүгә җибәрергә дигән карар чыгарыла. Университетларга җибәреп укыту өчен 4, урта уку йортларына - 20 стипендия билгеләнә, биш кешене Казанга югары милли курсларга, өч кешене учительский институтка җибәрергә килешенә.

YIII өяз мөселманнар съезды шулай ук 7 район күләмендәге, 17 ярдәмче китапханә ачарга, кинематограф сатып алырга, Әрҗән мәктәбендә столярный, Үдиктә күн эшкәртү, Сарашта тимерлек-слесарьлык эшенә өйрәтү мастерскойлары ачарга карар итә.

Съезд хәрби комиссариат вәкиле Заһидуллин һәм Әрҗән олысы башкарма комитеты рәисе Әмирҗан Кантугановның докладларын тыңлый,

Татар-Башкорт республикасын төзү идеясен хуплап, Ленин, Сталин һәм Вахитовлар адресына телеграмма җибәрә (12. N 26, N 32).

1918 елның май аенда Мәскәүдә Татар- Башкорт республикасы советлары съездын чакыру буенча киңәшмә үткәрелә. Пермь губерна мөселман комиссариаты исеменнән чыгыш ясап, Хәлим Әмиров анда болай дип белдерә:

— Оса өязендә 80 мең мөселман яши. Хезмәт ияләре Татар-Башкорт совет социалистик республикасы турындагы положениене хуплап каршы алдылар. Оса, Шадринск, Красноуфим өязе башкорт һәм татар эшчеләрендә ул зур шатлык тудырды.

Киңәшмә Татар-Башкорт республикасын төзү турында бик тә әйбәт карар кабул итә. Ләкин ул тормышка ашмый - тиздән гражданнар сугышы башлана.

Крәстиән, эшче һәм солдат депутатларының Оса өяз Советы башкарма комитеты газетасы «Известия»нең 17 һәм 24 август саннарында «1918-1919 уку елына өяз мөгаллимнәре исемлеге» басылып чыга. Бу исемлектә без районның беренче совет укытучыларының исем-фамилияләрен, аларның кайсы мәктәпләргә билгеләнүен беләбез.

Оса өязендә башланган бу тәҗрибә (укытучыларны алдан билгеләү) бөтен Пермь губернасында гамәлгә кертелә, аны башкару өчен махсус комиссия төзелеп, аның беренче әгъзасы итеп С.А.Абдусәләмов билгеләнә. (12. N 40, N 42).

1918 ел урталарында Оса өязе камалыштагы утрауны хәтерләтә. Екатеринбург, Ырымбур, Саратов якларыннан буржуаз хөкүмәтләр төзелә имеш дигән хәбәрләр килә, Ижевск- Воткинск ягыннан ак офицерлар фетнәсе яный, коньяктан ак чехлар һөҗүмгә күчәргә мөмкин. Әнә шундый шомлы көннәрдә, 1918 елның 15-20 октябрендә, Оса өязендә кызыл армиягә мобилизация башлана. Барда (Әрҗән), Сараш тобәгеннән алынганнар I Әрҗәнгә җыела. Ашап, Аспа, Ашинск, Бым, Юго-Осокино олысларында мобилизацияләнгәннәр һәм үз теләкләре белән язылганнар (меңгә якын кеше) Уинскида җыелып, Егор Бахматов җитәкчелегендә шулай ук I Әрҗәнгә киләләр. Биредә алардан 8 рота оештырыла. Осада бу роталардан Өченче Бөре полкы төзелә һәм Елово ягына җибәрелә (13).



Печменьдә Красногоркада туып-үскән кызыл дружиначы **Петр Иванович Садилов** отряд төзү эшенә тотына. Хәрби комиссар Багаевның ризалыгын алып, ул Печменьдә Иван Чепкасовны, Зязелгадан Алексей Чугаевны, Ашатлядан Егор Южанинны, Сергей Алехмин, Иван Уховларны яза. Печменьдә ирекле партизаннар отряды оеша икән дигән хәбәрне ишетеп, Шермейкадан берничә кеше ияртеп Степан Драчев килеп җитә. Шулай да отрядның төп өлешен Адыевка крестьяннары тәшкил итә. Аннан отрядка Александр Кузьминых, Яков Патраков, Алексей Гребнев, Филипп Зыкин һ.б. языла. Чабаталы аклар Сарашка якынлашканда отряд сиксәнләп кешене берләштерә. 1918 елның 22 октябрендә сигезенче рота исемен алып, отряд Сараштa Бишенче дивизиянең Икенче Бөре полкына кушыла, дүрт көннән Федоровскида сугышка керә. Күчтәнги- Печмень арасында фронт тота, продразверстка буенча 6 мең пот икмәк тупланган Деменевоны аклардан азат итә, Азин дивизиясе белән берлектә бу икмәкне Кама аръягына чыгарыша (14; 16).

«Известия Пермского губисполкома» ул көннәрдә фронт хәбәрләре белән тулган була. 4 ноябрьдә ул «Бардабаш һәм Озын Ялан авыллары районында сугышлар бара», 24 ноябрьдә «безнең частьлар контрһөҗүмгә күчте һәм Уймужны, Загорный, Үдик авылларын алды» дип хәбәр итә.

Шушындый хәвефле көннәрдә зуррак авылларда Октябрьнең берьеллыгы билгеләп үтелә. Бардада кызыл бантиклар тагып чыккан укучылар колоннасына Иске Чат, Бакчавыл, Әрҗән авылларыннан килгәннәр кушыла. Бәйрәм колоннасы төп урамнардан җырлап үтә. Аннары сәүдәгәр М.Корбангалиев ишегалдында (Пушкин урамы) көйләнгән сәхнәдә укытучы Муллануp Мушаков җитәкчелегендә яшьләр спектакль күрсәтә.

Сараштa демонстрантлар колоннасының башында үз теләкләре белән Кызыл Армиягә языланнар бара. Җыелган халыкка «Әлдәпсезләр арасында җиһансыз» спектакле күрсәтелә. Төп рольне уйнаучы Зиннур бай кызы Шәмсинурны оеннән дружиначы Шәйхулла алып килә. Репетицияләргә дә

аны тик шулай, винтовкалы кешеләр генә йөртә. Шунсыз этисе аны өеннән чыгармый (10).

Губерна газитенең 2 декабрь санында янә укыйбыз: «дошман Үдикне алды», 10 декабрьдә: «безнекеләр Байавылны, Бакчавылны алдылар. Сараш районында Гари алынды, дошманның 8 солдаты әсир төште, бер пулеметы, винтовкалары, башка кораллары алынды», 12 декабрьдә: «безнекеләр Барданы алдылар һәм Әрҗән ягына һөҗүм итәләр», 15 декабрьдә - «Батырбай авылы тирәсендә бәрелешләр бара», 17 декабрь - «Төнгүк, Башап Түз, Сараш, Танып, Күчтәнти авыллары алынды» (15).

Бишенче дивизиянең хәле авырлашканнан авырлаша бара. Көнбатыштан аны Воткинск акгвардиячеләре, көнчыгыштан Колчак армиясе кыса. Һәм шундый вакытта штабы Печменьдә торгаи икенче бригада комбригы дворян Шидловский хыянәткә бара: 15 декабрьдә 2 пулеметны 3 нче Кама полкына каршы юнәлтә һәм аны дошман ягына чыгарга мәҗбүр итә (16. 60 б).

Шул ук төндә штабы Сараштa урнашкан 2 нче полкка да һөҗүм ясала. Таң алдыннан штаб урнашкан бинаны авыл кулаклары оештырган төркем камап ала. Полк командиры Светлаков камалыштан качарга иткәндә патша армиясе унтер-офицеры Сәитҗан Мансуров тарафыннан аты остеннән атып төшерелә, батальон военкомы Новиков каты яралана. Полк Печмень ягына чигенә. Бер рота шулай да Таныпны кабат ала, ләкин Сараштa булган хәлне истә тотып, рота кичен яңадан чигенә. Анда тәвәкәлләп нибары 15 солдат төн чыгарга кала. Авыл байлары моны акларга хәбәр итәләр, Таныи ярты рота белән камап алына, 15 солдат җәзалап үтерелә. Берәү бу хәлне кызылларга барып сөйли. Шул ук төндә 2 нче полкның икенче ротасы Таныпка һөҗүм итеп, акларның бөтен батальонын юк итә. Шулай итеп, Таныи авылы бер төн эчендә ике тапкыр кызыллар, ике тапкыр аклар кулында булып ала (16. 61 б). Шушы вакыйгадан соң кызыллар әсир алмый башлыйлар, командирлар үз солдатларына карата да аяусыз кыланалар. Печменьдә ике командирның бер-берсен аңламавы нәтиҗәсендә дистәдән артык солдат стройга тезеп атыла, соңыннан «Нишләдек без?!» дип, ике командир чәчләрен йолкалар (13).

Урта Уралга кончыгыштан моннан да яманрак көчләр яный. Күңгер ягыннан яхшы коралланган регуляр Колчак армиясе һөҗүм итә. Ноябрь урталарында махсус билгеләнешле отряд саклаган Кама буе зонасын ерып чыккач, аңа биш меңлек Ижевск-Воткинск «Халык армиясе», аның составында Хикмәт Адутов полкы барып кушыла.

Күңгер, Оса өязләре территориясендә сугышлар алып барган II һәм III Армияләргә камалышта калу куркынычы яный. Һәм 28 нче Азин дивизиясенә III Армиягә ярдәмгә бару, дошманны Күңгер тирәсендә тоткарлап тору бурычы йөкләтелә (17).

1919 елның 1 гыйнвар төнендә бер төркем электәге патша армиясе офицерлары, Толбаш-Шермейка тирәсендә сугышлар алып барган 2 нче бригада штабын, 4 нче Кама полкын һәм 5 нче Урал дивизиясенең ике батареясын алдап дошманга тапшыралар (17).

Оса өязе җитәкчелеге яңадан эвакуацияләнә, бу юлы Фоки ягына, аннан Сарапул аша Казанга. Учреждениеләр белән бергә укытучылар, мәдәният работниклары һәм аларның гаиләләре дә эвакуацияләнә. Күпләр юлда армиягә алына, укырга җибәрелә, эшкә билгеләнә. Барда тобәгенең барлык укытучылары да диярлек Казанга җитү белән Вахитов курсларына языла-лар, өяз һәм олыс учреждениеләрендә эшләргә приказ алалар. С.А.Абдусәләмов, мәсәлән, Көнчыгыш фронтның ревтрибуналында, улы Гәрәй 2 нче армиянең махсус бүлегендә, Ә.Г.Батыркаев Казан өяз ревкомында тәэминат бүлегендә эшли. Алар белән бергә эвакуацияләнергә тиешле Хөсәен Адутов пишләптер тоткарланып кала. Берәүләр моны өяз партия комитеты чабаталы аклар вакытындагы кебек чигенүнең вакытлы гына булачагын аңлату очен калдырды дип, икенчеләр аклар ягында сугышып йөргән энесе Хикмәк-аксакны табып үтерергә калган иде, дип аңлата. Бу юрауларның кайсы дөрестер, әйтүе кыен. Тол буен аклар басып алгач та ул, чыннан да, Хикмәт Адутовның Озын Яланда булуын ишетә һәм шунда юл тота. Һәм шунда аклар кулына эләгә, Бардабаш юлына, Кала тауга алып чыгып атыла. Кыш буе кар астында яткан гәүдәсен яз коне кар эреп беткәч кенә табалар һәм табылган урынында ук җирлиләр дә.



**Хөсәен Адутов** - Үдик кешесе. 4 ел Казанда «Мохәммәдия» мәдрәсәсендә укый, 1906 елда авылына кайтып, җыен җыя, «Җәмгыяте хәйрия» (Мохтаҗлар җәмгыяте) оештыра, халыктан акча җыеп, атасы йортында китапханә ача, соңрак аны Кашшаф мулла йортына күчерә. Казаннан үзе дә китаплар, грампластинкалар алып кайта һәм уку йортына тапшыра. Грампластинкалар арасында «Ай Дунай, вай Дунай» дигәне дә булып, Хөсәен шунысын бик яратып уйната. Шуңар аны Хөсәен-Дунай дип йөртә башлыйлар. Һәм ул шул кушаматы белән халык хәтеренә кереп кала.

«Җәмгыяте хәйрия» милләтебезнең алга китүе өчен тырыша дип, башта аңа Зыя, Кашшаф, Зариф муллалар һәм сәүдәгәрләр дә булышлык күрсәтәләр. Ләкин оешманың революцион юнәлештә эшләвен күреп, алар Хөсәенгә карашларын үзгәртәләр, Октябрь революциясенә кадәр эш бирми йөртәләр. Патша армиясендә казаклар отрядында хезмәт иткән Госман Кадермәтов хәтта урам буйлап:

— Бай, кантон баласы имеш, эш бирмәү генә аз аңа, яндырып көлен җилгә очырырга кирәк, — дип янап йөри.

1917 елның көзендә Хөсәен Адутов сул эсерлар партиясенә керә, Осада, Үдиктә митингларда чыгыш ясап, Октябрь революциясенең асылын, аның февраль революциясеннән аермасын аңлата. Өяз Советы каршындагы Мөселман комиссариаты эшендә актив катнаша (7).

Тол буе авылларыннан эвакуацияләнгәннәр Татарстанда, Новгород губернасында эшлиләр, укыйлар, үзләрен Советларда эшләргә әзерлиләр һәм бер үк вакытта туган якларындагы хәлләр белән дә кызыксынып торалар, җаен туры китереп, сәфәргали-сәүдәгәр, адашкаппар кыяфәтендә үзләре дә кайтып әйләнәләр.

Оккупациядә калган территориядә чын фаҗига башлана. Беренче булып басып алынган Шермейка һәм Печмень олысларында совет властена хезмәт иткән, теләктәшлек күрсәткәннәрнең берсе дә качып котыла алмый. Аларның гаилә әгъзалары да үтерелә.

Бер Шермейкада гына группалап һәм берәмләп өч йөздән артык кеше атып һәм асып үтерелә. Башта биредә Смолин отряды аерылып тора. Бер-бер артлы якын-тирә авыллардан бирегә совет власте активистларын, аларның гаилә әгъзаларын куып китерәләр. Авыл читендә атыш тавышлары көндез дә, төнлә дә тынып тормый. Пулеметтан да, винтовкалардан да аталар. Шушындый вәхшилекләрнең шаһиты булганнар (А.Емельянова, А.Зайцева, А.Наумовалар) бер көндә булган бер фаҗигане менә ничек искә алалар:

— Кыш иде. Тирән кар ята. Урамда уйнап йөргән җирдән авыл читендә калкулыкта бер төркем кешеләр, яннарында пулемет күрдек. Ярымшәрә кызыларлмеецларны стройга тезгәннәр дә «Чишенергә, тезелергә! Кругом!» дип кычкыралар. Стройга тезелгәннәрнең берсе бер хәрәкәт ясамый. «Кругом» дигәненә җавап итеп дәррәү җыр башлыйлар. Аклар акырына, ә җыр дәвам итә. Иллеләп кеше әнә шулай җырлап үлем кабул итте. Ак солдатлар үз эшләрен эшләделәр дә юк булдылар. Атылганнар янында безнеңише бала-чага гына торып калды. Шунда без берәүнең ыңгырашкан тавышын ишеттек. Ярдәм итәргә хәлебездән килми, куркабыз да. Шулай да янына бардык, безнең күз алдында ул кардан торды, авыл ягына атлап китте, елганы чыкты, Черемныхлар йортына җитте. Соңыннан ишеттек: Черемныхлар аны киендергәннәр, ярасын бәйләгәннәр, ашатып идән астына яшергәннәр. Ләкин күршеләреннән кемдер акларга барып әләкләгән. Алары килеп эзләп табып, яралы солдатны икенче тапкыр атканнар.

Шермейканың үз кешеләреннән кызылармеецлар Максим Даниловичның хатыны, Яков Оглезневның әнисе, Авдотья Николаевна ерткычларча җәзалап үтерелә. Элекке земский управа начальнигы В.М.Шачков һәм священник Павел Пономарев- Красильников доносы буенча коммунистларның хатыннары, ревком әгъзалары, дружиначылар тотып үтерелә. Акларга олау бирүдән баш тартучыларны да шул ук язмыш көтә.

Жебрейка авылы тирәсендә йөздән артык кызылармеец атыла. Алар арасында 3 нче Кама полкы солдаты Үдиктән Закир Абдалов та була.

1919 елның 17 февралендә аклар Үтәй, II Әрҗән, Барданы алалар, кызыллар Озын Яланга чигенәләр. Һәм шушы көннән позицион сугышлар башлана. Ике якта да атышлар тынып торган арада политбүлекләр солдатлар арасында аңлату эшләре алып баралар, җирле халык белән җыелышлар үткәрәләр. Безнең район авылларында 2 нче армия политбүлеге каршында оештырылган 2 нче мөселман труппасы зур эш башкара. Локман Аитов җитәкчелегендә эшләгән бу труппа артистларын өлкән буын кешеләре 60 нчы елларда да әле яхшы хәтерлиләр иде.

Озын Яланда Сәгыйть Нуримөхәммәт (Нуриш бабай) улы Тляшев йортында моңарчы театр турында ишетеп тә белмәгән авыл кешеләре, солдатлар белән аралашып утырып, «Алдадык һәм алдандык», «Тегелгән кием» дигән спектакльләр карыйлар.

Труппа артистлары Хосәен Хәбибрахманов, Хәнәфи Габитов, оста биюче Мәстүрә Абканеева, җырчы Мөкәрәмә Әсфәндиярова, гармунчы Нәсыйбулла Чикиннар турында мин китаплардан укып, үзләре белән

очрашканчы ук Барда, Озын Ялан кешеләренең сөйләве буенча күп нәрсә белә идем. Артистлар театр инвентаре белән бергә бер тартма патрон, гранаталар да йөрткәннәр, һәркайсының кулында винтовка булган.

1969 елда труппа җитәкчесе Локман ага Аитов Казанда миңа менә нәрсәләр сөйләгән иде:

— Берзаман безнең гаскәрләр камалышта калды. Дошман 2нче армияне урап үтеп, Камага якынлашты. Без, аларны читтә калдырып, атларда чигенәбез. Шулай Бардада тукталдык та спектакль куеп ятабыз. Беренче пәрдәсен тәмамлап, икенчесенә күчкән генә идек, авыл очында атыш тавышлары ишетәбез. Кызу гына әйберләрне җыештырдык та чаналарга сикердек һәм Фоки-Богородски ягына юл тоттык.

Мәрьям апа Зәйнуллина икенче очракны хәтерли:

- Никольск дигән авылда «Деньщик сынатты» дигән спектакль куя идек. Авылның бер башында кызыллар, икенче очында аклар, ә уртасында без халыкка тамаша күрсәтеп ятабыз. Гәйнә авылларында ашаган май- каймакларның, бигрәк тә кайнатылган каймактан эшләнгән майның тәме әле булса авызда саклана кебек. Һәр авылда безне туганнары кебек каршы алалар, кунак итәләр. Шул авылларда күргәннәрне көндәлеккә язып барган идем, кызганычка каршы, шул сугыш юлларында югалттым шул...

Дүрт елга сузылган гражданнар сугышында Мәрьям апаның көндәлек дәфтәре генә юкка чыкканмы! Район территориясе өч айдан артык фронт зонасы булып торган. Тол һәм Барда елгасының уң як ярында Колчак армиясе, сул ягында — кызыллар. Әрҗән, Иске Чат, Кодаш авыллары бер караганда кызылларда, икенче карасаң — акларда.

Беренче алуларында тик бер Кодаш авылында колчаклылар авылның утызлап кешесен, шул исәптән комбед әгъзаларын, совет активистларын атып үтерәләр. Бардада, Әрҗәндә күпме алар!

Район территориясе икегә бүленеп калса да, авыллар арасында элемтә өзелмәгән. Фронт аша күзәтче-разведчиклар йөреп торган, кыюраклар төнлә белән туган- тумачасының хәлен белешеп кайткан. Моннан тыш авыллар арасында элекке болгарлар белән төньяк халыклары арасында барган «телсез сәүдә» үрнәгендә «телсез почта» эшләгән. Әйтик, Озын Яланда кемнең дә булса фронт аша ашыгыч хәбәр итәр нәрсәсе булса, ул аны хат итеп язып, Барда юлы өстендәге бер агач төбендә урнаштырылган әрҗәгә илтеп салган. Икенче яктан үз хаҗәте белән «почтага» килгән кеше, әлеге хатны алып кайтып, тиешле кешесенә җиткергән.

4-6 мартта Колчак һөҗүмгә күчә һәм шул көннәрдән Тол буе, бөтен Урал өчен кара көннәр башлана. Бер гаепсезгә җәзалап үтерелгәннәр саны йөзләр белән исәпләнә. Колчак армиясе штабы торган Каенавылда биш йөзләп кеше үтерелә. Җирләү мәшәкатен дә үз өстенә алырга теләмичә, җәза отряды аларны танымаслык хәлгә китерә дә сазга илтеп батыра. Шушы вәхшилекне башкару Кадыйр Адутов өчен бер уенга, мускул көчен сынауга әверелә: җәзалап үтерүгә хөкем ителгәннәрнең ул башта кылыч белән башын чабып өзә, башсыз гәүдә җиргә ауганчы, үзе мактанганча, «моментить насквозь живот», ягъни үле гәүдәнең корсагын айкап алырга өлгерә. Шулай ул күп саен ун-унбиш кешене җәзалый. Кычкырып аларны

атка тояп сазга илтеп батыралар. Каспавылга китереп, Әрҗәннән коммунист Гаделгәрәй Тимербулатов, комбед әгъзасы Шәрифхан Габдушев үтерелә. Бардада Кажмакты буенда комбедчылар Сафа Аптуков, Газиз Хөсәенов, Газый Кәримовлар шундый язмышка тарыйлар.

Бардада оккупация вакытында олыс башкарма комитеты җитәкчеләре күпләрне яшьләрен киметеп күрсәтеп Колчак армиясенә мобилизацияләүдән коткарып калалар. Шуны сизеп калып, волком рәисенә һәм секретаре Фазыл Назаровка суд оештыралар. Авылның халык яклы муллалары ярдәме белән генә яшь волком секретаре һәм рәисе зур җәзадан котылып калалар (Бу суд турында 5 томлык «Гражданнар сугышы тарихы» дигән китапта да укырга мөмкин). (18. 595 б).

Солтанайда Нажа Әлимовны ярлыларга теләктәшлек белдерә дип ат койрыгына тагып урам буйлап йортәләр, Рәхим мулла Ижбулатовны дүрт тапкыр атарга алып чыгалар. Кызыллар белән китеп өлгермәгән өяз комиссары Әмин Мансуровның үле гәүдәсен тереләрдән дә күбрәк җәберлиләр: үтереп аны Тол аръягына чыгарып ташлыйлар, аннан алып дуслары аны төнлә белән авыл зиратында җирлиләр, ләкин Гата Мансуров аны яңадан казып алдырта һәм елга арьягына чыгарып ташлата. Бу вәхшилек биш тапкыр кабатлана. Соңгысында кабердән казып чыгарылган сөякләрне Гата Мансуров сәнәк белән җыештыра һәм боера: «Шунда чыгарып ташлагыз!».

Минем утыз елдан артык җыйган материалларым арасында гражданнар сугышы чорына карагannары - иң күбе. Газета- журналлардан кисеп алынган мәкаләләр (алар арасында үзем язганнары да байтак) өч папка, истәлекләр белән шыплап тутырылган папкалар - тагын шул кадәр. Үдик авылында унбер кешенең, Бардада егермедән артык ветеранның сөйләвен язып алганмын. Һәркайсында - җәзалап үтерелгән кешеләр язмышы. Үдиктә 90 яшьлек Иртуганова Сәридә әби миңа нәрсәләр сөйләгән иде:

— Бер Уймуж ягында үтерелгәннәрнең генә дә чутына чыга торган түгел. Рәхия Мозаффарова белән сигез көн юдык шул мескенкәйләрдән салдырып алынган киемнәрне. Шунысы хәтердә нык калган. Барысы да акларга әсир төшкән солдатлар иде. Кызыллар әсир төшкәннәргә тимәделәр. Үзләре ягында сугышырга димләп карадылар да, ризалашмасалар, өйләренә кайтарып җибәрделәр. Ә болар әллә нинди кансыз кыландылар. Үдиктә фетнә конне үтерелгәннәрне, акларга әсир төшеп җәзаланганнарны төшемдә күреп, болай гына искә төшеп, әле булса дертләп китәм.

«Мин юкта ике энемне үтергәннәр»,- дип язып калдырган биографиясендә элекке Сараш олысы старшинасы батрагы Кронштад артиллеристы, 1917 елның октябрендә Рига вакыйгаларында катнашкан Әхмәр Яхин.

Колчак аккупациясе вакытында Оса төрмәсенең җиде камерасында Тол буе авылларыннан 370 кеше утырган. Һәркөн диярлек унбиш-егермесен Кама буена алып чыгып залп белән аталар, калган өч йөзен баржага тояп Пермьгә озаталар, аннан Төмәнгә... Аларның бик азы гына туган ягына әйләнеп кайту бәхетенә ирешә. Сараштан Ясәви Габдрахманов шундый-

ларның берсе иде. Өешнән кызыллар белән чыгып китеп, Красноуфим тирәсендә ул акларга әсир төшә, Тын океанга кадәр алар ягында сугышып бара, аклар белән бергә Японияга эләгә, аннан аларны Англиягә алып китәләр. Шунда ул Врангель армиясенә алына, Кырымда кызылларга әсир төшә һәм, бәхетенә, якташы А.И.Ездаков белән очрашып, ул аның язмышын үз өстенә ала,үзе белән туган ягына алып кайта.

1919 елның җәендә Кызыл Армия һөҗүмгә күчә. Составында 21 нче, 28 нче дивизияләр булган II армия 18 июньдә Каманы кичә. Иртәгесен, 19 июньдә, 28 нче Азин дивизиясе Елово һәм Коданны, ике көннән Акбаш һәм Уймужны, Үдикне, Әрәмәавылны азат итә һәм Тол буена килеп туктала. 23 июньдә дивизия элемтәчеләре Үдик-Бикбарда телеграф линиясендә Колчакның 4 нче Себер дивизиясенә бирелгән приказын эләктерәләр. Ә анда өч полк белән Тол буенда оборонада торырга, ә дүртенчесе белән кызылларга Каманы иркенләп кичәргә ирек бирмәү өчен Осага һөҗүм итәргә боерылган була.

Үдиклеләр ярдәме белән 249 нчы полк төнлә Җылы урман асты дигән урыннан Толны кичә һәм бер атышсыз дошманның биек Тол ярында урнашкан ут нокталарын зарарсызландыра, 700 ләп солдатын әсир итә, 2 пушкасын, 13 пулеметын, меңнән артык винтовкасын кулга төшерә. Бер сугышчысын югалтмыйча, бер полк дошманның ике дивизиясен стройдан чыгара һәм шушы батырлыгы өчен полк Мактаулы Кызыл Байрак белән бүләкләнә (17). Бу бүләкне полкка Сарапул пристанендә Н.К.Крупская тапшыра. Колчакны Екатеринбургка кадәр куып барган һәм шуннан көньяк фронтка күчерелгән дивизия командирларына байрак тапшырып, Надежда Константиновна шундый сүзләр әйтә: «Совет Русиясе хезмәт ияләре сезнең исемне ихтирам һәм горурлык хисе белән әйтәләр... Сез үтә дә кыюлык белән сугыштыгыз, арслandай сугыштыгыз» (19).

Азин дивизиясенең 200 дән артык сугышчысы, шул исәптән әлеге Тол арьягында эшләнгән батырлык өчен Азин үзе дә Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә, 17 командиры кыйммәтле бүләкләр ала. Бүләкләнүчеләр арасында Үдикнең азат ителүе уңаеннан митинг үткәреп, анда чыгыш ясаган һәм совет властен торгызу өчен калдырылган Сәгать Фәйзуллин дигән взвод командиры да була (17; 18).

Колчак чигенә, армиясе эри бара: ату белән куркытып җирле халыктан мобилизацияләнгән солдатлары урманнарга кача, күпләп әсир төшә. Колчакның Барда районын оккупациядә тоткан мактаулы Каппель һәм Ханжин армияләрен куа барып, Көнчыгыш фронтының II армиясе өч атнада 700 км.дан артык ара үтә. 24 июньдә шул армия составындагы Азин дивизиясе Тол буен азат итә һәм 28 июньдә Ирән буена җитә.

Ирән елгасы - күп сулы тирән елга, аны болай гына кичү мөмкин түгел. Аның аша салынган күперләрне яндырып, аклар аның биек таулы уңъяк ярында тирән окоплар казып, ныклап урнашканнар. Аннан аларга бөтен тирә-юнь уч төбендәге кебек, ә үзләрен һич күрә торган түгел. Саперларның елгага якынлашуы була, шундук таудан алар өстенә ургашын яңгыр яварга тотына. Шулай да Азин солдатлары югалып калмыйлар: күперләрне

төзәтү өчен материал әзерлиләр, һөҗүм итү өчен хәвефсезрәк урыннары карантыралар.

Межовка янындагы күперне ремонтлау өчен алар авылда бер бураны сүтәләр, төнге караңгылыктан файдаланып, аны яндырылган күпер янына ташырга тотыналар. Ләкин аларның бу эшен дә күреп алалар һәм пулеметлардан ут ачалар.

— Таки күрделәр бит, каһәрләр. Качарга кирәк моннан, — дип пышылдый шунда Платон Наумов дигәне, ачы сүгенеп.

— Качып кара! Азинның үзеннән пакет килгән, — дип җаваплый аңа Егор Лазарев. — Безнең комдивның, үзең беләсең, талканы коры: «үлсәң үл, ә кушылганны үтә». Безгә моны эшләү өчен бер юл бар: тауга менәргә дә кадетның (ягъни акларның) үзен домектереп, пулеметларын кулга төшерергә. Нәрсә ятырга монда? Йөзәргә беләбез...

Пулялар сызгыруы астында саперлар арасында шундый сөйләшү булып ала. Саперлар бу турыда артиллеристларга хәбәр итәләр. Алар пушкалардан залп бирүгә, саперлар суга сикерәләр, елганы йөзеп чыгалар һәм, куактан-куакка шуышып, тауга ук барып менәләр, акларның окопларына бәреп керәләр, пулеметчыларын кырып салалар, качарга уйлаганнарын үз пулеметларыннан атып куалар. Ул арада күзәтче-разведчиклар ярдәмгә килеп җитә. Саперлар янә елга буена төшәләр һәм үз эшләренә тотыналар.

Күперләр төзәтелә, санаулы сәгатьләр эчендә дивизия Ирәннең уң ягына күчерелә. Шуны тапкырлыгы өчен дивизиянең инженер- саперлар батальоны солдатларын Азин Кызыл Байрак ордены белән бүләкләүгә тәкъдим итә (17).

Атаклы Азин дивизиясенең инженер-саперлар батальонында Кече-Башап авылында совет власте урнаштыручыларның берсе Муллаяр Ибәтуллин да була. Шушы төндә ул авылына кайтып әйләнә, олыс советы башкарма комитеты рәисе Усман Сибгатуллинның, комитет әгъзаларыннан Әхмәтсафа Мозаффаров белән Хөсәен Гыйльметдиновларның кем тарафыннандыр (бусын авыл кешеләре унсигез елдан соң «Социализм юлы» газетендә басылган мәкаләне укып белерләр (20), акларга тотып бирелүләрен һәм атылуларын, гаиләсенең исән-имин яшәп ятуын белеп китә. Китә һәм шул китүеннән Екатеринбургка кадәр юл үтә, дивизия белән бергә Коньяк фронтка күчерелеп, Деникинга каршы сугышларда катнаша һәм, Царицыннан илле чакрым ераклыкта каты яраланып, Түбән Новгородка, госпитальгә озатыла. 1920 елның март аенда аңа бер айга өенә кайтып килергә рөхсәт ителә, озатучы ярдәмендә поездга утыртыла. Кызганычка каршы, Кече Башапның кызыл партизаны Муллаяр Ибәтуллинга бу юлы авылын кайтып күрү насыйп булмый: Әгерже станциясендә аның үле гәүдәсе поездан төшерелә һәм ул шунда җирләнә. Авылга аның документлары гына кайтарып тапшырыла. Беренче импери-

алистик сугыш елларында снаряд заводында эшләгән чагында рус хәрефләре белән үз телендә язып, Екатеринбургтан салган хатлары белән бергә алар аның улында, Кече Башан авылында оешкан «2 нче бишьеллык» артеленең беренче тракторчысы һәм шоферы Могаттар абзыйда (1903-1975), аннан аның улларында саклана.

14 июльдә азинлылар 21 дивизия белән бергә җиңүчеләр сыйфатында Екатеринбург урамнарын үтәләр һәм шуннан Царицын фронтына күчереләләр.

Авылларда яңа советларга сайлаулар үткәрелә, олыс башкарма комитетлары төзелә. Ләкин тыныч̧лап яшәү көннәренә ерак була әле. Урманнарда ак дезертирлар котырына, авылларга һөҗүм итүләр, совет активистларын үтерүләр, халыкны талаулар дәвам итә. Галич дачасыннан Әхмәр Адутов, Бардабаш урманыннан Кетов бандасы тынгылык бирми. Ике ел буена Оса ягыннан Егор Титов командасы һөҗүм итеп тора.

1919 елның көзендә (октябрь-ноябрь айларында) «партия атналыгы» үтә. Бу авыр чорда Шермейкадан А.А.Емельянов, И.С.Барашков, Е.М.Попова, Бардадан Ш.Т.Мәүлетов, Г.Г.Алдаров, Г.Г.Кузяшев, Сараштан Ә.Х.Сарманаев, Топлекаев, Мәүлетов, Үдиктән Хәким Акбашев, Т.А.Пугачева партиягә керәләр. 1918 елгы белән чагыштырганда районда коммунистлар саны ике тапкырга арта (8).

1918 елның җәендә билгеләнгән, ләкин эш башларга өлгерә алмаган укытучылар 1919 елның август аенда Осада яңадан конференциягә җыелалар. Ул мәктәп эшләреннән тыш надалныкка каршы көрәш, мәдәни-агарту эшләре турындагы мәсьәләләрне дә карый. Конференция Мөселман күчмә театрын оештыру турында карар кабул итә. Аның җитәкчесе итеп Муллануp Мушаков билгеләнә. Театрда аның хатыны Фәрхи Мушакова, укытучы, соңрак журналист Шәйхулла Тулвинский, Наилә Ягъфәрова, Хәдичә Ихсановалар уйный. Бераздан аларга бер төркем яшьләр кушыла. 1923 елда Хәдичә Ихсанова Казан театр техникумына укырга керә, аны тәмамлагач, байтак еллар Мәскәүдә эшчеләр театрында, Әстерхан театрында эшли, Ленинградта татар театрын оештыруда катнаша. Индустриализация чорында ул Каспий балыкчылары, Донбасс шахтерлары, Карелия, Мурманск, Ленинград өлкәләрендә торф чыгаручылар, корыч эретүчеләр алдында чыгышлар ясый. Һәм кайда гына булмасын, һәрчак Бардада театр булдыру хакында хыяллана. Боек Ватан сугышыннан соң Хәдичә апа Бардага кайта һәм калган бөтен гомерен театрга багышлый.

Кырык ел дәвамында ул тудырган сәхнә образларын Барда тамашачылары беркайчан да онытмаслар.

1921 елда Бардада шифаханә ачыла. Аның өч кабинетында авыруларны өч врач кабул итә, стационарында берьюлы 52 авыру (күз дәвалау бүлегендә 10, терапия бүлегендә 38, бала табу, гинекология бүлегендә 4) кеше ятып дәвалана ала.

Районда потребительләр кооперацияләре, кустарь-һөнәрчелек, авыл хуҗалыгы һәм кредит кооперативлары барлыкка килә. Х өяз партконференциясендә алардан Үдик кустарьчылар кооперативы иң әйбәте итеп күрсәтелә (8).

Промышленник Дәүләтша Алапанов яңадан эшкә тотына. Уллары Колчакка ияреп китәләр һәм кайтмыйлар, әтиләре күн заводын ходка җибәрә. Гарифулла Таһиров күн заводы този. Сарашта Фатих Мәүлетов патент алып, сәүдә эшенә керешә.

НЭП (яңа экономик политика) тиздән нәтиҗәләрен бирә дә башлый. Ләкин күп коммунистлар партиянең яңа политикасын аңламыйлар, капитализмга кире кайту дип кабул итәләр, партиядән чыгалар. 1922 елның 9 октябрендә узган Х өяз конференциясендә билгеләп үтелгәнчә, 1005 коммунисттан 671 е генә кала, аларның да 172сен өяз комитетында учетка алырлык булмый. Бер волость оешмасы - Үдик ячейкасы бөтенләй таркала, Әрҗән ячейкасының да хәле шәптән булмый - өяз конференциясенә делегат итеп җибәрерлек кеше табылмый.

Партиянең яңа политикасын аңлату өчен Уралга ҮКдан зур группа агитаторлар, агитпоезд һәм агитпароход җибәрелә. Осада тукталыш ясаган агитпароходта Бардадан бер делегация булып кайта.

Урыннарда партия эшен көчәйтү өчен Х өяз партконференциясе өяз комитеты әгъзаларыннан йөреп эшли торган инструкторлар булдырырга карар итә. Әрҗән районында (Барда, Сараш, Үдик һәм Печмень олыслары) ике инструктор билгеләнә: руслар белән эшләү өчен Федосимов,«нацменнар» белән эшләү өчен өяз комитетының бюро әгъзасы Солтан Абдусәләмов билгеләнә. Ячейкалар берләштерелеп, берләшкән ячейка секретаре итеп Газиз Кантуганов сайлана. Берләштерелгән өч ячейкадан Әрҗәндә үткәрелә торган җыелышларга Әрҗәннең үзеннән 6 (Атаманов, Биккулов, Айсин, Коряков, Шилов, Шаров), Сараштан 7 (Горбунов, Мәүлетов, Алдаров Габҗәлил, Кузяшев, Төплекаев Рәхим, Сарманаев Шәрифулла, Верзаков Н.И. - ячейка секретаре), Үдиктән 3 кеше (Барый Адутов, А.И.Тюлкин, Т.А.Пугачева) йөри.

1922 елның июнендә Әрҗән районы бетерелеп, ячейкаларда партия эшен алып бару түләүле политсекретарьларга йөкләтелә. Бу вазифага Әрҗәндә шул ук Г.Кантуганов билгеләнә, берникадәр вакыттан аны өяз

мәгариф бүлеге инспекторы, Искәвылда туып үскән Нурулла Айсин алыштыра.

1922 елның 21 июнендә өяз комитеты бюросы 20 кешедән торган агитаторлар коллегиясе булдыра. Һәр коммунистка Һичшиксез политграмота үтү бурычы йөкләтелә (8).

Озакка сузылган империалистик, гражданнар сугышларыннан соң ук яман ачлык еллары башлана. 1920-21 еллардагы корылык кешегә шиләр генә ашатмый, ел әйләнәсенә юкә, элмә агачын, җәен соякне онга әверелдерү, шикан, зәрәтә, чәберкәй (паратбаш) тамыры һәм сабагы, алабута... - ачтан үлмәс өчен барысы да ярый. Тик алар гына ач үлемнән коткара алмый: шешенеп үлгәннәрнең саны арткannan арта, күп авылларда алар җирләнмичә дә калалар, язын аларның сөякләрен урамнарда, авыллардан читтә, урманнарда да очратырга була. Бер Барда олысында гына 1922 елның 15 февраленә ачтан шешенгән 862 олы яшьтәге, 791 бала исәпкә алына. 1 февральдән шул ук 15 февральгә кадәр вакыт эчендә 258 кеше (160 олы яшьтәге, 90 бала) ачтан үлә. Җәен өлгермәгән ашлыкны тарттырып ашаудан «бормә чир» тарала (7; 21).

1921-1922 еллардагы ачлык — моңарчы күрелмәгән фаҗига була. Аның сәбәбе бер корылыкта гына да түгел. Моңарчы да, моннан соң да була яңгырсыз еллар. Ләкин бу кадәр халык кырылмый, чөнки табигатьнең тотрыксызлык очракларына дип игенче Мәнтәзиләрдә страх фонды булдыра, яңа уңышка кадәр дип үзендә запас калдыра. Яңа оешкан Совет власте кораллы продотрядлар көче белән бу запасларның берсе дә калдырылмый: гражданнар сугышы елларында Мәнтәзиләр буннан кала, кешенең үзе өчен калдырган бар игене продразверстка буенча тартып алына. Элекке кебек бурычка биреп торырдай кешеләр дә калмый. Нәтиҗәдә массовый ачлык, халыкның массовый кырылуы башлана.

Гражданнар сугышы, аңа ялганып киткән рәхимсез ачлык күп балаларны караучысыз калдыра. Мәктәпкә йөрисе урынга алар капчык асып хәер сорашып йөриләр. Мәктәпләрнең өчтән бере (35 проценты) эшләүдән туктый. 1921 елда өяз мәгариф бүлеге карары белән ятим балаларны җыеп балалар йортлары оештыру башлана. Үдиктә караучысыз калган ятимнәрне Мирзи Адутов йортына җыялар һәм аны балалар өчен приют дип атыйлар (7; 10; 22).

Шул ук елның августында Бардада балалар йорты оештырыла. Муллаҗан бай Корбангалиевтан тартып алынган ике катлы йортка мәктәп яшендәге илледән бала җыела. Аста - гомумторак, өстә - класслар.



**Рәсемнәрдә:** (сулда) Муллаҗан Корбангалиев йорты (Пушкин урамы, 1) 1921 елдан бирле Балалар йорты-коммуна мәктәбе. 1924 елдан утызынчы елларга кадәр райсовет башкарма комитеты, РКП(б) райкомы, утызынчы еллардан райпотребсоюз һәм райпромкомбинат дирекцияләре урнаша. Аста - егерменче еллардагы коммуна мәктәбе коллективы.



1922 елдан балалар йорты хезмәт мәктәбе- коммуна итеп үзгәртелә һәм Үдик приютындагы балалар да шунда күчерелә. Анда укыганнар (Солтанайдан Касим Исмәгыйлов, Аклыштан Минимулла Салихов, Төнгүктән Мукаев, Әрҗәннән Хөснимәрдән һәм Рәхмәтулла Сарманаевлар, Бардадан

Г.Мостәкыймов, Г.Шакманаев, Үдиктән Н.Батыров һ.б.) беренчеләр булып комсомолга керәләр. Соңрак без алардан күпләрне совет һәм партия работниклары, алдынгы игенчеләр һәм эшчеләр сафында күрербез.

## Чыганаклар:


1. Район ветераннары Ә.Г.Батыркаев, Б.Адутов, Е.И.Назаров, А.П.Ездаков хатирәләре.

2. Упрочение Советской власти в Пермской губернии. Документы и материалы. Пермь, 1966.

3. Десять лет Советской власти в Сарапульском округе. Ижевск, 1927.

4. Оса музее материаллары һәм Оса ветераннары сөйләүләреннән.

5. В.И.Ленин. Полное собрание сочинений. 34 том.

6. Всероссийское учредительное собрание (1917 г. в документах и материалах). М.- Л., 1930.

7. Б.Адутов, К.Х.Адутов, Ә.Г.Батыркаев, М.Мозаффаров, Суфый һәм Хәйдәрхан Ибраһимовларның хатирәләре.

8. Пермьнең яңа тарих һәм җәмәгать оешмалары архивы (элекке партархив). Фонд N 754.

9. С.М.Кәбированың (Казан) шәхси архивыннан.

10. Барый Адутов, Гали Габбасов, Фазыл Назаров, Хәдичә Ихсанова истәлекләреннән.

11. Г.С.Абдусаләмов (Ташкент) истәлекләре.

12. «Известия Осинского уисполкома Совета крестьянских, рабочих и солдатских депутатов». 1918.

13. Н.Д.Веретенников. 21я Пермская. В кн. «В пороховом дыму». Пермь, 1961 һәм авторның үзенә сөйләгәннәреннән.

14. П.И.Садилов (Уинск районы, Красногорка авылы) истәлекләре һәм шул истәлекләр нигезендә үзем язган мәкалә («Партизаннар командиры». «Таң». 1967, 26 август).

15. «Известия Пермского губисполкома». 1918.

16. П.И.Деткин. Очерки партизанского движения в Чернушинском и прилегающих к нему районах. ВКП(б)нең Чернушка райкомы басмасы. 1932.

17. Н.Кондратьев. Начдив Владимир Азин. М., 1968; В.Ладухин. Азин. М., 1967. Владимир Азин. Ижевск, 1958.

18. История гражданской войны. В пяти томах. Том 3. М., 1957.

19. Н.А.Кощеев. Н.К.Крупская в Прикамье. Ижевск, 1966.

20. Суд карарын хуплыйбыз. Социализм юлы. 1937, 14 июль.

21. С.Н.Назин. Барда районында сәламәтлек саклау тарихы. Реферат. 1980.

22. Р.Тюмисова-Мөхәммәдьярова. Тарих сәхифәләре. Таң. 1994, 6 апрель; Фаика Юсуфкулова. Тарих дөрес яктыртылсын иде. Таң. 1994, 2 февраль.

# IX. Гәйнә олысы район булып оешкач (1924- 1928 еллар)

1917 елда Октябрь революциясе җиңеп, совет власте урнаштырыла башлагач та яңа хакимиятнең губерналар, өяз һәм олыс кебек эре территорияләрне буйсындырып тота алмаячагы ачыклана. Һәм тоталитар система мәнфәгатьләрен сакларлык бүленешне эзләү башлана һәм бу эзләнү 1923 елга кадәр дәвам итә.

1923 елның апрель аенда мәсьәлә РКП(б)ның XII съездында тикшерүгә куела. СССРның административ-хуҗалык бүленешен үзгәртү реформасының төп бурычы, дип билгеләнә съезд кабул иткән резолюциядә, Ленинның «Рабкринны ничек үзгәртеп корырга», «Аз булса да яхшырак булсын» дигән әсәрләрендә бәян ителгәнчә, совет аппаратын гадиләштерү, арзанайту һәм массаларга якын торган органнарга әверелдерү (1.).

Районлаштыру реформасы башта ике төбәктә - бер промышленность һәм бер авыл хуҗалыгы өстенлек иткән крайда сынау үткәрергә карар ителә. Промышленность төбәге итеп безнең Урал регионы сайлана. 1923 ел 3 ноябрь СССР ЦИК карары белән Екатеринбург, Пермь, Чиләбе һәм Төмән губерналары территориясендә Урал өлкәсе булдырыла. Өлкәдә 15 округ, шул исәптән Сарапул округы, 205 район, 3100 авыл советы төзү карала. Декабрьдә Советларның I (IY) өлкә съезды үткәрелә, урыннарда районнар оештыру буенча оргкомитетлар төзелә һәм эшли башлый (2.183 б.).

Берничә олысны берләштереп, районнар оештыру кинәттән генә туган идея булмый. 1918 елның көзендә үк әле, ягъни совет власте урнаштырылып ярты ел үтүгә, Оса өязе җиде кече районга (подрайонга) бүленә. Тол буенда урнашкан Сараш, Әрҗән, Үдик һәм Шермейка олыслары җитәкчеләре башта Үдиктә, ә берникадәр вакыттан соң Әрҗәндә җыелышып, Әрҗән кече районы оештыру турында килешәләр. 1921 елда районнар төзү буенча проект әзерләнеп, Үдик, Акбаш, Байавыл, Каенавыл, Искир Оса районына, Барда, Озын Ялан, Казанка, Аклыш, Митроха, Печмень, Зязелга, Шермейка, Сарашны Әрҗән районына кертү карала. Дөрес, болары әле чын районнар түгел, ә партия әгъзаларын берләштерүче төбәкләр генә. Шулай да моны район чикләрен билгеләүдә беренче адым итеп карый алабыз.

РКП(б)ның XII съезды резолюциясендә район чикләре элемтә уңайлыкларын һәм халык массалары мәнфәгатьләрен исәпкә алып билгеләнә дигән бер пункт була. Шушы пунктка таянып, Үдик олыс советы

үзен Оса районына кертүне сорап карар чыгара. Шермейка олысы активистлары Күңгер районына, Аспа кече районына караган Печмень олысы активистлары Рябки (Чернушка) районына кертүне сорыйлар. Барда районын оештыру буенча оргкомитет, партия өлкә комитеты ризалыгын алып, бу олысларда махсус сессияләр үткәрә. Оргкомитет рәисе С.А.Абдусәләмов һәр өч совет депутатлары алдында административ- хуҗалык бүленешенең яңа принциплары турында доклад белән чыгыш ясый. Шушы сессияләрдән соң Үдиктән бер төркем активистлар (волбашкарма комитет әгъзалары һәм коммунистлар) өяз җитәкчеләренә Барда райкомына җаваплы секретарь итеп Абдусәләмовны куюны сорап мөрәҗәгать итәләр (3).

1924 ел башында Барда район советының I съезды үткәрелә. Райсовет башкарма комитеты рәисе итеп Газиз Әюп улы Кантуганов, җир бүлеге мөдире итеп И.М.Ханжин, мәгариф бүлегенә Ә.Г.Батыркаев билгеләнә. Әндәр ага бер үк вакытта сәламәтлек саклау бүлеге мөдире вазифаларын да үтәргә тиеш була (4).

**Газиз Әюп улы Кантуганов** (1893-1968) I Әрҗәндә ярлы крәстиән гаиләсендә туа. 1914 елда армиягә алына, 1917 елның маенда Герман фронтын ташлап кайта, 1918 елның мартында кызылгвардиячеләр отрядына языла. Һәм РСДРП(б) өяз комитеты, Мөселманнар комиссариаты кушуы буенча байларга контрибуция салуны үткәрә, олыс советларының эшчәнлеген тикшерә. Август аенда губерна Мөселманнар комиссариаты боерыгы буенча милли полк оештыра, 21 нче санлы Мөселман полкы исеме бирелгән бу полк гражданнар сугышында Колчакка каршы сугыша, III армия составында бер тапкыр безнең район территориясендә барган алышларда да катнаша. Г.Кантуганов полкның комиссары була.

1920-1923 елларда ВЧК һәм ОГПУда, Мәскәүдә югары партия мәктәбен тәмамлаганнан соң партия Үзәк Комитетының Башкортстан АССР буенча контроль комиссиясе коллегиясендә эшли. Аның бу еллардагы эшчәнлеге турында Башкортстан матбугатында күп мәртәбәләр язылды.

1921 елдан Г.Кантуганов берләштерелгән Әрҗән партия ячейкасы секретаре, өяз ЧКсының беренче рәисе, 1924-1927 елларда райсовет башкарма комитеты рәисе. 1937 елда кулга алына.

1924 елның 1 апрелендә I Әрҗәндә шул ук элекке волбашкарма комитет бинасында I район партия җыелышы үткәрелә. Анда 26 коммунист (24 партия әгъзасы, 2 әгъзалыкка кандидат) катнаша.Җыелыш район комитетын сайлый. РКның җаваплы секретаре итеп бертавыштан Солтанморат Абделман улы Абдуләсәмов сайлана (4, 8, 9.).



Абдусәләмовлар гаиләсе

**С.А.Абдусәләмов** (1871-1937) — Ырымбур губернасының Стәрлетамак өязе Ямансар авылында (хәзер бу авыл Башкортстанның Стәрлебаш районына керә) ярлы крәстиән гаиләсендә туа. Сигез яшьтән байларда көтү көтә, 1892-1895 елларда армиядә хезмәт итә, унтер-офицер званиесендә демобилизацияләнә. Казанда укытучылар әзерләүче семинариядә укый, 1917 елның җәенә кадәр башта I Әрҗәндә, аннары Искәавылда (Карьяуда) земский школада балалар укыта.

1905 елдан Ашап һәм Сүде земский школалары укытучылары В.С.Кибардин, В.С.Лобачев белән яшерен революцион эшләрдә катнаша. Сул эсерлар партиясенә керә. Осада совет власте урнашкач, РСДРП(б) сафына керә, губерна һәм өяз мөселман комиссариатларын оештыруда актив катнаша, өяз мәгариф бүлеген, өяз партия комитетының татар-башкорт секциясен җитәкли, өяз башкарма комитеты рәисе урынбасары вазифаларын үти.

Гражданнар сугышы чорында РКП(б)ның Казан губерна комитеты аны Мамадыш шәһәренә ревтрибуналда эшләргә җибәрә. Эвакуациядән кайткач, элекке вазифаларын үти. Советларның X Бөтенроссия, I Бөтенсоюз съездларында делегат булып катнаша. 1923 елдан Сарапул округ комитетының милләтләр эше буенча бүлек мөдире, бер үк вакытта округ мәгариф бүлеге инструкторы була. 1924-1927 елларда Барда райкомы җаваплы

секретаре, 1927-34 елларда Оса районының КК-РКИ рәисе урынбасары һәм партследователь (7).

Абдусәләмовның 4 улы, 5 кызы булып, иң олкәне Гәрәй (1899-1937) хезмәт биографиясен өяз үзәгендә ЧК хезмәткәре булып башлый, гражданнар сугышы чорында Көнчыгыш фронтта II армиянең махсус бүлегендә, 1920-1921 елларда фронт нацменнары эше буенча бүлек начальнигы урынбасары. Шушы ук фронтта Абдусәләмовның ике кызы (Зәйнәп һәм Сәлимә) халыкка һәм солдатларга культура хезмәте күрсәтү эшен оештыручылар булып йөриләр.

Гражданнар сугышы тәмамланып Осага кайткач, Гәрәй Абдусәләмов өяз гәзите «Известия» мөхәррире, губерна мәгариф бүлеге мөдире урынбасары, РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты матбугат бүлекчәсе мөдире, Таҗикстан ССРның агарту эшләре халык комиссары урынбасары, Дүшәмбе электростанциясе директоры. 1937 елда кулга алына һәм шул ук елны атып үтерелә.

Яңа оешкан партия райкомы һәм райсовет башкарма комитетының беренче эше авыл советларына сайлаулар үткәрү була. Моңарчы эшләп килгән биш олыс советы урынына 23 авыл Советы сайлана (17 се татар, 6 сы рус авылларында) (3.Эш N10).

Сарапул округына караган районнар арасында Барда районы партия оешмасы иң аз санлылардан була. Бу вакытка округта 1133, өяздә 378 партия әгъзасы, 127 әгъзалыкка кандидат булып, шул исәптән Оса районында 109, Аряж (Куеда) районында 36 коммунист булса, Барда һәм Елово районнарында 22 шәр генә коммунист исәпләнә.

Октябрь призывы чорында 45 кеше кандидат итеп алына, партия әгъзаларының саны 20 гә җитә. Партиягә бу чорда кергәннәрдән Үдиктән Газиз Абдусәләмовны, Кави Абраковны, Бардадан Камал Шакманаевны, Абдулла Нурсубин, Гәрәй Мөстәкыймов, Әрҗәннән Габделбәр Ибраев, Ваһап Савинов, Гәрәй Сакаевларны күрсәтергә мөмкин. Бер ел эчендә биш яңа ячейка, шул кадәр үк кандидатлар группалары барлыкка килә. Ләкин яңа алынганнар арасында без интеллектуаль көчләрне, сәясәтне аңлап эш итүчеләрне бик аз күрәбез. Биредә дошман көчләргә каршы көрәшәбез дип, Ленинга якын торган Троцкий, Зиновьевларга карата башланган шау-шуның тискәре роль уйнавы сизелеп тора. Партиягә яңа алынганнарның байтагы күп тә үтмәстән партиядән чыгарылалар яисә аннан үзләре читләшә (2.Гл.III, § 4; 8. Эш N9).

Район оешканда РКСМ әгъзаларының саны 124 булса, бер елдан алар ике йөзне арта. Җиде профсоюз оешмасында (мәгариф, мәдәни-агарту, авыл хуҗалыгы, урман эшчеләре, сәүдә, дәүләт учреждениеләре, медицина һәм почта эшчеләре) 366 әгъза булып, алар производствода эшләүчеләрнең 80 процентын берләштерәләр.

Яңа төзелгән районның экономикасы түбәндәге саннар белән характерлана: исәпкә алынган җирләрнең мәйданы 127.912 га, шул исәптән 42.254 га сөренте җир, 1357 га чабулык, 49.609 га урман тәшкил итә.

Районлаштыруга кадәр Тол буе бассейны олыслары (Үдик, Барда-Әрҗән, Сараш, Шермейка һәм Печмень олыслары) составында булган 14 авыл башка районнарга күчерелә. Барда олысындагы Бардабашка (154 хуҗалык, 650 кеше), Маремья-Каенлык (71 хуҗалык, 338 кеше), Куштамак (93 хуҗалык, 511 кеше), Ятыш-Бараба (63 хуҗалык, 358 кеше), Суганка, Чулпаныш (60 хуҗалык, 268 кеше), Кече-Кашкалак (40 хуҗалык, 176кеше); ул елларда Үдик олысында, соңрак Уймуж авыл советында йөргән Ольховка—Уймуж-Баш (17 хуҗалык, 61 кеше) - Оса районына, Сараш олысындагы Дектярка (4 йортта 21 кеше), Чәпчелде (9 йортта 40 кеше), Ермия буендагы Талый Ключ (5 йорт, 27 кеше) - Чернушка районына, Толбаш- Сосновка (71 йортта 331 кеше) 1965 елда Уинск районына күчерелде. 1908 елгы мәгълүматлар («Список населенных мест Пермской губернии») буенча бу 14 авылда 548 йорт-хуҗалык булып, анда 2452 кеше яшәгән.

1924 елда район буенча арыштан 76.278 центнер, сабан - ашлык культураларыннан 4.253 центнер, һәр гектардан уңыш 7 центнер җыела. Икенче елны бөртекләрдән тулай җыем 120 мең центнерга җитә. 1926 елда яңгыр күп явудан 58 процент чәчүлекләр харап була.

Районда бу чорда 9.260 аерым хуҗалык булып, алар 5790 ат, 7300 сыер, 1815 тавык, 1887 каз һәм үрдәк асрый. 1923 елда йорт саен йөреп үткәрелгән тикшерү буенча 4,1 мең крәстиән хуҗалыгы (45 процент) атсыз, халыкның яртысыннан күбрәге (5.685 йорт-хуҗалык) ярлы, 3.314 хуҗалык урта хәлле, 138 е - бай (зажиточный) һәм 23 хуҗалык кулак булып исәпләнә. 7,7 шәр дисәтинә җир биләгән башкорт-татарлар берәр генә дисәтинә җире булган руслардан күпкә начар яшиләр, дип язылa тикшерү материалларында (8;9).

Район партия оешмасы авыл хуҗалыгын күтәрү һәм халыкның материаль хәлен яхшыртуны үзенең төп бурычы итеп саный, моңа ирешү юлларын Ленинның кооперацияләү планын тормышка ашыруда күрә.

1924 елның май аенда РКП(б)ның Урал өлкә комитеты татар-башкорт авылларында кооперацияләү мәсьәләсен карап тикшерү өчен махсус киңәшмә җыя. Анда катнашучылар районга кайткач, пленум үткәрелә, кооперацияләү эшен җәелдерү турында киң карар кабул ителә һәм аны үтәү өчен урыннарга вәкилләр җибәрелә. Эш зур авырлыклар белән бара. Шулай да НЭП чоры яңа төзелгән районга күп үзгәрешләр алып килә.

1924 елның сентябрендә район үзәге Әрҗәннән Бардага күчерелә.

1926 елда дистәгә якын авылда (Зязелга, Федорки, Шермейка, Щипа, Батырбай авылларында) төрле форма кредит ширкәтләре барлыкка килә. Болардан тыш Шермейкада кортчылар ширкәте эшли, бер мең чамасы шәхси хуҗалыкларны берләштергән 4 машина ширкәте, ашлыкны сортларга аеру белән шөгыльләнүче 18 пункт оештырыла. Җитештерү кооперативлары төзү юлында беренче адымнар ясала. 1922 елда ук әле Шабаркада Илья Данилович Гусев инициативасы белән коммуна төзелә. «Проснись, бедняк!» исеме белән йөртелгән бу коммуна Родион Яковлевич Гусев (конюшня командиры), Матвей Семенович Турпанов, Афанасий Ананьевич Крылов, Петр Кириллович Бойцов, Иван Егорович Каракулов

гаиләләрен берләштерә. Соңрак аларга Шабаркадан күмәк хуҗалык төзүчеләрнең берсе Ефим Иванович Баженов һ.б. кушыла (8;9;13).

Коммунарлар өч ат, алты баш сыер, бер нәсел дуңгызы белән эш башлыйлар. Күгия һәм Шабарка общиналарының буш яткан җирен эшкәртеп чәчәләр, шунда ук хутор торгызалар. Дәүләт аларга дүрт сабан, сигез тырма, чәчкеч һәм җилгәргеч бирә, ат заводыннан Ордын токымлы атлар сатып алырга ярдәм итә. 1925 елда коммунарлар ике катлы сигез фатирлы йорт салып керәләр, илле баш мал сыешлы абзар, ике амбар һ.б. төзиләр. «Фордзон» тракторы сатып алалар. Районга беренче кайткан бу тракторда Василий Афанасьевич Крылов эшли. Шабарка коммунарлары районда беренчеләр булып 1925 елда клевер чәчәләр (10;13).

1926 елда Зязелга авыл Советының Сибирка пүчинкәсендә дә артель-коммуна оештырырга омтылыш ясала, ләкин аз санлы булуы сәбәпле ул рәтле эш күрсәтә алмый һәм тарала.

Адыевка авылында да коммуна оешкан иде дипючеләр бар. «Урал» исемен йөрткән бу коммунада 9 әгъза булып, аның рәисләре булып Яков Селиванов, Осколков, С.Ушаковлар эшләде, дип сөйли Дементьев Печменьнән. Ләкин бу коммуна турында шуннан башканы ишеткән булмады.

Озакка сузылган империалистик сугыш, революция, гражданнар сугышы нәтиҗәсендә нык хәлсезләнгән, тәҗрибәле, эшне оештырып йөрердәй белгеч-осталарыннан мәхрүм ителгән авыл тиз генә тернәкләнеп китә алмый. 1927 елда сыер малы буенча район 1916 елгы дәрәҗәгә җитә язып калса да (92 процент), төп күрсәткечләр бик түбән була: 32.698 гектар җирнең тик 48,6 проценты (19.612 гектары) эшкәртелеп чәчелә, атлар саны 67,8 процент дәрәҗәсендә кала. Кооперативлар дәүләткә нибары 990 пот иген җыеп саталар. Сәбәбе - авыл халкының яртысыннан күбрәге (9.269 хуҗалыкның 5.686 сы, яки 59,1 проценты) икмәк белән үзен-үзе дә тәэмин итә алмый. 49 процент тәшкил иткән атсыз крәстиәннәр җирләрен хәллерәкләргә арендага тапшырырга, үзләре эш эзләп шәһәрләргә, шахта, промыселларга китәргә мәҗбүр булалар.Артта калган авыл хуҗалыгын, беренче чиратта игенчелек белән терлекчелекне кузгатып җибәрү өчен НЭП чорында байтак чаралар күрелә: промышленность техника эшләп чыгаруны арттыра бара, кадрлар белән ярдәм итә. Эшне планлы һәм фән нигезендә алып бару өчен яңа оешкан райсовет каршында земотдел (башта ул земский стол дип атала) булдырыла. Аның мөдире Әхмәдуллин, өлкән агроном Искәндәр Шәфиев, ветфельдшер А.Поплоухин беренче эш итеп Сараштагы җир эшкәртү ширкәте каршында агрономик участок булдыралар. Байтак еллар бу участок бөтен Уралга үрнәк ролен үти. Өч басулы чәчү әйләнешләре күп басулыларга әверелдерелә. 1923 елда Сараш ширкәте районда беренче булып 125 пот минераль ашлама куллана. Җир эшкәртү ширкәтләренең саны дистәне-узып китә, аларның һәркайсы күргәзмә- үрнәк участоклар да булдыргач, районга 3 мең пот минераль ашлама («сукыр хәсфәт») кайтартыла һәм кулланыла.

Бу еллардагы Тол буендагы мәйданнарда агроном Шәрифҗан Арзыев үстергән эре турнепс һәм помидор бөтен тирә-юньне таң калдыра. Алар турында райком секретаре Солтан Абдусәләмов окружком пленумнарын-

да, конференцияләрдә сөйли, 1925 елда алар Бардада I район авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә күрсәтелә.

Земотдел белгечләре бер үк вакытта авыл хуҗалыгын планлаштыручылар һәм крәстиәннәр өчен киңәшчеләр дә, лектор һәм төрле түгәрәкләр оештыручылар да булалар. Бер 1926 елда гына бүлекнең 3-4 белгече игенчелекне фән нигезендә алып бару турында 144 лекция укый, 20 түгәрәк оештырып, үзләре үк анда дәресләр үткәрәләр. Алар җитәкчелегендә 37 ат кочыру, 10 сыер каплату пунктлары эшли. Сарашта терлекләрне үрнәк ашату, Мингәрдедә терлекчеләр ширкәте оештырыла.

НЭП чорында Совет хөкүмәте башкарган иң зур эшләрнең берсе итеп крәстиәнне җиргә якынайту сәясәтен үткәрүне санарга кирәктер. Патша Русиясе үткәргән Столыпин реформасы чорында район территориясендә утыз өч авыл-хутор барлыкка килсә, НЭП чорында (1922-1927 елларда) районда 50 яңа авыл-хутор барлыкка килә.

1922 елда Шабарка кешеләре «Проснись, бедняк!», Подказармино, Ключики, II һәм III Низовскийлар, Зверевка, Яланчик, Дектярики хуторларына, Шермейкадан Гребневка, Белоусовка, Плотиново, Аникино, Нестерево, Шачково (барлыгы 8 авыл-хутор), Антуфьево, Зайцево, Печмень тирәсендә тыгыз бөҗра хасил итеп унбишләп яңа авыллар барлыкка килә. Таныплылар — Игәткә, Күгиядән — Алтынайга, Югары Күгиягә, Әрҗәннән Кызылъярга, Үтәй-Башка бүленеп чыгалар (10; 11; 12).

50 нче елларда байтак еллар колхоз рәисе булып эшләгән Әхмәтсафа ага Туйгилдин бу яңа авылларның барлыкка килүен болай күзаллый:

- Ул елларда Бухарин турында күп сөйлиләр иде. Ул крәстиәнгә баерга куша, җирне яңача файдаланырга өнди, дип сөйлиләр иде. I Әрҗәннән башта 12 гаилә (Мөрсәлимов, Нурый абзый, Алапанов Галишан, Ибраев Сәгыйть, Хәсәнов Сәләхетдин, Хәлилов Габдулла, Рангулов Хәсән һәм Галимҗан абзыйлар, без - Туйгилдиннар ике гаилә) районнан рөхсәт алып, 1928 елда Сөҗән белән Бөрежле арасына, Иске Ялан дигән җиргә күчеп утырдык. Елганың бер ягында Сараш кешеләренең чәчүлекләре, икенче ягында - элекке Гата хәзрәт җирләре. Соңрак безнең янга тагын унлап гаилә килеп кушылды. Колхозлашу башлангач, НЭП чорында барлыкка килгән авылларны барлыкка китерү дөрес политика булмады, дип сөйли башладылар. Күп тә үтмәстән берничәсе кире таралды. «Проснись, бедняк», мәсәлән, нибары җидеме-сигезме ел, Шачково, Пальники, Озын Ялан ягындагы Баршынды хуторлары да шул чама гына яшәп калдылар. Шермеинск белән Артуфьево арасындагы Зязелга 1930 елда ук инде Иске Чат ягына күченеп, Вәриз авылын барлыкка китерде. Аннан ерак түгел Ишим (Чириз) елгасының башында Чириз авылы төзелде.

Бу чорда барлыкка килгән авыллардан иң эреләре саналган, 20-30 йорттан торган Сыркаеш (1924—1976), Кызыльяр (1924—1970), Яушкыр (1924—1970), Карагаш (1924—1974), Мингәрде (1924—1964), Игәт (1924—1974) һ.б. авыллар да безнең «Яңа тормыш» язмышын уртаклаштылар.

Шулай итеп, зур өметләр белән, озын тарихлы борынгы авыл-биләмә җирләренә күчеп утырсалар да, яңа хакимиятнең яңа ихтисади сәясәтенә

таянып, яңа тормыш корырга ниятләнгән авыллар янә тотрыксызлыкка, күченеп йөрүләргә дучар ителәләр.

— Сплошной эксперимент булды инде безнең тормыш. Сынау арты сынау үткәрделәр. Ни искечә яшәргә ирек бирмәделәр, ни яңа дигәненә күнектерә алмадылар. Колхоз бер оешты, бер таралды. Өченче елында ук иң нык эшләгәннәрне кулакка чутлап, йортларыннан куып чыгардылар, сөргенгә сөрделәр, бер гаепсезгә атып үтерделәр. Әнә шул чакта башланды крәстиәннең җиргә, эшкә карашы кире якка үзгәрүләр, дәүләтнең бетә башлавы. Бүгенге таркалу ул шул чакта башлаганның дәвамы гына (11).

Шундый нәтиҗәгә килә элеккеге колхоз рәисе: Яңа чорда яңа тормыш корам дип, үзгәреш арты үзгәрешләр кичереп тә һич мантый алмаган колхозының авылдан авылга күчереп йөртелгән идарәсенә ияреп, өзгәләнеп гомер кичергән Әхмәтсафа аганың сөйләгәннәренә бүген күпләр кул куяр иде дип уйлыйм. Озак сөйләштек без аның белән. Сөҗән авылының «Яңа тормыш» хуторыннан күченгәннәр урамында иртәнге якта башланган әңгәмәбез аракы әрҗәләреннән бүселергә торган кибете янында караңгы төшкәндә генә тәмамланды.

— Әнә шул шайтан суы белән агулана халык, авылда эшләр кеше калмады диярлек, без картайдык, эшләрдәйләр алып-сатарга әйләнде.— Шул ямьсез уйлардан арынырга теләгәндәй икебез дә таудан түбәнгәрәк төшереп, яңартып салынган мәктәп бинасына карап сүзсез калганбыз. Сүзебез юк, чөнки беләбез: ул мәктәп тә яңа ук түгел, утызынчы елларда мулласыннан мәхрүм ителгән мәчет бүрәнәләреннән оелган ул. Заманча яңа булып күренсен өченгә кагылган такталары астында тугызынчы дистәне ваклап барган Әхмәтсафа аганың яшьлеге, авылның абыну-сөртенүле үткәннәре ята.

НЭП чорында барлыкка килгән барлык авыллар да 60-70 нче елларда перспективасыз дип табылды һәм аларны колхоз үзәкләренә күчерергә карар кылынды. Ләкин күпчелек халык күченеп тормады, ә йортын сатып шәһәрләргә, район үзәкләренә китеп барды. Авыл янә байтак көчләрен - җир улларын югалтты. Яңа экономик политика дөньяга китергән 50 авылдан бүген нибары бишесе - Талканлы, Сарымьяда, Өчкул һәм Әмировка авылы исән. Тәмам бетә язган Игәт авылы янә терелеп килә.

Әмиров авылы (Әмировка)... Күчтәнти - Карман юлы остендәге бер урамнан торган авыл. Бүген анда 33 йорт, 62 кеше. Бу авылның барлыкка килүе кызыклы. Печмень зурая барган саен аның кешеләре Күчтәнти җирләренә күз салалар. Бәрелешләр дә булгалап ала. 1927 елның җәендә Күчтәнти кешеләре шул яктагы чәчүлек җирләрендә булган бер ыгы-зыгыдан соң үзара киңәшәләр дә кыйракларны яңа урынга күчеп утырырга ризалаштыралар. Җыелышып, бер төн эчендә итек басучы Рәхим Әмировның йортын күчереп куялар. Таң атканчы балчыктан мичен сугып, морҗасын да чыгарып куялар. Урыслар җирләрен киңәйтергә дип килсәләр, морҗадан төтен чыгып ята, йорт тирәсендә кешеләр мәш килә. Йортның түбәсе ябылып, морҗасы чыгарылган икән, кем булсаң да, синең аңа кагылырга хакың юк, дәгъва белдерә алмыйсың.Күчтәнти авылы өчен «чик сакчысы» булып утырган Әмиров янына тартмый-сузмый шул ук

жәйдә Гозәеровлар, Сафаров гаиләсе, Рахмангуловлар, Зөбәеровлар күченә (12)

Әмировкадан да иртәрәк Карман белән Толбаш ягында Баганалы-Кул (Крутой Лог) дигән авыл барлыкка килә.

Печменьлеләр дә тик ятмый, аларга да җирсез яшәве кыен. Алар төзелеп яткан яңа авылны урап үтеп, Сайгатка һәм Ореховка авылларына нигез салалар. 1965 елга кадәр яшәп калган бу авыллар бүген юк инде, урынарын усак-каен басып бетергән. Сарымъяда ягындагы Александровка авылының менә дигән чәчүлек җирләрен дә агач басты. Ә колхозга берләшкәндә бу өч авылның һәркайсында егермеләп йорт булгандыр.

Хәтердә, минем комсомол райкомында эшләп йөргән чорым иде. 1952 елның кышында булса кирәк, райком ашлама туплау, басуларга тирес чыгару үнкөнлеге игълан итте һәм мине Азин исемендәге шушы колхозга уполномоченный итеп җибәрде. Ул елларда авылларда бер эш тә (чәчү, урып-җыю, заем тарату һ.б.) районнан вәкилсез эшләнми иде. Хәтта бер колхозга, бер авылга икешәр-өчәр кеше җибәреләә иде.

Барып төштем авылга, кердем колхоз идарәсенә. Рәис шундук бригадирын һәм ат карауучысын чакыртып китертте, һәм без, бик зур эш кырган кебек, иртәгедән ничә ат җигеп, күпме тирес чыгарыласын «планлаштырырга» тотындык.

- Биш атыбыз бар, өчесен җигәргә була, икесен...- шулай диделәр дә бригадир белән конюх бер мәлгә сүзсез калдылар, ә без котәбез. - Искеләреннән җыештырсак, тагын бер чана әтмәлләргә булыр иде дә, тик камыт каян табабыз?

Конюх белән бригадирның карашы рәистә.

- Чернушкада бар диләр...

- Барын бар ла ул, үзем дә күреп кайткан идем. Акчасын каян табарга?

- Камыт алырлык та акчагыз юкмыни?

- Юк шул. - Тагын тынлык.

- Эх-ма-а, отчет җыелышын үткәрми торган булсак, камыт алырлык кына акчабыз бар иде лә ул. Булган бар акча иптәш Сталинга котлау телеграммасы сугуга китте.

Аңлыйм, биш кенә җигәрлек аты булып, аның да икесенә кидерергә камыты булмаган колхозның җитәкчеләре моны үзләре уйлап чыгармаганнардыр. Моны минем кебек уполномоченный итеп райкомнан җибәрелгән берәү әшләткән. Фамилиясен, тотылган акчаның суммасын да әйткәннәр иде, онытылган.

Партиянең бер карары белән тудырылган, икенчесе белән юкка чыгарылган Сайгатка, Ореховкаларның кайдадыр исән-сау яшәп яткан кешеләре Сталин үлгәннән соң мәзәк итеп сөйләнеп йөргән бу хәлне хәтерли торганнардыр.

Биш ат асралган абзардагы тирес икеме- өчме йөккә ике тоягдән артмады. Аларын басуга илтеп бушаткан арада рәис белән без кем ихатасында күпме тирес, кош тизәге, көл булуын ачыклап йөрдек. Район

үзәгендә шау-шу белән башланган кампания Азин исемендәге колхозда ике көндә тәгәлләнде дә бугай. Кайткач, мин шулай дип отчет бирдем.

НЭП чорында крәстиән хуҗалыкларына аякка басарга ярдәм итү бурычын үз өсләренә алган селькковлар (крестьянские комитеты обществ взаимопомощи - үзара ярдәмләшү җәмгыятьләре комитетлары) авыл-хуторларга бүленеп чыгучыларга ярдәм итүдән тыш та байтак эш башкаралар. 1926 елда алар 26, авыл Советы саен берәр була, аннары авыл саен диярлек төзелә. Батырбай авыл Советында, мәсәлән, алар бердән дүрткә җиткерелә. Сараш һәм Солтанай селькковлары иң көчлеләрдән санала. Аларның еллык балансы 8,4 мең сум тәшкил итә. Танып, Аклыш, Байавыл, Төңгүк җәмгыятьләре ярыйсы гына әйбәт эшлиләр. Җирне бергәләп эшкәртү, чәчүлекләрне планлаштыру, басуларга ашлама чыгару кебек эшләрне оештырудан тыш алар кешеләрне урман эшенә җәлеп итү, мунчала салу һәм эшкәртү кебек эшләрне дә әйбәт оештыралар. Ике сельккoв (Сараш һәм Печмень) кирпеч җитештерүне үзләштерә: беренчесе елына 36 мең, икенчесе 10 мең данә кирпеч суга.

Сараш промкооперативы 1925 елда Сараштан 25 чакрымда Кордак елгасында известь заводы төзи. Мастер Минһаҗ Мусин җитәкчелегендә төзелгән бу завод 1931 елга кадәр эшли. 1964 елда беткән Кордак авылының барлыкка килүе шушы завод белән бәйле.

Районда шулай ук күп эшкәртү, тимерчелек, күмер яндыру, деготь кайнату кооперативлары оештырыла.

НЭП чорында эшләгән бу җәмгыятьләр чын мәгънәсендә ирекле нигездә, бернинди көчләүләрсез, куркытуларсыз төзелә. Аның әгъзалары җыелышта җәмгыятьнең комитетын һәм президиумын сайлыйлар. Җәмгыятьләр сугыш инвалидларына һәм ярлыларга җирләрен эшкәртүдә, җитештерелгән продуктларын реализацияләүдә булышлык итәләр.

Селькковлар эшен координацияләү, җитәкләү өчен райккөв сайлана. Аның рәисе булып Дәүләтшин эшли.

1927 ел башына селькковлар саны 42 гә җитә, 7 авыл хуҗалыгы кооперативы, 25 супряг (халык телендә «чүпрәк»), 7 потребительләр җәмгыяте, тарту көчен вакытлыча файдалануга (прокатка) биреп тору буенча 2 пункт эшли (9;14).

Кайбер авыл кешеләре өчен мунчала салу, кап, чыпта сугу төп шөгыль һәм төп керем чыганагы булып тора. Район буенча елына уртача 36 мең пот (кайбер елларда 60 мең потка кадәр) мунчала эшкәртелә, аннан кергән доход игенчелектән кергән доходның якынча яртысын, гомум доходның 28 процентын тәшкил итә (Шунда ук).

Яңа оештырылган партия райкомы һәм райсовет башкарма комитеты хатын-кызлар, яшьләр белән эшләүгә үзгә әһәмият бирәләр. Ел саен хатын-кызлар конференцияләре, делегаткалар җыелышлары уздырыла. Татар-башкорт хатын-кызлары күбесенчә Бардада, руслар Зязелгада яисә Шермейкада җыелышалар. Райком каршында делегат бюросы эшли. Конференция карарлары белән ясле фондлары, сөт җитештерү артельләре оештырыла, бакча культуралары орлыгы кайтартыла, хатын- кызларны эшкә урнаштыру мәсьәләләре хәл ителә.

1925 елның 28-29 сентябрендә уздырылган II район партҗыелышы карары белән райком каршында эшләп килгән делегат бюросы урынына хатын-кызлар бүлеге булдырыла. Аның мөдире итеп райком әгъзасы, районда беренче хатын-кыз коммунист Разия Гатауллина раслана.

Оешуының беренче елларында районда 24 башлангыч, бер җидееллык мәктәп эшли (җидееллык мәктәп шул елларда Сараштан Бардага күчерелә һәм крәстиән яшьләре мәктәбе, ШКМ, дип аталып йортелә башлый). Коммуна мәктәбе дә булып, анда мең ярым бала укый. 1927 елда мәктәпләр саны 34 кә җитә, укучылар саны 2670 булып, бу мәктәп яшендәге балаларның 65 процентын тәшкил итә, янсә 35 процент балалар (1471 бала) укуга җәлеп ителмичә кала. Мәктәп һәм балалар йортларында эшләгән 71 укытучының берсе югары, 11 е урта, калганнары башлангыч белемле була.

Мәдәният учреждениеләре челтәре 11 уку йортыннан (изба-читальнядан), 7 кызыл почмактан, 5796 данә китап фонды булган бер район, оч авыл китапханәсеннән тора. 1927-1928 елларда культура ихтыяҗларына дәүләт бюджетыннан 12,7 мең сум акча тотыла.

1924 елда районда 19,4 мең (халыкның 24 проценты) укый-яза белми. Алар очен 30 дан артык пункт оештырылып, ел саен анда меңләп кеше укытыла. Алласызлар җәмгыятьләре (русча «Веселый безбожник»), үзешчәнләр очен «Үзең ойрән» дигән уку заллары, аз грамоталылар мәктәпләре эшли.

1927 елда район кешеләре 866 данә үзәк, шул кадәр үк олкә газитләре, 73 данә журнал алдыралар. Барда, Әрҗән, Үдик, Шермейка авылларында политмәктәпләр эшли. Моннан тыш партия райкомының агитпроп җитәкчесе Ә.Г.Батыркаев җитәкчелегендә күчмә политграмота мәктәбе, район үзәгендә ике стационар политшкола эшли. 1927-1928 елларда политукуга район буенча барлыгы 291 кеше, шул исәптән 107 хатын- кыз җәлеп ителә (8;14).

1927 елда сәламәтлеге начарлану сәбәпле Солтан Абдусәләмов райком секретаре вазифасыннан азат итүне сорап окружкомга гариза бирә. Ү район партҗыелышы аның бу үтенечен канәгатьләндерә. Райкомның җаваплы секретаре итеп бу вакытта окружкомда эшләгән Һади Хәсби улы Сарабский сайлана.

**Сарабский Һ.Х.** (1892-1975) Добрянка шәһәрендә эшче гаиләсендә туа. 1917 елның мартыннан партия әгъзасы, 1914 елдан эшчеләр хәрәкәтендә катнаша. Октябрь революциясеннән соң Чусовой, Чермоз районнарында партия һәм совет эшләрендә, 1920 елдан 1927 елга кадәр РКП(б)ның Пермь губкомы, окружкомы инструкторы. Барда райкомыннан соң Урал олкә комитетында инструктор, сектор мөдире, «Уральский пролетарий» заводы директоры, сугыш елларында эвакогоспиталь комиссары (15).

Ү район партҗыелышы бюро составына Һ.Х.Сарабскийдан тыш җаваплы секретарының агитпроп буенча ярдәмчесе һәм урынбасары Ә.Г.Батыркаев, нарсуд хезмәткәре И.Т.Смирнов, райсовет башкарма комитеты рәисе Г.Г.Гатауллин, РК хезмәткәре Д.А.Афанасьевларны сайлый (14).

**Гатауллин Габдулла Гатаулла улы** (1894- 1963 ) Үдик авылында туа. 1918 елда «Кызыл Урал» газете редакциясендә эшли, шигырьләр һәм поэмалар яза, аларны «Апуш» имзасы белән бастыра. «Шәпи агай» журналына, «Сабан-чүкеч» газетенә языша. Гражданнар сугышы чорында язган һәм 1920 елда «Коммунист» газетендә басылган бер шигыре («Гаскәр иптәшләргә») 1957 һәм 1968 елларда Казанда нәшер ителгән «Ялкынлы еллар» җыентыгында, берничә шигыре элегрәк Урал хәрби округы политидарәсе басып чыгарган китапларда донья күрә.

1924 елда Г.Гатауллин партия мәктәбе тәмамлый, 1927 елның сентябрендә Бардадан аны яңадан олкә үзәгенә, ВКП(б) олкә комитеты аппаратына алалар. Шуннан ул пенсиягә чыга. Гомеренең соңгы елларына кадәр Свердловскида яши (17).

## Чыганаклар


1. КПСС в резолюциях и решениях съездов, конференций и пленумов ЦК. Часть II. 1924-1930 гг. М., 1954.

2. История Урала. Том 2. Период социализма. Пермь, 1965.

3. РКП(б)ның Оса өяз комитеты бюро һәм пленумнары протоколлары. Өлкә партархивы. Фонд 574, тасв. 1, эш 10.

4. РКП(б)ның Барда райкомы бюро, пленум, партҗыелыш протоколлары. Өлкә партархивы. Фонд 754, тас. 1, эшләр 9-12, 38.

5. Барда районы буенча өлкә партархивы материаллары. Фонд 358, эш 84.

6. Г.Ә.Кантугановның туганнарында сакланган автобиографиясеннән.

7. С.А.Абдусәләмовның балаларында сакланган анкета-автобиографиясе, Сарапул окружкомының Урал өлкә комитетына биргән заключениесе. Свердловск архивы, фонд 4, тасв.5, эш 1.

8. РКП(б)ның Барда райкомы отчеты. Өлкә партархивы. Фонд 754, эш 9.

9. Кооперативлашуга кадәр Барда районы (1923-1929 еллар). Партархив материаллары буенча мәкалә. «Таң», 1977 ел, 17, 19, 24, 29, 31 март, 2, 5, 9, 16, 19 апрель саннары.

10. Ә.Г.Батыркаев, Ф.Назаров, Б.Адутов, А.И.Ездаков хатирәләре.

11. Ә.Туйгилдин (Сожән) хатирәләре.

12. Х.Тякин (Күчтәнти), М.Мөнәсыйпов (Солтанай) истәлекләреннән.

13. Е.И.Баженов, П.М.Курицын, А.И.Искәндәрова хатирәләреннән.

14. РКП(б)ның Барда райкомының 1927 елгы отчетлары. Өлкә партархивы. Фонд 754.

15. Свердловск өлкәсенең җәмәгать оешмалары архивы. Фонд 4, тасв. 5, эш 1; тасв. 7, эш 2; тасв. 8, эш 5.16. Десять лет Советской власти в Сарапульском округе. Сарапул, 1927.

17. Хатип Госман (Казан) биргән мәгълүматлар һәм Ә.Г.Батыркаев сөйләгәннәрдән.

# БАРДА РАЙОНЫ



# X. Күмәк тормышка юл

Партиянең 1927 ел декабрь аенда узган XY съезды, илдә халык хуҗалыгын үстерүгә анализ ясап, 1925-1926 елларда промышленность 1913 елгы дәрәҗәгә иреште, ә менә хосуси милеккә нигезләнгән авыл хуҗалыгы промышленностьны чимал, шәһәр һәм промышленность эшчеләрен азык-төлек белән тәэмин итәрлек хәлдә түгел, хәлне үзгәртү өчен авыл хуҗалыгында «тирән социалистик үзгәртеп корулар башларга кирәк», дигән резолюция кабул итә..

XIY съезд тарихка илне индустриальләштерү съезды булып керсә, бусы, XY съезд, партия әшлекле эшләренең чыгышларында авыл хуҗалыгын социалистик юлга бастыру съезды, дип бәяләнә. Съезд авыл хуҗалыгын коллективлаштыру, артельләргә берләштерү курсын билгели (1.432-491 бб.).

НЭП чорында төрле ширкәтләр белән рәттән районда җир эшкәртү артельләре дә барлыкка килә. 1928 елның язына, коллективлаштыру эшен башлаганчы ук, 107 гаилә-йортны үз эченә алган җиде артель оештырыла. Март аенда Никольск крәстиәннәре берләшә. «Бедняк» исеме бирелгән бу югары дәрәҗә кооператив- колхозның рәисе А.Н.Ездаков районда беренче булып земотделда аның уставын раслата. Алар артыннан Сараш (Суфый Мостаев, Габдулла Ижбулатов, Кәрим Ягъфәров һ.б.), Габделбәр Ибраев җитәкчелегендә Әрҗән коммунистлары, бардалылар (Әмирҗан Кантуганов, Мирзый Шәрипов, Сафия Мушакова һ.б.) колхоз оештыралар (2).

ВКП(б) Үзәк Комитетының коллективлаштыруның темплары һәм колхоз төзелешенә дәүләт ярдәме чаралары турында 1930 ел 5 гыйнвар карары белән СССР территориясе өчкә бүленә. Безнең Урал регионы икенче төркем районнарга кертелә һәм биредә коллективлаштыру нигездә 1930 елның язына тогәлләнергә тиеш була (1.664-667 бб.).

1929 елның октябрендә райком бюросы «Районда тоташ коллективлаштыруның барышы турында» мәсьәлә карый һәм Сараш, Солтанай, Таныш, Аклыш, Озын Ялан авыл Советлары авылларын тулысынча коллективлаштыру турында карар кабул итә, колхоз оештыру буенча җаваплы итеп билгеләнгән Әндәр Батыркаевка «удар эшләү бурычын» йокләтә һәм эшне тәмамлау өчен «бөтен авыл активын мобилизацияләргә» куша. Шушы ук карар белән 1929-1930 елларда 35 мең пот ашлык хәзерләү, колхозларда 7 мең гектар иген чәчү һәм һәр гектардан 7 центнер уңыш алу билгеләнә.

Гади кооперацияләр төзү чорында бөтен Уралга үрнәк итеп күрсәтелеп килгән районның җитәкчеләре бу юлы да алдынгылар рәтендә булу өчен бөтен тырышлыкларын салалар, югары тип кооперацияләр төзүне дә җиңел башкарып чыгарбыз дип өмет итәләр.

Чыннан да, моңарчы үзара ярдәмләшү, кредит, хезмәт ширкәтләре (ТОЗлар) уңышлы эшләгән җирләрдә алар ярдәме белән колхозлар тиз оеша. Мәсәлән, Аклыштагы үзара ярдәмләшү комитеты (рәисе Шакирҗан Савинов) трактор сатып ала һәм Әрҗәндә оешкан колхозга урып-җыюны

уткәрергә, инвентарь сатып алырга ярдәм итә. Ә Сараш кредит ширкәте (рәисе Сәләм Гайсин) «Бедняк» колхозына берләшкән Никольск крәстиәннәренә чәчкеч, сабан, тырма, орлык һәм 15 ат, Сарашның үзендә икс суккыч машинасы алу өчен ссуда бирә. Җирне берләшеп эшкәртү буенча гади кооператив «Супряг» базасында төзелгән Сараш колхозы (оештыручылары С.Мостаев, Г.Ижбулатов, И.Шәрәфиев һ.б.) чын үрнәк хуҗалык ролен үти. Үзләрендә урып-җыю эшләрен тәмамлагач, аның бер төркем әгъзалары (Суфый Мостаев, Әхмәр Яхин, Тохфәт Ижбулатов һ.б. - барлыгы 18 кеше) район буенча таралып, авыл кешеләре өчен колхозларга берләшүнең иң кулай юл икәнен турыдан-туры басуларда, машиналар кулланып демонстрацияләделәр.

Бу колхозда Свердловскидан «Социализм юлы» өлкә газитенең күчмә редакциясе булып китә. Зур газит битендә сөйләрлек нәрсәләре дә була шул. 120 гектарлык Каенсар басуында сарашлылар солыдан 25 әр центнер уңыш җыялар (сарашлылар кебек суперфосфат кулланып чәчелгән 8 гектар басудан «Гәйнә» колхозы да (Барда) шундый ук уңыш җыя). Басу трактор белән эшкәртелә, күп ашлама кертелә. Колхозга берләшеп яшәүләренең беренче елында ук колхозчылар хезмәт көненә 16 шар килограмм ашлык алалар. Колхозга 76 нчы әгъза булып кергән Бауд бабай хезмәтенә чыккан 15 йөк ашлыкны кая куярга белми, урам буйлап тезелгән олауны кире куа.

1932 елда Сараш колхозы рәисе Суфый Мостаев Уфага, Башкортстан колхозчылары съездына бара һәм Барда районында күмәк хуҗалыкларга берләшүнең барышы турында сөйли (3).

Свердловскида колхозчыларның өлкә съездында доклад белән чыгыш ясап, райсовет башкарма комитетының земотдел бүлеге мөдире Әндәр Батыркаев болай ди:

— Билгеле, без дә авылларга уполномоченныйлар җибәрәбез. Алар да авылларда кунып яталар, атналарлап өйләренә кайтып кермиләр, урындагы активистларга яңа оешкан хуҗалыкларның эшен җайга салуда, яңа членнар кабул итүдә ярдәм итәләр. Ләкин бездә төп рольне алар түгел, ә элегрәк Сараш һәм Аклыш кооперативлары сатып алган ике машина уйнады. Аларның тракторы һәм суккыч машинасы белән ышандырдык без авыл кешесен.

Президиумнан «Димәк, сез машина белән бутадыгыз крәстиәннең башын? — дигән репликага Әндәр ага горурлык белән:

— Әйе, бу ике машина безнең өчен мең агитаторга торды, - дип җавап бирә (2).

1928 елның 1 гыйнварына иң гади форма кооперативларга 143 крәстиән хуҗалыгы җәлеп ителгән булса, бер елдан 415 хуҗалыкны берләштергән биш колхоз, 1930 ел башына 1798 крәстиән хуҗалыгын берләштергән 32 колхоз барлыкка килә. Ә 1931 елның 21 февралендә ВКП(б) өлкә комитетына җибәрелгән «Информацион хат»та район комитеты, 4844 хуҗалыкны (503 ярлы, 2711 урта хәлле һәм 1601 хезмәткәр хуҗалыгын) берләштергән 60 колхоз төзелүен хәбәр итә (4.18 б.).

Рапорт-хатларда шома булса да, чынлыкта колхоз төзү зур авырлыклар белән бара. Авылның бер башында колхоз төзергә дип җыелсалар, икенче башында аны булдырмаска теләүчеләр җыелыш үткәрә. Күмәк хуҗалыкны башлап җибәрү өчен бөтен нәрсә - ат һәм инвентарь, чәчү орлыгы һәм башкасы халыктан талап, куркытып алына. Яңа оешкан колхоз җитәкчеләренең генә моңа көче җитмәвен истә тотып, район үзәгеннән авылларга комиссияләр оештырып җибәрелә. Алардан да алда халык арасында колхозда барысы да, шул исәптән хатыннар да уртак була имеш, бер юрган астында йокларлар имеш, үлгән кешеләрне крематорийларда яндырачаклар икән, дигән сүзләр тарала. Гражданнар сугышы елларындагы кебек, урманнарда качкыннар төркемнәре оеша, колхоз активистларына һөҗүм итүләр, юл басулар, талау, кеше үтерүләр башлана. Каенавыл советыннан нәкъ Гаял Савинов әйткәнчә килеп чыга. 1932 елның көзендә авыл советыннан вәкил килеп, бернинди сөйләшү-килешүсез аның кискән утынын төяп алып чыгып китәләр. Алты кешедән торган гаилә башлыгы власть кешесенә: «Син бүген мине таларга килгәнсең, әйдә тала, ләкин бездән барыбыз да шул талау, урлау юлына басачакбыз», дип әйтергә генә өлгерә (5).

Кодаш авылыннан Гаптел Шәрәф улы Ишманов хакимият башлыгына «Колхоз мине талады, совет власте үзе дә озак яшәмәс», дип белдерә, ә Зөфәр Гатаулхак улы Аптуков шул ук вәкилгә «Совет власте крәстиәннәрне Николай патша палачларыннан да рәхимсезрәк талый», ди. Шушы сүзләре өчен аларның барысы да «Кулаклар исемлеге»нә кертелә һәм 1933 елның февралендә «Сөрелүче кулак гаиләләрен күтәрү өчен» билгеләнгән уполномоченный Карычев аларны (авыл Советыннан 13 гаиләне) Куеда станциясенә алып китә һәм, мал тояп йөртә торган вагоннарга тутырып, Урал аръягына озата.

Коллективизация чорында кулланылган репрессив актлар халыкның колхозларга, совет властена булган ачуын шул кадәргә илтеп җиткерә ки, Озын Ялан авыл советыннан Андрей Кириллович Пономаревның НКВД органнары төзегән бер «дело»да «Хоть бы скорее война, может не было бы этой власти» дип ычкындырган сүзләре теркәлеп калган (5).

Халыкта ризасызлык арта, ә югарыгы хакимият органнары аның саен ашыктыралар.

Башта колхозларның зурлыгы керүчеләр теләгенә карап билгеләнә. 1929 ел көзендә Тол елгасының сул ягында урнашкан барлык колхозлар (Үдик авыл советыннан башкаларында - анда колхозларны авыл саен оештырырга рөхсәт ителә) бер зур колхозга, дөресрәге, колхозсоюзга берләштерелә. Сталин исеме бирелгән бу гигант колхозның идарәсенә атна эчендә Сараш авыл советындагы, 1 ноябрьгә барлык башка авыл советларында халыкның йөз проценты белән колхозга алып бетерелергә кушыла.

Райколхозсоюзга - Сталин исемендәге колхозга җитәкчелек итү өчен биш кешедән яңа идарә билгеләнә, аның рәисе итеп райбашкарма комитет рәисе урынбасары, земотдел мөдире Ә.Г.Батыркаев куела.



**БАТЫРКАЕВ Әндәр Госман улы** (1893-1971) Озын Яланда хәлле крәстиән гаиләсендә туа. Солтанай мәдрәсәсендә һәм Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә, Сарашта земский школада укый. Беренче империалистик сугышта катнаша. 1920 елдан өяз буенча мәктәп инструкторы, Бардада коммуна мәктәбе завучы һәм директоры, мәгариф работниклары профсоюзы өяз комитеты әгъзасы, 1924-1926 елларда - ВКП(б) райкомының агитпроп һәм райбашкарма комитетының мәгариф бүлеге мөдире, 1928-1929 елларда - земотдел, райколхозсоюз җитәкчесе, 1930-1931 елларда - ШКМда укытучы, 1932 елдан пенсиягә чыкканчы - потребкооперация һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү системасында эшли (6). 1937-1938 еллардагы репрессияләр чорында эзәрлекләнә башлап, районнан китеп торырга мәҗбүр була: Казанда авиозавод төзелешендә, Башкортстанда потребкооперация системасында эшли.

Әндәр ага гомере буена «Белем» җәмгыяте әгъзасы буларак атеистик темага лекцияләр укый, районыбызның тарихи шәхесләре турында газеталарга мәкаләләр яза, район тарихы буенча материал туплау өчен 1965 елда төзелгән комиссиянең эшендә актив катнаша.

Райколхозсоюз озак яшәми. мәсьәлә окружкомда каралып, район җитәкчеләренә гигант колхозны таратырга, колхозларны авыл Советлары, авыллар буенча төзәргә киңәш ителә (7).

1930 елның 29-30 октябрендә узган II район партҗыелышы колхозлашу эшендә күп хаталар җибәрелгәнлеген таный. Колхозга алынганнар санын арттыру белән мавыгып, диелә анда, район җитәкчеләре чәчүлек җирләрне киңәйтү, төзелгән колхозларның абруен күтәрү буенча аз шөгыльләнәләр (8).

Кызганычка каршы, район җитәкчеләре бу тәнкыйтьтән дөрес нәтиҗә ясый алмыйлар, хата артыннан хата җибәрәләр: ярты районны берләштергән гигант колхозны таратканнан соң районга ярдәмгә җибәрелгән 27 җир үлчәүчене элекке аерым хуҗалыклардан калган вак басулар күмәк эшкәртү өчен яраксыз дип ышандырып, күп колхозларны вак группаларга бүлгәлиләр. Озын Ялан колхозында, мәсәлән, 17 мөстәкыйль берәмлек барлыкка китерелә. Бу эш «крәстиәннәрне җиргә якынайту», «группалы җир төзелеше үткәрү» сылтавы белән башкарыла.

Берләшү урынына аерымлану килеп чыга. Бу ялгышны төзәтәбез дип, икенче чиккә ташланалар - тракторлар эшләрлек мәйданнарны бер колхозга берләштерү башлана (3).

Бу тотрыксызлык, беренче чиратта, район җитәкчеләренең еш алмашынуы белән бәйле булса кирәк. С.Абдусәләмовтан соң үткән ун ел эчендә биш РК секретаре, шул кадәр үк райбашкарма комитет рәисе алышына. Туктаусыз дәвам иткән репрессияләр нәтиҗәсендә колхозларның үзләрендә дә эшне белгән, тәҗрибәле кадрлар кимегәннән кими бара, күп колхозларда бригадир итеп куярлык кеше таба алмый аптырыйлар.

Районны шушы авыр хәлдән чыгару чараларын эшләү, ярдәм күрсәтү өчен партия өлкә комитеты районга Г.Гатауллин җитәкчелегендә вәкилләр җибәрә. Бөтен районның активистларын җыялар, колхозга алу белән артык мавыкмаска киңәш итәләр. Ләкин дустанә бу киңәшләрне районның кайбер җитәкчеләре «оппортунизм чагылышы» итеп кабул итәләр. Һәм тик Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» дигән мәкаләсе уңаеннан колхозлардан массовый чыгулар башлангач, райкомның эшчәнлеге окружком тарафыннан «перегиб» дип бәяләнгәч кенә хаталарны төзәтү юлына басарга мәҗбүр булалар.

Колхоздан чыгаруны сорап район буенча барлыгы 550 кеше гариза бирә: Сараштa - 150, Солтанайда - 26, Танынта - 80, Аклышта - 44, Күчтәптидә - 30, Печменьдә 47 кеше колхоздан чыга. Барданың «Гәйнә» колхозында 32 колхоз әгъзасыннан алтысы гына торып кала.

1932 елның 6 апрелендә «Колхозлардан массовый чыгу» мәсьәләсе райком бюросында тикшерелә. «Колхозлардан болай массовый чыгулар колхозларны ныгыту буенча оештыру-хуҗалык эшенең җитәрлек алып барылмавы, начар учет һәм икмәк хәзерләү вакытында кулак-бай элементларга һәм колхозлаштыру эшенә каршылык күрсәтүчеләргә җитәрлек басым ясамыйча, ярлыларга һәм урта хәллеләргә карата арттырып җибәрүләр (тентүләр) нәтиҗәсе булып тора», диелә бюро карарында (9).

Колхозчылар арасында аңлату эше үткәргәннән соң 157 кеше гаризасын кире ала, колхоздан чыгып өлгергәннәрнең дә байтагы кире кайта. Башка районнардагы кебек, колхозларның таралуына юл куелмый, перегиб чагыштырмача җиңел төзәтелә.

Аңлату эшендә район гәзите, МТС каршында оештырылган политбүлек һәм шәһәрләрнең авылларга кадрлар белән ярдәм итүе (егермебишмеңчеләр җибәрүе) нык ярдәм итә.

«Колхоз юлы» исеме белән чыга башлаган район гәзитенең 1 нче саны 1931 елның 15 августында чыга. 1940 елның 28 августына кадәр гәзит латин шрифты белән, кириллицага күчкәндә берничә саны ике шрифт белән басыла. Башта гәзитнең тиражы зур булмый (1 мең данәне узмый), ләкин аны кулдан-кулга йөртеп укыйлар. Нигездә өч кешедән торган редакция (вакытлы редакторы Галимҗан Туктамышев, җаваплы секретаре Җәмилә Ягъфәрова һәм әдәби хезмәткәре Ш.Искәндәров) заманы өчен бик тә кирәкле эш башкара: коллективлаштыру эшенең барышын яктырта,

алдынгыларны мактый, эшкә таяк тыгучыларны җәмәгатьчелек хөкеменә чыгара, тәнкыйтьли.

Елдан артык гәзит Оса типографиясендә басыла, 1932 елның 27 декабрь көне белән чыгарылган 59 нчы саны үзебездә җыелып басыла. Гәзит ике битле булып атнага ике тапкыр татар телендә чыгарыла. 1935 елдан 500 данә тираж белән русча «Ударник» чыга башлый (10).1939 һәм 1941 елларда «Колхоз юлы» һәм аның редакторы Заһит Закир улы Мөхәммәтҗанов Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә катнаша. Бу хөрмәткә район гәзите колхозчылар арасында алдынгы тәҗрибәне актив пропагандалаганы, житешсезлекләргә каршы кыю көрәшкәне өчен лаек була. Район гәзите белән бергә Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә «Алга» (Барда) колхозының «Югары уңыш өчен» стена гәзите, авыл хәбәрчеләре Абдулла Тимганов, Г.Нуриев, район гәзите хезмәткәре А.Солтанов, типография эшчесе Х.Хәлилов та катнаша.

Күргәзмәдә катнашучыларга бирелгән характеристикада без түбәндәге юлларны укыйбыз: «Район гәзите чыга башлаганнан бирле районның йөзе тамырдан үзгәрде. Биредә «Колхоз юлы»ның өлеше зур. Ул йөзләрчә селькорлар тәрбияләп үстерде. Бүген аларны һәр тармакта очратырга була. «Колхоз юлы» бөтен тырышлыгын партия күрсәтмәләрен үтәүгә юнәлтә, авыл хуҗалыгы уставын бозуларны бетерергә ярдәм итә, хәбәрчеләр санын елдан-ел арттыра». 1936 елда аның 150, 1939 елда 290 хәбәрчесе була, өч ел эчендә редакциягә килгән хатлар саны 1771 дән 2676 га, гәзитнең тиражы 1940 елда 3 меңгә җитә (11).

Район гәзите МТСлар эшчәнлеген яктыртуга үзгә әһәмият бирә. Башта чикле генә колхозларга хезмәт күрсәткән Барда МТСы акрынлап, асруча политбүлекләр оешкач, йогынтысын арттыра. 1936 елда колхоз басуларында 90 трактор эшләсә, сугыш алдыннан ике МТСта (Барда һәм Сараш) 119 трактор (40 СХЗ һәм ХТЗ, 23 - СТЗ-НАТИ), 50 комбайн, егермедән артык катлаулы суккыч машиналары булып, алар 80 колхозга хезмәт күрсәтәләр. 95 процент крәстиәннәрне, 99,8 процент җирләрне берләштергән колхозларның 52 мең гектар сөренте җирләрендә 60-70 процент кыр эшләре машиналар (трактор, комбайн һ.б. тор машиналар) көче белән башкарыла. Сигез ел эчендә МТСлар 500 тракторчы, йөзгә якын комбайнчы әзерләп чыгаралар. Механизаторларның 40 процентка якыны хатын-кызлар була.

Коллективлаштыру башлану белән партия Үзәк Комитеты авылларга 25 мең эшче җибәрә. Карабаш, Чусовой, Первоуральск шәһәрләреннән безнең районга 18 эшче килә. Аларның бишесе (Суханцев, Ярмөхәммәтов, Абдулатыйпов, Нурмөхәммәтов, Баранов) шундук колхоз рәисләре итеп сайланалар. Ш.Г.Гыйльметдинов МТС директоры, Гаинцев Шермейкага авыл советы рәисе һәм ячейка секретаре итеп җибәрелә. Калганнары төрле оешмаларга җитәкчеләр итеп билгеләнә. Игенчелек акрынлап алга бара. Бөртеклеләрнең гектардан уңышы 7 центнердан 11,5 центнерга күтәрелә. Ә менә терлекчелеккә карата моны әйтеп булмый. 20 колхозның сөтчелек фермалары булып, аларның һәркайсында сыерлар саны ун баштан артмый. 1122 гектар сөренте җире булган «Новый строй» колхозында нибары 4, «Октябрь байрагы»нда 5, «Кызыл Тол»да (Толбаш авылы) 17, «Яңа юл»

колхозында 2816 гектар сөренте җиргә ниБары 8 баш сыер асрала. 17 колхоз сарык фермалары булдыра, ләкин аларда да сарыклар саны ун башны узмый (12).

Утызынчы елларда кустарчылык производствосының, җирле промышленностьның электән килгән традицион тармаклары киң үсеш ала. 1928-1929 елларда төзелгән кирпеч заводы әйбәт кенә эшли. Барда урта мәктәбенең беренче кирпеч бинасы шушы завод суккан кирпечтән салынган.

1932-1933 елларда барлык авылларда дип әйтерлек промартельләр оеша. Өйдән-өйгә йөреп эшләүчеләр янсә үз йортларында кап, чыпта сугучылар шунда керәләр. 1935 елда Барданың беринчә промартеле Осипенко исемендәге бер артельгә берләшәләр. 1939 елда артель күн аяк киеме тегү, киез итек басу эшләрен үзләштерә, сугыш елларында тире эшкәртү цехы ача. 1940 елда биредә 612 пар күн итек, ботинка, туфля тегелә, 870 пар киез итек басып чыгарыла.

Промкомбинат (беренче рәисе Харис Әбүбәкиров) тегү мастерское оештыра. Беренче булып анда үз тегү машинасы белән Бикмохәммәт бабай Гайнуллин килә һәм бик күпләрне тегәргә, кием кисәргә өйрәтә.

Никольскида такта яру цехы оештырыла. Промартельләр промсоюзга берләштерелә. Щипа промколхозы 1950 елларга кадәр каешнан спирт кайната, Карманда спиртны ак чыршыдан ясыйлар. Яңа Чатта, Аклышта дегет кайнаталар.

Районда кустарь-промысел кооперативларының чагыштырмача яхшырак оештырылуын исәпкә алып, 1932 елда промартельләрне промсоюзларга, ә аларны районара промсоюзларга берләштерү эше башлангач, Оса, Елово һәм Барда районнары промартельләре берлегенең үзәге итеп Барда сайлана. Һәм бу очраклы гына эшләнми дип әйтә алабыз.

Өченче бишьеллыкка райпотребсоюз колбаса эшләү цехы, тегермән комбинаты, вальцовый тегермән төзүне планлаштыра, ләкин сугыш чыгып, бу план, башка күпләре кебек, үтәлмичә кала.

1940 елның 17 февралендә үткән гомумрайон партҗыелышында район гәзите редакторы З.З.Мохәммәтҗанов «районда нефть барлыгы билгеләре бар», дип чыгыш ясый. Һәм бу район кешеләрендә зур кызыксыну тудыра (13).

1932 елда Бардада 8 номерлы беренче телефон коммутаторы урнаштырыла. 1935 елда пекарня эшли башлый.

1940-1941 уку елында мәктәпләр саны 59 га җитә: 46 башлангыч, 12 җидееллык һәм бер урта мәктәптә 8 меңгә якын бала укый. Аларга 255 (җидесе югары белемле) укытучы белем һәм тәрбия бирә. Барда урта мәктәбе беренче чыгарылыш ясый, ә җидееллыктан урта мәктәпкә әверелдерелгән Сараш мәктәбендә тугызынчы класс ачыла.

Егерменче һәм аеруча утызынчы еллар район тормышына күп үзгәрешләр алып килә. Шик юк, Пермь олкәсе татарлары һәм башкортлары очен мәркәзгә әверелгән иске Гәйнә иленең - Барда районының уңышлары күбрәк тә булыр иде, әгәр шушы чорда аның өстендә Сталин балтасы

уйнап тормаган булса. Репрессияләрнең иң кызган чорында, 1937 елда, районның иң тәҗрибәле, белемле 113 зыялысы кулга алына, лагерьларда черетелә, 35 е атып үтерелә. Барда авыл Советыннан 22, Каенавылдан 5, Озын Яланнан 8, Үдик һәм Уймуждан алтышар, Сараш һәм Солтанайдан туг:зар, Әрҗәннән җиде...

Колхозлашу чорында гаиләләре белән йортларыннан куып чыгарылганнарны (окрисполком карарында алар «раскулаченные на месте» дип атала), бер гаепсезгә Себергә сөрелгәннәрне искә алсаң, чәчләрең үрә торырлык. 1930 ел 5 март карары белән районнан 161 гаилә (805 кеше) такта вагоннарга тутырып Карабашка озатыла. 1933 ел 4 апрель карары белән янә 211 гаилә (1115 кеше) илдән сөрелә. Инде кулакка санарлык юньлерәтле хуҗалык калмады дип торганда, югарыдан яңа нәрәд килеп төшә. 1933 ел 15 май карары белән райсовет башкарма комитеты кырып-себерып дигәндәй 279 гаиләне (1459 кешене) шул тарафка озата.

Берән-сәрән хөкемгә тартылганнарны исәпкә алмастан, оч агым белән халыкның каймагы булырдай иң сәламәт, тырыш, җитештерүчән катламыннан 651 гаилә (3479 кеше): Акбаштан 16, Аклыштан 22, Антуфьеводан 19, Бардадан 39, Каенавылдан 17, Озын Яланнан 23, Үдик авыл Советыннан 41, Зайцеводан 14, Зязелгадан 42, Искирдән 27, Әрҗәннән 41, Байавылдан 17, Яңа Баштан 37, Сараштан 39, Солтанайдан 29, Таныптан 43, Уймуждан 29, Шермейкадан 39...(5).

1923 елда йорт саен йөреп үткәрелгән тикшерү буенча сез районда 138 бай (зажиточный) һәм 23 кулак хуҗалыгы булганын белдегез. Ә биредә һәр авылдан күпме кулак тапканнар! 1931 - 1933 елларда кулак дип расланганнар исемлегендә кемнәр генә юк: Иске Баштан колхоз оештырып йөргән «килмешәк хәерче» Кави Уразаев, Таныптан авыл Советы рәисе Хисаметдин Урастимеров, Күчтәнтидән колхоз активисты Нәҗмехәммәт Тякин, Каенавылдан бер йорты да, бер сыеры булган колхоз хисапчысы Госман һәм Габделхәй Әмировлар, Зайцеводан кешедә генә торып йөргән Афанасий Куланов, Печмень авыл Советыннан колхозда ат караучы булып эшләгән Владимир Пешин, налогын вакытында түләргә, орлык фондына ашлык салырга хәленнән килмәгән гади колхозчылар һәм асрым хуҗалыклар, Бакчавылдан гади гаилә әгъзасы буларак түгел, ә гаилә башлыгы итеп теркәлгән 15 яшьлек Шәйхи Балтаев... Күпләренең «Контрреволюцион эшчәнлекләре» дигән графага язарлык гаепләре дә булмаган, шулай да гомум сүзләр белән «настроен антисоветски», «до революции имел 15 гектаров пашни», «держал пчел, имел доход до 1 тысячи рублей», «вел торговлю», «имел молотилку, сепаратор», дип язып куйганнар. Ә

Закир Шәриф улы Юсуфкулов дигән кеше исеме турысына әлеге графада «Гомум җыелышта «Колхозда эшлисең- эшлисең, кон-тон калдырмыйсың, ә бернинди тулкысы юк» дип чыгыш ясады» дигән сүзләр теркәлгән. Димәк, колхозга карата андый сүзләр дә әйтергә ярамаган.

Такта вагоннардан Себер тарафларына илтеп бушатылганнарның бик азлары гына срокларын тутырып туган якларына әйләнеп кайту бәхетенә ирешә алган. Икенче, өченче тапкыр кулга алынып, 1936-1939 елларда тагын «тройка» хөкеменә эләгүчеләр дә булган. Гражданнар сугышы елларында чабаталы аклардан (сәнәкчеләрдән) качып, Ирән буендагы Башап авылында мәдәният хезмәткәре (избач) булып эшләгән, районның беренче совет укытучыларыннан берсе Сүҗде авылыннан Фәттах Исмәгыйль улы Акҗигитов - шундыйларның берсе иде. Беренче тапкыр сөрелгәндә ул алты кешелек гаиләсе белән йортыннан куып чыгарыла. Соңгысыннан котылгач, Амур буйларыннан, Байкал артыннан кайда җәяүләп, кайда бер-ике станцияара юллык акча юнәтеп кайта. Аның белән бергә шундый ук алты кешелек гаиләсе белән агасы Әгъзам Акҗигитов та йортыннан һәм авылыннан куылырга тиеш була.

Биредә китерелгән фамилияләрнең байтагын без бүген район музеенда да укый алабыз. Ә анда күрсәтелмәгәннәре күпме? 1990 елда музей мөдире Сәгыйть Тляшев төзегән исемлеккә бүген һәр авылдан берничә кешене өстәргә була.

Бер гаепсезгә йорт-курасыз калдырылган, урамга куып чыгарылганнар, партиядән төшерелеп, эшсез йортелгәннәр, «халык дошманы» хатыны, улы яки кызы дигән тамга белән эштән куылып, сукбайга әвереләдерелгәннәрне, эзәрлекләүдән качып читкә чыгып киткәннәрне (үз-үзләрен сорүчеләрне) дә өстәсәк, күпме интеллектуаль көчләрен, тәҗрибәле җитәкчеләрен, оста куллы белгечләрен югалткан район!

Утызынчы еллар фаҗигасен Казан ханлыгын тар-мар итү, патша хөкүмәтенең XYII-XYIII йозләрдәге крәстиән хәрәкәтләрен канга батырулар белән чагыштырырга мөмкин.

Илдә барган массовый репрессияләрдә бер Сталин гына гаепле түгел диючеләр бар. Дорес, Үдик яки Каспавылның беренче совет укытучыларын, Сараш, Әрҗән авылларының муллаларын, урта хәлле крәстиәннәрен Карабашка, Пермь сөргененә (Соликамск, Мотовилиха, Курья, Краснокама, Пашый) һ.б. урыннарга сөрегез дип югарыдан исемле указлар төшерелмәгән, ләкин төгәл саннар күрсәтелгән нәрәд-заданиеләр килеп торган, бу нәрәд-заданиеләрне үтәүгә каршылык күрсәткәннәрне сизгерсезлектә гаепләп, эшләреннән төшергәннәр, алар урынына партия

күрсәтмәләрен күндәм үтәрдәй «сизгер-тырыш көрәшчеләр» куелган һәм шулар кулы белән законсызлыклар башкарылган.

1934 ел ахырында Гаделшин урынына партия райкомының җаваплы секретаре итеп җибәрелгән М.А.Бугулов, милләте буенча осетин, комвуз бетергән, нәкъ шундый кулай кеше була да. Районга яңа аяк баскан, ни район аны, ни ул районны белми, ләкин яңа гына комвуз бетергән Бугулов Сталинның социализм төзү чорында сыйнфый көрәш йомшармый, көчәя генә бара, дигән зарарлы «теориясен» үтәү өчен менә дигән функционер. Беренче көннәрдән үк Бугулов җиң сызганып партия, совет органнарын дошман элементлардан «чистарту», район хезмәткәрләрен массовый эзәрлекләү эшенә тотына, Сталин уйлап чыгарган «сыйнфый көрәшне» үзара ярышка әверелдерә, теге яки бу хезмәткәрләрнең партиягә, совет хакимиятенә тугрылыгын аның күпме дошман табуы белән бәяли, күрше районнардан калышмас өчен бөтен көчен сала.

Бугулов эшләгән еллардагы бюро утырышлары, партҗыелышлар үзара кычкырыш- талашка әвереддерелә. Беренче көннәрдә үк бер гаепсезгә үзенең беренче ярдәмчесе, РКның икенче секретаре Г.Х.Аджигитовка карата «Антипартийная деятельность второго секретаря Аджигитова» дигән «эш»уйлап чыгара. РКда эшләү чорында бер дошман да тапмады дигән гаеп тагып, аны ике тапкыр партиядән чыгарта, эшсез йөртүгә ирешә. Район газите редакторы Зыя Сәләхетдинов та, Барда МТСының беренче директоры, 1918 елдан партия әгъзасы Шәйхетдин Гайнетдин улы Гыйльметдинов та, Сараштан карт коммунист, гражданнар сугышы ветераны, партизан Илья Яковлевич Горбунов, роно мөдире Рәхим Хәлилов та шамый аңа. Аларның басымына да ул «буржуаз элементлар белән элемтә тотасыз» дип бәйләнә, югарыда барган ыгы-зыгыларга охшатыйм диптер, «Адутовщина», «Батыркаевщина» дигән «дело»лар уйлап чыгара. Үзенә охшамаган барлык кешеләрне ул амбар кенәгәсеннән эшләнгән махсус кенәгәгә теркәп, һәркайсына «компромат» җыя. Кем белән кем очрашкан, туганнары кемнәр, совет властенә, партиягә карата кайсы нәрсә әйткән - барысы да аның шушы кенәгәсендә теркәлеп бара. «Вески аргумент» өчкә җиткәч, алар «өчлеккә» тапшырыла. Роно мөдире Рәхим Хәлиловны гаепләү өчен аның өендә «халык дошманы» дип белдерелгән кешенең фотосы саклануы, икенче берәүнең мич алдына ут чыкмасын дип калай кагуы җиткән, район прокуроры Вәсфи Мөхәммәтҗановка бюрода тикшергәндә «син әтисез үскәнсең, кулак-сәүдәгәрдә тәрбияләнгәнсең, хатының мулла кызы, сыйнфый дошман элементлар белән элемтә тотасың», дип бәйләнә, партиядән дә, эшеннән дә төшерә.

Ялган сизгерлек, закон, әхлак нормалары белән исәпләшмәү аны шуңа илтеп җиткерә ки, ул хәтта сыңар куллы банк управляющие Михайловны закон бозу юлына басарга күндерә алмагач, райкомның икенче каты баскычыннан тартеп төшерә һәм имгәтә. Аның шушындый кыланышларыннан куркып, хәтта бюро әгъзалары райкомга йөрүдән туктыйлар: күп утырышлар 7 әгъзадан 3-4 е генә катнашында үтә. Күп мәсьәләләр буенча карарлар телефон аша сорашу юлы белән кабул ителә.

Сәяси тотрыксызлыгы өстенә Бугуловның мораль йөзе дә күпләрдә ризасызлык тудыра. 1935 елдан 1941 елга кадәр комсомол райкомында, аннан соң пенсиягә чыкканчы партия райкомында эшләгән Идият абый Аптукаев 1966 елда менә нәрсәләр сөйләгән:

- Комсомолда эшләгән чак иде. Утыз бишенче елның 7 ноябрендә Сарманаевта кунакта утырабыз. Берәү тәрәзә кага. Чыксак - Бугулов: җирән атка атланган, кулында сары камчы. Җырламагыз, урамга ишетелә, таралыгыз, ярамый, ди. Тыңлашып килгән.

- Бик тә тупас кеше иде ул. Өстәлендә пыяла урынына чуен калай, шуңа дөп итеп суга. Кабинетына җыеп шул калайны тоя-тоя иртәнгә кадәр утырта иде. Икенче каттан тибеп төшерүләр, камчылап таплаулар бер генә булмады. Аның очен закон юк иде, аңа сүз әйтергә куркалар иде.

Бугуловның тупаслыгын район җитәкчеләре беренче көннәрдән үк күргәннәр. Башта дусларча кисәтергә тырышып караганнар, алай да тыңламагач, ике тапкыр бюрода сүз алып барганнар. 1937 елның 9 августында өлкә газете «Социализм юлы»нда, 11 августта «Уральский рабочий»да тәнкыйтьләнгән: «Бугулов гаепсез кешеләрне эзәрлекли, тәнкыйтьне кыса, ялагайларны күтәрә, мактый - менә нинди кеше утыра Барда районының башында», дип тәмамлана Быков, Галиев, Ващуклар имзасы белән басылган мәкалә (15).

Бугуловның тырышлыгы аркасында район күп тәҗрибәле кадрларын югалта. Аеруча укытучылар коллективы зур зыян күрә. 110 укытучының яртысына якыны турыдан-туры репрессияләнә, калганнары эштән куыла. 1936 елның 25 июлендә сайланган 9 бюро әгъзасыннан 1938 елның мартына тик берсе кала, берничә ай райком җитәкчесез тора һәм 1938 елның 25-27 апрелендә узган район партҗыелышы беренче тапкыр райкомның эшен канәгатьләнмәслек дип таба. 86 коммунисттан җыелышта 30 кеше сүз алып чыгып ясый. Һәм шушы ук җыелышта беренче тапкыр Почетлы президиум сайлана, Үзәк Комитет Политбюросына рапорт-хат кабул ителә. Традициягә әверелгән бу шапырыну, югаргы органнар алдын да ялагайлану 1985 елга кадәр дәвам итә һәм район дәрәҗәсе белән генә дә чикләнмичә, колхоз, куст җыелышларында да озын-озын хатлар, телеграммалар кабул ителә.

Җыелыш яңа райком, өлкә конференциясенә бер хәлиткеч, бер киңәш бирү хокукы белән ике делегат сайлый. Райкомның җаваплы секретаре итеп өлкә комитетыннан җибәрелгән Махнутин Александр Иванович сайлана (16).

Шушы партҗыелыш материалларын, Бугуловны тикшерүгә багышланган бюро протоколларын укыйсың да гаҗәпкә каласың. Бер гаепсез

кешеләрне эзәрлекләүләрне фаш итәбез дип, чыгып ясаучылар үзләре дә шушы ук юлга керен китәләр: партия карарларын үтәмәүчеләрне утлы табага бастырырга, халык дошманы итеп илдән куарга, чыгарып атарга чакыралар.

1910 елдан 1939 елга кадәр Пермь мөселманнары безнең саулыкка дога кылган, намаз укыган Алла йортында, мәчеттә урнашкан партархивта, саргаеп беткән, күпләре папирос кәгазьләренә язылган протоколларны укыйм да атеист башымнан «Ай аллам!» дип куям, үзем-үзем «Боларның кайсы ак та, кайсы кара соң?» дигән сорауны бирәм. Алга табан үзләрен үтә дә кызыл итеп күрсәтергә ашкынганнарның да кулга алынуын, халык дошманы итеп белдерелүен, күпләренең атылуын, Карабаш, Колыма якларына сөрелүен беләм. Шулай да ул алтмышынчы елларда без әле чын дөреслекне белми идек, күп нәрсәләр бездән яшерен сакланды, без - журналистларга бу темага язарга ярамады. Бу тарихны язу да әнә шул «ярамау» аркасында сузылды һәм туктап торды. Район тарихын язу идеясен беренче күтәргән Зәбир Галим улы Имайкинның уе буенча ул Совет властеның илле еллыгына язылып бетәргә, нәшриятка тапшырылырга тиеш иде. Кәгазе табылган, кайда басылачагы билгеләнгән иде. Ләкин өлкә комитетына бер баруында ул шундый хәбәр алып кайтты:

- Идеология секретаренда булдым. Безнең эшне хупый. Тик анда репрессия турында бер сүз дә булмаска тиеш, ди. Югыйсә китапны үткәрмәячәкләр, - диде ул. Мондый шартны кабул итү минем өчен җыелган материалны утка ташлау белән бер иде. Секретаребызның кисәтүенә мин:

- Ансыз нинди тарих булыр икән соң ул? - дип кенә әйтә алдым. Икебезнең дә башлар түбән иелгән иде: район тормышында булган утызынчы еллар фаҗигасен күрмәмешкә салышу ул үзебезгә ярдәм итешеп, материал туплашып йөргән ветераннарның өметен акламау, репрессия корбаннарының рухыннан көлү булачак иде.

Күпме тотынып карасам да, бу бүлекне дә, башка бүлекләрдә әйтелгән тәнкыйтьне дә алып ташларга кулым бармады. Шундый уйлану-газаплануларда утыз елга якын вакыт үтте. Район тарихының китап булып чыгасын көтеп йөргән картларның күбесе һәм аны язуны дәртләндереп йөргән комиссарыбыз Зәбир Имайкин үзе дә доньядан китеп бардылар.

Күмәк тормыш корабыз дип чәбәләнеп йөргән утызынчы елларда нинди генә югалтуларга дучар ителмәгән безнең халык. Шул елларда ныклап урнашкан тоталитар система Гәйнә халкының асыл улларын һәм кызларын юк итү белән бергә аның гасырлар буена тупланган рухи байлыкларын да юк иткән. Кешеләре төрмәләргә, каторгаларга озатылган, атып үтерелгән, мал-мөлкәте торгиларда сатылган, хөкүмәт милкенә әверелгән, ә зыялыларның шкаф-шкаф китаплары утта яндырылган, утка ташланмый калган кыйммәтле кульязмалар «бәладән башаяк» дип, җиргә күмелгән, макулатурага тапшырылган. Нинди генә булмагандыр ул китаплар, ул кульязмалар арасында!

Шушы ук утызынчы елларда бер-бер артлы әлифба алмаштырыла. Могҗиза белән сакланып калган «комган хәрефле» китаплар «искелек

калдыгы» саналып, укыр кешесен тапмый, чүплекләргә чыгарып ташлана. Халык үткәненнән аерыла.

1948 елда Пермь китапханәчеләр техникумын тәмамлап Бардага килеп эшли башлавымның беренче коннәрендә үк мин «Безнең Бардада Тукайга туган тиешле кеше яшәгән, аның Гәйнә тарихы язылган калын дәфтәре булган» дигән сүзләрне ишеттем. Ишеттем һәм авыл саен сорашып йөри башладым: Тукайга туган тиешле кеше кем булган, «Гәйнә тарихы» язылган дәфтәр чыннан да булганмы?» - бу минем өчен ифрат та мавыктыргыч, йокыларны качырырлык серле йомгак иде. Тукайга туган тиешле кеше шагыйрьнең әнисе ягыннан бабасы Зиннәтулла Әмиров икәнлеге ачыкланды һәм аның турында район газетенда һәм «Казан утлары» журналында басылып чыкты. Һәм хәзер Бардада аны белмәгән кеше юктыр дип уйлыйм.

Ә менә Гәйнә тарихы язылган калын дәфтәр, Солтанай, Таның мәдрәсәләре шәкертләре алып барган көндәлек, истәлекләр әле булса табылганы юк. Татарстанда Зиннәтулла Әмировның шәхси китапханәсе табылды. Анда хаттат (китап күчереп язучы) Зиннәтулла кулы белән күчереп язылган тарихи китаплар да бар. Бардада берничә кешедә аның Васыятьнамәсе саклана. «Туган илем Кажҗымакты кәрьясәдер» дигән шигырен беләбез. Ә менә Гәйнә тарихы, калын дәфтәр... Бардадан киткәндә ул аны туганнарының берсенә калдырып киткәндер дип уйлаучылар бар. Ләкин кемгә?

Үткәннәр турында кемдә нинди язма- комарткылар булуын белгән очракта да аларны тиз генә кулга төшерә торган түгел иде шул. «Комган хәрефле» язулар күпләрнең котын очыра иде. Хәтердә, Бардада Хәким ага Шәфиевта атаклы тюрколог Зәки Вәлиди китаплары барлыгын ишеттем. Болай таныш кеше. Барда тарихы буенча күп нәрсә сөйләгәне бар. Минем тарих белән кызыксынуымны белә, якын итә. Ләкин ничек кенә сүз башласам да Зәки Вәлиди турында чишелеп китә алмый. Башта «Ялгыш әйткәннәр, андый кешеләрнең китабын тотарга минем башым икемени?» дип кырт кисте. Еллар үтеп, культ заманы тәнкыйтьләнә башлагач, бер очрагында уңайсызланып кына Зәки Вәлидинең безнең якларда булуы турында сөйләп алды, ахырда «Өйдә үзем генә булганда кил әле син миңа, бер нәрсә күрсәтермен», дип өметләндереп куйды. Бардым.

— Озак кына актарынырга туры килде. Менә бер кечкенәсен таптым. Зурырагы да бар иде, кая яшергәнне искә төшерә алмыйм, - дип сөйләнә-сөйләнә Зәки Вәлидинең мөселман-төркиләрнең мәдәнияте турында дәфтәр калынлыгы бер китабын чыгарды, кеше күзенә күрсәтми генә укырга кушып һәм кат-кат кәгазьгә төреп, кесәмә тыкты.

Китап ише әйберне кешегә биреп тузДырудан, пычратудан түгел, «иске тормыш тарафдары» булып телгә керүдән курка иде кеше.

Кыен булса да, бүген без репрессиягә эләккәннәрнең санын исәпләп чыгара алабыз, ә менә алар белән бергә күпме рухи байлык (китап, кулъязма) юк ителгәнен беркем дә әйтә алмас. Осада Абдусәләмовлар фатирыннан гына ике ат йөге тояп алып чыкканнар, улы Гәрәйнең китапханәсе әтисенекеннән күпкә баерак булган.

Күпләр кулга алынасыларын сизенеп, шкаф- шкаф китапларын капчыкларга тутырып җиргә күмгән. Йокшер авылыннан Халисә әби Акбаева 1937 елда әтисе елга буена алып төшеп күмгән ике капчык китапларны әле булса эзли. Корәк тотып үзе чокчына, елга буенда казынучылар күрсә, алар янына йөгереп төшә.

— Илле елдан артык вакыт үтте, черен тә беткәннәрдер, ә шул кадәр байлыкның юкка чыгуы белән күңел килешә алмый, йокылардан уянып уйланып яткан чаклар була. Анда сезгә кирәкле нәрсәләр дә булгандыр. Ай аллам, нинди генә могҗизалар күрсәтмәделәр безгә, ничекләр генә итеп ботарламадылар безнең тормышны. Яхшы якка тозәтәбез дип тә әнә нишләттеләр авылны? Яшьләрне алдалап шәһәрләргә алып китеп бетттеләр дә без — картларны бер ярдәмчесез калдырдылар. Кем иген игә дә, шул кадәр шәһәр халкының тамагын кем туйдыра? Эшләмәде безнең башлыкларның башы, бүгенгеләренең дә шул — башсыз башлыкларга тарыды безнең мескен башлар. — Акбаева Халисә әбинең бу сүзләренә, моң-зарына бүген һәр авылда кушылучылар табылыр.

Репрессия чоры кешеләрне бер-берсеннән шикләнеп, куркып яшәргә, үз кабыкларына бикләнеп яшәргә өйрәтте, күркәм сыйфатларыннан ваз кичтерде. Гәйнә илендә гомер-гомергә шундый йола-гадәт яшәгән: берәрсенә еракта кунак килсә, ул бөтен авылның кунагы булган, еракта килгән кешене үз өенә дәшеп алу һәркем өчен дәрәҗә саналган. Сугышка кадәрге елларда туганнарның чиратлайнын әле берсендә, әле икенчесендә җыелышып, эчкесез табыннарда сайрашып утыруларын әле мин дә хәтерлим һәм үземнең җиде буын туганнарымны белүемне шул җыелышып утырулардан күрәм.

Гадәти кешнәрдә бер урамда, бер авылда торучы туганнар самавыр янында җыелышса, төрле авыл, калаларга сибелгән туганнарны, дусишләрне сабантуйлар, җыеннар бергә җыйган. Гәйнә иленең барлык авылларында да диярлек үткән алар. Язгы чәчүдән соң башланып, алар печәнгә төшкәнче дәвам иткән.

Утызынчы елларда бу күркәм бәйрәмебез дә эзәрлекләүгә дучар ителде. Өлкә, район җитәкчеләре үзләрен милләтчелектә гаепләмәсеннәр өчен аларны «советлаштырдылар», интернациональ төс бирәбез дип, аны барлык халыклар өчен уртак «Хезмәт һәм спорт бәйрәме» дип атый башладылар. Чын сабантуй һәм җыеннарны без картлар сөйләвеннән һәм язып калдырганнан гына беләбез.

1919 елга кадәр Гәйнә ягына караган Кайпан төбәгендә үткән сабантуй һәм җыеннар турында элекке Солтанай мәдрәсәсе шәкерте һәм мәдрәсә каршындагы кызлар мәдрәсәсе могаллиме язучы Кәрим Әмири менә ничек язып калдырган:

«Җыен вакыты өчен алдан әзерләнә, тәкәләр алдан карап, суеласы билгеләп куела. Атна-ун көн элек кунаклар чакырыла. Шәңгә пешерелә, сөттән эремчек, табикмәк, күмәчкә солы-арпа, тары оннары, кибеттән ак он, кош теле, әлбә, бал әчтеләә,юыласы кер юылып, өй тәртипкә китерелә, өй хуҗасы суккан чаршау белән бүленә, тәрәзәләргә кызыл башлы сөлгеләр, чуптарлап (бизәкләп) сугылган кашага әләләр. Урамнар, ише-

галлары чистартыла - бөтен авыл чип-чиста булып кала. Июнь аеның соңгы атна башы җомга көн җитүгә кунаклар килә, яшь киленнәр төшерелә. Бу көн «килен төшерү» көне дип атала.

Атта-тарантаста кияү-кыз, кучерда кияү егете кызыл башлы сөлгене иңбашына сала. Дугаларда кыңгырау. Аның артыннан беренче арчи, туганнар.

Җомгадан чыгуга егетнең якыннары, авыл яшьләре килен төшкән йортта җыйнала. Киленне көткәндә гармун уйнап, уеннар оештырыла, такмак әйтешүләр була.

Киленне мендәргә бастыралар, атлар капкадан кергәндә мылтыктан аталар. Мал арбаларындагы придан өйгә кертелә. Килен су алып кайта.

— Чиләге сулы, тормышыгыз тулы булсын, — дип.

Кунак килгән өйләр арасында ашка-чәйгә йөрү башлана.

Кич җиткәч, авылның атаман егетләре яңа төшкән киленнәрдән сөлге җыярга чыгалар, ул сөлгеләр белән җыен арты сабан туйлары үткәрелә.

Килен төшкән өйгә кереп:

— Безгә килен кирәк! — диләр. Килен сөлге биргәч:

— Уңган киленнең сөлгесе беренче килгән атка булыр. Рәхмәт! — диләр.

Икенче көн - шимбә. Килгән кунаклар базар күрергә баралар. Аннары сабан туе башлана. Уен-көлке.

Өченче көн — якшәмбе. Бусы чын җыенның беренче көне. Арбалар тезелгән — сату итү. Урыслар сыра, ачы бал сата. Якшәмбе көндә тугыз-уннарга җыен урыны көйләнеп беткән була. Ун-унберләрдә халык җыела. Һәр гармунчы яңа көй өйрәнеп килә, һәр тарантас хор белән җырлап үтә. Кыз-хатын кычкырып җырламый, бусы гаеп санала. Агач төпләрендә картлар-олылар борынгы озын көйләрне җырлый, түгәрәкләп утырып.

Кайбер вакытны егетләр арасында торле хәлләр дә була... Хәтеремдә, тугызынчы елгы җыенда шундый вакыйга булган иде. Хәзерге Пермь өлкәсе Барда районы Солтанай авылыннан Әфәнде исемле бер егет безнең авылның (Буләк арты Кайпан) Хисметдин Галәветдинов дигән бер егеткә кунакка килә. Галәветдинов кунагын Хөснулла исемле кешенең Хәтирә исемле кызы белән таныштыра. Кичә генә егетнең кесәсенә чигүле яулык салынганлыгын ишеткән Нури малае Муллануурга җиткерәләр. Җыен тәмам кызып киткәч, Муллануур иптәшләре белән әлеге Әфәндене эзләп табалар да суга манчылган сүс чыбыркы белән пешерергә тотына.

Кичен — кичке уен. Анда да берничә авыл яшьләре...Икенче көнне җыен икенче авылда.

Чәршәмбе көн — соңгы көн, Чокыр авылында. Бу авылның сабан туен Гали Чокрыйның кечкенә улы Ахунҗан хәзрәт ача...

Кешеләрне сынау ягыннан да җыенның әһәмияте бар иде. Җыенда кем үзен ничек күрсәтә, шул турыда байтакка кадәр сөйләнә торган иде» (17).

Барда җыенының даны еракларга таралган була. Аның батыры Башкортстанда, Уфа, Казаннарда көч сынаша. Үзебездә 18 ел рәттән батыр исеме

алган Нурый Балтаев (II Әрҗән) 1938 елда Казан сабантуенда беренчелекне яулап, иң зур бүләк - сабан алып кайта.

Җыен буласы көнгә Бардага еракларданкунаклар чакырыла, сәүдәгәрләр килә. Аңарчы авыл саен гармуннар уйнап сорән сугыла, сабантуйлар үтә. Халык җыелгач, үзеннән үзе бәйрәм башлана. Аны авылның иң абруйлы кешесе ача. Доклад-фәлән сөйләүләр булмый. Барданың абруйлы аксакалы, ул елларда «Алга» колхозының бригадиры булып эшләгән һәм Барда җыены өчен урын әзерләшеп йөргән Фатыйх абый Акманаев әйтүенә караганда, сабантуй һәм җыеннарда доклад сөйләү колхозлар чыккач башланган. Гасыр башыннан сиксәненче елларга кадәр Барда җыен Әрҗән белән Барда арасында үткән. Утызынчы елларга кадәр халык Барда елгасының ике ягында да җыела торган булган, бер генә ягына сыймаган. Илленче елларда җыен берничә тапкыр Тол буенда, Пәчин төбәк дигән җиргә каршы болында булып алды.

Моннан тыш Сараш җыены, Уймуж күпере янында Бәкин тау җыены, Түбәнавыл белән Тауавыл арасында Бүртауас җыены, Озын Ялан ягында Куштамак җыены һәм ярминкәсе, Тауавыл, Искирдә урыс җыены дип аталган бәйрәмнәр булган. Шул ук сабантуйлар чорында Үдиктә Әндри базары үткәрелгән. Ватан сугышы елларында боларын үткәрү туктатылган һәм бүтән кабатланмаган.

Узган гасырларда, күп мәхәлләле Әрәмәавыл, Ишмән, Чуашай авыллары бер- берсенә ялганып дигәндәй киткән тоташ бер авыл тәшкил иткән заманнарда (бүген моны тезелеп утырган тупыллардан, археологлар ачкан авыл урыннары һәм каберлекләрдән сизеләргә була), Олы Әмҗе буе бөтен Оса дәруги кешеләрен үзенә җәлеп итеп торган. Биредә, авыллар арасындагы иркен аклангарда да зур-зур җыеннар, ярминкәләр үткән.

Җыеннардан соң Сөҗән, Батырбай, Борежле һ.б. авылларда Җиләк җыены үткәрелгән. Ирән буе авылларында сабантуйлардан соң Тор авылында Җуа җыены үткәрелә торган булган.

«Пермские татары» дигән китапта кызыклы таблица китерелә. Анда рус авылларында була торган базар-ярминкәләр көннәрендә кайбер татар авылларында үтә торган үзенчәлекле бәйрәмнәр теркәлгән. Йанапай, Әри Тамак авылларында 20-22 сентябрьдә Козге Әри базары, Искәвыл (Карьево)да - декабрьдә Кышкы Микола, Кече Башанта - 1 октябрьдә Пукрау, 19 гыйнварда - Кышкы Ясыл базары, Озын Яланда - коз көне Куштамак ярминкәсе, Танып авылында 2 октябрьдә - Козге ярминкә исеме белән Сараш ярминкәсе, Сараш, Барда, Әрҗән авылларында Кышкы Никола көнендә (декабрьдә) - Каҗмакты ярминкәсе үткәрелә торган булган (19. 125-126 бб).

- Язгы чәчүдән соң үткәрелә торган сабан туйлары, җыеннар элек заманнарда икенче туйларның башы булып китә торган иде, - ди Барданың йөзләрчә яшьләренә гаилә корып яшәргә фатиха биргән Фатыйх ага Акманаев. - Егет кеше сабантуйларда, җыен, ярминкәләрдә кыз күзләп, танышып кайта да, ата-анасының ризалыгын алып, кызга яучы җибәрә. Ике якның да ата-анасы риза булсалар, туй турында сөйләшәләр. Элек бу туйлар җәйге эшләр беткәч, коз көне генә уздырыла иде. Өйләнешәбез

дип, яшьләр кешене җәйге кызу эшләрдән бүлмиләр иде. Яраштан кенә өйләнешәләр иде. Ата-ананың ризалыгыннан башка өйләнешү юк иде. Шуңадыр дим, аерылышулар сирәк буладыр иде. Сугыштан соң китте ул ата-анадан сорамыйча өйләнешүләр. Элек болай кушылуны урлап алу, ябышып чыгу дип атыйлар иде, гаеп санала иде (18).

Балаларның да үз бәйрәмнәре булган. Кайдадыр ул «Карга боткасы» дип, кайдадыр балалар сабантуе дип аталган. Ничек аталуына карамастан, балаларның үзара аралашу, тормышта үзләрен күрсәтү, тәҗрибә туплаулары булган (20).

Сабантуй, җыеннарны, әртилгә йөрү- кунаклашуларны милләтчелек, кешене эштән биздерү галәмәте дип тыйсалар, «Карга боткасы» үткәрүне, йомырка буяу кебек балалар бәйрәмнәрен совет балаларына соранып йөрү килешми дип тыйдылар, аның урынына урысларда киң таралган пекникка чыгуларны гадәткә керттеләр. Ә алар исерткечсез үткәрелми. Хәтта укучы балалар да андый чараларга шешә кыстырып чыгалар һәм моны аттестат юу дип атыйлар. Аракы белән үткәрелгән бәйрәмнең ни белән бетүен, нинди нәтиҗәләргә китерүен кабатлап торасы юк - барыбызның да күз алдында.

1936 елда СССР Верховный Советына сайлаулар үтә. 1922 елда сайлаучыларның дүрттән берсе генә, 1924 елда - 33 проценты катнашса, 1936 елгы сайлауларда 98,5 процент сайлаучылар катнаша. «Җиңүле социализм»ның Сталинчыл Конституциясе кабул ителә. Төп Закон совет кешеләренә күп төрле хокуклар вәгъдә итә, ләкин аларның күбесе кәгазьдә килеш кала. Мәсәлән, вождан иреге турындагы мәтдә кабул ителгәч тә бозыла: мәчетләр ябыла, дин әһелләренең күбесе «халык дошманы» дип игълан ителә. Тик бер Барда районында гына 54 мәчет, 5 чиркәү эшләүдән туктый. Бу исә яшьләрдә әхлак формалаштыру эшен тагын да кыенлаштыра, яшьләрнең олыларга булган ихтирамын төшерә, ике якны да терәксез-ярдәмсез калдыра.

## Чыганаклар:


1. КПСС в резолюциях и решениях съездов, конференций и пленумов ЦК. Часть II. 1924-1930 гг. М., 1954.

2. Ә.Г.Батыркаев, А.Н.Ездаков, С.Мостаев, Ә.Ф.Кантуганов истәлекләре.

3. Социализм юлы. 1931, 11 апрель.

4. Информационное письмо Бардымского РК ВКП(б) от 21 февраля 1931 г. ПГАНИОО, ф. 1603, оп.1, ед. хр.6, 18 стр.

5. Репрессияләнгәннәрнең эшләре. Район архивында сакланган папкалардан.

6. ВКП(б) райкомы өчен тозелгән анкетадан.

7. ВКП(б) ның Сарапул окружкомы карары. СГАНИОО, ф.4, оп.10, дело 5.

8. II район партҗыелышы карары. 1930 ел 29-30 октябрь.

9. ВКП(б) райкомы бюросы протоколы. 1932 ел 6 апрель.

10. Райархив. «Колхоз юлы» газетасы тупламалары (1931-1940).

11. Район газитенең ВДНХда катнашуы. ПГАНИОО, ф. 1603, оп.1, дело 179, кор.15.

12. ВКП(б) райкомының партия өлкә комитетына отчеты.

13. 1940 елның 17 февралендә үткән район партҗыелышы протоколы. ПГАНИОО, ф. 1603, эш. 153, кор.11.

14. И.Аптукаев, У.Г.Бадыгин истәлекләре.

15. Яраксыз метод, дошман стиле. Социализм юлы, 1937, 9 август; В Барде неблагополучно. Уральский рабочий. 1937, 11 август.

16. 1938 ел 25-27 апрельдә үткән гомум район партҗыелышы протоколы. ПГАНИОО, ф. 1603, эш 129.

17. Кәрим Әмири. Кайпан җыены. Идел. 1994, N 1.

18. Фатыйх Акманаев истәлекләреннән.

19. Пермские татары. Казан, 1983.

20. Н.Сафина, Р.Уразман. Доньяда иң тәмле ботка. Сөембикә, 1994, N 4.

# XI. «Бөтенесе - фронт өчен, бөтенесе - җиңү өчен!»

Халыкның болай да буталган тормышы 1941 елның җәендә янә асты өскә килә. 22 июнь иртәсендә радио сугыш чыгуын — фашистик Германия гаскәрләренең ил чиген бәреп кереп, зур территорияне бомбага тотуын, моторлаштырылган эре колонналар белән ил эченә һөҗүм башлавын хәбәр итә.

Бу көнне бер нәрсә белмәгән Барда халкы Тол буенда рәсми төстә гади ял көне, чыннлыкта Барда җыены булачак болынга агыла. Якын-тирә авыллардан атларга төялешеп килүчеләр дә байтак була. Өйләрендә радиоалгычлары булганнар, Тышкы эшләр комиссары В.М.Молотовның тетрәткеч чыгышын тыңлап, иртәнге чәйләрен дә эчеп тормастан, эш урыннарына, райсовет алдындагы мәйданга йөгерешә, җитәкче работниклар партия райкомында җыела. Райкомның беренче секретаре Махнутин, райсовет башкарма комитеты рәисе Вәлишин, рәис урынбасары Якупов кичтән елга буена балык кармакларга төшеп киткән булалар. Җиңел машиналары булган райком, хәзерләүләр инспекциясе һәм МТС шоферларын чакыртып алып, аларны Тол буена җитәкчеләрне эзләргә төшереп җибәрәләр.

Җыен буласы урыннан ерак түгел елга буенда эмка машинасы биргән озын-озак гудок тавышы ишетеп, бәйрәм итәргә килгән райком, райбашкарма, военком работниклары «тикмәгә түгел бу, бер-бер хәл бардыр», дип, шундук кайтыр юлга төшәләр һәм, райком инструкторы Бану апа Әхметшинаны очратып, хәлне белешәләр.

Елга буеннан җиңел машиналар әйләнеп кайтканчы ук райсовет алдындагы мәйданда халык, райкомда районның җитәкче работниклары, бюро әгъзалары җыелыша. Бюро район хәрби комиссары майор А.И.Пьянковның мобтелеграмма (мобилизацион телеграмма) алынуы, бүгеннән үк армиягә алулар башланачагы турында хәбәрен, беренче секретарьның бюро әгъзаларыннан кемгә нинди бурыч йөкләтелүен тыңлыйлар һәм барысы бергә халык алдына — мәйданга чыгалар. Митинг башлана. Ә төнлә белән райкомда бөтен район активистлары катнашлыгында киңәшмә уздырыла (1).

Иртәгесен район үзәгеннән җибәрелгән вәкилләр (политуполномоченныйлар) авылларда митинглар үткәрәләр. Ике көн эчендә 141 митинг үткәрелеп, аларда 16 меңләп кеше катнаша. Йөзләрчә кешеләр, фашизмны фаш итеп, үзләренең илне сакларга әзер торуларын белдереп чыгыш ясыйлар. Сараштан гражданнар сугышы партизаны, районның иң карт коммунисты И.Я.Горбунов «Мин өч ул үстердем, дүртенчесе үсеп килә, бүгеннән барысын да фронтка җибәрергә әзер. Кирәк булса, алар да җитмәсә, үзем китәрмен, илебезне дошманга бирмәбез!» дип белдерә (2).

Барда, Үдик һәм Сараш авылларында махсус билгеләнгән җыелу пунктларында армиягә алыначак кешеләрне теркәү, юлга әзерләү, командаларга билгеләү эшләре башлана (3).

Район буенча армиядә хезмәт итәргә срогы җиткән 1012 егет, төрле сәбәпләр белән отсрочка бирелеп килгән 1921 өлкәнрәкләр исәпкә алына. Аларның 815е строевойга яраклы дип табыла, биш егет хезмәткә җибәрүдән азат ителә, алар арасында өч егетнең сәяси-әхлак йөзе тотанаксыз дип табыла һәм алар җавапка тартыла. Бер литвалы, бер латыш үзләренең милли хәрби частьларына җибәрелә. 131 егет хәрби училищеларга, 4 кеше полковой школага, 35 коммунист һәм комсомолец хәрәкәттәге дивизияләрне тулыландыруга, 10 егет һава- десант гаскәрләренә, 20 егет чаңгычылар батальонына, 15 егет һәм кыз - радистлар курсына, һава һөҗүменнән саклаучылар хәзерләү мәктәбенә 26, элемтәчеләр итеп әзерләү өчен 20 кыз укырга җибәрелә (2).

Ил өчен үтә борчулы, дошман Мәскәүгә якынлашкан көннәрдә гариза биргән кызларны фронтка озатыр алдыннан Бардада зур кичә уздырыла. Бу кичәдә күп яшьләр катнаша һәм иртәгесен партия һәм комсомол райкомына гаризалар тотып яңадан-яңа яшьләр килә. Бу кичәнең үзәгендә йөргән Нажия Шәрипова, курс тәмамлап, сержант званиесе ала, хатын-кызлардан төзелгән 1 нче санлы ирекле укчылар бригадасында взвод командиры ярдәмчесе, Галия Нурсубина отделение командиры, Акбаштан Мәгъсумә Хәкимова, Әрҗәннән Зәкия Хәлилова (хәзер Таһирова) пулеметчылар булып Волоколамск тирәсен, аның тимер юл станциясен, күперләрен дошман самолетлары һөҗүменнән сакладылар. Башап Түздән Мөслимә Ижгузина Горький шәһәре янында Волга күперен саклауда торды. Ефрейтор Сәкинә Субакова һ.б. Рязань тирәсендә элемтәчеләр булып хезмәт итәләр (4).

Сугыш башланып ике атна үтүгә районда 420 һәм 450 кешедән торган ике команда әзер булып, аларның берсе Куеда станциясенә, икенчесе Оса пристанена озатыла.

Икенче, өченче агымда китүчеләрнең дә саны шуннан ким булмый.Кайбер көннәрдә район биш йөзгә кадәр кешене фронтка озата. Беренчеләр сафында коммунистлар, комсомолецлар китә. Райкомның 22 июньдә үткәрелгән экстрен бюросында ук 94 кешенең, шул исәптән 12 коммунист, 36 комсомол, 36 хатын-кызның фронтка җибәрүне сорап язган гаризалары турында белдерү ясала, шул ук көнне бу гаризалар ябык партия җыелышларында карала. Алар арасында райком, райсовет, МТС работникларыннан кергән гаризалар да була. Беренчеләр булып үз теләкләре белән фронтка җибәрүне сорап, райкомның оештыру бүлеге инструкторы М.Ш.Мәсәгутов, пропаганда бүлегеннән Ш.Гайнетдинов, инструкторлар Г.В.Гайнуллин, З.Сакаев, Б.Гарипов, район элемтә бүлеге начальнигы Д.А.Афанасьев, район газетасы редакторы С.М.Заварыкин һ.б. гариза язып керттәләр (2).

1941 елның ноябрь аена кадәр көн саен диярлек уңлап җитәкче работник фронтка китә. Сугыш башланып өч ай үтүгә күп партия оешмалары—

Шабарка, Зязелга, Батырбай, сентябрьдә Солтанай һәм Озын Ялан партия оешмалары я бөтенләй бетә, я кандидатлык группасы гына булып кала.

Мобилизациянең чагыштырмача оешкан төстә башлануын, призывникларның югары әзерлектә булуын районның беренче хәрби комиссары майор Пьянков болай аңлата:

«Ул елларда безнең халыкта илнең көченә ышану, патриотизм көчле иде. Моңа 1938 елда өлкә үзәгенең урыннарга якынаюы, Екатеринбургтан Пермьгә күчүе, һәр районда хәрби комиссариатлар оешу һәм хәрби учениеләр үткәрү нык ярдәм итте. 1938 елга кадәр биш ел эчендә грамотасы җитәрлек булмау һәм авыру (трахома) сәбәпле 140-150 кеше хәрби хезмәткә яраксыз дип табыла, йөзгә якыны ярым- йорты гына грамоталы, трахома белән авыраучы 98 призывник исәпкә алына. Аларны укый-язарга өйрәтү өчен Яңа Башап урман участогында, кап сугу остаханәләрендә кыска сроклы курслар ачыла, кайбер призывниклар мәктәпләргә беркетелә. Трахома белән авыраучы призывникларны дәвалау өчен район шифаханәсендә 25 койка бүленә, трахоманың авыр формасы белән зарарланганнар Свердловскига җибәреп дәвалана.

Бер үк вакытта призывникларны сборный пунктларда җыеп, хәрби хезмәткә өйрәтүләр оештырыла. Башлангыч әзерлек үткәннәр Бикбардада оештырылган лагерьга озаграк сроклы учениегә җибәрелә. Яшьләрне өйрәтү буенча Осоавиахим (рәисе С.А. Афанасьев), авыл активистлары зур эш башкара. Авыл советлары каршында ике атналык, җәй көннәрендә унар көнлек укулар оештырыла.

1940 елда хәрби билетларны алмаштыру, армия хезмәтенә яраклыларны яңартып учетка алулар үткәрелә. Бу эшне Барда, Сараш һәм Үдиктә оештырылган өч пункт башкара. Аларның эшен һәркөн военком ярдәмчесе капитан В.З.Гусев йөреп тикшереп тора (3).

Кыскасы, бөтен ил белән бергә безнең район да сугышка әзерләнә. 1941 ел башына барлык колхозларга, МТСларга хәрби комиссариат приказы буенча армиягә җибәрергә әзер трактор, автомашина, арба, дирбия хәзерләү бурычы йөкләтелә, һәркайсына план төшерелә. Фронтка җибәрердәй пар ат җигүле беренче ат арбаларын Озын Яланда Әхмәй Иткинов ясый. Ул ясаган арбалар бөтен район өчен үрнәк ролен үти. Әхмәй абый ясаган арбалар тирәсендә семинарлар үтә, аны җигеп Әхмәй абый район үзәгенә дә килә. Олы яшьтә булуына карамастан, арба ясау остасын армиягә дә алалар. Сугыш беткәнче ул Чиләбе заводларының берсендә тимерче булып эшли (5).

Ул елларда арба ише нәрсә ясый белүчене табуы җиңелдән булмый. Сугыш кырында файдаланырдай трактор, автомашина әзерләү тагын да кыенракка туры килә - ремонтлау өчен запчасте, әзер техниканы үз хуты белән станциягә илтү өчен рәтле юлы юк. Кыш көне буран баскан юлдан Куеда станциясенә алып чыгу өчен трактор, автомашинаны узелларга бүлгәләп, һәркайсын өчәр ат чанасына салып, тимер юл станциясенә илтеп җиткерергә, анда аларны янгын депосына кертеп бергә җыярга һәм платформага төяп озатырга кирәк була.

— Юлы булмагач, тиешенчә ремонтлап җибәргәне дә кушылган срокка билгеләнгән урынга барып җитә алмый. Бер вакыт Пермьгә җибәрелгән машиналарны коч-хәл белән эзләп таптык. Пермьнән: «Кайда җибәргән машиналарыгыз?» дип шалтыраталар. Военком Пьянков, ярдәмчесе Гусев белән киттек эзләп. Осада юк. Һәр авылда сорашып барабыз. Өшеп-туңып эзләнә торгач, таптык боларны - ватылганнар. Кире алып кайтып, яңадан ремонтлаттык, яңадан җибәрдек (1).

Сугыш елларында МТС кешесе кем генә булып эшләмәгән, ниләр генә ясамаган! Запчасть юк дип, аның каяндыр китерелүен көтеп утырмаганнар: МТМ мөдире Шачком Александр Петрович, механик Иван Алексеевич, токарь Окулов, радиаторчы Фатих Зәетов, слесарь Суяргулов, яңа институт бетереп кайткан баш инженер Д.Ф.Ланцев җитәкчелегендә шестерня, гусеница-чылбыр бармакчасыннан алып кружка-кофейник ише нәрсәгә кадәр үзләре эшләгәннәр.

— Бер вакыт Гайвага трофейный техника килә башлады. Пермьдә, авыл хуҗалыгы идарәсендә әйтәләр: «Бар шунда, кара, бәлки үзегезгә кирәк нәрсә табарсың», диләр. Киттем, Орджоникидзе заводы директоры белән сөйләшеп, аннан баржа алдым да төяттем шуны тулганчы. Осага кадәр су буйлап, аннан машиналарда әллә ни кадәр әйбер кайтты, — дип искә ала Усман Гыйльманович.

— Сугыш еллары нык сакчыллыкка, юкны бар итәргә өйрәткән иде. Хәзер менә шуны кирәксенмиләр, топ-төзек детальләрне чүп- чарга чыгарып ташлыйлар. Искергәнен реставрацияләү турында әйтеп тә торасы юк. Бер литр ягулыкны артык тоткан шофер, тракторчы җавапка тартыла иде. Ә хәзер трактор, комбайн белән «ярты» эзләп чабалар. Эшмени бу! Берсен бер җавапка тартучы юк.

Шулай ачынып сөйли сугыш елларында Барда МТСы директоры булып эшләгән һәм үзе дә ярыйсы гына җитди җаваплылыкка тартылып йөртелгән Усман Гыйльман улы Бадыгин.

Барда МТСы хәбәр килү белән 40 СХТЗ, 18 газогенераторный, 2 НАТИ, 6 ЧТЗ тракторларын фронтка җибәрердәй хәлдә тота, икесен җибәрә. НАТИларын Украинага җибәргән Бикбарда МТСына 18 трактор бирә.

1941 елның июль аенда райбашкарма комитет рәисе К.К. Миңнуллин, Осоавиахим советы җитәкчесе (барлыгы тугыз кеше) составында ПВО һәм ПВХО район штабы төзелә. Аның начальнигы итеп район милиция начальнигы Г.Фатыйхов билгеләнә. Штаб армиягә алыначак бар халыкны мәҗбүри хәрби хезмәткә өйрәтү эшен җәелдерә. Район үзәгенең партия, совет һәм хуҗалык активы аерым взвод тәшкил итә һәм ул киңәйтелгән программа буенча укытыла. Сугыш эшләренә өйрәтү белән авылларда иллеләп коммунист, 140лап ВЛКСМ әгъзасы шогыльләнә. Әрҗәннән Үзәкәев, Каенавыл советыннан Х.Кадрматов күп значкистлар әзерлиләр һәм өлкә советы башкарма комитеты грамоталары белән бүләкләнәләр (2).

Сугыш елларында бөтен эш картлар, хатын- кызлар, үсмерләр өстенә торып кала. 1944 елдан 80 колхоз рәисенең унбише хатын- кызлардан, бригадирларның 30 проценты, хисапчы-бухгалтерларның яртысы хатын-

кызлардан була. Райсовет башкарма комитетының барлык бүлекләрендә, потребсоюз идарәсендә хатын-кызлар гына эшли. Райместхозны Рәхимә Акжигитова, Акбаш, соңрак Барда авыл советын Нәгыймә Кучукбаева, «Алга» колхозын Сафия Мушакова җитәкли, аны Сария Кәбирова алмаштыра (6).

Сугыш елларында райком секретаре булып эшләгән Әхмәтҗан ага Акжигитов шундый хәлләрне искә ала:

«Кайбер колхозларда бер ир заты калмады. «Боец» колхозында (Караул авылы) председательдән алып тимерлектә эшләүчеләргә кадәр хатыннардан куелды. Жебрейка авылының «8 Март» колхозы председателе сугышка китә, аның урынына башка кеше куярга кирәк. Җыелдылар, ә куярлык кеше юк. Утыра торгач, колхозчылар җыелыш барган йорт хуҗасының исемен әйттеләр:

— Бу җыелышка безне син җыйдың, әйдә, Евдокия Петровна, колхозны үз кулыңа ал.

Мондый сүзне ишетеп, мич башында яткан Азанова үкереп еларга тотынды. Тавышка куйгач, әтисе, әнисе дә яшь агыздылар.

Башка чара юк иде - елатып булса да сайладылар, һәм шуннан алып Азанова өчме- дүртме ел колхозга җитәкчелек итте. Һәм начар да эшләмәде» (7).

Трактор һәм комбайннарда да күбесенчә алар эшли. Әрҗәннән Рәйхәнә Мөстәкыймова, Рәхилә Сәбәләевалар, Солтанайдан, Гайникамал Атнабаева (Исмәйгыйлова) Бардадан Гарифә Хәсәнова, Күгиядән Гөлсәмига Димасова, Үдиктән Мөнибә Абдалова, М.Котлыбаева, Иске Чаттан Н.Бәширова, В.Балтаевалар, Сүзедән Мәрзия Ласина, Шермейкадан С.В.Куланова, З.И.Бабушкина, А.И.Курицына һ.б. бөтен сугыш елларында әйдәп йөрүче алдынгылар булалар.

Өлкә Советы һәм партия өлкә комитетының 1943 ел 30 гыйнвар карары нигезендә өлкәдән йөз трактор, аларда эшләү өчен өч йөз тракторчы, ун механик, ун агроном, 30 бухгалтер, ун МТС директоры Ростов өлкәсенә җибәрелергә тиеш булып, Барда районыннан Гөлсәмига Димасова (Күгия), Федор Родионов (Антуфьево) тагылма кораллары белән тракторларын үз ходы белән Пермь шәһәренә илтеп куялар.

1935 елда ук тракторчы белгечлеге алып, яхшы эшләгәне өчен Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә дә катнашкан Фатимә Хәмзинә (Тауавыл) сугыш елларында үзе берничә хатын-кызны тракторда эшләргә өйрәтә (6).

Барда МТСы алдынгылары Мөнибә Абдалова, Вәсимә Мусина, Галия Батыркаева 1942 елның 20 сентябренә 198 гектар урынына 326 гектар җир сөрәләр, 230 кг ягулыкка экономия ясыйлар. Фатимә Хәмзина «8 Март» колхозында 386 гектар җир сөрә, 589 кг ягулыкны экономияли. Комбайнчы Мөслимә Абдалова (Үдик) 1941 елда 200 гектар иген ура, 30 тонна ашлык суктыра. Шофер Клавдия Гусева, тракторчы Сөгъдә Иманаева, Вера Варовалар да мактауга лаек, дип яза район гәзите 1942 ел 30 сентябрь санында.

Лəкин күпме генə тырышсалар да сугыш чорының кырыс планнарын үтəү җицел булмый. Башка чарасын таба алмагач, күп колхоз җитəкчелəре тупас алымнар куллануга: эшкə чыкмаганнарны, нормаларын үтəмəгəннəрне кыйнау, йорт киртəлəрен җимерү, əзерлəгəн печəн-саламнарын талап алу, штраф салуларга тотыналар. Район җитəкчелəре исə кисəтү урынына аларны еш алмаштыру белəн хəлне төзəтмəкче булалар. 1943 елның июнендə партия өлкə комитеты «Барда районында язгы чəчүнең канəгатьлəнерлек булмавы турында» карар кабул итə. Тагын бер елдан комитет җибəргəн комиссия районда күп кенə закон бозу фактларына тап була. Мəсьəлə янə өлкə комитетта тикшерүгə куела. Колхоз җитəкчелəренең колхозчылар белəн тупас мөгамəлə итүлəренə, кыйнау, штраф салу, тентү белəн мавыгуларына күз йомганнары, кисəтү урынына «каты куллыларны» мактау юлына басканнары өчен райком секретарьлары Ш.Шəйхетдинов һəм Ə.Акҗигитовларга өлкə комитет бюросында җитди кисəтү ясала, ə беренче секретарь А.И.Махнутин эшеннəн алына. Җинаять җаваплылыгына тартылучылар да була. (8. 1-50 бб).

Шуның белəн бергə районның уңай эшлəре дə күренми калмый. Яшь механизаторларның, комсомолларның сугыш елларындагы тырышлыгы, мəсəлəн, ВЛКСМ Үзəк Комитетының Мактау грамотасы белəн билгелəнə. Фронт фондына акча җыюда активлык күрсəткəн авыл советларына, предприятие коллективларына, аерым кешелəргə Верховный башкомандующий Сталин исеменнəн язылган рəхмəт хатлары, телеграммалар килə.

Район халкыннан танк колоннасы, самолет эскадрильясе төзүгə акча җыела. Укытучылар «Халык укытучысы», укучылар «Яшь патриот» дигəн самолет эшлəүгə, колхозчылар «Колхозница» дигəн танк колоннасына акча җыялар. Барлыгы район кешелəре фронт фондына өч миллион сумнан артык акча җыеп тапшыралар. Моннан тыш алар, Төньяк-Көнбатыш фронтның шефлары буларак, җылы кием: тун, бияләй (өчбармак), киез итек, оекбаш хəзерлилəр һəм посылка итеп җибəрəлəр. Колхозчылар 1941 елда гына 56 мең хезмəт көннəрен, 1413 центнер икмəк, 84,4 центнер сөт, 135 центнер бəрəңге һ.б. төр продуктлар тапшыралар.

«Алга» колхозы əгъзасы, соцрак рəисе Сафия Мушакова бирүзе 8 мең сум акча, «Кызыл Октябрь» (Түбəнавыл) колхозыннан Х.Кадрматов 1942 ел өчен алган бөтен икмəген (19,5 пот) фронт фондына тапшыра. Алар үрнəгенə башкалар иярə (2).

Җирле промышленность предприятиелəре (промартельлəр, промкомбинат,райлеспромхоз) махсус заказлар үтилəр: 1942 ел башына алар фронтка 10 мең пар чаңгы, 4 меңнəн артык агач көрəк, меңгə якын чана, 281 мең кап, 300 лəп дуга, палатка кору өчен 9 меңнəн артык казык- терəткеч, 25 мең данə көрəк сабы, байтак күлəмдə кашык һ.б. əйберлəр ясап җибəрəлəр.

Район армиягə биш мең баштан артык ат, 26 автомашина, берничə трактор бирə. Эш көчлəре кими бара, ə бурыч артканнан арта. СССР Совнаркомы һəм ВКП(б) Үзəк Комитетының 1941 ел 17 ноябрь карары белəн район, төп планнан тыш «оборона фонды»на дигəн задание үтəп,

чәчү җирләрен киңәйтергә тиеш була. 1940 ел белән чагыштырганда, 1942 елда 3 мең гектарга күбрәк иген чәчелә.

Сугыш башланып өч ай үтүгә фронт зонасыннан эвакуацияләнгәннәр килә башлый. 1945 ел башына аларның саны 3 меңне узып китә. Барда урта мәктәбе Ленинградның 298 нче санлы интернат- мәктәбен кабул итә. Куйбышев-Совет урамнары чатындагы асты таш, өсте агач ике катлы бинада ике йөздән артык укучы урнаштырыла. Алар белән бергә Бардага интернат-мәктәпнең директоры Р.К.Левицкий, укытучылары һәм тәрбиячеләре дә килә. Блокададагы шәһәр балаларының Бардадагы тормышы турында пенсиядәге укытучы Ф.Ш.Юлаева белән сугыш елларында Тимур командасы җитәкчесе Д.Н.Плешивых күп хатирәләр саклыйлар. Фәридә Шиһабетдинова элекке коллегалары, укучылары (хәзер инде үзләре дәү әни һәм дәү әтиләр) белән күп еллар хат алыша, очрашулар оештыра (ул туплаган материаллардан бүген матур гына бер музей оештырырга мөмкин).

Эвакуациядә булганнарны әле сугыштан соң да очратырга мөмкин иде. II Әрҗәндә партоешма секретаре булып эшләгән Надежда Степановна Орлованы, Әрҗән сельпосы рәисе Л.Г.Петрованы күпләр белә торганнардыр. Югары эрудицияле, бай тәҗрибәле, төрле профессиягә ия кешеләр кайда эшләсәләр дә үзләре турында тик уңай фикер калдырдылар.

1943 елның февраль аенда Урал хезмәтчәннәре Дәүләт оборона комитетына планнан тыш берничә йөз танк эшләп, шулардан ирекле танк корпусы төзергә рөхсәт сорап мөрәҗәгать итәләр. Аларның бу үтенече канәгатьләндерелә. Хәбәр таралу белән хәрби комиссариатларга, махсус төзелгән комиссияләргә гаризалар ява башлый. Бардада 58 кеше гариза бирә: милиция бүлегеннән 12, райсовет хезмәткәрләреннән 10, партия райкомыннан 4, Барда МТСыннан 13 кеше (директоры, замполиты, мастерской- работниклары,тракторчылар), укытучылар (Уймуждан Халидә Имайкина, Бардадан Рәйсә Рәхимова) һ.б. гариза бирә. Комиссия аларның тик өчесен: Барда МТСы тракторчылары Әмин Алешкин белән Минимулла Йосыпов һәм Сараш МТСы өлкән механигы Габдрахман Илкәевны сайлап ала. Тагын унберенә медицина комиссиясе үтәргә рөхсәт ителә (9).

Ирекле Урал Танк корпусы Орел-Курск дугасында сугышка керен, Берлингача канлы юл үтә, баш күтәргән Прага хезмәтчәннәренә ярдәмгә ыргыла һәм аларга халык власте урнаштырырга булыша. Урал Танк корпусында Үдиктән укытучы Сәлим Арзыев, Искирдән Сәгыйт Кульмашев, I Әрҗәннән Закир Таһиров, Өчкулдан Әсхәт Яхин, Озын Япаннан Вәсил Тляшев, Бакчавылдан Гаделгәрәй Уразов, Сәмикъ Балтаев, Илал Назаровлар, Иске Чаттан Сәетсәлим Кузаев фронтның иң кызу участокларында канлы сугышлар алып баралар. Ирекле танк корпусы оештырылганда аларның барысы да Березники шәһәрендә ТЭЦ та һәм химия заводында эшлиләр, шунда гариза бирәләр һәм корпуска алыналар. Аларның күпләре сугыш кырларында ятып калалар. Әсхәт Яхин 1944 елның декабрендә Венгрияне азат иткәндә, Минулла Йосыпов 1944 елның 1 августында госпитальдә үлә һәм Смоленск шәһәре зиратында җирләнә. Орел-Курск дугасында барган танклар алышы вакытында каты яраланган

күзәтүче-хисаплаучы Сәлим Арзыев елдан артык госпитальдә ятып, ике авыр операция кичерә һәм II группа инвалид булып өенә кайта. 40 елга якын мәктәптә балалар укыта, туган авылының тарихы буенча бай материал туплап, музей эшләп калдыра, 1965 һәм 1985 елларда корпус ветераннары белән очрашуларда катнаша һәм 1993 елда дөнья куя (10, 11).

Сугышның беренче елында 952 кеше (115 коммунист, 149 комсомолец, 38 хатын-кыз) халык ополчениесенә языла. Ополченецлар, корал тотып, җәмәгать милкен, иген кырларын, авылларның тынычлыгын саклыйлар, НКВД, военкомат хезмәткәрләренә дезертир-качкыннарны ачыклауда һәм җавапка тартуда булышлык итәләр.

Бөек Ватан сугышы фронтларына районнан барлыгы җиде меңнән артык кеше китә. Кара диңгез, Кавказ тауларыннан алып Төньяк боз океаны ярларына кадәр җәелгән фронтның кайсы гына участогында, нинди генә частьдарда сугышмады икән алар. Ватаныбызның азатлыгы, кешелек дөньясын фашизм коллыгыннан коткару өчен кайларда гына башын салмады икән Гәйнә иле кешесе!

Районнан фронтка киткән җиде мең кешедән 4345е «Хәтер китабы»на кертелгән. Шул кадәр улларын югалтты район. Алар сугыш кырларында, чит-ят җирләрдә ятып калды. Бу 4345 кешенең 2391енә карата «Хәтер китабы»нда «билгесез югалды» дип язылган — аларның каберен дә, соңгы язмышын да белүче юк. Ватаныбыз азатлыгы өчен гомерләрен биргәннәрне ачыклау дәвам итә. «Хәтер китабы»на яңадан йөзләп исем өстәлер дип көтелә. «Билгесез югалганнар»дан кайберләренең исән-имин өенә кайткан булуы, чит илләрдә яшәп ятуы ачыкланырга мөмкин.



Ике меңнән артык сугышчының фронтларда күрсәткән батырлыклары орден-медальләр белән билгеләнә. Сараш егете комсомолец **Шәрифҗан Казанбаев** Советлар Союзы Герое дигән исемгә лаек була. Бу бөек исем аңа гвардиячеләр байракларын дошман кулына төшүдән саклап калганы өчен бирелә. «Үлмәс чәчәк» дип атады аны шагыйрь Мостафа Ногман. «Үлмәс батыр» дип язалар аның турында Молдавия журналистлары. Туган авылы Сараштa һәм Молдавиянең Чеколтен авылында аңа һәйкәлләр куелды (12, 13).

1944 елның март башларында Украинаның өч фронты уңышлы һөҗүм башлый, фашистларга төрле юнәлештә аяусыз ударлар ясый. Буг, Днепр елгаларын кичеп, 21 мартта безнең гаскәрләр Молдавия территориясенә барып керәләр. Шәрифҗан хезмәт иткән 6 нчы гвардиячеләр дивизиясе дә алга бара. 1 апрельгә каршы төндә Казанбаев хезмәт иткән 14 нче полк дошман тылына үтеп керә һәм немецларга сугыш кирәк-яраклары ташый торган Кишинев-Черновцы юлын бүлә, Чеколтен авылын ала. Немецлар көннең икенче яртысында, һушларына килгәндәй, 5 транспортер, ике танк, 400 солдат белән контратакага күтәреләләр. Полк аларның беренчә атакасын кага. Дошман яңа көчләрен, мотоциклчылар группасын сугышка кертә. 14 нче полк штабына камалышта калу куркынычы яный. Комендант взводы, аның составындагы Казанбаевның байракчылар отделениесе дә ярсыган дошманнарга автоматтан ут яудыра. Немецлар якынайгач, полк штабы начальнигы майор Фарберов байракчыларга камалыштан чыгарга приказ бирә. Ләкин байракчылар бер-бер артлы һәлак булалар. Ахырда Шәрифҗан бер үзе кала. Ике байракны (һава-десант бригадасының хәрби кызыл байрагы да анында була) дошманга бирмәс өчен, аларны җиргә күмә һәм, шул җиргә ятып, атуын дәвам итә. Байраклар өстендә яткан килеш тә ул дошманның 14 сугышчысын атып үтерә һәм шунда аңын югалта, ләкин байракларның кайда икәнлеген аңлатып өлгерә (14).

Районның ике батыры — Солтанайдан Зариф Хурамша улы Әминов, Түбәнавылда туып-үскән Әхәт Габделхәй улы Даутов Дан орденнарының тулы кавалерлары булып кайталар.



**Зариф Әминов** легендар генерал Шәйморатов командалыгындагы Башкорт атлылар дивизиясендә сугыша, 45 мм.лы орудие командиры була. Курск, Белгород, Балтик буенда барган сугышларда, 1944 елның җәендә Витебск янында «Багратион» операциясендә катнаша. 1944 елның 23 гыйнварендә ясалган уңышлы һөҗүм — дошманның корал тоягән 3 йөк машинасын, унбиш солдатын юкка чыгарганы, яралангач та дошман өстенә ут яудырудан туктамаганы өчен аңа III дәрәҗә Дан ордены, шул ук елның 22 июнендә дошманның пулемет ноктапарын юк итеп, пехотага Сиротин авылын бер югалтусыз алырга, 26 июньдә һөҗүм итүче частьларга Көнбатыш Двина елгасын уңышлы кичәргә ярдәм иткәне өчен II дәрәҗә, 29 июньдә дошманның көчле атакасын кире кагарга, 31 июньдә өч җиңел машинасын, ике тягачын, бер миномётын һавага очырганы, 22 солдатын юк иткәне өчен, шулар өстенә автоматтан атып янә 6 гитлерчыны юк иткәне өчен 1945 елның 24 мартында I дәрәҗә Дан орденнары белән бүләкләнә.

Болардан тыш Зариф ага Белгород юнәлешендә һөҗүм иткән дошманның 3 танкысын, Балтик буе сазлыкларында ике пушкасын, оч дзотын топчыктыра. 1945 елның 1 маенда часть байрагы янында фотога төшә — фронтовиклар белә: аның бусы да — зур бүләк (15).

З.Әминов 1939 елгы фин сугышында Маннергейм линиясен өзүдә дә катнашын, анда күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл байрак ордены белән бүләкләнә.



Гвардия өлкән сержанты «ИС-122» танк орудиесе командиры **Әхәт Габделхәй улы Даутовны** полкта «танк пушкасы снайперы» дип йөртәләр. 3 нче санлы гвардия танк армиясе составында ул Берлинны штурмлауда, баш күтәргән Прагага марш-бросок ясауда катнаша. Эльба ярларына җитеп, союздаш армияләр сугышчылары белән очраша (11, 6 б).

Районның оч батыр сугышчысы Дан орденының II һәм III дәрәҗәләре, 54 кеше — III дәрәҗәсе белән бүләкләнә (шунда ук).

Федорки авылыннан Галимҗан Мурадимов II һәм III дәрәҗә Дан орденнары, «Кызыл Йолдыз», Бардадан Әхмәдиша Бохаров — III дәрәҗә Дан, «Кызыл Байрак» һәм «Кызыл Йолдыз», Габделбәр Акбашев — ике «Кызыл Байрак», I һәм II дәрәҗә «Ватан сугышы» орденнары, Польшаны азат итүдә катнашкан Муллануp Тимганов — «Кызыл Йолдыз», I һәм II дәрәҗә «Ватан сугышы» орденнары, Биҗан Мирсәет улы Мостәкыймов — Берлинны алганда күрсәткән батырлыклары өчен «Александр Невский», Прага өчен «Кызыл Йолдыз» орденнары белән бүләкләнә. Рота, батальон комиссары, полк парторгы Нәзи Гәрәй улы Юсуфкулов Сталинград, Ленинград фронтларында, Эстония, Латвияне азат итүдә катнаша, ротадан оч-җиде кеше калган чаклары була, ә ул исән-имин кайтып керә, аның күкрәген «Кызыл Байрак», I дәрәҗә «Ватан сугышы» орденнары бизи.«Мәскәүне обороналаган өчен», «Варшаваны азат иткән өчен», «Берлинны алган өчен» — болары сугышның башыннан ахырына кадәр кичергән «Кызыл Йолдыз» ордены кавалеры Байназар Маннаф улы Юлаевның сугыш юллары. 1975 елда Пермьдә «Письма с фронта» 1941-1945 гг.» дигән китап басылып чыкты. Анда Б.М.Юлаевның да ике хаты урнаштырылган.

Бөтен бер район кешеләренә бирелгән орден-медальләрне санап бетерү мөмкин түгел һәм бу кирәк тә түгелдер. Совет кешесе орден-медаль өчен утка-суга кермәде бит. Шулай да минем тагын бер медаль (орден түгел, фәкать медаль!) хакында берничә сүз әйтәсем килә. Пермь краеведение музеенда саклана бу медаль монета сарайларында меңәрләгән данәдә штампланганнардан түгел. Урманнарда күчереп йөртелгән тимерлектә кул-

дан чүкеп эшләнгән ул. Саф көмеш тәңкәнең ал ягына йолдыз ясалган, «За храбрость» («Кыюлык өчен») дигән, ә артына «К.К. Рокоссовский исемендәге партизаннар бригадасы» дигән сүзләр язылган. Музейга бу үзенчәлекле медальне 1948 елдан 1962 елга кадәр Барда районында райсовет башкарма комитеты рәисе һәм райкомның беренче секретаре булып эшләгән Шәйхелислам ага Нигъмәев тапшырган (дөресрәге, тапшырттырганнар). Дистәләгән орден-медальләре арасында аның өчен бусы — иң кадерлесе.



Сулда — Ш.Н.Нигъмәев (1960 елда төшкән фото).

1984 елда Белоруссиянең азат ителүенә 40 ел тулган көннәр. Витебск өлкәсе Рассоны район үзәгендә очрашу вакытында фашистлар оккупациясе вакытында җәзалап үтерелгән партизаннарга һәйкәл-паркта төшерелгән фото. Алгы рәттә - К.К.Рокоссовский исемендәге партизаннар бригадасы командирлары. Сулдан икенче — бригада комиссары Ш.Н. Нигъмәев, аның белән рәттән — бригада командиры.



Адыевка авылында туып-үскән генерал-майор **Анатолий Федорович Картапов**, Озын Яланнан атказанган хәрби штурман дигән мактаулы исем йөртүче, күп еллар ДОСААФ Үзәк Комитетында эшләгән **Хәмзә Гарифел улы Иткинов** белән дә горурланырга хаклы без. Алар икесе дә сугышның беренче көннәреннән фронтта махсус заданиеләр үтәгәннәр. Дошман башкалабыз Мәскәүне басып алу белән янаганда Х.Г.Иткинов дошман тылына очышлар ясаган, фашистларның хәрби объектларына бомбалар яудырган.

1942 елның язында Калинин фронты штабы **Ш.Н.Нигъмәевны** махсус отряд составында партизан хәрәкәте оештыру өчен дошман тылына җибәрә. Отрядта командирның авылдашы - Түбән Септәй Әхмәтзыя Сафин, Ворошилов исемендәге күрше бригадада Искирдән Гомәров та була. Берничә отрядтан К.К. Рокоссовский исемендәге бригада оешкач, Шәйхелислам ага аның комиссары итеп билгеләнә. Ике ел эчендә ике йөз километрга сузылган территориядә 1600 кешедән торган бригада дошманның 4340 солдатын һәм офицерын, 480 полицаен юк итә, 20 тимер юл күперен, 317 шоссе юлы күперен сафтан чыгара, 54 тимер юл эшелонын мәтәлдерә (16).

Партизаннар бригадасы комиссары һәм бер үк вакытта подпольедагы Россаны райкомы әгъзасы Ш.Н.Нигъмәев турында «Белоруссия совет энциклопедиясе»ндә, «Белоруссиядә немец-фашист илбасарларына каршы ботенхалык көрәше» дигән өч томлык китапта күп мактау сүзләре язылган, турыдан-туры аның җитәкчелегендә башкарылган диверсион актларның, аларны башкаручыларның фотосурәтләре басылган.

Сугыш һәм хезмәт ветераны Шәйхелислам Нигъмәй улы әле бүген дә алгы сафта: Пермь өлкәсенең татар-башкорт иҗтимагый үзәге бүлегенең совет әгъзасы, Пермь шәһәре татарларының аксакаллар шурасы рәисе буларак, сигезенче дистәсе белән баруына карамастан, актив эш алып бара.

Никольскида туып-үскән хәрби очучы генерал-майор **Анатолий Федорович Картапов,** Озын Яланнан атказанган хәрби штурман дигән мактаулы исем йөртүче, күп еллар ДОСААФ Үзәк Комитетында эшләгән Хәмзә **Гарифулла улы Иткинов** белән дә горурланырга хаклы без. Алар икесе дә сугышның беренче көннәреннән фронтта махсус заданиеләр үтәгәннәр. Дошман башкалабыз Мәскәүне басып алу белән янаганда Берлинга очышлар ясаганнар, фашистларның хәрби объектларына бомбалар яудырганнар.

Районнан алты сугышчы (Бардадан Мәлик Мухайлов, Биҗан Апков, А.И.Вострецов, Иске Чаттан Ганләхәт Суяргулов, Озын Яланнан Кәшфулла Абдулов...) 1945 елның 24 июлендә Мәскәүдә Кызыл мәйданда үткәрелгән Җиңү парадында, күпләр (мәсәлән, Сараштан Кәлим Ижбулатов) сугышта зур борылыш ясаган әһәмиятле плацдармнарны алу хөрмәтенә һәм Җиңү көннәрендә салют бирүләрдә катнашканнар. Без аларның да исемнәрен белергә тиешбез. Парадта һәм салют бирүдә катнашырга кандидатлар сайлаганда да иң югары орденнарга тәкъдим иткәндәге кебек үк нык таләпләр куелган: шәхсән үзләре дә, алар хезмәт иткән частьлар да сугышта күрсәткән батырлыклары белән, аерым кешеләре буй-сыннары белән башкалардан аерылып торырга тиеш булганнар.

Кызганычка каршы, җиңү яулаучыларның күпчелеге бу Җиңүне күрә алмады. Тик бер Барда районыннан киткән җиде мең кешедән 4345 е - 60 процентган да артыгы - өйләренә әйләнеп кайта алмады, сугыш кырларында ятып калды һәм бүген аларның күбесенең (4345 тән 2391енең) кайда ятып калганлыгын, җирләнгәнме икәнлеген дә белгән кеше юк. «Хәтер кенәгәсе»ндә алар «билгесез югалган»нар булып йөри. Алар исеме астына шундый сүзләр язылган. Бусы, минемчә, безнең ил кичергән иң

зур фаҗигадыр. Сугышның башында, тәртипсез рәвештә чигенергә дучар ителгән чакларда гына түгел, ә җиңүчеләр тосендә дошманны куып барган чакларда да «билгесез» югалучылар күп булган. Үлгәннәрне генә түгел, исәннәрне дә онытып калдыру очраклары күп булган. И.Шарыгин «Без Берлинны алдык» дигән кызыклы хатирәсендә «Атналар буена кайнар аш күрмәгән чаклар булды», дип яза (17). Атналар гынамы?!

Бөрежледән Гайса ага Уртаев сугышка кадәр Колыма-Камчатка лагерьларында эшли, сәяси тоткыннарны эшкә йортә. Сугыш чыккач аны, аның белән бергә эшләгән яисә тоткынлыкта булган күпләрне фронтка җибәрәләр. Курск тирәсендә оборонага куялар һәм ... аларның барлыгын да оныталар. Кайнар аш белән кухня түгел, коры паек та китермиләр. Ачка җидәшкән солдатлар чиратлашып тирә-юньдә ни дә булса табарга өметләнеп эзләнәләр. Кайда үлгән ат табып, шуны кискәләп алып кайталар, адашкан сыер яисә мал очраса, ул көнне алар өчен бәйрәм була.

Акбаштан сугышның икенче көнендә өеннән чыгып китеп, сугыш беткәч тә әле байтак вакыт кайтарылмый йортелгән Кәлим Әширов та шундый ук шартларга эләгә: кар астыннан чыккан үлгән ат та, башка тор малы да калмый, утын яркасы белән салам сугып ачтан үлмәскә тырышалар. Дошман пулясыннан түгел, ә ачтан кырыла солдатлар. Немецлар күргән аларны: «рама»дан «Сезнең Сталинга кирәгегез юк,-бирелегез!» дип листовкалар ташлаганнар, ә үзебезнекеләр өч ай буена аларны күрмәгәннәрбелмәгәннәр.

Күпләрне фронтка алып киткән җирдән айлар буена поездларда сәфәр кылдырганнар. Бардадан Мөэминов Гайса аганы 1938 елда действительныйга алалар. Ерак Көнчыгышта авиадесантныйда хезмәт итә. 1939 елда десантчыларны фин сугышына алып китәләр. Барсалар, сугыш беткән. Аларны янә ботен ил буйлап кире Хабаровскига алып китәләр. Килгәндә ай да ун көн, кире кайтканда - бер ай. Шунда авиадесантчыларны шоферга укыталар. Укуларын тәмамлап, бераз командирларны йортеп калалар. Кыш җитүгә танковый училищега җибәрәләр. Укып яткан җирдән танк-пехота десант полкы составында янә конбатышка алып китәләр. Мәскәү тирәсендә сугышка кертәләр. Тула янында уноч көн камалышта ятканнан соң Украина фронтына күчереләләр. Авиадесантчы шофер-танкист яраланып, Харьков өлкәсендәге Дергачи поселогында урнашкан госпитальгә эләгә. Һәм бүген шул госпитальдә ятканлыгына белешмә алам дип янә «ил гизә» - архивларга хатлар яудыра. Ләкин кая гына язса да, «Син яткан 1417 нче санлы госпиталь анда юк» дип җавап килә. Дүрт дистә ел госпитальне таба алмыйлар! Аерым кеше генә түгел, ә йозләрчә яралыларны кабул итеп дәвалаган госпиталь кадәр госпиталь «билгесез».

Мондый «билгесез югалулар» кеше кадере иң түбән дәрәҗәгә төшерелгән безнең Русиядә генә булырга мөмкин.

1945 ел. 8 май. Фашистик Германия өчен капитуляция ясау көне. Безнең өчен - озак көтелгән Җиңү көне. Ботен ил белән шатланыштык, бәйрәм иттек без бу көнне һәм шул ук вакытта исәпсез-хисапсыз югалтулар өчен кайгырыштык, елаштык та. Җиңү көне җиту белән «кара кәгазьләр» алу да тиз генә тукталмады. Сүз биредә Японияга карны алып барылган сугыш

күз алдында тотылмый. Шул ук Германиядән, ул басып алган Европа илләреннән, Украинадан, Белоруссиядән, фашистлар калдырып киткән диверсантлар хәрәкәт иткән районнардан килде андый хәбәрләр. Фашистлар оккупациясендә булган районнарны диверсантлардан арындырырга, завод-фабрикаларын, колхоз-совхозларын торгызырга ярдәм итәргә кирәк иде. Безнең өчен бу үзебезгә дә җитмәгән техниканы, мал-туарны алар белән уртаклашырга дигән сүз иде.

Сугыш срактагы тыл районнарына да исәпсез-хисапсыз зыян китерде. Чәчүлек җирләре, маллар саны нык кимеде. Ашлыкның гектардан уңышы, тулай җыемы икеләтә кимеде: 1940 елгы 10,6 центнер урынына 1945 елда нибары 4,7 центнерга калды. Атлар саны 38, сыер малы 30 процентка, һәр сыердан савым 450-500 литрга кадәр кимеде. Сугышка кадәрге дәрәҗәгә җиту өчен генә дә әле безгә ким дигәндә ун еллап вакыт кирәк булачак. Дөрес, аерым колхозлар, бригадалар акрынлап булса да артталыктан чыга бардылар, ярыйсы гына уңыш җыя, хезмәт көненә түләүләрне арттыра башладылар. «Кызыл сабан» (II Әрҗән), «1 Май» (Бакчавыл), «Советларның YIII съезды» (Сүҗде) колхозлары игенчеләре, мәсәлән, 1946 елда гектардан 20-25 центнерга кадәр уңыш җыйдылар. Һәм шушы беренче уңышлары өчен районның зур гына төркем алдынгылары 1947 елның 29 март указы нигезендә орден һәм медальләр белән бүләкләнделәр. Һәр гектардан 25 центнердан артык бодай алган II Әрҗән звеночылары Нәҗибә Балтаева белән Мөхәммәтҗан Хәсәнов Ленин ордены, шул ук колхоздан бригадирлар Суфыйҗан Атнабаев, Зариф Рангулов, Әбүбәкер Балтаев, Шәрхулла Мостакыймов, сыер савучы Н.С.Орлова, звеночылар Сәбилә Әхмәрова, Шакирҗан Рангулов һ.б. - «Хезмәт Кызыл байрагы», 9 кеше, шул исәптән «Советларның YIII съезды» колхозы бригадирлары Фатих Абдалов белән Газнәви Акҗигитовлар, звеночы Галишан Зобәеров - «Хезмәттәге батырлык өчен» орденнары белән бүләкләнәләр (18).

Моңа кадәр шушы ук колхозларның җитәкчеләре, шулай ук Куйбышев исемендәге (Шабарка) колхозы рәисе Е.И.Баженов, «Кызыл кыр»дан Мирза Таразов һ.б. (барлыгы 53 кеше ) сугыш елларында күрсәткән тырышлыклары өчен «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында батыр хезмәт өчен» медальләре белән бүләкләнәләр (19).

1947 елда район беренче мәртәбә дәүләткә 108 мең центнер ашлык тапшыра. Аның 10 мең центнеры планнан тыш (20).

Сугышка кадәр районда 292 коммунист (167 әгъза, 124 әгъзалыкка кандидат) булса,1948 елда аларның саны 642гә җитә һәм моңарчы елына 3-4 тапкыр үткәрелеп килгән гомум җыелышлар урнына конференция үткәрелә. 18-19 гыйнварда үткән бу конференциядә 514 партия әгъзасыннан хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән 153, киңәш бирү хокукы белән 28 делегат катнаша. Отчет доклады белән 1946 елның 30 августында кооптация юлы белән 1 нче секретарь итеп куелган **М.И.Вагин** чыгыш ясый. Конференция районның тугыз еллык эшчәнлеген тикшерә һәм экономик артталыктан чыгу өчен коммунистларның, кадрларның идея үсешен тизләтергә, партиягә алу, коммунистларның санын үстерү белән

мавыкмаска, ә сыйфат ягыннан үстерүне беренче бурыч итеп санарга дигән нәтиҗәгә килә.

Тугыз ел эчендә райком 259 кешене партиягә әгъза итеп, 284не кандидат итеп ала. Армиядән 413 коммунист кайта. Аларның 70 проценты окопларда кабул ителгән кешеләр. Сүз юк, энергияле, яшь патриотлар, ләкин партия тәрбиясе алып өлгермәгәннәр. Фронтта партиягә алынганнарның 89 проценты кандидатлык стажын уздырган, вакытында әгъза итеп алынмаган. Коммунистларның белем дәрәҗәсе бик түбән, шуңа карамастан, аларның 40 проценты беренчеле укуга да җәлеп ителмәгән.

Районның барлык 27 авыл Советында да, 79 колхозның 73ендә партоешмалар бар. Һәр оешма елына уртача 18,5 җыелыш үткәргән, диелә докладта, һәм «Кызыл сабан» колхозы партия оешмасы (секретаре Н.С.Орлова) һәм Үдик территориаль партия оешмасы (секретаре Н.Б.Арзыев) башкаларга үрнәк итеп күрсәтелә. Бу оешмаларда ел саен 23-27 җыелыш үткәрелә һәм... нәтиҗәсе - «бу колхозлар барлык планнарны срогыннан алда үтиләр» (20).

1940 елда 24 кешедән сайланган райкомның нибары 6 әгъзасы калган, кооптация юлы белән 5 кеше өстәлгән һәм шулар белән йозәр, йоз иллешәр кеше катнашлыгында пленумнар, партхозактив җыелышлары үткәрелгән.

Конференция кадрларның еш алмашынуын, аларның күбесенең (79 колхоз рәисенең 64е) башлангыч белемле яшьләрдән торуын билгеләп үтә.

Докладта «Авыл хуҗалыгы Уставын бозуларны бетерү турында» дигән бүлек зур урын алып тора һәм конференциядән соң бу эш райком һәм район башкарма комитетының төп эшенә әверелә.

1946 елда, диелә докладта, колхозларның идарә аппаратына 8 процент урынына 11 процент, ә кайбер колхозларда 20 процентка кадәр хезмәт көне тотыла. Колхозларда минимум хезмәт көне эшләмәгән 1573 кеше булып, аларның 126 гектар бакчалары киселгән. Предприятие һәм оешмаларның колхозларга 1,5 млн. сум бурычлары ачыкланган. Элек каз һәм куян үрчетү белән дан тоткан районда бүген нибары 85 каз, 172 баш (планга карата 19 проц.) куян калган, тавыклар бетүгә таба бара. «Бәкин тау» колхозында, мәсәлән (рәисе Минкин), ике тавык асрыйлар... 1947 елда гына колхозларда 553 ат, 739 сыер малы, 328 баш дуңгыз, 1395 баш сарык үлгән, йөз биядән нибары 26 колын, йөз сыердан 57 бозау алынган...

Райком отчетын тикшерүдә катнашканнарның чыгышлары да шундый ук күңелсез фактлар белән тулы.

Конференция 35 кешедән торган райком составын сайлый. 30 гыйнварда булган пленум беренче секретарь итеп яңадан М.И.Вагинны, икенче итеп Е.Ф.Кайгородовны, секретарь итеп Г.А.Шәмсетдиновны сайлый.

1948 елның 1 декабрендә **Гали Абдрахман улы Шәмсетдинов** райсовет башкарма комитет рәисе итеп сайлана, райкомда аның урынына Ш.Н.Нигъмәев сайлана.

1949 елның 26-27 февралендә үткән II район конференциясе РКның 13 айлык эшчәнлегенә отчетын тыңлап тикшерә. Бурыч шул ук - коммунистларның сәяси үсешен тәэмин итү, партия политикасын, Ленин, Сталин

әсәрләре һәм биографияләре, «ВКП(б) тарихының кыскача курсы» буенча политмәктәп, түгәрәкләр, семинарлар оештыру, лекцияләр уку, барлык коммунистларны һәм комсомолларны да укуга тарту.

Районның экономик хәле акрынлап булса да үзгәрә. 1949 елда, 1945 ел белән чагыштырганда, тулай продукция житештерү 35,2 процентка арта. Сугыштан соң беренче тапкыр хезмәт житештерүчәнлеге күтәрелү, табыш алып эшләүче предприятиеләр турында сүз алып барырга мөмкин була. Кайбер предприятиеләр, мәсәлән, Осипенко исемендәге артель продукция житештерү күләмен 36 процентка, райпромкомбинат 17 процентка арттыра.

Сугышка кадәр үк әле, 1939 елның 27 маенда, СССР хөкүмәте һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты «Колхозларда авыл хужалыгы артеле Уставын бозуларны бетерү чаралары турында» карар кабул иткән була. Ләкин сугыш чыгып, ул карар онытылып тора. Һәм ул тик 1949 елда гына игълан ителә. Халык теленә «бакча кисү» законы булып кереп калган бу карарны үтәү зур шау-шулар белән бара. Аның иң төп пункты—колхозчылар өчен минимум хезмәт көнен билгеләү. Пермь өлкәсе өчен ул артык күп булмый - нибары 60, ләкин колхозлар бу минимумны үзләре дә билгели алалар. Карарда әйтелгәнчә, минимумны үтәмәүче колхозчылар колхоздан чыгарылган дип саналырга, бакчалары киселергә тиеш була. Бу яктан карар колхозчыларның хезмәт активлыгын күтәрүгә юнәлтелгән, дип кабул ителә. Ләкин аның төп максаты «аз җирле районнардан колхозчыларны күп җирле районнарга күчерү» була. Бакча кисүләр белән бер үк вакытта промышленность төзелешләренә, чирәм җирләргә мобилизацияләү башлана.

Карарда киселгән бакчалар колхоз җирләренә кушылырга тиеш дип әйтелсә дә, алар кычыткан-әрем баскан ташландык җирләргә әвереләләр.

1950 елда авыл саен япән килгән колхозларны берләштерү турында сүз кузгатыла. Районда бу эшне беренче булып Өчкул һәм Малиновка колхозчылары башлый. «Малина» җиргә бай, ләкин производствоны үстерү өчен эшче көчләре җитәрлек түгел, ә Киров исемендәге колхозның кешесе күп, чәчү җирләре, көтүлекләре һәм чабулыгы аз, урманы юк. Ике колхозны берләштерү административ персоналны, терлекчеләрне кыскарту, төзелеш эшләрен киңрәк җәелдерү мөмкинлеге бирә. Берләшүнең беренче елында ук колхоз 50 башлык бозау абзары төзеп куя, 300 башка сарык абзары төзи башлый (21).

1951 елда Аклыш авыл советының «Кызыл йолдыз», «Кызыл маяк», Солтанай авыл советының Ворошилов исемендәге колхозлары Ворошилов исемендәге бер колхозга, Барда авыл советының «Алга» һәм «Советларның VIII съезды» колхозлары Шверник исемендәге колхозга берләшәләр, Башап Түзләге «Йолдыз» колхозы «Кызыл Урал» (Солтанай) колхозына кушыла (20).

Илленче елларда туган берләшү идеясе колхозлар белән генә чикләнми, предприятие, оешма, мәктәп һәм хәтта район һәм өлкә гәзитләренә дә кагыла.

Ике район гәзитен бергә кушу мәсьәләсен тикшергән райком бюросы моның кирәклеген шулай аңлата: «бер районда ике гәзит булу котылгысыз рәвештә параллелизмга, бер- берсен кабатлауга китерә, райкомга гәзитләр эшен күзәтеп баруны, кадрлар сайлауны кыелаштыра (шунда ук, 152 б).

Ике телдә мостәкыйль рәвештә чыгып килгән ике гәзитне бергә әверелдерү ирекле рәвештә, берииди кочләүсез башкарылган кебек булса да, без, журналистлар, бу идеянең югарыдан төшерелгәнлеген, милли матбугатны бетерүгә юнәлтелгән чара икәнлеген яхшы аңлый идек. Берләштерелгән гәзитләргә материал, кадрларның ниңди булуын, тиражларын исәпкә алмыйча, рус телендә эшләнергә, шул телдән тәрҗемә ителергә тиеш була. Шөкер, бу хата 1965 елда төзәтелде һәм район гәзите янә үз телебездә эшләнә.

Сугыштан соңгы упьеллык экономик артталыкны бетерү юлларын эзләү белән характерлы. Ләкин һаман да әле югарыдан каты кул янавы, тормышның авырлыгыннан зарланулар утызынчы еллардагы кебек үк властька каршы фетнә әзерләү кебегрәк кабул ителә. 1947 елның 14 гыйнварында үткән райком пленумында МВД район бүлеге начальнигы, бюро әгъзасы Г.Ф.Черняков шундый чыгыш ясый: «Нимесләрдә әсирлектә булган байтак кешеләр кайтты. Алар үзләренең явыз эшләрен башкаралар. Вахитов исемендәге колхозда шундыйларның берсе әйтә: «Әгәр дә безнең илдә бүген дә колхозлар буласын белгән булсам, кайтмаган булыр идем, китәр идем шунда Англиягәме кая». Ә Үдиктә Адутов нәрсә ди? «Икмәкне колхозга калдырмыйлар икән, әйдәгез бастовать итәбез» (23).

Әле сугыш елларында ук, 1943 елда, «Кызыл сабан» колхозы Тол елгасында Кызыльяр астында, Иманаевларның иске тегермәне урынында, гидростанция төзи. Ләкин буасын тота алмау сәбәпле икенче елны 24 квт. куәтле җылылык станциясе төзиләр (25). «Кызыл кырчы», «Кызыл маяк» колхозларында шундый ук станцияләр төзелә. Бу колхозларның инициативасын хуплап, 1945 елның февралендә үткән район партҗыелышы «Кече ГЭСлар төзү турында» резолюция кабул итә. Кышын промкомбинатка агач хәзерләргә, яз җиткәч МТСларга Бардада һәм Сарашта станцияләрне төзә башларга кушыла. Искир, Озын Яланда тегермәннәрдә станцияләр монтажлана (24). 1946 елда Орджоникидзе заводы ярдәме белән Бакчавылда 25 квт.лы, 1947 елда Бардада 30 квт.лы станцияләр төзелә. Бардада 1935 елда ук әле Кажмакты елгасында гидростанция төзеп карыйлар, тик аны юньләп эшләтә алмыйлар һәм, халыктан йөзәр сум акча яки йөзәр йомырка, берәр кг. йон җыеп, яңа генератор сатып алалар һәм утын (шакмак) ягып эшләтелә торган станция төзиләр (1).

1947 елда «Яңа», «8 Март», Вахитов исемендәге колхозларда станцияләр төзелә. 1948 елда Батырбай авыл Советының «Алдынгы» колхозы, дәүләттән 65 мең сум ссуда алып, Ноне елгасында гидростанция төзи. Бу станция 76 йортны, ферма һәм ат абзарын яктырта, сугу, такта яру машиналарын, җилгәргечләрне эшләтә.

1954 елда «Кызыл флаг» колхозы (Үдик) Әмҗе елгасында 22 квт. куәтле станция төзи һәм ул 1963 елга кадәр, Үдиктә дәүләт линиясеннән (Пермь ТЭЦыннан) тукланучы подстанция төзелгәнче эшли (26).




**Рәсемдә:** Гражданнар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм тыл хезмәтчәннәре (1987 ел).

Ч.Рәхимов фотосы.



**Рәсемдә:** Ватан сугышында катнашкан хатын-кызлар район җитәкчеләре белән. (Рәсем Бөек Җиңүнең 30 еллыгына багышланган очрашу вакытында төшерелгән).

Ч.Рәхимов фотосы.

## Чыганаклар:


1. Н.Г.Юсуфкулов. У.Г.Бадыгин истәлекләреннән.

2. Райкомның партия өлкә комитетына җибәргән информациясеннән. ПГАНИОО. Фонт 1603, тасв.1, сакл.берәм.67, кор. 8.

3. Район хәрби комиссариатында сакланган «Тарихи белешмә».

4. Галия Нурсубина. Безнең дә өлешебез бар. «Таң», 1967, 5 октябрь.

5. Озын Яланнан Нургали Илмәкачев сөйләвеннән.

6. «Колхоз юлы», 1942, 8 март, 30 сентябрь; 1967, 20 июль.

7. Ә.Акжигитов. Нинди көч ярдәм итте. «Таң», 1967, 5 октябрь.

8. Район партҗыелышы протоколы. ПГАНИОО. Фонд шул ук. Эш 77.

9. Урал танк корпусына гариза бирүчеләр исемлеге. Райкомның корпуска алу буенча информацион язмасы. Пленум, бюро протоколлары. ПГАНИОО, сакл. берәмл. 83, кор. 10.

10. Ә.Мансуров. Җиңү көнен якынайтучылар. «Таң». 1993, 19 март.

11. Книга памяти. 1941-1945 гг. Бардымский район. Пермь, 1993.

12. Мостафа Нугман. Үлмәс чәчәк легендасы. Казан, 1971.

13. И.И.Меняйло. Үлмәс батыр. «Таң». 1972, 6 май.

14. Ф.Зеленовский, тарих фәннәре кандидаты. Молдавия өчен сугышларда. Молдавиянең Оргеев районы газите «За коммунизм». 1965, 9 май.

15. Б.Шалухо. Герой батырлыклары. «Таң». 1976, 20 ноябрь.

16. И.Вагизов. Медаль партизанской чеканки. «Звезда», 1991, 1 гыйнвар; И.Закиров. Медаль из партизанской кузницы. «Сельская жизнь». 1991, 9 гыйнвар.

Белорусская советская энциклопедия. Том 7, 496 б.

Всенародная борьба в Белоруссии против немецко-фашистских захватчиков. Том 1, 1983; том 2, 1984; том 3, 1985.

Н.Климов. Люди Нарочанского края. «Беларусь», 1975.

Ф.Мәүлиев. Утлар-сулар аша. «Халык чишмәсе», 1992, 1-7 гыйнвар.

17. И.Шарыгин. Без Берлинны алдык. «Халык чишмәсе», 1994, N 14.

18. Районның авыл хуҗалыгы алдынгыларын бүләкләү. «Колхоз юлы», 1948, 27 март.

19. «Колхоз юлы», 1945, 28 ноябрь.

20. I район конференциясе протоколы. 1948 ел 18-19 гыйнвар. ПГАНИОО, эш 125.

21. Әгъләм Нурбаков. Берләшү безгә нәрсә бирде. «Колхоз юлы», 1950, 22 июль.

22. ПГАНИОО. Сакл. берәмл. 139, кор. 16.

23. ВКП(б) райкомының 16 нчы пленумы протоколы. 1947 ел 16 гыйнвар. ПГАНИОО. Эш 116.

24. 1945 ел 14 февраль. Гомум район партҗыелышы протоколы. ПГАНИОО, сакл. берәмл. 83, кор. 10.

25. М.С. Иманаев хатирәләреннән.

26. Ф.Р.Йосыпова. Районны электрлаштыру. 1986 елда ПГУда яклаган диплом эше.

## ЭЧТӘЛЕК:


Фидакарь зат. Керен сүз. Р.Ягъфәров ........ 3
I. Гәйнә иле борынгы чорда ........ 4
II. Гәйнәлеләрнең хәтер сандыгыннан ........ 26
III. Ханлыклардан - губернага ........ 45
IY. Крылов утарыннан - Батырша хәрәкәтенә ........ 62
Y. Гәйнә иле промышленниклары. Ширәмәт бакыр заводы ........ 77
YI. Гәйнәлеләр Пугачев хәрәкәтендә ........ 86
YII. Русия тарихының «яңа чоры» ........ 109
YIII. Революцияләр, үзгәрешләр ........ [illegible]
IX. Район булып оешкач ........ [illegible]
X. Күмәк тормышка аяк басып ........ [illegible]
XI. Бөтенесе - фронт өчен ........ [illegible]



**Амир Фатыхов**


# ГАЙНИНСКИЙ КРАЙ

**(История Гайнинской волости - Бардымского района Пермской области)**
**(На татарском языке)**


Рецензенты - академик Академии наук Татарстана И.Р.Тагиров, ст. научный сотрудник Института языка, литературы и истории АНТ Д.М.Исхаков.

Редактор - кандидат филологических наук Р.Ф.Ягафаров.

Художник обложки Э.Я.Зарипов.

Компьютерная группа: Р.Т.Масагутова, Г.Н.Уразова, З.Л.Миропольская.

Корректоры Р.Л.Туктамышева, Д.Н.Юсуфкулова.

Офсетная печать. Формат 60х90.16. Объем 13 условно-печатных листов. Тираж 10 тыс. экз. Заказ N 118.

Газетно-книжное издательство: 618150, с. Барда, ул. Куйбышева, 26.

Лицензия А 108 609. Регистрационный номер 009.